КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Татар нефте. *Цикл.* ....3
Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ. Тау башында бүре бар. *Роман.* ....10
Рәшит БӘШӘР. Күк исе килә кыйтгалардан... *Шигырьләр.* ....66
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Басынкы Бастам. *Повесть.* ....71
Закир ӘКБӘРОВ. Күлим дисәң, күл, укучым... *Мәсәлләр.* ....93
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Кешенекен алу – язык. *Хикәя.* ....97
Зинаида ЗАХАРОВА. Зәй үзе дә тынлык ярата... *Шигырьләр.* ....110

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Миләүшә КАҺАРМАНОВА. Җизнәм. Мандолина. Зәңгәр төймә. *Хикәяләр.* ....114

ЯҢА ИСЕМНӘР

Алмаз ӘХМӘТГАЛИЕВ. Галәмнәрдән ишетелә аһәң. *Шигырьләр.* ....129

ЮБИЛЕЙЛАР

Марсель БАКИРОВ. Кара таплы бәхет.
*Биографиям, тормыш һәм хезмәт юлым турында бәян.* ....132

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА. Ак чәчәкләр кебек...
*(Язучы Айгөл Әхмәтгалиева иҗатына бер караш.)*....160

ФӘН

Фирая ГАФФАРОВА. Татар телендә аңлатмалы сүзлекләр. ....164

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Татар мулласы – солтан кунагы. ....171

*Хатлар яздым утырып:* Миргазиян Юнысның Марсель Галиевка язган хатлары. ....178

2023 ЕЛ – РОССИЯДӘ УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

Телләр белү – кешенең иң яхшы сыйфатларыннан *(«Адымнар» полилингваль комплексы директоры Айдар ШӘМСЕТДИНОВ белән Алинә ХӘБИБУЛЛИНА әңгәмәсе.)* ....182

«Казан утлары» архивыннан. ....186

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем... (*Гадел Кутуйның тууына – 120 ел.)* ....188
Фидакарь әдип *(Риза Ишморатның тууына – 120 ел.)* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ

*№ 11 (1213) 2023*



*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**

*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**



✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru



★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.09.2023, график буенча 30.10.2023, басылып чыгу вакыты 03.11.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2981. Тираж 5580.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+



© «Казан утлары», 2023 ел



Лилия
Гыйбадуллина

# ТАТАР НЕФТЕ

ЦИКЛ

*Җәйрәп ята бодай басулары.*
*Язгы җилдә яшел дулкыннар.*
*Җир астында кайнар дәрья тоеп*
*кайный микән әллә ул кырлар?*

*Кыр түренә басты манаралар,*
*сискәндереп арыш басуын.*
*Кеше җирнең үзәгенә төште,*
*серен ачып миллион гасырның.*
Саҗидә Сөләйманова

Сер тулы йомгактай җир шары
Тәгәри гасырдан-гасырга.
Ул серләр туфракка күмелгән,
Ул серләр күкләргә асылган.

Күкләрдән өзелеп төшкәнме,
Туфрактан өзелеп тамганмы –
Йолдызлар хикәят сөйлиләр –
Кара җир йөзенә язганны.

Борынгы хикмәтле хикәят
Ким түгел «Мең дә бер кичә»дән:
«Җир сыман кап-кара хак алтын
Саркыла икән лә чишмәдән.

Җир сыман кап-кара хак алтын
Сибелгән икән лә суларга,
Кап-кара дулкыннар чайкалып
Киләчәк көннәрне сугара.

---

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА (1987) – *шагыйрә; «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Алтынга тиң кара туфракның
Төбендә тибенә-тибенә,
Сулкылдый-сулкылдый җир аслап,
Җир өсләп кара җыр түгелә.

Җыр булып яңа чор чаң суга,
Чаң булып яңа җыр җырлана.
Кешеләр ярыша-ярыша
Кара май сөзәләр елгадан.

Гасырдан-гасырга бу хәбәр
Дөньяга җил булып тарала.
Җир-Ана карынында тирбәлеп,
Өр-яңа юаныч ярала.

Вавилон, борынгы Мисырдан –
Хәбәрләр ерактан-ерактан:
Елгадан табылган кара май
Һәр эштә гамәлгә яраклы.

Нефть – бәлзәм, нефть – дәва, нефть – кәлга
Һәм утлы корал да дошманга.
Кешеләр күкләргә очына
Кешеләр туфракка ышана.

Җир өсләп, җир аслап җыр ага.
Чор ага, чорнала бугазга.
Кешеләр коелар казыйлар,
Кешеләр салалар буразна.

Калалар кыбырсып калкына,
Караңгы урамнар яктыра.
Тормышың җайланыр – җиреңнән
Кап-кара шул майны тап кына!»

Кара май – яктылык. Гөлт итеп
Тарихта лапмалар кабына,
Җирдәге утларның яктысы
Йолдызлар катына кагына.

Чор күчә, ут күчә, җир – күчәр,
Күчәрдә сүрелми ут яна.
Гасырдан гасырга күчә ул –
Борынгы һәм кабат өр-яңа.

Кара май манылган таякта,
Кәрәчин салынган лампада,
Ут булып кешеләр өендә,
Нефть үзе җир өсләп яктыра.

Бу утлар яктырта дөньяны,
Караңгы төннәрне яктырта.
Җир каны – кара май яктысы
Ак булып сирпелә һәр йортка.

* * *

*Шөгерләргә барам әле,*
*Шөгер суы тәмлегә.*
Татар халык җыры

*...Авыл кешеләре бу сыекча белән арба күчәре майлыйлар иде. Кара чишмәдән чыккан кара сыекча белән майланган арба тәгәрмәче бик җиңел тәгәри.*
Гәрәй Рәхим

Шыгыр-шыгыр килә җир күчәре,
Көе, җае, көне авырая.
Җир йөзендә сугыш, сугыш, сугыш...
Кай тарафка йөзне борырга, йә?!

Шыгыр-шыгыр килә җир күчәре.
Сыкрый-сыкрый әйләнгәндә җирең,
Борынгы бер сөаль сытылып чыга:
«Бу ватанда яшәү кемгә җиңел?»

«Бу ватанда яшәү кайчан җиңел?»
Шушы сорау тора җилдәй улап.
Ак кәфенлек төсле ак кылганнар
Йөгерәләр һаман дала буйлап.

Шыгыр-шыгыр... Майлап җибәрсәң лә,
Мае кирәк, мая кирәк көнгә!
Әйләнсен җир кояшлырак җайга,
Әйләнсен җир кояшлырак көйгә!

Ватан сугышы бара – бөек сугыш...
«Барысы да фронт өчен!» Гази[1]
Рейхстагка байрак кадаганчы,
Ничек тә түз, дөнья, билләһ газыйм...

Татар ире яуда сугышканда,
Татар җире тылда суырыла.
Барысы да фронт өчен кирәк!
Кирәк җирдән нефть суырырга!

Карыныңны каер, татар җире.
Йөрәгеңне каер, татар ире.
Бәгырь катламында катмар-катмар
Үткән тарихының зәмһәрире:

Зәһәрлеге җелекләргә үткән,
Түзсен генә, түзсен генә йөрәк.
Фронт өчен, уртак җиңү өчен...
Хәтәр барда татар һәрчак кирәк.
Суырып ала вакыт дигән чоңгыл,
Иләк аша или элеккене.

[1] Рейхстагка тәүге Җиңү Байрагын кадаган Гази Заһитов.

Җаны, җыры, җире – ватан өчен,
Ә үзе соң бу ватанның кеме?

Җир өсләтеп вакыт шуыша тора,
Җир аслатып кара чишмә ага,
Кара алтын тулы татар җире –
Сызлап тора, бәгырен ачып кара.

Шыгыр-шыгыр... Шөгер туфрагында
Шөкер итеп яшәп яткан чишмә
Киләчәкнең серен илгә чишә,
Киләчәкнең серен җиргә чишә.

Шөгер, Шөгер! Җандур тавы[2] булып
Чал тарихың сакта торадыр ла.
Заманында җир читеннән килеп,
Тауларыңның төбен тырнадылар.

Нефтьле җир дип бораулады күпләр,
«Нефтең бир!» дип бораулады заман.
Тамырында типкән бәрәкәткә
Кырык өчтә бәреп чыгу язган.

Мең тугыз йөз кырык өчтә бары,
Сулык-сулык торган чакта көнең,
Һәр тарафта иңрәп торган чакта
Кабер тынын бөркеп сугыш өне.

Кырык өчтә Шөгер басуыннан
Күтәрелгән тәүге скважинада
Ватан өчен, җиңү өчен дигән
Тәүге аваз – өр-яңа җыр ага –

Татар җыры! Татар туфрагында
Каралмас дан һәм кара кан сеңгән –
Әрнү төсле, әче өмет төсле
Кара алтын кубарыла җирдән.

Бәгыреннән өзеп татар җире
Канын бирә. Мәгез! Ватан өчен...
Сугыш дигән дәһшәт капкынының
Богауларын болгап ватар өчен,

Һәм торгызыр өчен ил-ватанны –
Сугыш соңра күтәрмәгә калган,
Һәм космоска юллар сузар өчен
Шөгер басуыннан нефть ага.

Шыгыр-шыгыр килгән җир күчәрен,
Күтәрелеп Шөгер басуыннан,

[2] 1870 елларда Америка сәнәгатьчесе Л.Шандор авыл территориясендә механика остаханәләре төзетә, нефть чыгару өчен 2 скважина бораулата. 1881 елда гудрон (битум) заводы ача. Аның янындагы тауны авыл халкы Җандур-тау дип атый башлый.

Кара алтын – татар нефте майлый.
Һәм беразга чор җайлана сыман...

* * *

*Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә...*
Габдерәхим Утыз Имәни

*Күренекле татар шагыйре Утыз Имәни яшәгән Тимәш авылында, шагыйрь өеннән ерак та булмаган тау битендә, атаклы Ромашкино нефть чыганагын ачып җибәргән 3 нче скважина 1948 елның июлендә девон ятмасындагы нефтьне көчле фонтан итеп күккә чөя. Ул тәүлегенә 120 тонна нефть бирә башлый һәм СССР нефть промышленностенда иң зур рекордлы скважина була.*
Гәрәй Рәхим

Җилләренә тисәң – җирсенерсең,
Суларына тисәң – сугарыр,
Бу төбәкнең җире, җиле, суы –
Җаннарыңны җилпи торганы.

Җыру әйтсәң – көең таныр таулар,
Сүз эндәшсәң – таныр үзәннәр.
Илгә чәчәр якты йолдызларны
Күк тибрәтеп монда өзгәннәр.

Тиеп кенә, кагылып кына уза,
Кагып кына уза иңнәрдән –
Замананың җилбер-җилбер җиле
Алга таба әйдәп җибәрә.

Җырларыма тимәс булсаң гына,
Тимәс булсаң гына телемә,
(Билемдә бит балтам әзер тора...)
Кулларыңны сал син иңемә,

Заман җиле! Капкам ачык сиңа,
Ни соранып тагын килешең?
Тел төбеңдә һаман иске сөаль,
Үзгәрсә дә килбәт-килешең.

Төзелешләр арты төзелешләр,
Заводлары, биек йортлары,
Шәһәрләре, таш юллары кирәк –
Дәвер тынын буып тотарлык...

Иманыма тимәс булсаң гына,
Тимәс булсаң гына телемә,

Бәгыремне ярып, каным бирәм
Тимәш[3] яны – татар җиреннән.

[3] «Ромашкино» нефть чыганагы табылган авыл. Инкыйлабка кадәрге чыганакларда Ромашкино исеме белән дә билгеле.

Тынлык тибрәп яткан басуларда,
Изрәп яткан үзән йөзендә,
Таулар үзәгендә, үләннәрдә
Кап-кайнар бер ташкын сизелә.

Җир өсләтеп заман җиле исә,
Җир аслатып кара җыр ага –
Миллион гасыр элек яралса да,
Ил иркендә әле өр-яңа.

Тимәш басуында скважина
Яңа тарих яза ватанга.
Елъязмага уелыр яңа исем
«Татар нефте» диеп атала.

Тимәш басуыннан бәреп чыккан
Татар нефте илне күтәрә,
Татар нефте яңа юллар яра
Һәм космоска күпер үткәрә.

Татар нефте хәрабәгә калган
Калаларны кора кабаттан.
Татар нефте машиналар төзи,
Татар нефте илне яңарта.

Кырык сигезенче елның июлендә,
Тибеп чыгып Тимәш басуын,
Җир белән күк арасында ургый
Йолдызларга гүя асылып.

Күккә чөя – яңа куәт илгә,
Күккә чөя кара җир канын,
Тик иминлек булсын туган җирдә,
Тик исән-сау булсын ватаным.

...Көлемсерәп тарих карап тора,
Башын кыңгыр салып җай гына.
Утыз Имәниләр ымы булып,
Иңнәреңә җайлап кагыла.

Каралмас дан һәм кара кан тамган,
Тетрәп торган татар җире бу.
Кылганнары ап-ак дога укып,
Тибрәп торган татар җире бу.

Бәгыреннән суырып җыр чишмәсен
Ил гаменә койган җирләр бу.

Иелеп сәлам иңдер. Җыруыңны
Таулар аңлар телдә җырлар бул.

Иелеп рәхмәт укы. Сүз эндәшсәң,
Сөйләмеңнән таныр таңнары,

Сәламеңне тыны белән тартып,
Кайтавазга кушар таулары.

Утыз Имәниләр ут тергезгән,
Тәкъбир әйтеп торган туфрак бу.
Шуннан килеп, шуңа кайтасың бар –
Кунак булсаң җирдә, тыйнак бул.

Җанын тырнап ап-ак җырын койган,
Кара алтын койган чишмәләр
Мәңгелекнең моңлы өне булып,
Гади бер сер сиңа чишәрләр:

Туфрак өсләп ак кылганнар ага,
Туфрак аслап кара җыр ага,
Татар үзе, татар сүзе сыйсын
Татар нефте сыйган дөньяга!..

Кара алтын булып татар җаны,
Татар рухы ага, аңласаң.
Үзен, сүзен, телен данла аның,
Җырын данла, малын данласаң.

Бер карасаң, дөнья кара кебек,
Ага кебек чишмә җаена.
Ак яулыгын ябып аткан таңнар,
Керләнә дә төнгә ябына.

Бер карасаң, мең карасаң, мәңге...
Зәңгәр күк һәм туфрак арасын,
Сер йомгагы итеп бу җир шарын,
Барасы да һаман барасы.

Җилләренә тисәң – җирсенерсең,
Суларына тисәң – сугарыр,
Бу дөньяның җире, җиле, суы –
Җаннарыңны җилпи торганы.

Җилпеп кенә узган заман җиле,
Әйләнә дә кайта кай ара.
Җир күчәре һаман шыгыр-шыгыр –
Татар нефте кирәк дөньяга...



Равилә
Шәйдуллина – Мурат

# ТАУ БАШЫНДА БҮРЕ БАР

РОМАН

**Беренче бүлек**

Асия Гөлсем апасының акрын гына:

– Тор, кызым, авылга сөткә төшәсең бар, балалар уянганчы иртәнге ашны өлгертергә кирәк, – дигәненә уянып китте.

Нинди иртәнге аш, нинди сөт, әле генә йокларга ятты лабаса! Кыз кургаш кебек авырайган күз кабакларын ачып, үзенең кайда икәнлеген аңларга тырышып озак кына аңышмыйча торды. Ләкин шушы халәте аңа торырга вакыт җиткәнен, алда аны тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшләр көткәнен исенә төшерә иде. Күзләрен ачса, үзенә таба иелгән Гөлсем апасын күрде.

Йа Алла, ул пионер лагерена ашчы ярдәмчесе булып эшкә урнашты бит, үзенең сыйныфташларына ашарга әзерләп тора. Тау астындагы чишмәдән су ташый, бәрәңге, суган, кишер әрчи, табак-савыт юа. Кичә кичке ашны ашатканнан соң, көч-хәл белән өстерәлеп, палаткадагы тимер караватка кереп ятты. Колагында сыйныфташларының чыркылдап көлгән тавышлары һәм өзек-өзек кенә ишетелгән җыр исендә калган:

*Взвейтесь ко-о-с-т-р-а-а-а-ми,*
*Си-ни-е ночи…*

Шунда ук кыз упкынга чумган кебек тирән йокыга талды.

Әле генә яткан иде бит. Инде Гөлсем апасы, сак кына иңнәренә кагылып:

– Тор, кызым, авылга сөткә төшәсең бар, – дип эндәшә.

Кыз, уянып, тимер карават читенә торып утыргач, ашчы апасы чыгып китте.

Ялан аякларына артсыз башмакларын элеп, инде тапталган үлән өстенә чыгып басты. Тирә-юнендә дуслары таралып төшеп йоклый. Аларның тигез сулыш алып, рәхәтләнеп таң йокысын йоклауларына кызыгып, пөхтәләп урын-җирләрен җыеп куйды. Ябык иңбашлары үтереп сызлый иде.

---

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ (1949) – *язучы; «Ялантауга ай кунган», «Сихәтләнү», «Алмагач дәресе» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Әйе, кичә тау асты чишмәсеннән көн дәвамында унтугыз көянтә су алып килде. Иңнәрен кисеп кергән көянтәгә берәр нинди тастымал урарга кирәк булгандыр да. Балачактагы кебек, Ялантау чишмәсеннән су алып кайткан җиде-сигез яшьлек кыз чагындагы кебек, тик нигәдер иптәшләреннән оялды. Инде ундүрт яшьлек җиткән кыз, оялмыйча... Бигрәк тә малайлар палаткасындагы тугызынчы сыйныфта укучы Вәкил күрсә...

Юк, юк, ничек тә сер бирмәскә, сынатмаска кирәк! Инде менә бүген соңгысын – унтугызынчы тапкырын чишмәгә төшә. Тау асты чишмәсеннән күтәрелер өчен җитмеш җиде басманы менәргә кирәк. Ялантаудан чыгарган яссы ташлардан унынчы сыйныф малайлары баскыч ясадылар. Басма кырыйларын цемент белән катырган баскыч бик тә текә иде. Әйтерсең ул тау түбәсе өстенә менеп, тын гына агып барган болытларга тоташа!

*Таулар биек, баскычлар юк...*

Кыз бала күңелендә җыр юллары кабатлана. Баскычлар бар ул, тик бигрәкләр дә текә. Бу басмалардан чиләк-көянтәсез менүе дә җиңел түгел, ә иңнәрдә көмештәй су белән кынысына кадәр тулышкан чиләкләр булганда! Бер басма, ун басма, егерме басма... Ял ит инде, чиләкләреңне куеп тор да калтырап торган арган аякларыңа ял бир, иңнәреңнән төшереп тор көянтәңне, ди йөрәк, ә үзе дөпе-дөпе тибә.

Ләкин ярты юлны булса да узарга кирәк, туктамаска кирәк дип, үҗәт акыл тау түбәсенә өнди, утыз сигез басманы күтәрелгәч, ял итәрсең, ди. Вак бер калтырау белән калтырап торган аякларыңа ял биреп, басмаларына утырып торсаң да ярый. Чөнки лагерьда ял итүче балалар баскыч тирәсендә күренми. Тугызынчы сыйныф малае Вәкил дә кичә кич буе тальян сайратып арыгандыр. Алар иртәнге сәгать җидегә кадәр йоклыйлар. Татлы йокыны, таң алды йокысын йоклыйлар! Ә кыз менә, сәгать биштән үк торып, үзенең сыйныташларына иртәнге аш әзерли, тау асты чишмәсеннән су ташый. Иптәшләре уянганчы, иртәнге аш әзер булырга тиеш. Кирәк, кирәк тирәкне еккан, ди.

Палатка ишеген күтәреп, дөньяга чыккан Асия, кояш нурларыннан күзләре чагылып, йөзен куллары белән каплады. Җиһанны нурга төреп, таң аткан.

– Уяныгыз, йоклап ятмагыз, шундый гүзәллекне күрмичә каласыз бит! – дигәндәй, ду китереп, кошлар сайрый. Нинди генә авазлар юк.

Әнә, тукран тукылдый, күке кемнеңдер гомерен саный: – Күк-күк, күк-күк.

– Күке, әйтче миңа, минем гомерем күпме?

Кыз, күке туктамаса ярарые дип, күзләрен күке кычкырган якка төбәде. Әйтерсең, күке тынып калса, туктаса, аның да гомере өзеләчәк. Алла сакласын! Әле генә таралып йоклап яткан иптәшләренә кызыгып, дөньяга чыккан иде. Инде менә гамьсез йоклап ятучыларны кызгана.

– И, бичаралар, шушындый матур иртәдә йоклап яталармы? – дип сикерәатлый такта корылмага – ашханәгә таба йөгерде.

Гөлсем апасы кесәл пеширергә плитәсе өстенә су куеп җибәргән. Такта өстендә ит турап маташа.

– Бар, кызым, чиләк-көянтәләреңне җилкәңә ал да авылга сөткә төш.

Иртәнге савымны биштә үк җәйләүдән менгерәләр. Соңга кала күрмә, иртәнге ашка манный болгатырмын дигән идем. Тик башта берәр телем ипи белән чәй эчеп ал.

– Юк, Гөлсем апа, чәйләр эчеп тормыйм, чишмәдә юынып кына алам да авылга төшеп китәм, – дип, кичтән юып, казык башына элеп куйган чиләкләрен алды да Асия чыгып йөгерде. Күңелендә, җанында әллә нинди җиңеллек, рәхәтлек иде. Нигәдер йөрәге кысылып сулкылдый. Моңарчы белмәгән, сизмәгән бер хис тоеп, йөрәге нидер көтеп, рәхәт бер сызлану белән сулкылдый иде.

Чишмәгә төшеп җиткәч, бит-кулларын юып, тешләрен чистартты. Әбисе әйтмешли, таң суы белән битеңне юсаң, кешеләргә мәхәббәтле күренерсең, ди. Әйе, әйе, әбисе гел шулай әйтә иде. Асиянең исә Вәкилгә матур булып, мәхәббәтле булып күренәсе килә. Аның энҗе тешләрен балкытып елмайганын күрәсе килә. Аның өздереп, тальян гармунда уйнаганын ишетәсе килә. Әле кичәге кичкә чаклы һич тә алай түгел иде.

Вәкил малайлар арасында бер дә аерылып тормый кебек. Ә кичә кич нәрсә үзгәрде соң?

Асия табак-савытларны юып бетереп, чишмәгә төшеп киткән иде. Иртән Гөлсем апасы килүенә әзер булып торсын дип, соңгы тапкыр төшүе иде. Инде иңнәренең сызлавына түзә алмыйча, тәне иңгелдәп тора.

Ничек менеп җитәргә, ничекләр генә җитмеш җиде басманы үтәргә? Менеп җитә алсамы? Әй, рәхәтләнеп, палаткадагы сиртмәле караватка ятып, сызлап торган иңнәренә, калтырап торган аякларына ял биреп, алты сәгать йокларга була!

Чишмәгә төшеп җиткәч, аякларын юып, битләренә салкын су сипте. Ару-талулары бетеп киткән кебек тоелды. Улактан агып төшкән көмештәй суга кереп, шактый гына басып торды. Салкын су башта аякларын өтеп алгандай иткән иде, соңыннан калтырану басылып, балтырларына азрак хәл керде, рәхәт булып китте.

Инде утыз сигезенче басмага менеп җиткән иде. Туктап ял итәргә кирәк, аннары утыз тугыз баскыч кала, ни бары утыз тугыз баскыч...

Тик туктарга өлгерә алмый калды. Арттан килеп, кемдер иңнәреннән чиләк-көянтәсен күтәреп алды. Чак-чактан гына егылмыйча калды кыз бала. Аякларының тәмам җегәре беткән, бер адым атлар хәле дә калмаган иде.

– Бир чиләкләреңне, ә көянтәңне иңеңдә калдыр, – диде куе калын тавыш. – Суыңны мин алып меним. Бигрәк авырдыр сиңа, баскычы бигрәк текә бит. Чиләкләрең берәр потлы.

Һәм бүтән берни әйтмичә, җиңел адымнар белән баскычтан менеп китте.

Кыз бала берни әйтергә дә өлгермичә калды. Югары сыйныфта укучы Вәкил Асиядән ике генә яшькә өлкәнрәк иде. Кыз бары аның озын тәнәфес вакытында гармун уйнап, балаларны биеткәнен, җырлатканын гына хәтерли. Һәм башка малайлар кебек туп типкәнен, кышын инештә, итегенә тимер аяклар бәйләп, кәшәкә уйнаганын күргәне бар. Анысы да бәкегә кер чайкарга төшкәч, салкын суда куллары күшегеп, кер янына салып алып төшкән азрак кына кайнар суга кулларын тыгып җылытып торганда, кыз янына атылып килеп төшкән алканы тотып, кәшәкә уйнаучыларга атканда иде.

– Рәхмәт, Асия, – дигәннәр иде малайлар.

– Бәхетегез, чүт кенә бәкегә төшмәде алкагыз, – дип көлгән иде кыз. Болай гына, сүз булмаганда сүз булсын дигән кебек кенә әйткән иде.

Шуларны уйлап, җиңел генә, чиләкләр авырлыгын да сизмәгәндәй, яр якасына менеп киткән егет артыннан атлады Асия. Чиләкләрсез генә, бабасы бөгеп биргән көянтәсен иңнәренә салып кына атлады. Башка малай-егетләрдән бер ягы белән дә аерылып тормаган Вәкилнең: «Авырдыр сиңа, бир чиләкләреңне, суыңны үзем алып меним», – дигән сүзләре колагында яңгырап, җанын җылытып тора иде.

Тау түбәсенә көчкә менеп җитте кыз. Ашханә янына менеп җиткән егет сулы чиләкләрен агач эскәмиягә куйды да Асиягә карап:

– Менә булды да, бар, ял ит инде, арыгансыңдыр, – дип елмайды һәм китеп барды. Егетнең төз, озын буена, җиңел адымнар белән атлап баруына ул күздән югалганчы карап калды кыз. Рәхмәт әйтергә дә онытты.

Нигәдер күзләренә яшьләр тулды. Вәкилнең аны кызганып әйткән сүзләре күңеленә тиде. Гел шулай ул – берәрсе ачуланса, кычкырса, бөтен көчен, халәтен бер учка туплый да нык булып кала. Кызганып, йомшак сүз әйтсәләр, бетте инде, күзләреннән чишмәдәй яшь ага башлый. Җебегән нәрсә! «Вәкилнең ике чиләк суыңны күтәреп, ашханәгә кадәр китергәненә күңелең тулып, елап тор инде син, сытык!» – дип, үзен сүгә-сүгә, чиләкләр өстенә япкан тастымаллары суга төшмәсен дип, уклау куйды да палаткага таба атлады. Балалар барысы да тау түбәсендәге акланда җырлыйлар. Асиягә аларның шат тавышлары, җырлары ишетелә. Әнә, Саба районыннан практикага килгән Равилә апалары балаларга җыр өйрәтә:

*Куба – любовь моя –*
*Остров зари багровой…*

Аның артыннан җырны балалар күтәреп ала:

*Песня летит над планетой звеня,*
*Куба – любовь моя!*

Асия, уйлары белән океаннарны узып, Куба утравын кан төсенә манып күтәрелгән кояш нурлары астында адашып йөри. Нинди бәхетле кешеләр яшиләрдер анда! Океанда су коенып, алтынсыман комлыкларда ял итеп яталардыр! Аларның кукуруз басуыннан эт эчәгесе, алабута, билчән җыясылары юктыр. Җитмеш җиде басмалы баскычтан күтәрелеп, иңнәренә потлы чиләкләр элеп, су ташыйсылары да юктыр. Их, барып күрсәң иде шул илләрне, Европаны, Американы!

Юк, күреп булмас, чит илгә чыгарга ярамый – алайса үз илеңә дошман, шпион буласың, ди бит. Аннан соң ничек яшәргә, ди? Яшәсеннәр шунда капиталистлар, кеше канын эчеп. Ә без монда социализмда яшибез, коммунизм дигән – җирдәге җәннәтне төзеп ятабыз.

Укытучылар әйтә, сиксәненче еллардан соң бөтен дөнья халкы гел русча гына сөйләшәчәк, ди.

Һай, һай, булырмы икән? Әле менә Алансу халкы да русчага өйрәнеп бетә алмый. Бөтен дөнья халкы тиз генә русча сөйләшүгә күчә алмас. Әнә безнең авылдагы чын руслар – тегермәнче Николай абый белән авыл духтыры Нюра апа үзләре татарча сөйләшергә өйрәнделәр. Тик Нюра апаның ире

Михайло белән Николай абый хатыны Тамара апа русча сөйләшәләр. Аларның башлары юкарактыр инде, өйрәнә алмыйлардыр.

Нюра апа әниләре авырган вакытта килә дә:

– Мене безде шылай инде, Михайло ды сметан ярата, мин де бал белән сметан яратам, – ди.

Әниләре, чоланнан алып кереп яртышар литрлы банкада бал йә каймак биреп җибәрә.

Татарча белгәч, әйбәт инде. Үзләре мал асрамагач, ашыйсылары киләдер. Әйдә, ашасыннар, әниләре генә исән булсын.

Әле менә киләсе елга яңа йорт салырга әзерләнәләр. Акчалары юк инде, шуңа күрә Асия җәй көне лагерьга ашчы Гөлсем апасына ярдәмче булып урнашты. Акчасы аз булса да, иш янына куш була ул, ярап тора. Ә сигезне бетергәч, Казанга чыгып китәр. Абыйсы унынчыны тәмамлый, ә Асия сигезне. Шәһәрдә акча эшләп, әниләренә, ике сеңлесенә булышыр. Һәм укыр, журналист булыр. Хыяллар, хыяллар!..

Күзгә йокы эленеп, инде йоклап китәм дигәндә, кемдер «Яшь наратлар»ны сыздырып уйнап җибәрде. Вәкил инде ул уйнаучы! Куба утравында океанда коенып, алтын комлы пляжларда кызынучы бәхетле кешеләр юкка чыктылар. Кызның күз алдында ап-ак тешләрен ялтыратып:

– Бир чиләкләреңне, авырдыр сиңа! – дип елмаеп торучы Вәкил генә калды. Һәм тальян моңы.

*Мин сөялеп озатып калдым сине*
*Бөдрәләнеп үскән наратка.*

Асиянең торып, иптәшләре янына барасы килде. Елыйсы килде.

Әнисе әйтте бит:

– Кызым, бик авыр эш Ничек тә түзәрбез әле, барма, иптәшләрең белән ял ит, – дигән иде.

– Юк, барам, – диде кыз, үҗәтләнеп. – Киләсе елга йорт салмакчы буласыз, әти эшләми, абый белән икәүләшеп, Казанга чыгып китәргә торабыз. Ни эшләмәкче буласың, әни?

– Яңа гына ундүрт яшең тулды, шундый авыр эшкә барма, кызым, гомерлегеңне алырсың.

– Әни, үгетләмә, авыр булса ташлармын.

– Синме инде ул үз әйткәнеңнән кире кайтучы. Котдус бабаң үҗәтлеге күчкән сиңа. Ярар, үзеңә кара, – дигән иде әнисе, үгетләүдән файда юклыгын аңлап. – Ни эшлисең инде, әнә абыең КХТИга керергә җыена. Син дә Янсуарга бармыйм, дисең. Киләсе елга икәүләшеп чыгып китәргә торасыз шул. Йорт та тузды, – дип, әнисе кызын кызганып елаган иде.

Бәлки сыйныфташлары белән белән ял итәргә кирәк булгандыр. Уйнап-көлеп, җырлап-биеп. Тик әти-әниләре ике баланы рәттән укыта алмаячаклар. Ярар, җан биргәнгә җүн бирер әле Алла. Көндез эшләсә, укыр өчен кичке мәктәп бар дип, үзен юатты кыз.

Ничек кенә йөрәге талпынса да, яткан урыныннан кузгаласы итмәде кыз.

Әнә Вәкил бер көй артыннан икенчесен уйный. Ундүрт-уналты яшьлек балалар, инде йөрәкләрендә беренче мәхәббәтләре бөреләнеп килгән җилкәнчекләр җырлыйлар. Балачак, яшьлек!..

Балачактан үзләре дә аңламаган яңа дәвергә күчәргә торган яшь

җаннарының җырлап, күңелләре очынган заманнары. Сандугачлар да бары алар өчен генә сайрыйдыр сыман. Йөрәкләр дә, күзләр дә үзенә тиң ярларын эзли. Кем ул, кем булыр сиңа гына багышлап җыр җырлаган берәү? Сиңа авыр вакытта иңнәреңнән авыр йөкне алып, үз җилкәсенә салачак, сине гомерләрең буе саклап барачак ир-егет?

Ул кичтә беренче мәртәбә әллә нинди татлы уйлар кочагына чумып йоклап киткән иде Асия.

Чишмә суында юынып торганда да, иртәнге савым сөтенә төшеп барганда да, кичә булган хәлләрне күз алдына китереп, үзалдына елмаеп йөрде кыз. Җыеп куйган чәчләрен сүтеп, авыр толымнарын таратты кыз. Аягына иске чүәкләрен киеп, тау итәгеннән Алансуга таба аталады. Чык төшкән йомшак үлән өстеннән атлавы шундый рәхәт. Тау итәгендә әллә ниткән чәчәкләр үсә. Кыз аларның күбесенең исемнәрен дә белми. Чәчәкләрдә зөбәрҗәттәй янып торган чык тамчылары уйный. Иртәнге тынлыкны кошлар җыры, чикерткәләр чурлавы, бакалар хоры гына бизи. Әнә аргы якта, Тереклек елгасының теге ягында атлар кешни, алар печән утлыйлар, бер-берсенә тавыш бирешә, сөенешеп кешнәшәләр. И-ха-ха!

Калада мондый гүзәллек юк инде ул, дип уйлый кыз. Таш арасында нәрсә булсын, ди. Ничек яшәмәк кирәк ул кала дигән җирдә? Ләкин калада акча эшләп, әти-әниләргә булышу мөмкинлеге шундый күп. Аннан соң авылга кунак кыз булып кына кайтасы була инде. Биек үкчәле туфлиләр киеп, күрше Хәдичә түтәйләргә җәйләрен кайта торган Сөмбелә сыман. Малай-егетләрнең телендә шул Сөмбелә – матур кыз. Клубка Хәдичәттәйнең оныгы Хәмидәгә ияреп, кызыл эчле ялтыравык кәлүшләрен киеп килә дә аларны сәхнә артында биек үкчәле ак туфлиләргә алыштыра. Ул туфлиләрнең матурлыгы! Әле ул ак туфлиләрнең йөзлегенә ялтырап торган сәдәф, зәңгәр төймәләр ябыштырылган. Бөтен егет-малайларның күзе шул Сөмбеләдә генә. Шаккаталар инде шул кызга, чистый исләре китә.

Әй җаным, әгәр Асиянең дә Сөмбеләнеке кебек кояш итәкле алсу ефәк күлмәге, биек үкчәле ак туфлиләре булсамы?! Аның төз, матур аякларына шундый да килешер иде ул туфлиләр! Юк шул, Асиянең өстендә Сания апасының иске күлмәген сүтеп, әнисе теккән күлмәк, аягында ак брезент чүәкләр. Җәен кичке уенга чыкканда, чүәкләрне акбур белән буяп агарткач, ярыйсы гына була үзе. Ярап тора. Әнә авылдагы башка кызлар да шулай ук киенәләр. Әгәр каладан кайткан Сөмбелә ишеләр булмаса, андый матур киемнәр барын белмәсләр дә иде әле, бер көе генә яшәп ятарлар иде.

Үз уйларыннан үзе уелып, кошлар моңына коенып бара торгач, шактый юл үтелде. Әнә аяк астында нәп-нәни бака балалары сикерешә. Асия аларга басудан куркып сакланып кына атлый. Әбисе Фәгыйлә әйтә:

– Ул нәни бакаларны туфан үзе белән күккә күтәрә дә яңгыр итеп яудыра икән, – ди.

Юктыр, дөрес түгелдер, ничек инде күктән бака яусын, ди.

Кызның уйлары тагын Вәкилгә әйләнеп кайтып төште.

Быел кыш көне Вәкил мәктәпкә шундый да матур бүрек киеп килде. Соры постаудан тегеп, эченә мамык сырып, маңгаена, колакларына йомшак тире куеп теккән бүрекне күреп, малайлар шаккаттылар. Сыйныфташлары бүрекне тотып-тотып карадылар.

– Карагыз әле, малайлар, безнең күрше эте Актүш көчегенең тиресе түгелме соң бу? Тучны! Актүш малаеныкы бу, – диде Вәкилнең артындагы партада утыручы Харис. – Синең атаң – ахутник, Актүшнең көчеген атып үтергән дә сиңа мехавай бүрек теккән. Актүш янына бу бүрекне киеп килә күрмә! Юкса, бугазыңа ябышыр. – Кызлар да, Актүшне кызганып, Вәкилгә әллә ничек читләшебрәк караган кебек тоелды.

– Китегез, булмаганны! Аучы дигәч тә, ни эшләп күршеләр көчеген атсын, ди, Мишараб абый? Бүре баласын атып алган ул. Әби әйтә, төннәрен ана бүре баласын эзләп, авыл башына килеп улый, ди. Кышкы буранлы төннәрдә хатыннар йомышларын үтәргә тышка чыгарга да куркалар, ди. Бала бүрегә дә тансыктыр инде ул, – дип, күршеләре Гафур Вәкилне яклап әйтеп куйды.

Шулай итеп бүре тиресеннән теккән йомшак бүрек егетнең горур башында, башкаларны кызыктырып, кышны чыкты. Аннан соң күршеләрнең эте Актүшнең дә, көчегенең дә урамда чабулап йөрүен күргәч, Вәкилгә кыз-кыркынның карашы да әүвәлге хәленә кайтты. Озын тәнәфестә егет тальянын сайратып, балаларны биетә, җырлата. Тегүче Гыймран Рәхиме теккән, колакчын бүрек Вәкилнең башын суыктан, бураннан саклый. Әтисенә охшап, мәһабәт гәүдәле булып үсеп килүче егетне бүреге тагын да биегрәк итеп күрсәтә иде.

***

Йөрәкләргә яшәү дәрте өстәп, күңелдә әллә нинди сөенечләр уятып, Алансуга яз килеп ята. Инде көндезләрен тәүге тамчылар боз сөңгеләре очыннан март карына тамдылар. Җаннарда, күңелләрдә – күтәренкелек, нидер булыр, нидер үзгәрер кебек.

Мишараб хатыны Латыйфа яңа туган бикәч бозауны бәрәннәр абзарына япты. Яшь бозау, әнисенең җылы җилененнән аерыласы килмичә, аяк терәп, каршы торып маташса да, эткәли, төрткәли торгачмы, карышуның файдасы юклыгын аңлагангамы, хәлсез аяклары белән алпан-тилпән атлап, Латыйфа түтигә иярде. Парландырган саламга көрпә салып болгаткан башак ашап торган җиреннән сыер да, моңсу күгелҗем күзләрен бозавына төбәп:

– Ник тиясең инде минем балама, туйганчы имсен, – дигәндәй, зарлы итеп мөгрәп куйды.

Латыйфа түти арулап юып, читән казыгына элеп куйган савым чиләген алып, бозаудан калган сөтне савып бетерергә дип, тәбәнәк урындыгына килеп чүмәкте. Сыер да тынычланып, башак чәйни башлады.

Шундый матур башланган иде ул көн.

Латыйфа түти караңгы мал абзарыннан чыккач та, күзе чагылып, әллә ни гомер күзен ача алмыйча торды. Йортлары авыл читендә. Алардан соң иксез-чиксез Ялантау болыны җәелеп ята. Күз камаштыргыч аклык! Үтә күренмәле җемелдек челтәр каплаган кар өстен. Кояш нурларында әллә нинди төсләргә кереп, ялтырап ята.

– Йа Раббым! Сөбханалла, нинди гүзәллек! Аллаһ гомерләребезне бирсен! Бала-чагага чир-зәхмәт кагылмасын, тамакларын ач итмәсен! Менә сыерыбыз да бозаулады. Рәхмәт яугыры, бозавы да бикәч булды. Аллаһ теләсә, нәселгә калдырырбыз. Яренгә карт сыерны суярбыз да ярты

түшкәне сатып, балаларның өс-башын бөтәйтербез. Һай, игелекле мал булды карт сыерлары. Җиде баланың тамагын туйдырып торды моңарчы. Сыерлы кеше – сыйлы кеше, дип, юкка гына әйтмәгәннәр. Сөтеннән, маеннан, катыгыннан өзелеп тормадылар.

Шундый уйлар белән төшкелек өчен аш әзерләргә дип, өенә кереп китте Латыйфа түти. Озак та үтмәде, тирләп, яныш пешеп, ире Мишараб кайтып керде. Кулында яңа гына атып алган ак куян иде.

Март башы гына бит әле. Көннәр кыска. Мал-туар карап, кар көрәп, кыска көн кичкә тоташты. Төнгә керделәр. Ул төнне нигәдер бакча башларына килеп, шомлы итеп улаган бүре тавышы да ишетелмәде. Шулай да Мишараб, малларның сабырсызланып шыбырдашкан тавышына борчылып, абзарга чыгып керде. Әллә ни борчылырлык сәбәп тапмагач, карчыгы сәкегә җәеп куйган йомшак урынга ятып, калын юрганын ябынып, гырлап йоклап та китте.

Иртән торып, бозау эчертергә чыккан Латыйфа җиңгинең чәрелдек ачы тавышы әле йоклап яткан Мишарабын, балаларын уятты.

– Сиңа әйтәм, Ми-ша-раб, сиңа әйтәм, бү-ре бу-бу-ган, бетергән! Аллакаем гынамдыр ла!

Мишараб, татлы таң йокысыннан айный алмыйча, сәке читенә торып утырды.

– Нинди бүре турында сөйлисең син, әнисе?

– Чык инде, күр инде ул тамашаны! Бетергән, барлык яшь малны бугазлаган! – дип үкседе Латыйфа җиңги.

Мишараб шунда гына аңына килеп, ак күлмәк-ыштаннан гына мал абзарына атылды.

Ә анда әле ае да тулмаган бикәч бозау абзар ишеге төбендә тәгәрәп ята. Аның пыялаланган күгелҗем күзләрендә – рәнҗеш! «Ник инде сакламадыгыз мине? Ник мине ерткыч бүредән бугазлаттыгыз? Әгәр исән-сау үскән булсам, мин шундый игелекле мал булган булыр идем», – дигән киная иде ул матур күгелҗем күзләрдә.

Мал абзарының агач идәнендә өч ак бәрән, бер кара кәҗә тәкәсе канга батып аунап яталар.

– Каһәр суккыры! Ашамаган да бит, бер рәттән барысын бугазлаган бәдбәхет! – дип сүгенеп куйды Мишараб.

Мишарабның ул белән кызы да торып чыкканнар икән:

– Баласы үчен алган инде бу, бүрегә дә баласы газиз, – дип, күз яшьләрен сөртеп әйтеп куйды кызы Нурия. – Кыш буе бакча артындагы каенлыкта улап, тәмам йөрәккә төшкән иде, инде үзенекен иткән.

– Тик кенә тор! Бик күп теленә салынып тор әле! Барыгыз, кереп китегез. Ачу килгән чакта аяк астында буталмагыз! – дип, җанына буылып кычкырды әтиләре. Балалар шунда ук юк булдылар. Ул арада фонарьлары да мелт-мелт итеп сүнәр-сүнмәс торды да сүнде. Керосины беткән каһәрнең!

Иренең холыксызлыгын белгән Латыйфа дәшмәде. Тын гына сыктады:

– Йа Аллакай гынам, сабырлык бир, башка бәла-каза китермә. Хәсрәт бер килә башласа, туктатам, димә. Аннан капканы бикләп куеп кына котылып булмый, – дип сөйләнде.

Нурия Вәкил янына килде дә:

– Абый, син башка ул бүрегеңне кимә, әнкәсе үзеңә дә ташланырга күп сорамас, ерткыч бит ул. Аңа да баласы газиз.

– Ул бүрекне үземнең дә киясем килми. Башкалар сыман постау бүрек киеп йөрермен. Малайлар да ирештерә. Күңелем ятмады минем ул бүре бүрегенә. Әти тунаган вакытта ук бүренең ачык калган күзе акаеп, миңа карап торган кебек иде. Хәзергә чаклы күз алдымнан китми. Бүре баласы: «Әни минем өчен үч алачак әле сездән», – дип әйтә кебек иде. Инде менә ул көн килде, күпме малны харап итте. Бер нәни генә, күрше Актүш көчеге хәтле генә бүре баласы өчен әнә нинди булды ана бүренең үче! Авылдашларны шомландырып, төннәр буе улады бит. Күрше Газзәбикә әби этигә ничә әйтте:

– Мишараб, – диде, – баласын аткач, ана бүренең үзен дә атып ал инде, үч алмый калмаячак, авылга зыян салмыйча туктамаячак. Әрәмәгә чыбык кисәргә барган бала-чагага ташланмагае. Алла сакласын! – диде. – Әнкә бүренең үче бик яман була ул, – диде.

– Әти ничә тапкыр иртәнге якта бүре эзеннән барып карады, тик таба алмады. Кичә дә аудан кайткач, әнигә әйтеп торды:

– Сиңа әйтәм, мин, – диде, – ул бүренең күз карашын тоям, кая гына барсам да, артымда гел шул бүре торадыр кебек. Әллә ничек кенә шунда, җилкә чокырыннан ниндидер кымырҗык салкын өшетеп куя да, шул салкын йөрәккә үтеп керә. Гомер калтырамаган кулым калтырап, ничә тапкыр куянга тидерә алмадым. Өч адымдагы куянга тидерә алма инде син! Әллә бүре каргышы төште инде? Әле кичә генә төлкене ычкындырдым. Нуриягә пәлтә якасына шәп була иде. Тәтегә басам дигәндә, теге бүренең күз карашын җилкә чокыры тирәсендә тоеп, кулым калтырап китте дә, төлкедән җилләр исте. Чикләвек куагы ботагын гына кыеп төшердем.

– Әтисе, Алла сакласын, сак була күр, ул явыз өстеңә сикереп, муеныңны гына өзеп алыр! – диде куркынган Латыйфа җиңги.

Кырыс, йомшак сүзләр әйтә белми торган Мишараб та:

– Латыйфа, әле аучы Мишарабны ботарларлык бүре дөньяга тумаган һәм тумаячак та, – дип, авыр эштән тупасланган кулы белән карчыгының җилкәсеннән кагып алды.

Мишараб көне буе яшь бозауны, бугазлары чәйнәлгән бәрәннәрне тунап, тиреләрен мал абзары диварына тарттырып йөрде. Үләксәләрне үләт базына ташыды.

Икенче көнне авыл халкы аһ итте: Мишарабтан әнкә бүре үч алган! Абзардагы яшь малларын бугазлап, каннарын эчеп чыгып киткән!

***

Асия Фәрит абыйлары турына килеп җиткәндә, әле Гайнулла азый иртәнге савымны китереп җиткермәгән иде.

– Ай–яй, кызым, бүген бигрәк иртәләгәнсең. Әле Ренат абыең йокыдан да тормаган, – дип каршы алды кызны Тереклек суына казлар төшерергә чыккан Гайшә түти. Соры казлар каңгылдашып, инде канат чыккан бәбкәләрен ияртеп, тиздән Тереклекнең көмештәй суына чумасыларын уйлап, оча-калка, Әхмәдиләр тыкрыгына таба элдерделәр.

Кыз, йорт каршындагы имән бүрәнә өстенә утырып, Гайнулла агайның сөт тутырган бидоннар төялгән арбасының авыл башында күренгәнен көтте.

Әле көтүне кумаган. Ишек алларыннан зеңгелдәтеп сыер сауган, йокылары туймаган хатын-кызларның малларга кычкыргалап куйган, сарык бәрәннәренең дөнья бетереп, яшь тавыш белән бәэлдәшкән тавышлары ишетелгәләп тора. Бер–берсен уздыра–уздыра, әтәчләр сөрән сала. Авыл йокыдан уянып килә. Урыстау өстеннән ялкауланып, кызарып, кояш күтәрелә.

Тиздән әнисе, чиләк-көянтәләрен асып, Шәяхмәт картка сөт китерә килер. Әни сөт китерә килгәнче, Гайнулла агай күренмәсә ярар иде. Атна буе күрмәгән әнием белән очрашыр идем идем, дип уйлап куйды Асия. Тик ул арада авыл башыннан дөбер-дөбер бидоннар бәрелгән, тигезсез юлда дыңгырдап тәгәрәгән тәгәрмәчләр тавышы ишетелде. Ярар, бүген кичен, бәлки, авылга төшәргә мөмкинлек булыр дип, үзен тынычландырды кыз.

Асия тау асты чишмәсенә барып җиткәнче, әллә ничә тапкыр туктады. Башына бәйләгән яулыгын салып, көянтәсенә урады. Кичә иңнәрен баскан көянтә-чиләкләр авырлыгы бүген дә сызлап тора иде. Үзен-үзе кызганып, күз төпләренә яшь җыелды. Салкын чишмә суын учларына алып, битенә сипте, азрак хәл кереп киткән кебек булды.

Әле җитмеш җиде басмалы баскычтан яр башына күтәреләсе бар. Асия алдында түбәсе болытларга кадәр тиеп торган Урыстау. Кыз көянтәсенә ураган яулыгын чишеп алды да көянтәсен иңнәренә салды.

Бер баскыч, ике баскыч, ун баскыч... Күңелдә әллә нинди шигырь юллары кабатлана:

*Иң-нә-ре-мә ки-сел-гән-дә*
*Чи-ләк-ләр авыр-лы-гы*
*Унбиш баскыч... утыз баскыч...*
*Ке-ше-ләр-гә сиз-дер-мәскә*
*Җит-те лә са-быр-лы-гым.*

– Әти-әнигә әйтергә кирәк, арыдым мин, башка эшләр хәлем юк. Иртәгә үк бу эштән китәм дә иптәшләр белән ял итә башлыйм. Тагын өч басмадан соң туктыйм, хәл алам. Юк, бүген үк китәм.

Ул сөтле чиләкләрен баскыч басмасына куеп, ял итәргә утырды. Аяклары калтырый иде. Әнисе әйтте бит: «Ял ит, кызым, иптәшләрең ял иткәндә эшләмә», – диде. Юк, тыңламады. Асия үҗәт иде, әйткән сүзеннән кире кайта торган гадәте юк аның.

Тагын утыз сигез басманы узса, кайтып җитә. Кыз, урыныннан кузгалып, тагын басмалар санын тезеп санап китте.

Бер басма... ун басма... утыз басма...

Кинәт кыз үзенә төбәлгән күз карашын тойды. Яшьләренә чыланган керфекләрен күтәреп караса, ни күрсен! Баскычның иң өстендә – яр кашында бүре басып тора!

Кыз, курыкса да, бер өн чыгармыйча, бүре күзләренә текәлеп, баскан урынында катып калды. Авызыннан:

– Әни, бүре бар, – дигән аваз чыктымы, әллә үзенә генә ишетелдеме?

Җаннарын өшетеп, бер уй йөгереп үтте: «Беттем, миңа котылу юк. Хәзер бу ерткыч минем өстемә ташлана да...»

Бүре дә Асиянең күзләренә карап, таш сын сыман кузгалмыйча басып тора бирде. Менә ул бер-ике адым алга, кызга таба атлады...

Асия аякларында басып кала алмады, егылды һәм таудан түбән тәгәрәде. Аның артыннан чиләкләрдәге иртәнге савым сөте елга булып акты.

Асия башка берни хәтерләми. Аның канга баткан гәүдәсен кем табып алган, кем күтәреп, палаткадагы тимер караватка китереп салган – берсен дә белми.

Кургаштай авырайган күз кабакларын ачкач, үзен уратып алган укытучыларны, вожатыйларны һәм Гөлсем апасын гына күрде. Гөлсем апасы чиләк белән су, тастымал алып килгән дә аның йөзен, канап беткән аяк-кулларын сөртә иде.

– Хәзер, кызым, хәзер, Вәкил Нюра апаңны алырга авылга төшеп китте. Болай сынган әгъзаларың күренми, баш миең селкенмәгән булса ярый, косасың килмиме?

– Гөлсем апа, тау башында бүре бар иде. Мин шуннан куркып, каушавымнан аска тәгәрәдем. Сөт түгелде. Балаларга нәрсә ашаттың соң, Гөлсем апа?

– Әй, кара әле моны, чак үлемнән калган бала нәрсә турында уйлап хәсрәтләнеп ята бит, ә! Ярый әле исән калдым, диген! Бүре дигәннән, бүреләр җәй көне алай каршыга чыкмый инде алар. Йә күзеңә күренгәндер, йә аучы Мишараб атып алган баласын әнкә бүре эзләп йөридер. Сиңа тимәс иде дә инде ул, куркыта шул. Син кыз бала түгел, өлкәннәр дә куркыр иде. Әй, кызым, сиңамы соң, ять-яшь башыңнан шундый авыр эштә эшләргә? Үз иптәшләрең уйнап-көлеп күңел ачканда, интегә-интегә эшләп йөрисең. Әниеңә әйтермен, эшләтмәсен, гомерлегеңне алырсың.

– Юк, юк, Гөлсем апа, әнигә әйтә күрмә, үзем әйтермен. Ә сөткә башка үзем генә төшмим, бүредән куркам мин. Гөлсем апа, авылга сөткә төшәсе булса, миңа берәр иптәш бирсеннәр. Ә болай бүген генә ятып торам да иртәгә эшкә чыгам.

Әнисе, хәлне ишетеп, шул сәгатьтә лагерьга менеп җитте. Елый-елый әйтте кызына:

– Эшләмисең, ачка үләбезме әллә?! Ничек әле исән калгансың! Ана бүре ничекләр генә Мишарабларның малларың бугазлап аткан кебек ябышмаган үзеңә, Аллаһ саклагандыр инде. Андый-мондый хәл булса, ничекләр түзәр идем, акылдан язар идем.

– Әни, мин эшлим. Әйтмә дә, үгетләмә дә, эштән китмәячәкмен. Бүген генә хәл алам да иртәгә үк эшкә чыгам. Бер җирем дә сынмаган, Аллага шөкер.

Шул көннән соң тау асты чишмәсеннән су ташырга дежур малайларны билгеләделәр. Авылга сөткә төшкәндә, Асияне озатырга да көн саен берәр малай билгеләнде. Иң беренче көнне үк Вәкил үзе теләп, Асияне озата китте. Барганда да, кайтканда да, Асия көянтәсен генә күтәреп барды. Сөт тулы чиләкләр Вәкил кулына күчте.

Барганда бер-берсенә бер сүз дә әйтмчә, тын гына бардылар. Лагерьга кире кайтканда исә, ничектер сүзләре үзеннән үзе ялганып, көлешә-көлешә атладылар.

– Асия, син каршыңа бүре килеп чыккач, бик курыккансыңдыр инде, иеме?

– Курыктым, Вәкил, котым очты. Сезнең малларыгызны буып ташлаган

кебек миңа да ташлана дип торам. Абау, бүренең күзләре шундый куркыныч була икән. Мин бит эттән дә куркам. Мин аны башта эт дип уйладым. Соңыннан гына аңладым бүре икәнен.

– Син миңа үпкәлисеңдер инде. Ул бүре баласын минем әти атып алган иде бит. Кыш буе киеп йөрдем бүре баласы бүреген. Башка кимим. Сеңлем Нурия дә: «Абый, башка кимә ул бүрекне, энисе саклап торып, өстеңә сикерер», – ди. – Юк, мин куркудан түгел, киясем килми. Бүре баласы да кызганыч, күңел дә тартмый.

– Ник кимисең инде, сиңа шундый килешә ул бүрек.

– Ә синең күргәнең бармы? Мин сине миңа игътибар итмисең дип уйлый идем.

– Юк, Вәкил, синең озын тәнәфес вакытында тальян гармунда уйнавыңны да, концертларда җырлавыңны да бик яратып тыңлыйм. Бигрәк тә әниләр бәйрәмендә җырлаган бер җырыңны ошаттым. Исемен оныттым инде. «Бишмәтеңдә синең биш төймә лә, нигә төймәләмисең», дип җырладың. Моңарчы бу җырны ишеткәнем юк иде. Әллә ни гомер тавышың колак төбендә яңгырап торды. Бүрегең дә сиңа бик килешә, киеп йөр син аны. Кешеләр әллә нинди туннар киеп йөриләр әле, берничә җәнлек тиресеннән тегелгән.

– Асия, кич белән ник син уенга чыкмыйсың, ә? Мин син күренмәссеңме дип, башка кызлар арасыннан эзлим-эзлим, син күренмисең. Әйдә, бүген кичен уенга чык әле, шундый рәхәт анда. Бүген учак ягарлар, чык яме.

– Бик арыйм мин, Вәкил. Чын әгәр, җеп өзәрлек хәлем дә калмый. Хәзер менә суны малайларга ташыта башладылар, алай миңа җиңелрәк. Әле менә сөтне дә син күтәреп кайтасың. Арыгансыңдыр, бир мин алып кайтыйм. Көянтә башына элсәң, җиңелрәк ул.

– Юк, Асия, син күп ташыдың инде, моннан соң сөткә икәүләп төшәрбез, яме. Мин бит җәй буе лагерьда эшләячәкмен, гармунчылары юк. Завуч бик сорады инде.

– Әй, Вәкил, алай яхшы түгел бит инде ул. Вожатый апа әйтте, миңа авылга төшәргә көн саен бер малай билгелибез, диде.

– Юк, Асия, мин синең башка малайлар белән сөткә баруыңны теләмим. Йә берәрсенә күзең төшеп куяр.

– Кит, җүләр, нинди сүз сөйлисең син? Нинди күз төшү, ди, кечкенә ич әле мин, – диде кыз, күзләрен тишелә башлаган чүәкләренә текәп.

– Мин сине бүген түгәрәк кырыендагы имән янында көтәрмен, яме. Сөтеңне дә ташышам, кирәк булса, табак-савытыңны да юарга булышырмын. Тик учак янына чык кына.

Кыз дәшмәде.

– Тукта, Асия, чиләкләрне куеп, азрак ял итеп алыйм әле, ату беләк мускулларым зеңгелдәп тора, – дип, Вәкил чиләкләрне сукмак читенә куйды.

– Азрак үзем алып барыйм инде, син ял ит, йә менә көянтә белән күтәр. Алай күпкә җиңелрәк.

– Син миннән «көянтәле җиңги» дип көлмәссеңме соң?

– Булмаганны, син миңа булышып, сөт күтәреп кайтасың, ә мин синнән көләм, ди! Юу-у-к, Вәкил, мин сиңа рәхмәт кенә әйтәм.

Егет кыз кулыннан көянтә алып, чиләкләрен элеп атлап китте. Тик адымнары эре булыпмы, сөт чайкалып түгелә башлады.

– Болай күпкә җиңел икән, тик сөт түгелә.

– Син адымнарыңны ваграк атла, алай түгелми.

– Чишмәгә төшкән яшь киленнәр кебекме?

– Кызлар кебек инде.

– Мин бит алай йөреп өйрәнмәгән.

Вәкил көлә-көлә, адымнарын акрынайтып китте.

Тау түбәсенә җиңел генә менеп җиттеләр. Асия бүген басмаларны да санамады. Күккә, болытларга таба күтәрелгән басмаларның күбрәк булуын да теләмәдеме икән әле? Җанында әллә нинди бер җиңеллек, моңарчы тоймаган бер рәхәт җылы хис иде. Менә Вәкил тау башына менеп җитәр дә, җиңел адымнар белән атлап, үзе яши торган палаткага кереп югалыр. Ә аннан соң Асия аны көне буе күрә алмас. Дилбегә буе озын көн бит ул! Моңарчы ник алай булмаган? Егет башка малайлардан әллә ни аерылып тормый иде. Ә теге тау түбәсенә менеп җитәргә утыз сигез басма калган чакта, аяк буыннары сыгылып-сыгылып торган көндә, Вәкил килеп, чиләкләрне күтәреп алды.

Шул көннән башлап, яшүсмер кызга әллә нәрсә булды, дөнья үзгәрде. Яр өстенә менүе дә җиңеләйде. Әйтерсең көянтә кискән арык иңнәренә канатлар үсте! Асия үзе дә аңлый алмый торган ниндидер хис җанын җылытып, алда әле бәхетле көннәр киләсен искәртеп тора иде.

Вәкил тау түбәсенә менеп җитте дә чиләкләрен чирәм өстенә куйды.

– Асия, кухняга чаклы үзең генә алып бар инде, авыр булмасмы?

– Ю-у-у-к, Вәкил, менеп җиттек бит инде, рәхмәт сиңа, яме. Зур рәхмәт!

***

Ай-яй, озын булды бу көн! Бабасы әймешли, дилбегә буе, билләһи! Асия иртәнге аштан соң калган табак-савытларын юып куйды. Төшке ашка бәрәңге, кишер, суган әрчеде. Вакыт табып, тиз генә кичен киясе, ак җирлеккә кара борчаклар сибелгән күлмәген почмаклары тимерле иске чемоданыннан чыгарып, селкеп, караватт башына элеп куйды. Үтүкләп алыйм дип, үтүк эзләсә дә, таба алмады. Кичә генә тумбочка өстендә тора иде. Күрше палатка кызлары алып чыгып киткән, күрәсең.

Ул кызларның кыланмышларын күрсәң, исең китәрлек! Кич җитә башласа, авылдан алып килгән ватык көзгене берсе тотып тора, икенчеләре, болай да карлыгач канаты кебек кара каш-керфекләрен каралтып, яшьлектән сусылланып кабарып торган, әле беркем кагылмаган иреннәренә, кояшта янып, алсуланып торган битләренә иннек, кершән сөртеп, әй боргаланалар, әй кыланалар инде! Җаннары әллә кайларга ашкынып, очынып тора. Инде торнаныкыдай аяклары тулыланып, күкрәкләре калкынып, билләре учка сыярдай булып нечкәреп, зифа буйлары егет-малайларның йөрәкләрен җилкендереп торган чак. Асия, арып-талып караватына кереп ауган чакта:

– Әй, җүләрләр, ник инде рәхәтләнеп ятып йокламыйлар, – дип уйлый иде. Инде бүген үзе тумбочкадан китек көзге тартып чыгарды да, кеше-кара югында чәчләрен иңнәренә таратып, йөзенә текәлде:

– Бик әллә кем түгел инде, каш-керфекләре дә Сөмбеләнеке кебек

буялмаган, битенә иннек-кершән дә якмаган, – дип, үзен тагын кунак кызы Сөмбелә белән чагыштырып куйды.

Аягындагы чүәкләре дә тузган, баш бармагы турысыннан менә тишеләм, менә тишеләм дип тора. Менә бу айны эшләп бетерсә, бераз акча түләячәкләр, аякларына яңа чүәкләр алып кияр. Аннан соң Казанга китсә, умырып акча эшли башлар, Сөмбеләнеке шикелле биек үкчәле ак туфлиләр алыр, баш-башларына сәдәф брошкалар ябыштырганын, күзләрнең явын алып торганын. Нәкъ Сөмбеләнеке кебекне! Аннан соң өрфиядәй, тымызык җәйге көндә дә үзеннән-үзе җилфердәп торган киң итәкле алсу ефәк күлмәк, чын ефәк күлмәк алыр!

– Хыялый! – дип куйды Асия. – Тавык төшенә тары кергән, ди, алырсың алай тиз генә. Әгәр минем шундый алсу ефәк күлмәк, биек үкчәле ак туфлиләр кигәнемне Вәкил күрсә, ни эшләр икән? Күрде бит Асия, авылда клуб бакчасына чыккач, тальян тартып утырган егетнең куе кара керфекләрен тибрәндереп, Сөмбеләгә текәлеп карап торганын күрде. Ул вакытта әле Асияне кунак кызның киеме генә кызыктырып тора иде. Ә бүген...

Ничә көннәр инде Асиянең күз алдыннан егетнең күзләре китми. Ниндидер сихри моң агып торган күзләре!

– Асия, авырдыр сиңа, бир чиләкләреңне, үзем күтәрим.

Кыз үзалдына елмаеп куйды. Кара, дөнья нинди матур икән ләбаса! Кошлар сайравына да ниндидер сихри моңнар кушылган, сандугачлар да пар-пар булып чутылдыйлар! Бер-берсенә сайрашып җавап бирәләр. Их, кошлар телен белсәң икән ул!

Кичә «бер генә көн түзәм дә кайтып китәм, ял итәм» дип, үз-үзенә антлар эчкән кыз бүген бөтән утта яна. Ярый әле, кайтып китмәгән. Әгәр авырлыкларга түзә алмыйча, кайтып киткән булса, бүгенге ләззәтле көтү минутларын кичерер иде микән? Юк, вакытлыча булган авырлыкларга түзәргә кирәк! Тормыш ул аклы-каралы икән. Каралыгына түзсәң, аның артыннан аклыгы килә икән. Кайгы-борчулар артыннан, яңгырдан соң чыккан кояш кебек куанычлары, шатлыклары килеп, синең сыкрап, әрнеп торган җаныңны җылыта икән. Дөнья шундый матур икән! Балалык чоры үткәч, мәхәббәт дигән бер могҗиза килеп, синең яшь йөрәк кылларыңны чиртеп, сине күкнең җиденче катына күтәрә икән! Ә анда зәңгәр күзләреннән зәңгәр моң агып торган Вәкил исемле егет бар икән. Җир йөзендә аннан да матуррак, акыллырак, затлырак ир-егет юк икән. Аны бала вакытта белмисең генә икән!

Асия, шау-гөр килеп кызлар кайтып килүен ишеткәч, тиз генә көзгене тумбочкасына тыгып куйды да Гөлсем апасы янына атлады.

Төшке аш вакыты җитеп килә, суга төшәсе юк. Ана бүре очраганнан соң кызның бер мәртәбә дә чишмәгә суга төшкәне юк әле. Малайлар ташый. Элек тәртип бозган малайларга тау астыннан таш ташыталар иде. Ялантаудан чыгарган ташны күтәреп менәләр дә яңадан чишмә буена төшерәләр.

– Әй, балам, бу ана бүренең каршыңа очравы синең файдага булды бит әле. Күрәсеңме, суны кая куярга белеп булмый. Укытучы Мәгъсүм абыеңның башына ник килмәгән элегрәк бу фикер? Мишараб абыең баласын атып

алган бүре дә сине кызгангандыр. Япь-яшь кыз бала интегеп, су ташый, исләренә төшерим әле, малайларга таш ташытканчы су ташытсыннар, файда булыр, дигәндер. Шулайдыр, кызым, бер дә юкка түгелдер. Бүреләр алар шакал түгел, кызым, аларның да җаннары бар. Бу Мишараб ник аткан инде ул бүре баласын? Ана бүре язын Мишарабның яшь малларын буып ташлаган кебек башкаларга да зыяны тимәсә ярый инде. Авыл башында торучы Газзәттәй төннәр буе йоклый алмый ятам, ди. Салам түбәне тишеп кенә керә бит ул, гөнаһ шомлыгы! Кешеләр таң алды йокысын йоклаган вакытта сарайларына төшә, Алла сакласын. Бүре баласы бүрегә бик матур була икән. Кышын мәктәпкә барганда, Вәкил каршы очрады. Башындагы бүреген кулыма тотып карыйсым килде. Шундый йомшак кебек, җылы кебек инде. Аннан соң Мишарабның ул малае бигрәк чибәр. Буй-сыны әтисенә охшаса, йөзе-бите – нәкъ әнисенеке. Вәкилнең әнисе Латыйфа – бигрәкләр дә матур, акыллы хатын. Мишараб кансызрак, усалрак инде ул. Латыйфаны уналты яшендә ул Балыклыдан утырмадан кайтканда урлап алып кайтты. Җәяүләп кайтып килгәндә, артыннан кара айгыр белән куып җитеп, толыбына төреп, өенә алып кайтып киткән. Төне буе елаган кыз.

Мишарабның әтисе Хәлиулла Латыйфаның әти-әнисенә:

– Кызыгыз бездә, югалтмагыз. Тик үкереп елый, ашамый-эчми, ни эшләтик? Безнең Мишарабны беләсез, акылы керәле дә чыгалы. Әгәр алып кайтабыз дисәгез, беркемнең дә кулы кагылмаган, үзегезгә карагыз.

Моңа каршы Латыйфаның әтисе Абдулла:

– Хәлиулла, балачактан имансыз булды малаең. Үзеннән кечкенәләрне кан елатып, бакчаларыгызга кергән кәҗәләрне үтергәнче кыйнап, тавык-чебешнең муенын гына борып ата иде. Инде кызымның башына җиткән икән. Тау асты урамының Сәлимҗан улы Галихан белән туганлашырбыз дип исәп иткән идек. Бер атна элек кенә шулардан яучы килеп, алыш-биреш ясарга тора идек. Инде хараплар гына булган икән кызыбыз. Ни эшләр инде балам? Ничекләр генә яшәп бетерер, – дигән.

– Абдулла, минем бер генә дә гаебем юк. Кызың минем хатын белән йоклый. Ишеккә дә өстәлне тартып терәтеп куйдым, кызыңа бер тигән кеше юк. Әгәр, китер, дисәң, китереп куям. Чип-чиста кызың. Үземнең дә үзәкләрем өзелә, Латыйфаны жәллим. Минем карчыкка әйткән:

– Мәфрүзә апай, яратмыйм бит мин Мишарабны, бигрәкләр дә кансыз бит ул. Минем бит ярәшкән егетем – Галиханым бар. Инде ни эшлим, үз- үземә кул салыйм микән? – дигән. Аңа кушылып минем хатын елый.

Анда малай дулый:

– Тиз арада мулла чакырыгыз, әгәр никах укытмасагыз, ни эшләргә икәнен беләм мин, никахсыз гына үз эшемне эшләрмен, – ди.

Шулай итеп, икәүләшеп кызыгызны үз малаебыздан саклыйбыз. Шуңа күрә, Абдулла, син ни дисәң – шул була. Үзем караңгы төшүгә ат җигеп китереп куям Латыйфаны. Тик минем малай әйтә:

– Әгәр ул эшне эшләсәгез, бөтен авылга данын таратам, кыз түгел ие, шуңа күрә ата-анасына миңа кеше калдыгы кирәкмәгән өчен илтеп аттым дип әйтәм, данын чыгарам, ди. Инде ни эшлибез, барысы да синнән тора, Абдулла кордаш?

– Хәлиулла кордаш, инде буласы булган, күлмәк-ыштан тузган, берни

эшләр хәл юк. Авыл халкына рисвай булып даны чыкканчы, әйдә, бүген мулла чакырып, никах укытыйк. Бигрәк бәхетсез булып туган икән бу кызым, – дип, атасы кызының күзендәге яшьләрен сөрткән.

Латыйфаның анасы гына:

– Алып кайтыйк кызымны, утларга салма балакаемны, бердәнбер кызым, куанычым лабаса, калган бишәве – малайлар. Әни кешегә серен сөйләргә, идән-сәке юарга кыз бала кирәк. Галихан барыбер ышанмаячак Мишарабның нахак сүзләренә. Әй, җаныйларым, шундый пар килгәннәр иде. Өй каршында үскән пар каеннар сыман иде ләбаса! Кызымдыр ла, бәгыремдер лә! – дип, иренең аякларына ятып елаган.

– Юк! – дигән Латыйфаның атасы, – әйттем – бетте! Абдулла башым белән авыл кешеләре күзенә күренергә оялып йөрер хәлем юк. Кияү куенына кергәч, яратыр әле. Байлык ялаштыра, юклык талаштыра ул, Аллага тапшырдык!

Иртәгәсен Мишараблар капкасыннан Хәнәфиләр коесына суга килгән яшь килен Латыйфаның яшьле күзләре төбендә күгелҗемләнеп кара янган урынны күреп, авыл хатыннары шаккатканнар.

Никах укылгач, зөфаф кичәсендә карышып маташкан яшь кәләшнең күз төбенә Мишарабның олы чүкеч чаклы йодрыгы килеп төшкән. Чаршау артында йоклап яткан Хәлиулла белән Мәфрүзә «аһ» иткәннәр. Мәфрүзә каенананың күзләреннән чишмә булып яшьләре аккан. Тик дәшмәгәннәр, эчтән генә тынганнар. Ир белән хатын арасына керергә ярамаганны аңлаганнар.

Мәфрүзә каенана икенче көнне уң як күршеләре Сәкинәгә төнлә булган хәлләрне елый-елый сөйләгән.

– Яхшыдан яман туган нәрсә, әтисе Хәлиулла – нинди ару, укымышлы нәсел баласы, күр инде моны, бүре баласы шикелле бит, малай җаным. Яхшылап әйткәнне дә белми. Дилбегә белән дә ярып карады атасы. Бер айлык песи балаларын тагарактагы суга тончыктырып үтерде, кансыз. Ана мәче җан ачылары белән җир тырный-тырный елады. Мәче каргышы төшәр әле үзенә! Пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа сәлаллаһу-галәйһи-әссәлам чапан итәгендә мәче йоклап киткәч, аны уятмас өчен җаббә итәген кисеп калдырган, ди бит.

Йа Раббым Аллам, ниләр кылана бит, ниләр кылана! Авылның каш астындагы кызы бит ул Абдулла кызы Латыйфа, яшь киленебезне әйтүем. Үзең беләсең, ахирәткәем Сәкинә, кан җылатты бит кызны! Ни эшләтәсең, башка балаларым андый түгел, монысы, белмим, кемгә охшагандыр, тәүфигы арткыры! Аллаһы Тәгалә адәмнәрне яралтканда, менә моннан үрнәк алыгыз, дип, яхшыларын, менә моннан гыйбрәт алыгыз, дип, яманнарын яралткан, ди. Бу Мишарабны гыйбрәт өчен яралткандыр. Аның урынына бер таш яралткан булса, ул Аллаһка зекер әйтеп утырыр иде. Белмим, ни эшләп кенә бетәр бу килен? Ничекләр бу аждаһа белән гомер итәр?

Бу сүзләрне күршеләре Сәкинәгә сер итеп кенә сөйләгән иде Мәфрүзә.

– Беркемгә дә әйтә күрмә, – дип кисәткән иде. – Әгәр малай белсә, миңа аяу юк, – дигән иде. Тик авылда кеше теленә менсәңме, беттем диген инде. Кыш көнендәге җепшек кар кебек тәгәрәткән саен зурая барып, зурайган

саен яңа сүзләр өстәлеп, бу сер тау чаклы булды, билләһи! Мишараб авылның бер явызына әйләнеп, ул, урамда күренсә, күрше эте дә койрыгын кысып, тиз генә капка астына кереп китә торган булды. Чөнки белә, бу залимның аяк астына эләксәң, тибә дә очыра, йә күсәк алып китереп ора. Әллә ничә тапкыр арт санын өстерәп йөрде күрше Газзәттәйнең эте. Шуңа күрә куркалар иде Мишарабтан. Авыл халкы котлары чыгып тора иде.

Латыйфаның зөфаф кичендә үк күз төбе күгәреп, алсу йөзле кызның битенә сары ягылды, күз карашына сагыш ятты.

Коедан чиләкләренә көмештәй су тутырып кайтып килгәндә, биштәрен асып, авылдан чыгып китеп баручы Галиханга тап булды. Күзендәге күгәреген күрмәсеннәр дип, йөзен ап-ак бәс каплаган мамык шәленә яшерә төшеп атлаган Латыйфа дерт итеп сискәнеп китте.

Тик егет күрде.

– Үтерәм, бәреп үтерәм мин ул кабахәтне, Латыйфа, мин сине үзем белән алып китәм. Әйдә, чиләкләреңне ташла да, китәбез, – диде.

– Юк, Галихан, мин сиңа тиң түгел инде, кирәкми. Тизрәк кит, йә мылтыктан атып үтерер, анда иман заты юк.

Тик «ахутник» Мишарабның очлы күзләре хатынының су юлында сөйгән егете белән бер минутлык сөйләшеп торуларын күреп өлгергән иде инде. Җилкапканы ачып, ишегалдына керүгә, яшь хатынның яңагына китереп орды.

– Әле син, кәнтәй, көпә-көндез егетең белән сөйләшеп торасыңмы?! Төнлә очрашырга сүз куештыгызмы, мине ил-күз алдында рисвай итеп?!

Сулы чиләкләрне тибеп очырды Мишараб. Кар өстендә аунап яткан Латыйфаны тибә-тибә кыйнады. Хатынның ачыргаланып кычкырган тавышына ишегалдына атылып чыккан Мәфрүзә улына килеп асылынды:

– Улым, нишлисең, үтерәсең, бетерәсең баланы! Кеше баласы бит, япь-яшь кыз.

– Кит, әни, яклама ул уйнашчыны, суга барган җирендә сүз куешканнар бит!

– Кит, улым, нинди сүз куешу, булмаганны! Кагылма кеше баласына, кулың корыр. Гөнаһысы юк хатыныңның, – дип, ике арага керде Мәфрүзә. Тик улының хатынына сугасы кулы астына эләгеп, кар көртенә килеп төште.

– Үтер! – дип инәлде Латыйфа. – Син мине сугып үтер! Синең белән яшәгәнче үлүем артыграк! Яратмыйм мин сине, сөймим!

Мишараб хатыныннан мондый сүзләрне көтмәгән иде. Инде акылга утырттым, мине санлап, яратып торыр дип уйлаган иде.

Бу сүзләрдән соң үзен-үзе белешмичә, сарай кырыендагы салам өеменә кадап куйган сәнәккә үрелде.

– Үтерә-ә-әм, бәдбәхет!

– Улым, ни эшлисең, Мишараб! – дип, ачы тавыш белән кычкырды әнисе. Инде дүрт япьле сәнәк Латыйфаның күкрәгенә кадаласы иде, күзе- башы тонган ир сәнәкне хатыны өстенә күтәргән иде. Шунда һаваны ярып, мылтык тавышы яңгырады. Бу тавыштан каршыдагы каенга җыелып, томшыкларын канат асларына тыгып утырган чыпчыклар пырхылдашып очып киттеләр. Мишарабның сәнәк күтәргән кулы салынып төште. Кулыннан башта тамчылап кына, аннары шыбырдап аккан кан кар өстен кызыл комач төсенә кертте.

– Әти, ни эшлисең? – диде Мишараб, тынына буылып. – Шушы кәнтәй өчен үз улыңны үзең үтермәкче буласыңмы?! Көпә-көндез бит, йөргән егете белән сөйләшеп тора бит, кайчан очрашу турында сүз куешып торалар!

– Мин син кабахәтне үз кулларым белән атып үтерәм!

– Улым, кил тизрәк, кулыңны бәйлим, – дип көч-хәл белән читән буена өеп куйган кар көрте өстеннән күтәрелгән карчыгына акырып салды Хәлиулла:

– Кит, кырыена киләсе булма, бүре каны ага анда, адәм каны түгел, әнә кар өстенә агып бетсен шунда! Җырткыч җанвар, кеше баласын, бер гөнаһсыз кыз баланы рәнҗетә бит, бәдбәхет! – дип, барып, Латыйфаны кулыннан тартып торгызды да өстендәге киемен сырган кан катыш карны кагып төшерде.

– Кызым, бар кер, бит- кулларыңны ю да, мин сине әтиең йортына илтеп куям. Әти-әниең төшергән сандыгың да әле ачылмаган килеш. Бу чучка сиңа рәхәт күрсәтмәячәк, вакытында котыл бу адәм имгәгеннән!

– Юк, әткәй, мин әти-әни нигезенә кайтып егылырмын да бит, тик ул – китеп кенә кара, бөтен авылга даныңны чыгарам, йөзеңә кара ягам, рисвай итәм мин сине! – ди. – Мин үзем ничек тә түзәрмен, бу тәмугта яшәүгә караганда, туган йортымда яшәү күпкә артыграк, тик әти-әнием ничекләр итеп түзәрләр? – дип, акрын гына Мишараб янына килеп, канга баткан ак каеры тунын салдырды да, баш яулыгын салып, ярасын бәйләде.

Хәлиулла, башыннан мамык шәле шуып төшкән, йөзе-бите күм-күк булган килененә карап:

– Йә Раббым Аллам! Ничек кенә торып бетерерсең бу адәм актыгы белән, кызым, ничекләр итеп кенә тормыш итәрсең? Язмыш дими, ни дисең инде менә моны? – дип, Мишарабка таба борылды.

– Син, чучка, ишетсен колагың, тагын бер тапкыр хатыныңа кул күтәреп кара, менә анаң алдында ант итеп әйтәм, кулымда мылтык. Атып үтерәм мин сине. Юк, үтермим, җан җиреңә турылап атармын, җәфаланып үләрсең. Кеше кызларын рәнҗетерлек калдырмыйм мин син имгәкне! – дип, мылтык түтәсе белән Мишарабның аркасына китереп тондырды.

– Латыйфа балакаем, әле шуның ярасын бәйләп торасың. Агып бетсен шунда агулы бүре каны. Моннан соң, әгәр бер генә тапкыр тырнак белән генә чиртсә дә, миңа әйткән бул. Тора алмасаң, мин хәзер үк аңа өч тапкыр «талак» дип әйттерәм. Без әниең белән шаһит булырбыз. Бер дә кайгырма, балам, моннан соң бу хәлләр кабатланмас, – дип, өенә кереп китте Хәлиулла.

Шул хәлләргә унҗиде еллап вакыт үтте. Ике балалары аваз ярып, дөньяга килделәр. Иллә дә мәгәр тәртипле булып үсте оланнар. Нәкъ Латыйфа инде! Олы уллары Вәкил, әтисе әнисенә авыр сүз әйтсә дә, араларына кереп Латыйфаны яклый торган иде.

Җүнсезнеке гел җүнсез инде, Хәлиулла үлеп киткәч, хатынын кыйнарга ябышкан бу. Вәкилгә җиде-сигез яшьләр тирәсе булгандыр. Тавышны ишетеп, мәктәптән генә кайтып кергән Вәкил тешләрен әтисенең кулларына батырган. Шуннан соң әллә ниткән микроб кереп, Мишарабның бармагы чери башлап, көчкә кулын саклап калганнар.

Азрак әче бал кабып алгач, табындашларына үзе сөйләгән:

– Хатынга сугыйм дип кул күтәргән идем, малай кыргый җанвар кебек

миңа ташланды. Бармагымны чәйнәп өзә дип торам. Шакырдатып чәйни бит самай тәтегә баса торган бармакны! Көчкә авызын каерып ачтырып, кулымны тартып ала алдым. Бетерде, кулымны чисти хараплар итте. Буып атыйм дип, бугазына ябышкан идем, әнкәсе таяк белән башыма орды. Күз алларымнан бер көлтә ут күренеп, аңымны җуйганмын. Бармакның үтереп сызлавына аңыма килдем. Бүре баласы кебек чекерәеп миңа карап тора:

– Тагын бер генә тапкыр әнигә тиеп кара, йоклап яткан җиреңдә суеп үтерәм мин сине, ди. Беләсезме сез шуны! Икенче сыйныфта гына укый лабаса! Шул чебеш сиңа чучка чәнчегән кебек суям дип торсын әле!

Башта әти хатынга бер сүз әйттермәде:

– Тиеп кенә кара, атам да үтерәм, өтермәнгә кереп утырсам утырам, ләкин мин сине дөньяларда яшәрлегеңне калдырмыйм, – дип, бәгырьләремә төште. Инде улым...

– Син, Мишараб, иң башта үзеңне бел инде, Латыйфага көн күрсәтмәдең ләбаса. Башта урлап алып кайтып, хараплар иттең. Аннан ничә еллар буе канын эчтең, үзәгенә үттең. Ярый әле, балалары үзенә охшап миһербанлы булдылар. Аллаһ кызгангандыр инде үзен, олыгайган көнендә рәхәт күрсен, дигәндер.

Мишараб, өстәлдәшләреннән теләктәшлек тапмыйча, болары да шулар җырын җырлый дип, сүгенә-сүгенә өенә кайтып китте.

Инде менә Вәкил дә үсеп җитте. Өйдәге вак-төяк эшләрне кызлары башкарса, тыштагысын җимертеп, Вәкил эшли. Әниләре кебек тырыш, уңган балалары. Кечкенә генә өйләре курчак өе кебек ялт итеп тора, керсәң, чыгасы килми! Сап-сары итеп юылган идәннәренә басарга куркып торырсың! Комнар белән ышкый-ышкый, Колич әрәмәсендәге Сөлек күлдән чыгарган мунчала белән юа кызлары идәннәрен, көн саен юа. Идән-сәкене юып чыгаргач, өйдә һава алышына, рәхәт булып китә, өйгә агач исе тарала. Селтеләр белән кайнатып урын-җирне, кашага-пәрдәләрне ап-ак итеп юып элә. Күрше-күлән шакката. Ничекләр итеп агартып юасыз ул керләрегезне, Латыйфа, серен әйтегез әле? Зәңгәрсуланып, җилдә җилфердәп тора җуып элгән керегез, – дип аптырыйлар.

Мишараб та юашланды. Улының күз карашыннан ук куркып, Латыйфага тел-теш тидермичә, йә урманга – сунарчылыкка, йә Мишәгә балыкка төшеп китеп, кышкы көннәрне өенә дә кайтып керми. Чөнки хатыны тарафыннан булсын, балалары тарафыннан булсын, үзенә карата җылылык тоймый.

Соңгы көннәрдә гел түшәк-ястык өстеннән төшмәгән каенанасын Латыйфа яшь баладай тәрбияли. Түр башындагы сәкедә, чиста урын-җир өстендә килене Латыйфага хәер-дога теләп ята Мишарабның әнисе. Хәлен белергә кергән күрше-күләнгә Латыйфаны, оныкларын мактап бетерә алмый. Тик улы турында ник бер җылы сүз әйтеп карасын!

***

Гөлсем апасы, Асия күңелендә ни барын белепме, белмичәме, кызга Вәкилнең бөтен гаилә тормышын сөйләп ташлады. Аучы Мишарабның мылтыгын асып, ак киемнәр киеп, аудан кайтканын Асиянең әллә ничә тапкыр күргәне бар иде. Әнисе Латыйфа апаны да очратканы булды. Кечкенәрәк буйлы, ябык кына аксыл йөзле хатын. Яшьлегендә бер рәхәт тә күрмәгән икән Вәкилнең әнисе. Бигрәк тә сөйгән ярыннан аерылгач читен

булгандыр. Асия, үз уйларыннан уелып, көнне Вәкилләр гаиләсе турында уйлап үткәрде. Инде менә кояш моңсуланып, шәфәкъны кызгылт кан төсенә манып, баеп маташа. Ай, аксыл-сары шар төсле булып, бер болыт әсәре булмаган күк йөзендә йолдызлар арасында йөзеп йөри.

Балалар, кичке ашны ашап, палаткаларга таралганнар. Кичке учак янына чыгарга җыеналар.

Асиянең әле, табак-савытларны юып, киптерергә куясы бар. Чөнки Гөлсем апасы алданрак, якты күздә авылга төшеп китә. Иртән сәгать биш тулганчы гаиләсен ашатып, бетмәс-төкәнмәс эшләрен тәмамлап, килеп җитәсе бар.

Асия эшләрен бетереп палаткасына кайтканда, Урыстау өстендәге аланлыкта учак ялкыны күтәрелгән. Чаткылар күккә үрләгән ялкын телләре өстендә җем-җем килеп атылалар иде инде.

Әнә кошлар сайравына, чикерткәләр чурлавына тальян моңы кушылды.

Сарман буйларында яшел алан,

Печәннәре җитәр бер заман.

Кыз тиз-тиз генә өс киемнәрен алыштырды, чәчләрен иңнәренә таратты.

Бергә булулары бик күңелле,

Әмма аерылышу бик яман!

Вәкил көтәдер инде.

– Чык, – диде бит. – Мин сине имән агачы төбендә көтеп торам, син килмичә китмим, – диде. – Килмәсәң, төнне шунда кунам.

Асия учакка таба атлады. Әллә ничек уңайсыз иде, чөнки беренче тапкыр егетләр янына чыгуы. Әле аңа унбиш тә тулмаган, ә йөрәге ашкынып, җилкенеп тора. Оят, ләкин җаны ашкына.

**Икенче бүлек**

Ул көн иртәдән үк шыксыз, суыгы әллә ни каты булмаса да, Казан ягыннан искән әче җил үзәкләргә үтәрлек иде. Латыйфа сәгать дүрттә үк торып, мичен үрләтеп җибәрде. Олы мичен кичә кичтән үк ягып, өен җылытып алган иде. Ләкин көн җилле, салкын да булгач, өйнең җылысын җил алып бетергән. Кучкардагы җиделе лампага ут элендереп җибәргәч, мич астына кереп йоклап яткан ак бөдрә йонлы ике бәрән торып чыгып, хатынның аяк астына кереп сырпаландылар. Чөнки беләләр, йортта җанлану булса, ут кабынса, әниләрен өйгә кертәчәкләр. Тамаклары туячак.

Латыйфа казанга шаулатып су салды, учак астына ут үрләтте.

Тиздән улы уяныр, анысы әнисе шикелле сак йокылы. Иртән мәктәбенә киткәнче малларга су эчереп, башак болгатып китә. Әгәр кичләрен соң кайтып йоклап калса, мал карарга әнисе үзе чыгып китә. Кичтән әзерләп куйган болын печәнен сыерына, сарыкларына сала.

Кипкән коры печәннән ушың китәрлек тәмле исләр килә – болыннар исе, мәтрүшкәләр исе, җәй исе. Аннары, кайнар суда пешекләгән саламга көрпә сибеп, башак болгатып бирә. Аннан соң малларның иренеп кенә урыннарыннан кузгалып, мекерт-мекерт итеп печән-салам күшәүләрен, җанында бер җылылык уянуын тоеп, күзәтә. Ярата Латыйфа иртән маллар арасында йөрүне! Абзарның үзенчәлекле исе бар. Әтисе әйтмешли, абзарның

иясе бар аның. Аны мал тотмаган кеше аңлый алмый. Әнә, сыеры, аңардан сөт исе, бәрәкәтле бер муллык исе аңкый. Сыерлы кеше – сыйлы кеше инде ул!

Быел соңрак бозаулар, сыерлары иртә буаз булмады. Әгәр бозауны көзгә чаласы булса, Вәкиленә өс-баш юнәтерләр иде. Юлына да азрак акча җыеп бирергә кирәк булыр. Кала хәтле калага чыгып китәргә җыена улы. Бер көнне кичке ашка утыргач әйтте:

– Мин унынчы классны тәмамлагач институтка керергә уйладым.

Мәктәптә завуч та:

– Галимов, сиңа укырга керергә кирәк, авылда калып әрәм булма! Илгә синдәй башлы, укымышлы яшьләр кирәк. Син, Вәкил, уйла әле, ярыймы, – диде.

Мишарабның шадра йөзе каралып китте, шадралары кызарып, бүртеп чыктылар:

– Ниемә кирәк сиңа ул уку! Монда калхузда эш беткәнме? Аннан соң урманы, мул сулы Мишәсе! Сунарчы булырсың, балык тотарсың. Барыгыз да, койрык чәнчеп, Казанга таярга торасыз! Беләбез, берегезнең дә әче таңнан кояш баеганга кадәр кара җирдә чиләнәсегез килми. Калада гармун күтәреп, тиракайланып җырлап, биеп йөрисең киләдер! – дип, шап итеп йодрыгы белән өстәлгә китереп орды.

Латыйфа сискәнеп китте. Табындагы чәй түгелеп, идәнгә шыбырдап ага башлады. Хатын тиз генә самавыр өстеннән борыны китек чәйнекне алып куйды. Һәм, күңелләрне күтәреп җырлап утырган җиз самавырны кече якка – мич арасына кертеп куйды. Алла сакласын, холыксыз ире самавырны бәреп төшермәсен!

– Йә, Алла! – дип уйлады Латыйфа. – Вәкиле китсә, бу җанвар тагын мине эт урынына кыйный башлар бит!

Яңакларын пешереп, күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәде.

Вәкил куе кара керфекләр уратып алган зур күзләрен тутырып, этисенә карады да:

– Эти, ник син бер генә мәсьәләне дә тыныч кына хәл итә алмыйсың ул, ә? Әле монда йодрык төярлек берни дә булмады лабаса! Гомерләрең буена кеше кебек яши алмадың, өйдә тынычлык булмады. Мин бит клубка чыкканда да, әнигә бер-бер зыян салмадың микән дип куркып торам. Менә әле дә беренче уем әни турында. Әгәр китеп барсам, әни синең янында кала. Ерткыч җанвар кебек бит син, эти! Билләһи, ерткычлар да синең кебек булмас! Ә син үзеңне ашатып-эчертеп торган, кием-салымыңны юган хатыныңны кыйнап, канын эчеп торасың. Әгәр акылыңа килмәсәң, Казанга китүгә берәр фатирга кереп, әнине дә, сеңлем Нурияне дә үз яныма алдырам. Кал шунда ялгыз карт бүре кебек өеңдә. Ату һаман безне мин салган өйдә торасыз, дип табалыйсың. Курыкма, күп калмады. Мин ике сөйләшмим! Тагын бер генә кат әнигә кул тидереп кара! Юк, кул тидерү түгел, авыр сүз әйтеп кара! Миңа инде унсигез тулды, эти дип тормам! Әни күбәләк кебек кенә булып калды, аңа бит нибары утыз биш яшь. Шулай газаплыйсы булгач, ни пычагыма аны сөйгән ярыннан аерып урлап кайттың?

Вәкил җөмләсен тәмамлый алмады, Мишараб урыныннан сикереп торды да өстәлне әйләндереп ташлады:

– Әле син атаңа каршы сөйләп торасыңмы?! Хәзер үк атып үтерәм, берегезне дә калдырмыйм. Син минем улым түгел, кәнтәй анаң Галиханнан тудырды сине, Галихан улы син, – дип, мәче тизлеге белән мылтыгы эленеп торган аралыкка чумды.

– Балалар, качыгыз, атып үтерә хәзер! – дип, Латыйфа иренең аягына ябышты.

Моны көтмәгән Мишараб гөрселдәп, мич кырыена килеп төште. Борыныннан киткән кан, башта акрын гына саркып торса да, соңыннан шактый ук ага башлады. Вәкил, әтисе кулыннан мылтыгын тартып алып, урамга атты. Мишараб мичкә аркасын терәп утырды да әллә ниткән тамак төбе тавышы белән үкерде:

– Барыгыз, бүген үк атагыз Галихан янына чыгып китегез, күзем күрмәсен! Анагыз-ана мәчене көтеп, әле дә өйләнмәгән Галихан, минем үлгәнемне көтәдер.

Вәкил, үзен-үзе белешмичә йодрыгын төйнәп, әтисенә таба атлаган иде, әнисенең үзәге өзелердәй булып кычкырган тавышына кисәк кенә туктап калды. Әнисенең тавышында шулкадәр газап, әрнү, гаҗизлек иде:

– Улы-ы-ы-м, Вәкил! Син ни эшлисең, атаңа кул күтәрәсең түгелме, улым?! Илдә, көндә булмаган хәл! Гөнаһысын кая куярсың? Авылга атасын кыйнаган дигән даның чыгар. Урамга чыгарлыгымны калдырмассыз. Тор, Мишараб, бу гөнаһсызга рәнҗетүләреңне мин кичермәм, Аллаһ кичерсен. Әйе, әйе, Аллаһ хөкеменә калдырам. Балаларның әтиләренә кул күтәрергә хаклары юк! Гәрчә Вәкил дөресен сөйләсә дә. Улым, беркайчан бу эшне эшләмә. Бу минем сиңа әманәтем!

– Әй, әни җаным, мондый ата буламы?! Ата хакын хаклау өчен балаларыңа үрнәк ата булу кирәк бит ул. Ә без, син үзең нинди тормышта яшәдек соң, әни! Нәрсә генә күрдек соң, кыйналудан чыкмадык. Гел кабахәт сүз, нахак, нахак! Ә син түзәсең, барысын да гафу итәсең. Безнең хакка, балаларың хакына түзәсең бит син, әни! Әйтерсең ике гомерең бар! Әйтерсең сине алда шатлыклы, сөенечле озын гомер көтә! Мин бала чакта балалар йортында яшәүчеләр нинди бәхетле дип, ятим балаларга кызыга идем. Аларның әтиләре, эчеп кайтып, әниләрен кыйнамыйдыр, ул ятимнәр йортында тынычлыктыр, дип уйлый идем.

Вәкил, сәке читенә утырып, битен кулы белән каплап елап җибәрде. Сеңлесе:

– Абый, абый! – дип килеп кочаклады. Әнисе, ябык кулларын улының киң җилкәсенә салып:

– Елама, улым! Килешми ул – егет кешегә елау! Әле синең гомерең озын, шулай була күрсен! Үзең яраткан, җаның тарткан кыз белән тормышыңны кор. Гаиләдә ике арада мәхәббәт булганда гына, гаилә нык, бәхетле була, белгән инде аны. Мин күргәнне сезгә күрергә язмасын! Сез инде Нукса шулпасын гарык булганчы эчтегез, гыйбрәт алырлык булды. Инде калган тормышыгыз бәхет-сәгадәтле булсын!

Сиңа әйтәм, тор, Мишараб, адәм теленә кереп, рисвай булмыйк. Кызыбыз Нурия әйтеп килә:

– Безнең кебек гаиләгә кем яучы җибәрсен?! – ди.

– Кызың ялгыз калмасын, дисәң, тузга язмаган сүз сөйләп кеше көлдермә.

Инде кырыкны узгансың, акыл керергә вакыт. Ә балалар үзләренчә яшәсеннәр, безнең сүз белән йөрер яшьтә түгелләр, әлхәмдүлиллаһ! Тәртипле, иманлы булып үстеләр, – дип, тыныч тавыш белән сүзен тәмамлады Латыйфа.

Менә шул кич турында уйлады хатын. Бигрәк ямьсез, күңелсез тәмамланды улының әти-әнисе белән киңәшләшү ниятеннән башлаган әңгәмәсе. Югыйсә тавыш чыгарырдай бер генә сәбәп тә юк иде. Унсигез яшенә чыккан егетнең әтисеннән бер җүнле сүз, киңәш ишетәсе килгәндер. Ә ата улына нинди авыр сүзләр, адәм баласы күтәрә алмый торган сүзләр әйтте. Йа Раббым, син минем улым түгел, Галихан улы ди бит! Ничек телләре әйләнеп әйтә диген син?! Ничек аны җир күтәреп тора?

Унтугыз ел элек күз төбендәге күгәреген, кеше күрмәсен дип, йөзен ап-ак бәс сырган кәҗә мамыгы шәле эченә яшереп кайтып килгәндә, соңгы тапкыр очраткан иде Галиханны. Шунда йөрәге туктардай булган иде.

– Үтерәм, Латыйфа, хәзер керәм дә буып үтерәм мин аны! Әйдә, киттек, аның белән барыбер рәхәт күрмәссең! – дигән иде егет.

– Хуш, – диде Латыйфа, – мәңгелеккә хуш, җаным. Мин, ул мине урлап алып кайткан көнне үк үлдем. Менә син минем аркада авылны ташлап чыгып китеп барасың. Бәхетле бул, Галихан, минем өчен дә бәхетле булып яшә!

– Мин сине мәңге оныта алмам! Мәңге йөрәгемнең түрендә булырсың!– дип, Галихан хушлашып китеп барган иде.

Мишараб та, бәлки, хаклыдыр. Ул бит ире кочагында, күзләрен йомып, Галиханны уйлап ятты. Сизә иде Мишараб аның гөнаһлы уйларын. Бәлки азрак мәрхәмәтлерәк булса, Латыйфа йөрәгендәге бозны эретә алган булыр иде. Күп кирәкмени соң хатын-кыз күңелен эретергә! Җылы сүз, җан азыгы булган бер җылы сүз! Ишетмәде хатын, унтугыз ел буена бер җылы сүз ишетмәде. Югыйсә Мишараб урлап алып кайтканда, уналты яшьлек, кеше кулы түгел, күзе дә төшмәгән саф кыз иде. Гүзәл иде, зифа иде, табигате белән дә бик йомшак күңелле иде. Нинди искиткеч хатын булыр иде ул сөйгәненә! Ә нинди балалар тудырыр иде! Алай дисәң, улы да, кызы да шундый чибәрләр, уңганнар, булганнар. «Әллә инде бала яралган чакта Галиханны уйлап ятканга шундый миһербанлы балалар тудылармы икән?» дип уйлап куйды Латыйфа. Соңыннан үзенең гөнаһлы уйларыннан үзе үк оялып куйды:

– Юньсез хатын, ир хатыны, балалар анасы, ә башында нинди уйлар!– дип, кечкенә урындык алып, сыер саварга утырды. Алып чыккан җылы су белән сыер җиленен юып сава башлады. Чиләк төбенә зеңгелдәп, күңелләрне күтәреп, сөт төшә, ә сыер моңсу күгелҗем-кара күзләре белән хуҗасына карап алды.

Абзар капкасын ачып, улы килеп керде. Аягына олтанлы киез итек, өстенә әнисенең иске сырмасын кигән.

– Әй, әни, тагын мине уятмагансың инде. Әйттем бит, үзем карыйм малларны, дидем. Болай да эшең күп.

– Улым, уятасы итмәдем шул, кичә имтиханнарга әзерләнеп, бигрәк соң яттың бит, жәлләдем. Бар-бар, өйгә кер, башыңа да кимәгәнсең. Бүрегеңне киеп чыксаң ни була? – дип, улын өйгә кертеп җибәрде.

Аллага шөкер, нинди балалары бар, сөбханалла, күз генә тия күрмәсен! Нуриясе пешкән җиләк булып җитешеп килә. Күргән-белгәннәр әйтә:

– Чат үзең инде кызың, өзелгән дә төшкән. Уңганлыгын, булганлыгын әйткән дә юк. Ярый әле, иреңә охшамаган.

– Минем иремә нәрсә булган? Тормышны алып бара. Бар кешенең дә ирләре бер төсле булмый инде ул.

Ире нинди генә булса да, кешегә сиздермәскә тырыша Латыйфа. Өйдәгене урамга чәчкән кешене җене сөйми. Ул иләкнекен – чиләккә, чиләкнекен иләккә авыштырып йөргән гайбәтче хатыннардан ераграк тора. Чөнки белә, Мишарабның холкы барысына да мәгълүм. Иренең гаять тәрбияле атасы белән анасы үзләре үк күрше-күләнгә сөйләп калдырганнар:

– Башка балаларыбыз шулкадәр тәртипле, итагатьле, каян гына шундый явыз булып туды бу чүл бүресе?

Шуннан соң Мишарабка Шакал Мишараб дип кушамат тактылар. Тора-бара Мишараб исеме төшеп калып, Шакал гына калды.

Авылдашлары сөйләшәләр:

– Шакал куян атып кайткан. Шакалны баласын югалткан ана бүре һаман эзәрлекли, ди. Хәзер сунарга чыгарга да шүрли, ди.

– Баш чүмечемдә ана бүренең күз карашын тоям. Тәтегә басам, ә җәнлеккә тидерә алмыйм, – дип зарлана икән.

Латыйфа сыерын савып бетерде дә өйгә керде.

Һай, һай, урамда ачы җил, буран чыгарга торамы? Тизрәк балаларны ашатып, укуларына озатырга кирәк. Вәкиленең Янсуарга чыгып китәсе бар. Башка малайлар белән бергәрәк чыксыннар. Алла сакласын, җиде чакрым барасылары бар. Янсуар юлы җенле, диләр, адаша күрмәсен. Берәр атна торакта торсалар да, ярар. Җиле – җил генәме, суыгы – суык кынамы?!

Балаларны озаткач, сәке өстенә матурлап урын-җирен җыеп куйды. Сүзсез генә чәйгә утырдылар.

– Мин Ялантау түбәсен, Чакрактау итәкләрен әйләнеп кайтыйм әле. Күптән ауга чыккан юк, – диде Мишараб, маңгай астыннан сөзеп карап.

– Сиңа әйтәм, буран чыгарга тора, йөрмә сәнә.

– Синнән сорап торганнар, ди, анда. Әнә, Галиханың отпускыга кайткан, ди. Иркенләп әниеңнәргә төш, шунда күрешерсез.

Латыйфа дәшмәде. Мичен томалап, әзерләп куйган борчак ашын, чуен өстен таба белән каплап, мич түренә утыртып куйды.

– Мичкә син яраткан сарык ите белән борчак ашы куеп җибәрдем, озак йөрмә. Төшке ашны тәмләп ашарбыз.

Мишараб дәшмәде. Җылы киенеп, башына бүре баласы бүреген киеп чыгарга әзерләнде.

– Кимә сәнә шул бүрекне, әнкәсе үзеңә ташланмагае.

– Минем өскә сикерердәй бүре тумаган әле, туасы да юк! Ә инде мине бүре ботарласа, котылырсың. Күптән минем үлememне көтеп йөрисең бит инде. Галиханың белән кавышу турында хыялланасың. Мәңге онытасың юк бит шуны, ана мәче!

– Тәүбә, әстәгъфирулла, диген. Телең ни сөйләгәнен колагың ишетми, Хода бәндәсе!

– Бик телеңә салынып тор әле, яклаучыларың юк, кулда мылтык, тоттым

да атып үтердем. Башта – сине, аннары – үземне. Син себерке белән яшәгәнче үлгәнең артык.

Мишараб ишек тоткасын җибәреп, хатынына таба атлады. Җилкәсенә аскан мылтыгын алып, Латыйфага төбәде.

– Рәхәт күрсәтмәдең син миңа, гомерем буе хатын-кыз назы күрмичә яшәдем мин, беләсең килсә! Чит хатыннар янына барып карадым. Алары да: «Бар, Шакал тәре, хатының янына кайт, кырыема киләсе булма», – дип кудылар. Миңа нәрсәгә кирәк соң син, ир күңелен күрергә дә ярамагач. Каклаган каз кебек кипкән нәрсә! Тотам дисәң, тотар җирең юк, ә себерелергә ярыйсың. Ә көчекләрең тагын, Галихан көчекләре! Алар минем бугазымны чәйнәп өзәргә торалар бит, валлаһи газыйм! Икенче сыйныфта укыганда ук, самай тәтегә баса торган бармагымны шатырдатып чәйнәде Вәкилең. Бүре баласы кебек күземә карап чәйнәде. Әгәр табагач белән башыма бәрмәгән булсаң, буып үтерә идем мин аны.

Мишараб кызды. Инде аны туктатырлык түгел иде. Латыйфа:

– Лә илаһы иллалаһы вә Мөхәммәд әр-Рәсүллулаһ! – дип, күзләрен йомды. Күзләреннән яңакларын пешереп, яшь акты.

Шулчак кинәт, өй ишеген каерып ачып, күршеләре Фәттах килеп керде.

– Исәннәрмесез, күршеләр!

Күзләрен тондырып, Латыйфага мылтык төбәп торган Мишарабны күреп, тиз генә мылтыкны мичкә таба этте.

– Ни эшлисең, күрше?! Ни кыланасың? Үлгәнче өтермәндә черисең килмидер ич? Көпә-көндез гомер иткән хатыныңа мылтык терәп тор инде син, ә! Аучы дигәч тә, әзрәк тәртип кирәк! Йа Хода, ни эшли бит, ә, ниләр кылана!

Синең белән яши-яши, гөл кебек хатының чырага калды бит инде! Ярый әле, Маһруй камыр куясы булган да, чүпрәсе беткән, мин киенеп тормыйм, бар, Фәттах, бер чеметем чүпрә алып чык әле, – дип мине кертеп җибәрде. Нинди фаҗига буласы булган бит, бетәсе булгансыз. Латыйфа гына түгел, Мишараб, үзең дә бетәсе булгансың. Өтермәндә черисе булгансың.

– Пшул бар! – диде Мишараб, Фәттахка кизәнеп.

Тегесе әвен хәтле гәүдәсе белән Мишарабны аралыкка этеп кертте, бала башы кадәр йодрыгы белән яңагына кундырды.

– Әле син, Шакал, миңа кизәнеп торасыңмы? «Көрәшче Фәттах» диләр мине! Унсигез яшемдә Кукчәнең Сабантуй батырын баш аркылы чөйгән кеше мин! Үзеңне көчле дип саныйсыңмы? Әнә улың Вәкил быелгы Сабантуйда мине селтәп атты. Шаккаттым, селтәп кенә атты! Кайтсын гына, барысын да сөйләп бирәм. Хатыныңа мылтык терә инде, фашист шикелле, ә!

Фәттах Мишарабны җилкәсеннән сөйрәп, урамга чыгарып атты.

– Латыйфа күрше, кит син бу адәмнән, торма моның белән. Гомереңнең азагы үкенечле булачак. Атып үтерәчәк бу сине, әйтте диярсең, атып үтерәчәк. Иман юк бит монда!

– Рәхмәт, Фәттах, мин инде беттем, үлдем дип торам, – диде Латыйфа. Аның иреннәре дерелдиде, тешләре шак-шык итеп шакылдый иде. Кулына тоткан тастымалын шулкадәр каты итеп кыскан, баскан урыныннан

кузгалмыйча тик катып тора. Күзләре әллә нинди хәвеф көткән сыман утлы күмер кебек көйри.

Фәттах:

– Ни булды моңа? – дип куркып, аның янына килде. – Латыйфа, Латыйфа! Әйдә, утыр әле, менә берәр йотым су эчеп куй. Айнып китәрсең.

– Мин инде үлдем түгелме соң?

– Юк, юк, исән син, курыккансың гына. Курыкма, әнә Шакалың урманга таба китеп бара. Кая, берәр тынычландыра торган даруың юкмыни соң?

– Мин инде үлдем дип торам, – дип, янә кабатлады Латыйфа.

– Әйдә, утыр әле, исән син, исән. Алла боерса, яшисең әле, яшәргә язсын, – дип, хатынны җитәкләп алып, сәке читенә китереп утыртты Фәттах. – Әй, нинди кызны харап итте бит теге. Син баскан эзләргә басып йөрсәң иде дип, күпме егет хыяллана иде, шул исәптән мин дә, – дип, шкафтагы дарулар арасында корвалол-мазар булмасмы дип, Фәттах почмак якка кереп китте.

Шулара ишектән мамык шәленә бөркәнгән хатыны килеп керде.

– Безнекен үлем артыннан гына җибәрерлек, малай җаным, мәңге эзләп тапмас. Чыгып киткәненә ни гомер. Инде камырым әллә кайчан күтәрелгән булыр иде. Әле һаман кайтып җитә алмый, – дип, ишек төбендә туктап калды. – Бәй, Фәттах сездә түгелмени?

Латыйфа абайламый утыра. Ул ара кулына дару шешәләре тотып, почмак яктан Фәттах килеп чыкты.

– Бар монда хәлләр! Ярый әле, чүпрәгә керттең. Теге Шакал Латыйфаны харап итәсе иде. Инде тәтегә басты дигәндә, мин кереп, мылтыгын бәреп төшердем. Чисти дәҗҗал икән, җанвар икән бу Шакал. Әнә Латыйфа әле дә аңына килә алмый. Мә, кара әле, шушы дарулар арасында нербыны тынычландыра торганы, йөрәк даруы юкмы?

Фәттах үзе дә аптырап басып торган хатынына өч-дүрт кечкенә дару шешәсен тоттырды. Маһруйбикә итеген дә салып тормыйча, тораташ хәлендә катып калган Латыйфаны куенына алып:

– Күрше, күрше, әйдә берәр сүз әйт инде. Мә, йөрәк даруы тамызып бирәм, – дип, Латыйфаның кулыннан тастымалын алмакчы булып, күпме азапланмасын, бармакларын ачтыра алмады. Иреннәренә тидергән су да авыз читеннән генә агып төште.

– Бар, духтырга йөгер, әллә ни эшләгән бу. Куркуыннан тәмам катып калган.

– Тукта әле, фронттан кайткан Гайсә әйткән иде: яшь солдатлар куркудан шулай катып кала торган була икән. Яңагына каты итеп суксаң, аңнарына киләләр алар, дип. Яңагына сугып кара әле.

– Кит булмаганны, ничек күршенең яңагына сугасың ди, ул?

Фәттах, хатыны куеныннан Латыйфаны алып, үз янына утыртты да шактый каты гына итеп яңагына орды. Латыйфа дертләп, сискәнеп китте дә кулындагы тастымалы белән йөзен каплап үксеп елап җибәрде.

– М-и-ин и-сә-ән-ме-е?

– Исән җаным, исән. Әле ярый Фәттахны чүпрәгә кертеп җибәрдем. Яшәп бетермәгән гомерләрең бар икән. Ничек әле тәтегә басып өлгермәгән! Бигрәк имансыз Шакал бит ул, фашист бит ул. Ничек торасың син аның белән? Кит син аннан, ташла да кит. Илдә чыпчык үлми. Әнә, каядыр кешеләрне эшкә җибәрәләр, ди.

Вәкилең генә кайтсын, түкми-чәчми сөйләп бирәм, валлаһи газыйм. Син, җебегән, тагын гафу итәрсең әле шуны, балаларның атасы, диярсең. Ата хакы, ир хакы диярсең. Ю-у-к, бу юлы үзем хәл итәм. Нокта куям мин бу хәлгә. Өтермән бит аның соңгы юлы, өтермән. Малаең гына кайтсын. Тукта, ә малаең кайтканчы үзе кайтып керсә, кара эшен ахырына хәтле эшләсә. Әйдә, киен, безгә керәбез. Нурияң дә безгә керер. Вәкил кайткач, калганын хәл итеп бетерербез. Урамда буран чыкты әле анда, чисти котырырга маташа. Әйдә, малай җаным, мә, мамык шәлеңне башыңа ура, жикетыңны җилкәңә сал да, безгә керик. Самавырым җырлап калды. Бүген иртүк торып, мич каршында коймак та пешереп алдым. Иллә дә күпереп пеште коймакларым. Каз маенда коендырып кына, балаларыма ашатып укуларына озаттым, – дип сөйләнеп, Латыйфаны өйләренә алып чыгып китте Маһруй.

Урамда чынлап торып буран котыра иде.

– Вәкилем Янсуарга барып җитә алдымы икән? Ай-яй бураны! Янсуар юлы – җенле юл ул, адаша күрмәсеннәр. Карале, Фәттах, Мишараб шушындый буранда чыгып китте, кайтып җитә алырмы икән?

Фәттах белән Маһруй бер-берсенә карашып алдылар. Беркайчан да Мишарабны ташламаячак Латыйфа. Әгәр урын өстенә калса, караячак, тәрбияләячәк. Татар хатыннарына хас сабырлыгы, чисталыгы, сафлыгы белән, ир суккан урын утта янмас, ничек ташлыйм, балаларымның атасы бит ул дип, гомер буе яшәячәк, газапланачак. Ире атып үтергәнчегә, яисә кыйнап гарипләндергәнчегә чаклы.

Нуриянең мәктәптән кайткан вакытын сагалап торып, Фәттах аны да үзләренә алып керде. Өйләрендә булган хәлләр турында ишетеп, әнисенең калтырап торган ябык гәүдәсен кочып, үксеп-үксеп елады Нурия.

– Әни җаным, әйдә китик бу каһәрләнгән йорттан, әбиләргә күчеп китик. Үзәккә үтте бит инде, бәгырьләргә төште бит инде бу эти! Абый да әйтә, дөнья читләренә чыгып качар идем, әнине күндереп булмый, ди. Укырга китсә дә, курка, тагын әнине кыйный башлар, мин китүгә тотына инде ул, ди. Әйдә, әни, кешедә торып булмый бит, әбиләргә төшәбез.

– Юк, кызым, мичкә әтиең ярата торган борчак ашы куйган идем. Бәрән ите белән борчак ашын үлеп ярата ул. Фәттах абыеңа әйт әле, төчеләнеп беткәнче чуенны мичтән чыгарып, сәкегә куйсын. Ухватны мичкә сөяп куйган. Әтиең кайткач ашар. Сунардан туңып, ачыгып кайтыр. Ачуы да басылып кайтыр. Алла теләсә рәтләнербез әле.

– Әни, чынлап та җүләр бугай син! Үзеңне атып үтерергә әзер фашистны кызганып утырасың. Җитте инде сиңа, туктарга вакыт. Үзең өчен яшәргә кирәктер бит иде сиңа, әни җаным!

– Алай димә, кызым, ата хакы бар. Теге дөньяга баргач, мәңгелектә, ирең сиңа бәхиллеген бирдеме, ireңә хезмәт иттеңме? – дип сорарлар. Әгәр ирең сиңа разый булмаса, сиңа җәннәтнең ишек төбе дә эләкмәячәк, тәмуг булачак. Син дә колагыңа киртләп куй. Кияүгә чыккач, ireңә хезмәт ит, бәхиллеген алып кал. Әтиең көнләшә инде, көнләшә. Көнләшү – чир бит ул, аннан бернинди дәва юк.

– Их әни, аңламасаң да аңламассың икән!

Нурия мамык шәлен ябынып, өстенә бишмәтен элде дә урамга чыгып китте.

Урамда күз ачкысыз буран, бер адымда каршыдагы читәнне дә күреп булмый. Инде караңгы да төшеп килә. Ай-һай, бу буранда басуда яки урманда калсаң! Нуриянең җаны өшеп китте, әтисе шунда адашып йөрсә яки катып үлсә! Әгәр бүреләр өеренә очраса! Әстәгъфирулла, тәүбә! Әтисен кызганып, әнисе акылдан шашачак бит.

Кызның озын кара керфекләренә буран сырышты. Өйалдына керергә дип ишекне ачса, яба алмыйча аптырап бетте. Буран әллә ниткән ерткыч җанвар тавышлары, ниндидер хәвеф килүен сиздергән авазлар чыгарып дулый иде.

Ул кергәндә, әнисе инде киенеп, үзен авыр вакытта сыендырган күршеләренә рәхмәт әйтеп, ишек түрендә басып тора иде.

– Әйдә, кызым, өебезгә чыгыйк, маллар да ачыкканнардыр, әтиең дә кайтып төшәр. Өй ташлап йөрү юньлегә түгел, – дип, ишек тоткасына үрелде.

Нуриянең, букчасын күтәреп, әнисенә иярүдән башка чарасы булмады.

– Хәерлегә генә булсын инде, балакаем! Нәрсәгә, кемнәр башына гына котыра шул кадәр гөнаһ шомлыгы булып бу буран? Әтиеңә генә хәвеф-хәтәр тимәсен, Раббым Аллам!

Өйләренә кереп, матчага асып куйган җиделе лампага ут элендереп җибәрде. Өй эчен саргылт яктылык әллә ниткән хәвеф-хәтәрле сагышка төрде.

***

Мишараб чаңгысын тагып, мылтыгын аркасына асып, Чакрактауга таба шуып китте. Гаиләсендәге бу үзе дә аңлый алмый торган хәлләр, улының, йодрыгын төйнәп, өстенә килүе башыннан чыкмады. Бу хәлләргә үзе гаепле түгелме соң? Үз улыңа, син минем улым түгел, Галихан улы дип тор инде син! Хатынының әнә очы кадәр дә гаебе юклыгын Мишараб белә. Бөтен сунарчы җаны белән белә! Ләкин ни эшләсен, ярата алмады аны хатыны. Төн – ир белән хатын аңлаша, яратыша торган вакыт. Төнлә барлык көндез чишелә алмый торган мәсьәләләр чишелә. Җаннар, тәннәр бушап, җиңеләеп кала. Хәтта илләр арасында булган сугышлар, орышлар да төнлә хәл ителә кебек тоела Мишарабка.

Ә Мишарабның кочагында мәңге еремәслек боз, бөтен җаны-тәне белән беренче мәхәббәте Галиханны сагынып яшәүче хатыны Латыйфа ята. Ничек түзеп тормак кирәк бу хәлгә?! Кайчагында Латыйфаның мендәре юеш була. Бу – сагыну яшьләре. Галиханны сагынуы хатыны йөрәгендә кайнап чыга да, кайнар күз яшенә әйләнеп, Латыйфа белән Мишарабның уртак түшәкләренә тама. Беренче төннәрендә чаршау белән генә бүленгән уртак ятакларында Мишарабның кулы тәненә тиеп китүгә:

– Кагылма, хәшәрәт! – дип, стенага сыенган иде хатыны. Әйе, чын-чынлап «хәшәрәт» диде. Мишараб үзенең зур борыны, чәчәк авыруыннан калган шадра кызгылт йөзеннән хурланып, озата кайткан кызларның:

– Кит әле, шадра шайтан, кырыемда йөрисе булма! – дип әйтүләренә хурланып, ачуы эчендә агу булып җыелган егет, авылның иң чибәр уналты яшьлек кызын сөйгән яры Галиханнан урлап алып кайтты. Ә кичә кибеттән кайтып килгәндә, өстендә солдат киеме, дисәң, ошамаган, яшькелт форма

кигән бер ир-атны күреп сискәнеп китте. Бу – ул иде, Галихан. Тиз атлап, Мишараб каршына килә. Исәнләшми генә узып китте. Ишетте Мишараб, әле һаман өйләнмәгән икән.

– Минем хатынны көтә инде, шуңа өйләнми, – дип уйлады, йөрәгенең дөп-дөп типкәнен үзе ишетеп. Ачуы йөрәгенә, корычтай йодрыкларына төйнәлде.

Улы киткәч, абзарга кереп, кибеттән алып кайткан бер ярты шайтан суын авызыннан гына эчте. Тәненә көнчелек, ачу белән бергә рәхәт бер җылылык таралды.

– Хәзер кереп иманын укытам, котын алам бу кәнтәйнең! – дип, өйгә керде. Башта ничек сүз башларга аптырап торды. Нинди генә авыр сүз әйтмәсен, Латыйфа тыныч, салмак тавыш белән ипле генә итеп җавап бирә, кызып китми. Әле шуның өстенә ачу китереп:

– Мишараб, бик озак йөрмә, мичкә син ярата торган ризык – яшь бәрән ите белән борчак ашы куйдым, – дип тора, җаһил. – Кимә бүре баласы бүреген, баласын эзләүче бүре өстеңә ташланыр, – ди.

Болай да абзарда чөмергән аракысы җанын кыздырган иде, шул, көнчелеге белән кушылып, Мишарабны үзен-үзе белмәслек, аңламаслык хәлгә китерде. Әгәр Фәттах килеп кермәсә, мылтыгын бәреп төшермәсә, инде тәтегә баскан иде, Латыйфаның башына җиткән иде.

Буранда шактый йөргәннән соң, аракы сөременнән айный башлагач, күз алдына Латыйфаның зур булып ачылган, гаҗизлектән аптыраган нәфрәт тулы күзләре килеп басты. Кычкырмады, качмады, үзенең шул хәленә риза булып, буйсынып, тик карап торды. Хет кычкырсын иде, атма дип ялынсын иде! Аякларына егылсын иде, юк бит, юк.

– Үтер, синең белән яшәгәнче үлгәнең артык! – дигәндәй, мылтык көпшәсенә йөрәген терәп, тик басып торды. Ничек әле Фәттах килеп керде, Аллаһның рәхмәте! Башы берни эшләми иде ирнең. Тәмам күзе-башы тонган иде. Инде улы да әнине калага алып китәм, дип тора, күзен дә йоммый. Мишараб аларны үстермәдемени? Сунарчылыктан кайтып кермәде. Куянын, үрдәк-казын алып кайтты. Әле бервакыт ап-ак аккош та атып алды.

Сөенеченнән күккә сикерердәй булган иде Мишараб. Үз гомерендә беренче тапкыр шундый бәхет тәтеде үзенә. Иренеп, саркылып кына, Урыстау өстеннән кояш күтәрелеп килгәндә, Ялантау күленә ике пар аккош очып килеп төштеләр. Тын күл өстендә, иртәнге кояшны сәламләп, дымсу күзләрен зәңгәр күккә төбәп ачкан сары төнбоеклар арасында, яңа гына туып килүче көннең иркә кояш нурларына коенып йөзә иде пар аккошлар. Бернинди дә куркыныч юк кебек иде. Табигать кочагында Ялантау куенында оеп утырган зәңгәр күлдә бары тик балаларның йокыларыннан уянып, яңа көнне сәламләп, салмак кына үз көйләренә җырлавы ишетелә. Чишмә буендагы куаклыкта берсен-берсе уздырып, сандугачлар сайрый. Әй, үзәкләрне өздереп чутылдашалар инде җаныйларым! Күбәләкләр дә уянып, болын гөлләре өстендә ефәк канатларын җилбегәй җибәреп очалар. Алар шулкадәр күп һәм төрле-төрле. Йа Раббым, булса да булыр икән гүзәллек! Менә шушы матурлыкка сокланып, ял итәргә төшкәннәр иде ул горур кошлар.

Кинәт һаваны мылтык тавышы яңгыратты. Түгәрәк күл генә түгел, Ялантау да сискәнеп куйды кебек. Аккошлар, куркып, ак канатларын кагынып очып киттеләр. Тик зәңгәр күккә бары өч кенә аккош күтәрелә алды. Ә берсенең күкрәк турысындагы ап-ак каурыена кып-кызыл кан агып төште һәм ул мәһабәт горур муенын сары чәчәкле төнбоеклар өстенә салды. Төнбоекның сары чәчәгенә аккош каны агып, күлгә төште. Аккошлар йөзеп йөргән күлнең суы шәфәкъ төсенә керде. Ике аккош күккә күтәрелделәр дә сулкылдап хушлашып, китеп бардылар. Ә берсе, Мишараб атып алган аккошның ише, күл өстендә әллә нинди авазлар чыгарып, аһылдап, сулкылдап бәргәләнде. Сөйгәненә булыша алмаудан, парын мәңгелеккә югалтудан әрнеп, Шакал Мишарабка рәнҗеп сулкылдады ялгыз аккош. Мишараб аккошның очып китмәвенә сөенеп, улы чәйнәп гариплэнгән бармагы белән тәтегә басты, хәрәкәтсез яткан пары өстендә бәргәләнгән аккошка төбәп атып карады. Тик ялгыз аккош, канатларын җилпеп йә күккә күтәрелә, йә атылып, күлгә төшә. Җене чыкты Мишарабның. Ачуыннан кулы калтырап, бөтен булган ядрәләрен атып бетерде, тик ялгыз аккошка тидерә алмады. Күл читендә яткан аккошны муеныннан сөйрәп чыгарды да каны агып беткәнче күтәреп торды.

– Хәйран саллы инде, шактый май туплаган, – диде Мишараб.

Ялгыз аккош, өзгәләнә-өзгәләнә, Мишарабны өенә кадәр озатып куйды.

Ә өенә кайтканда, аны иң беренчеләрдән булып авыл хатыннары каршылады. Үч иткән кебек, җыелышып, көтү куып кайтып киләләр иде. Шунда ук Ахутник Мишараб биленә аскан аккошны күреп алдылар. Аккошның канлы муены җиргә хәтле асылынып төшкән, Мишарабның баш өстендә парсыз аккош әйләнә иде. Ул өзгәләнеп, газаплы җан авазлары чыгарып, рәнҗеп, сулкылдый иде. Бу күренешне күреп, тынсыз калган хатыннар шаулаша башладылар. Күршеләре Маһруйбикә чәчрәп, Мишарабка ябышты:

– Нишләдең, кабахәт, аккош атмасаң, ачтан катар идеңме?! Күр, пары ничек өзгәләнә. Үзеңә дә ялгыз аккош шикелле ялгыз калырга язсын! Латыйфаң ташлап китсен үзеңне, барыбер син аңа рәхәт күрсәтмисең.

Маһруй елап җибәрде дә алъяпкыч итәге белән күзләрен сөртте.

– Аккош каргышы төшәчәк үзеңә. Юк, үзеңә төшми ялгыз аккош каргышы, газизеңә төшә ул, бел шуны, Шакал! – диде Маһруй. Әле ярый бөтен авылыбызга төшмәсә, Алла сакласын, безнең газизләребезгә төшсә, ни хәлләр кылырбыз. Кара, бәгырькәем, ничек өзгәләнә пары, ничек сулкылдый!

– Күп чәйнәшеп торыгыз әле, – дип, Мишараб өйләренә таба атлады. Өстендә үк бәргәләнеп очкан аккошка мылтык түтәсе белән янады:

– Көш, көш, кит, синең дә үләсең киләме? Бар ишләрең янына оч, имгәк.

Өйләренә кайтып җиткәндә, хатыны болдырда сепаратта сөт аертып утыра иде. Балалар әле уянып кына киләләр. Латыйфа, ишек тавышына сискәнеп китеп, моңсу кара күзләрен иренә күтәреп карады да:

– Аһ Аллакаем! – дип катып калды. Авызыннан иңгелдәүле әллә нинди аваз ишетелде. – Ни эшләдең, Мишараб!? Ниләр генә эшләдең? Аккошларны атарга ярамый. Ничек кулларың күтәрелеп, шул матурлыкка, гүзәллеккә мылтык төзәдең, Хода бәндәсе?

– Сөйләнеп тор әле, салып торып җибәрермен, – дип ысылдады ир, һәм аккошны хатынының аяк астына атты. – Мә, йолкы, кичкә токмач басып шулпа пешерерсең. Күр, нинди авыр. Шактыйга җитәчәк бу, берничә көнгә аш пешерергә җитәр.

Аккош, лапылдап Латыйфаның аяк астына килеп төште. Озын муены бөгәрләнеп калып, ачык калган күзләре хатынга текәлеп карыйлар кебек иде.

– Имансыз, ничек кулларың барды? Ничекләр генә җир йотмый сине? Йә, Аллакаем, йә, тәңрем! Кичә Нурияләр сыйныфлары белән Ялантау күленә барганнар иде.

– Әни, күлгә аккошлар төшкән, күрсәң аларның матурлыкларын! Муеннары шундый озын, үзләре шундый ак, әни, шундый ак инде, яңа яуган кар кебек. Иртәгә бергә барырбыз әле, аккош ашатырга күлгә барырбыз, – дип, шул гүзәллеккә сокланып кайткан иде. Инде менә шул аккошның гомерен өзгәнсең! Хараплар гына иткәнсең. Йолкымыйм да, пешермим дә. Ничек тамагыңнан үтсен, ди, ул ризык? Раббым, Аллам.

– Йолкымый кара, үзеңне дә үтерәм! – дип үкерде Мишараб, – пешерми генә кара!

Өйдән атылып, Вәкил чыкты.

– Нәрсә булды, ник кычкырасың? – дип, тыныч, басынкы тавыш белән сорады Вәкил. Идәндә озын муенлы хәрәкәтсез яткан аккошны күреп, тотлыгып тынып калды.

– Аккош аткан, аккош аткан! – дип кабатлады.

Латыйфа, артсыз урындыкка сыгылып төшеп, тавыш-тынсыз гына үкси иде.

Нурия килеп, Мишарабка ябышты:

– Ник үтердең аккошны, ник үтердең?

Әтисе яныннан китеп, үле кош янына килеп утырды да аккошның башын тезләренә куеп, нәни куллары белән сыйпап, әллә ниләр сөйләнде. Күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь тама иде.

Ә улы йодрыкларын төйнәп, кара күзләре белән әтисенә карап тора. Шулкадәр ачу, нәфрәт иде ул күзләрдә. Әйтерсең Мишараб аккошны түгел, әнисен атып үтергән.

– Нәрсә күзләреңне тондырып, бүре баласы кебек карап торасың? Әгәр тәтегә баса торган бармагымны чәйнәп гарипләндермәгән булсаң, мин аның парын да атып ала идем. Сездән гомерегездә дә тормыш алып бара торган юньле кеше чыкмаячак, анагыз кебек җебегәннәр. Берегезгә дә минем кан кермәгән. Мин аның ник икәнен беләм, Галихан каны сездә. Аның турында тавык суярга да күршеләргә керә, дигән иде анасы. «Әни, ничекләр итеп тере җанга пычак тидермәк кирәк? Суйганда, тимә миңа, минем дә бит яшисем килә, дигәндәй, күзгә карап тора бит ул», – дип әйтә дип сөйлиләр иде. Менә шуның каны ага сездә, тфү! – дип төкерде дә ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Такта ишек чак кына күгәнендә эленеп калды.

– Үземдә шакал каны акмаганына бик шат мин, – дип, йөрәгеннән кысып чыгарып, бер җөмлә әйтте Вәкил. – Әгәр дә әти кебек булсам, җир йөзләрендә яшәп тә торасы юк. Әни, үсеп кенә җитим, мин әти янында бер көн дә тормаячакмын, сезне дә алып китәм.

Латыйфа кулындагы тастымалы белән күзләрен сөртте дә:

– Улым, – диде, – әтиең каядыр чыгып китте булса кирәк, капка тавышы ишетелде. Бар, балам, бакча башындагы каен төбенә илтеп күмегез аккошны. Ни эшләмәк кирәк? Нурия, кызым, син дә тор. Үлгән инде ул, балам. Барыгыз, анда иске ак җәймә бар, шуңа төрегез дә илтеп күмегез. Безгә рәнҗер инде. Кая, мин ашарга хәзерли торам, әтиегез ачыгып кайткандыр.

Авылда бу яман хәбәр яшен тизлеге белән таралыр инде. Урамга чыгарлыгыбызны да калдырмады лабаса. Ул да ни эшләсен инде, шундый каты күңелле булып тууына үзе гаепле түгел бит инде, балалар. Аңа шундый җан иңгән, явыз кеше җаны иңгән ул мескенгә.

– Әни, нинди кеше син? Нинди генә кеше соң син, әни? Ник син үзеңне кызганмыйсың? Һаман безгә әтиегез, әтиегез, дип торасың. Ул табынга утырмыйча, безне ашатмыйсың да бит син! Тукта, атагыз кайтсын, әти кешене санларга кирәк. Нинди генә булмасын, ул сезгә гомер бүләк иткән кеше. Әти-әнине сайлап алмыйлар аны. Нинди булса да санлап, яратып яшәргә кирәк, дип тукып торасың. Ә үзеңнең күзеңнән яшь, сагыш киткәне юк. Күреп торабыз бит – бер җүнле сүз ишеткәнең юк синең, әни. Сине кешегә дә санамый лабаса ул.

– Ярар, балалар, инде берни эшләр хәл юк. Башны ташка бәрсәң дә, баш ватыла, ташны башка бәрсәң дә, баш ватыла, бер нәрсәне үзгәртеп булмый, минем язмышыма шулай язылгандыр. Сез андый булмагыз. Үсеп җитәрсез, үз парларыгыз булыр. Бер-берегезне саклап, авыр сүз әйтеп рәнҗетмичә яшәгез, балалар. Бу минем сезгә васыятем, кеше баласын рәнҗетеп яшәмәгез, үзегезгә тиң, хәләл ана сөтен имеп үскән мөселман балаларын насыйп итсен Аллаһ! Гомерләрегез пар аккошлар кебек узсын, – дип, өйдән чиста җәймә алып чыкты. Аккошны җәймәгә төреп, Вәкилгә тапшырды. Ә күктә аккошның пары аһылдый-сулкылдый парын эзли иде.

Менә шуларны, аккош атып кайткан көнен, исенә төшерде Мишараб, Шакал Мишараб. Шул көнне улы Вәкилнең ачу, нәфрәт тулы күзләре йөрәгендә уелып калды. Әтисенең күзләренә бүре баласы кебек карап тора иде улы.

– Үсеп кенә җитим, мин барысы өчен дә, әнинең каһәрләнгән язмышы өчен дә, Нурия сеңлем белән икебезнең бәхетсез балачагыбыз өчен дә үч алачакмын әле синнән дигән уй-тойгыларын укыган иде улының күзләреннән аккош атып кайткан ак пәрдәле ак иртәдә Латыйфаның ире.

Менә бүген киң табанлы чаңгыларын тагып, мылтыгын асып, Чапрактау артындагы урманга китеп бара. Буран чыгарга тора, йөзенә бәреп искән җил Мишарабның шадраларын кисә, күзеннән яшьләр агыза.

Тукта әле, нәрсәгә дип, хатынына мылтык төбәде соң ул? Атып үтерерлек нинди сүз әйтте Латыйфа?

– Бик соңга калып кайтма, мичкә бәрән ите белән син ярата торган борчак ашы куйдым, диде. Бернинди авыр сүз әйтмәде ләбаса. Ярый әле Фәттах керде дип, Мишараб яңабаштан күңеленнән күршесенә рәхмәт әйтте. Төрмәдә чери идем ләбаса. Ул вакытта Латыйфаның өзеләчәк гомере, ятим калачак балалары турында уйламады, бары тик үзен кызганды. Бу хәлләргә әле дә баягы, Латыйфаның күңеленнән мәңге чыкмаячак Галиханның кичә

каршысына очравы сәбәп булды. Инде унтугыз ел буе очрашканнары юк иде, юллары кисешкәне булмады. Кулына шактый зур чемодан тотып, өстенә әллә ниткән яшел форма кигән Галихан – гөрнәдир шикелле төз гәүдәле егет – Мишарабның көндәше, нык адымнар белән урамны иңләп кайтып килә иде. Кибеттән чыгуына нәкъ каршысына очрап торуын күр әле син аның! Күкчәдән җәяүләп кайткан, күрәсең. Битләре кызарып янып тора. Тар сукмакта очраштылар да, бер генә секундка туктап, күзгә-күз карашып тордылар. Исәнләшмичә, ләм-мим бер сүз дәшмичә, кузгалып киттеләр. Мишарабка Галиханның кара күзләре улы Вәкил күзләренә охшаган кебек күренде. Йөрәген көнчелек уты кимерде. Кайчан, кайда очрашканнар Латыйфасы белән Галихан? Галиханның күзләреннән нәфрәт уты бөркелеп тора иде. Менә шуннан чыкты да инде бу тавыш, барысына да Галихан гаепле! Ул – Мишарабның тормышын бозучы.

Мишараб, ярсып, Ялантау түбәсенә менде. Тау түбәсендә җил тагын да куәтлерәк, ярсурак иде. Өстенә кигән ак халатын тарта, йолкый.

Нинди ау инде бүген? Бу буранда нинди куян, төлке очрасын, барысы да өннәрендә посып яталардыр. Хәер, Мишарабка бүген куян да, төлке дә кирәк түгел, өйдән чыгып китәргә генә кирәк иде.

Балаларына авыр сүз әйтте – минеке түгел сез, сез Галихан балалары, диде. Белә, Мишараб, Латыйфаның бер гаебе дә юк, балалары үзенеке. Ләкин көнчелек, кара көнчелек үзәген өзә иде. Әле дә өйләнмәгән, ди бит. Авыл хатыннары сөйли:

– Латыйфамны оныта алмыйм, мәңге онытасым юк. Яратмаган кызга өйләнеп, кеше баласын рәнҗетәсем килми. Әгәр иреннән аерылса, ике баласы белән алыр идем. Барыбер рәхәт күрсәтми ул аңа, – дип әйтеп әйтә, ди.

– Кешедән калган хатын да ярый микәнни Галиханга? – дип, ачуыннан буыла Мишараб.

Урманчылыкта эшли икән Галихан. Дәрәҗәсе һаман үсеп тора, ди. Акчаны көрәп ала икән. Казан читендә зур гына фатир да алган. Шуларны Мишарабка җиткереп тора авыл халкы. Ишеткәннәренә үзләреннән дә өстәп җиткерәләр болай да йөрәге янып торган иргә.

Менә шуннан чыкты бу чак кына һәлакәткә китермәгән ызгыш-талаш. Барысына да шәһәргә китеп олаккан Галихан гаепле!

Мишараб, җилдән йөзен каплый-каплый, Ялантау өстеннән узып Чакрактауга табан юл тотты. Көнозын йөреп тәмам арыды, аякларының хәле китте, ләкин өенә кайтасы итмәде. Улы, кызы мәктәптән кайтканнардыр. Фәттах әйтте бит, Вәкил генә кайтсын, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм, диде. «Әллә үз улымнан куркам инде», дигән уй баш миен яндырып үтте.

Инде тәмам караңгы төште, үзе ачыкты. Күкрәк астында сулык-сулык килеп, ашказаны ашарга сорап авырта иде. Күз алдына Латыйфаның ухват белән мичтән борчак ашын тартып чыгарганы, чуен өстенә каплаган табаны ачкач, өйгә таралган хуш ис – басулар, болыннар исе, һәм тәмам мәмрәп пешеп, сөягеннән аерылып таралып торган яшь бәрән ите. Өстәл уртасына турап өеп куйган бодай ипие! Өйгә шундый бәрәкәтле муллыкисе таралгандыр! Һәм каршында күкрәкчәле алъяпыч япкан, җыйнак ябык

гәүдәле, сагышлы уйчан карашлы, матур ак йөзле, зур кара күзле, күндәм, йомшак табигатьле хатыны, улы, кызы! Ә ул ялгыз торна, ялгыз аккош, юк ялгыз бүре кебек урманда йөри. Өенә кайтасы килми, бураннарга уралып, үртәлеп йөри! Никтер күңелендә әллә ниткән үкенү бар. Күз алдына хатынының мылтык көпшәсенә карап катып калган, куркынган йөзе килеп басты. Күзен дә йоммыйча карап тора иде хатыны.

– Миңа барыбер, теләсәң ни эшлә, – дип әйтә иде хатынның карашы.

Ялынсын иде, тезләнеп: «Үтермә сәнә, җаным, мин сине шундый яратып торырмын», – дисен иде. Юк бит, юк! Мылтык көпшәсенә карап, тастымалын күкрәгенә кысып, тик басып тора. Шунда Мишарабның күз алдына улының, Латыйфаның, Галиханның карашлары килеп басты. Нәфрәт, гаҗизлек тулы кап-кара күзләр!

Мишараб урман юлы буйлап бара иде. Кинәт юлын кирегә, кайтыр юлга борасы итте. Чөнки җилкә чокырын кемнеңдер күз карашы бораулый иде. Бөтен вөҗүден курку, әллә нидән курку биләп алды. Күзләренә кадәр батырып кигән бүреге чигәләрен кыса иде. Әйләнеп, артына карыйсы итте. Урман арасыннан аңа ике пар утлы күз карап тора иде. Каударлана-каударлана бияләйләрен салып, мылтыгын җилкәсенә төшерде һәм шул янып торган күзләргә төбәп атмакчы булды. Көне буе чаңгы таягы тотып барган куллары оеган иде, сунарчылар җәһәтлеге белән мылтыгын төзәп атып өлгерә алмады. Ана бүре Мишарабның өстенә сикерде.

– А-а-а! – дип гаҗизләнеп кычкырып, Мишараб куллары белән бүренең бугазына ябышмакчы булды. Ләкин икенче бер бүре Мишарабның аркасына сикереп, тешләрен ирнең бугазына батырды. Мишарабның күз алдында бүренең янып торган күзләре, улының, хатынының, көндәше Галиханның нәфрәт тулы күз карашлары белән буталып мәңгелеккә юкка чыктылар. Башыннан төшкән бүре баласы бүреген буран Чакрактау түбәсеннән Ялантау өстенә таба тәгәрәтеп алып китте. Әйтерсең лә нәни бүре баласы:

– Әһә, әни синнән минем өчен үч алдымы? – дип сөенеп, кар баскан Чакрактау өстеннән үзен көтеп торган әнисе янына уйнаклый-уйнаклый чаба иде.

***

Көне буе көтеләр Мишарабны гаиләсендә. Улы да Янсуардан укудан кайтты. Инде утырып, төшке ашны да ашадылар, малларны карап, кичке эшләрен дә тәмамладылар, Мишараб күренмәде.

Ә буран котыра, урамга чыгар хәл юк, эләктереп алып, үзе белән очыртып китәргә тора.

– Улым, хәерлегә түгел бу хәл, әтиең адашып йөридер. Әче таңнан кичкә кадәр ничек бу буранда йөрмәк кирәк? Әллә эзләргә чыгып карыйсыңмы? Алай дисәң, үзең дә адашуың бар. Катыплар гына үләрсең, балакаем. Кая әле, Фәттах янына кереп, аның белән киңәшеп карыйм. Бәлки авылдагы хәллерәк ир-егетләр белән эзләргә чыгарсыз. Алла сакласын, хараплар гына булыр атаң. Башына да бүре баласы бүреген киеп чыгып китте бит. Әйтә тордым:

– Кимә бүре баласы бүреген. Үзең беләсең, бүре баласы исен сизә ул, өстеңә генә сикереп бугазлап атар, – дидем. Әтиегезнең холкын беләсез, кеше тыңлый торган адәм түгел.

– Мине бугазларлык бүре тумаган, һәм тумаячак та, имеш.

– Күңелем сизә! Нидер булган атагызга, нидер булган. Кичә төшемдә күргән идем, сыңар алкамны югалттым. Каенанамнан калган ак ташлы сыңар алкамның берсе колагымнан төшеп калган. И эзләдем, и эзләдем. Каенанама әйтәм:

– Әни, – дим, – синең бүләгеңнең берсе колагымнан төшеп калган, эзләмәгән җирем калмады, югалттым. Ачуланма иде, әни – дим.

– Ярар, кызым, эзләмә инде син аны. Сиңа биргәндә үк ташы чатнаган, биге ватык иде. Бер дә кайгырма, яңа колак алкасы алырсыз, – ди.

Әни төсе итеп, саклап кына кия идем. Еладым, алкамны жәлләп еладым. Иртән уянсам – мендәрем юеш. Тиз генә алкаларымны тотып карадым, Аллага шөкер, икесе дә исән, и сөенүләрем инде. Каенанам бүләге бит. Мине шундый ярата иде әни, беркайчан да исемем белән дәшмәде, «кызым» дип кенә торды. Ничекләр яшәп бетерерсең, балам, моның белән, үзәкләреңә үтте ләбаса. Түздең, сабыр иттең, балалар хакы, ир хакы, дидең. Каенатаңны балалар караган кебек карадың. Рәхмәт сиңа, үзеңә шуның өчен Аллаһ әҗерен бирсен, балаларыңның рәхәтен күр, диде. Инде әнинең бу дөньяны ташлап киткәненә дә күпме вакыт узды.

Хәерлегә түгел бу хәл, төше дә рас килеп тора бит аның.

– Әни, үзеңне чак кына атып үтермәгән ireңне жәлләп утырасың. Әле ничек кенә исән калгансың, – дип, әнисенең сүзен бүлде Вәкил. – Кайтыр әле, адаша торган әти түгел. Ул бу тирәдә барлык куакны, һәрбер түмгәкне белә. Хәзер каян табасың аны? Бәлки әле Таутегермән тавындагы Микулай дәдәйләргә кергәндер. Шунда самогон эчеп, җырлашып яталардыр. Ә син монда ут йоткандай утырасың.

– Юк, улым, хәерлегә түгел бу, нидер булган. Әйтә тордым, кимә шул бүре баласы бүреген дидем, тыңламады, – дип кабатлады Латыйфа. Яшьле күзләрен сөртеп, Аллага тапшырдык дип, күршеләре Фәттахка кереп китте. Латыйфа күршесен ишегалларында ук очратты. Фәттах иске сырмага төреп, яңа туган сарык бәрәннәрен күтәреп кереп килә иде.

– Менә сарыгыбыз бәрәнләде. Җылы сараебыз булса да, курыктым, өши күрмәсеннәр. Бикәч бәрәннәр алып кайткан кара сарыгыбыз. Быел сарыкларыбыз икешәр бәрән ә мериносыбыз өчне китерде, Аллага шөкер. Сыерыбыз да буаз, – дип сөйләнде. – Кайттымы, синеке, азрак бете басылып кайткандыр.

– Юк бит, кайтмады. Ниләр генә булды икән инде, Раббым, бер Аллам? Инде күзне төртеп тишәрлек, берни күренмәслек караңгыга калды. Ул буранны күр син. Җүнле адәм этен дә урамга чыгармаслык көндә ауга чыгып китүен күр син аның. Үзең беләсең, кеше сүзен тыңлый торган бәндә түгел. Үз башына ашкынуы булдымы? Әй, котырып карады инде бу арада, – дип, Латыйфа мышкылдап елап җибәрде.

– Хәзер бәрәннәрне өйгә кертәм дә, сөйләшербез, киңәшербез. Таутегермән урысы Микулайга киткәндер. Әле шунда самогон эчеп, эчен бушатып ятадыр, – дип, Фәттах өенә кереп китте. Төнлә эзләргә чыгуның файдасы юклыгын аңлап, бу эшне иртәгә калдырдылар.

***

Төнне барысы да йокысыз үткәрделәр. Латыйфа елады да елады.

– Начар, явыз дигәч тә, аның яхшы яклары да күп иде. Мал таба белде, ач-ялангач итмәде. Көнләшкәндер инде, шуңа кыйнап torгандыр, йөрәгенең януына түзә алмагандыр.

Мишарабны бер генә начар сүз белән дә искә алмады хатын.

– Микулайга кереп, шунда куна калган гына булса ярар иде. Әйттем бит мин аңа, мичкә борчак ашы куйдым дип. Соңга калма, әбәткә кайтып җит, дидем. Инде чисти ачыккандыр. Иртән дә җүнләп ашамыйча чыгып киткән иде, бичаракаем.

Вәкил белән Нурия әниләренә аптырап карап торалар. Гомере буе әтисе тарафыннан бер юньле сүз ишетмәгән, ору-сугудан тәмам җәфа чиккән әниләре: «Исән-сау гына була күрсен!» – дип тора бит!

– Шулай, балалар, Алла теләсә, барысы да яхшы булыр. Кайтыр әтиегез, кайтыр.

***

Икенче көнне буран басылды. Ялт итеп кояш чыгып, Ялантау болыны ап-ак булып, күзләрне иркәләп, үзенә чакырып тора. Авыл ир-атлары, җыйнаулашып, Мишарабны эзләргә чыктылар. Берәүләре Таутегермән Микулайга юнәлделәр. Башкалары бүленеп, кем урман буена, кем Чапрактауга, кем Ялантау түбәсенә менеп киттеләр. Кар күп яуган, Мишарабның эзләрен күмеп киткән иде. Барысы да, аптырап, таба алмый кайттылар. Ике көн узгач кына, Мишарабның танырлыгы калмаган гәүдәсен ат чанасында салам өстенә салып алып кайттылар.

Латыйфа елый-елый шешенеп бетте. Балалар да елаштылар. Чөнки хатын балаларында иренә карата хөрмәт уятырга тырышып үстерде. Ата хакы – Тәңре хакы, диде. Әтиегезгә авыр сүз әйтергә сезнең берегезнең дә хакыгыз юк. Сезгә ул гомер биргән, ашаткан, эчерткән, тәрбияләгән. Ишетсен колагыгыз, берегезнең дә авызыннан әтиегез турында начар сүз ишетәсе булмыйм, диде.

Авыл хатыннары гына:

– Яшәвен дә кеше кебек яшәмәде, үлеме дә адәмчә булмады, аккош каргышы гына төште үзенә, – дип сөйләштеләр. – Әнә, парын югалткан аккош ел саен ялгыз башы күлгә төшеп, иптәшләреннән аерылып, күл читендә ямансулап, сары төнбоеклар арасында сагыш таратып йөри.

– Ие инде. Ә ана бүре күпме эзәрлекләде үзен, тәки үч алган бит, Алла рәхмәте.

– Латыйфа котылды инде, ир дигәне гомере буе канын эчеп яшәде бит. Күләгәгә әйләнде авылның йөзек кашы кебек кыз. Кипте, корыды.

– Алай димәгез, гомер иткән ире бит. Латыйфаның күзеннән яше гөрләп агып тора. Ир бирмәк – җан бирмәк, ди. Ни эшләмәк кирәк, Галиханнан көнләде. Тегесе дә ялгыз, берүзе тилмереп яши. Ни эшләсен?

Шулай итеп озатты авыл халкы Мишарабны. Җир туң иде, кәйләләр, ломнар белән каберне көчкә казып бетерделәр.

Кабер казучылар арасында Галихан да бар иде.

Мишарабны әти-әнисе янына җирләделәр.

Зиратта шундый тынлык. Агачлар ап-ак бәскә төренгәннәр. Җир ана барысын да үз кочагына ала. Кемнең кем булуына карамастан, барыбыз да шунда барасы.

– Аллаһ гөнаһларын ярлыкасын, җәннәтләрен насыйп итсен, – диде җеназа укучы имам.

Шулай итеп ап-ак бәскә төренгән Алансу зираты үзенең тагын бер бәндәсен куенына алды.

**Өченче бүлек**

Җәйнең инде моңсуланып, көзгә кереп барган мәле. Җанда үзең дә аңлый алмый торган әллә ниткән сагыш. Көннәр шундый аяз тора. Әйтерсең гомер үзенең тагын бер җәе – күпме генә эзләсәң дә, мәңге кире әйләнеп кайтмаячак җәе белән хушлаша. Бәрәңге бакчаларында каермаларга, ызаннарга кытай ефәге кебек тоҗымнар сарган. Ул ефәк җепләр, урала-урала, битләргә чорналалар. Әллә нинди серле бер халәт бу. Иртән иртүк инешкә казлар төшергән, яңа гына унбиш яше тулган Асия үз җанына да күчкән бу халәтне аңлый алмый йөди. Тын гына агып яткан елга ярында су кондызлары үзләре аударган карт тал агачының юан ботагына утырып, инде шактый исәйгән бәбкәләрен күз угыннан ычкындырмаган ата каз белән ана казның, тын елганы яңгыратып, каңгылдауларын, чума-чума коенуларын күзәтте. Су буендагы сыек таллар инешкә иелгәннәр. Инешнең суы шулкадәр саф, чиста, төбендәге шомарып беткән ташлар арасында йөзеп йөргән ташбаш көтүләре күренәләр. Әй, балачак! Әниләрдән яшереп алып төшкән җәймә белән ташбаш сөзгән чаклар! Сез шушы җәйләр кебек гомер елгасында эреп югалырсыз!

Су өсләтеп, сирәк-мирәк кенә саргайган тал яфраклары Мишәгә таба йөзеп баралар. Талгын гына аккан көмештәй инеш суында, яфраклар түгел, сары сагыш йөзә. Тиздән, бик тиздән агачлар ялангач калырлар, үзләре урынына яңа яшь бөреләргә урын калдырып, Тереклек елгасына сары тал яфраклары коелыр. Алар ашыга-ашыга агарлар да агарлар. Инеш өстенә моңсу авазлар сибеп, торналар очып узар. Киек казлар тавышын да инеш үзе белән еракка-еракка, әле Асия белмәгән, күрмәгән якларга таба алып китәр. Менә шулай гомер үтәр.

Әнисе һаман әйтә килә кызга:

– Кызым, син бик сизгер, – ди. – Кеше күрмәгән әйберләрне дә күрәсең, – ди. – Инде Казанга чыгып китәргә торасың, бу сәерлегең, юмартлыгың белән ничекләр генә яшәп бетерерсең икән? Башка балаларым өчен борчылмыйм, синең өчен генә кайгырам. Төннәр буе йоклый алмыйча ятам. Бик тиз ышанучан бит син, кызым, – ди.

– Әни, ә нигә ышанмаска, ышанам! Мин беркайчан беркемне алдамаячакмын. Мин гомерем буе чиста күңел белән яшәячәкмен. Алла кушса, әни, мин журналист булам, ә бәлки әле язучы... Әй, анысы буш хыял инде, тормышка ашмаслык буш хыял. Гомәр Бәшировлар, Фатих Хөсниләр, Галимҗан Ибраһимовлар кебек язучы була да алмам! Ләкин мин, әни, үзем генә күрә алган, ниндидер аңлашылмый торган бу халәтемне ап-ак кәгазь битләренә төшерәчәкмен. Мин менә шуңа ышанам, әни.

– Әй, кызым, абыең быел унынчы сыйныфны тәмамлый, син – сигезенчене. Әгәр бергә чыгып китсәгез, безгә дә җиңелрәк булыр иде. Әтиеңнең дә рөхсәте юк. Миңа әйтә: «Әнисе, үзең сөйләшеп, аңлатып кара әле балаларга. Быел йорт кузгатырга торабыз, авыр ел, диген. Кызыбыз Янсуарга барып укыса, азрак акыл кермәсме үзенә? Әле кичә генә бәрәңге казыганда чыккан тычкан балаларын учына алып, җылытып йөри иде. Җаныйларым, ди, әнкәгез булмагач, ачка үләрсез бит сез, ди, күзләреннән яшьләре ага. Җиңелчәрәк, сәеррәк инде безнең бу кыз. Нинди Казан аңа, нинди ялгыз башка яшәү, ди? Әйт кызыңа, әтиең ризалыгым юк, дип әйтә диген, тагын ике елдан соң бераз акыл утыргач китәр. Ул көйгә абыйсы химия-технология институтының икенче курсын тәмамлар.

Мин әйттем:

– Белмим, белмим, тыңлатып булмас. Аның үзсүзлелеген беләсең. Бабасы кирелеге күчкән аңа, әйткән сүзеннән кире кайтмаячак. Аның авылда булуы миңа да рәхәт бит әле. Дәфтәрләремне тикшерешеп тора. Ул алтынчы сыйныфта укый башлаганнан бирле дәфтәр тикшергәнем юк. Аннан соң, үзең беләсең, начар укучы балаларны өйгә чакыртып укытам бит. Анысын да үз өстенә алды. Күрсәң син аның кыланмышын! Читтән генә күзәтәм үзен, чын укытучы инде менә!

– Безнең укытучылык аның канына сеңгән инде. Шундый булып туган ул. Ярар, әле вакыт бар, бәлки, үзгәрер, бәлки, авылда калыр. Юлына акча бирмәбез. Казан сиңа авыл түгел, бусагаңны атлап чыкканга да акча сорый ул кала дигән җир!

– Мин тагын сөйләшеп карармын, ләкин бер дә күңелем ышанмый. Әни, мин унибиш яшьтә инде, үз язмышымны үземә хәл итәргә мөмкинлек бирегез миңа, дигән була бит әле. Әйтерсең егерме яше тулган кыз. Алла рәхмәте!

Шулай итеп, Асиягә әнисе әтисе белән ике арада булган сөйләшүне сөйләп биргән иде.

Ул көнне барысы да бакчага бәрәңге алырга чыктылар. Ап-ак бәрәңгеләр кара җир өстендә яктырып яталар, шулкадәр эреләр! Биш-алты бәрәңге салуга чиләгең тула да китә.

Җитмеш ямаулы, үткән көздә Тереклек суында юып киптереп куйган бәрәңге капчыклары гаскәр кебек тезелешеп, бакчаны тутырганнар. Әтисе белән әнисе сөйләшәләр:

– Алла боерса, үзебездән артканны сатып, улыбызга пәлтә алырбыз, мех токкан бүрек җиткерербез. Әнә, дус егете Рафаэльнең ак куян бүреге бар, шундый килешә үзенә.

– Ярар, – ди әтиләре, – бәрәңгене ипле генә, уңышлы гына урнаштырырга кирәк булыр. Аннан соң тышкы базга саласы бәрәңгеләрне өй базына саласыннан аерырга кирәк. Әгәр ике базга да салсаң, яз көне сатканда, бәясе ике тапкыр артыграк була да бит, акчасы бүген кирәк шул аның, йорт салырга, малайга Казанда торырга, яшәренә дигәндәй. Әй, үтерә шул акчасызлык! Мин дә эшли алмыйм ичмаса, берүзең бит, берүзең! Кайдан гына таптылар бу чирне! Әллә бу кәгазьне, йогышлы чир дигән кәгазьне махсус язып бирделәр инде? Бер йөткереп тә карамыйм бит. Әгәр үпкәдә чир булса, бер билгесе булыр иде. Алла боерса, малай укырга керсә, зур

кеше булыр, Нурания, бигрәк башлы малай бит. Буй-сыны дисеңме, йөзебите дисеңме, – дип, бәрәңге казучы улларына яратып карап куйдылар.

Асия тулы чиләкләрен сөйрәп килеп, капчыкка салам дигәндә, әнисе йөгереп килеп җитте.

– Тукта, кызым, капчык авызын үзем тотыйм, бәрәңгеләрең чәчелмәсен.

Әнисенең кояш нурларында вак-вак кына тир тамчылары җемелдәгән алсу йөзе шундый матур, сөйкемле иде. Әнә, алар әтисе белән гөрләшәгөрләшә, алдагы планнары, киләчәктәниләр эшлиселәре турында сөйләшәләр. Телләрендә гел дә гел Данир. Имеш, улыбызга аны алабыз, моны алабыз. Улыбыз Данир химия-технология институтына керәчәк, аны тәмамлагач, зур кеше булачак.

Ә Асия кайда? Ник аның турында бер кәлимә сүз юк? Асиянең дә матур киенәсе килмиме?! Сөмбеләнеке кебек зәңгәр брошкалы ап-ак туфлиләр, өрфиядәй очып китәргә торган ефәк күлмәк кызның төшләренә кереп йөдәтмиме? Әй, нәрсә беләсез соң сез! Минем күңелемдә ниләр барын белсәгезме? Һичкайчан мине сәер дип әйтмәс идегез дип, Асия күзләреннән ирексездән агып төшкән күз яшьләрен сөртеп алды. Алар аның алсуланып торган яңаклары буйлап тәгәрәделәр. Җанында әллә ниткән әрнү, үпкә... Менә күрерсез әле, барыбер китәм, әле абыйдан да югарырак үрмәләрмен. Сәер дигән буласыз, бер дә сәер түгел мин! Алай дисәң, бик дөрес үк тә түгел бугай инде. Әти-әнисенә шулай сәер күренгәч, Вәкил дә мине диванаракка санамыймы икән әле? Йә, Аллаһым! Әгәр шулай булса!

Әниләре алданрак кереп китте дә әтиләре чалган яшь әтәчтән шулпа куеп җибәрде. Аннан соң бакча башына чыгып:

– Асия, кызым, кер әле, калганын үзләре чүпләп бетерерләр, әллә ни күп калмаган. Камыр басып кис әле, синең токмачың аеруча нәзек була. Гөлсем апаңнан аш-суга өйрәндең! – дип чакырып алды.

– Токмач кисәргә мин кирәк. Ә бәрәңге саткач, кием-салым улыбызга, улыбызга, – дип үртәлеп уйлап, Асия, бакча тузанын кага-кага, өйгә таба юнәлде.

Әнисе казан астын үрләтеп җибәргән. Учакта чатыр-чытыр килеп, утын яна. Асия, кулларын юып, өч йомырка сытты да аз гына су өстәп, токмач басты. Камырын ун минутка калай табак белән каплап куйды.

– Кызым, – дияр иде Гөлсем апасы, – камырны баскач, ун гына минутка каплап куеп тор. Камырның аның җаны бар, азрак сулыш алсын, җәяргә дә җиңелрәк була. Җәймәңне юка итеп җәй, астына куйган гәҗитне укырлык булсын.

Асия лагерьда токмач камырын егермешәр йомыркага басар иде, аннан соң, җәймәсе кипкәч, җеп калынлыгында кисәр иде.

– Кулларыңнан куан, кызым. Сөбханалла, токмачны мин дә болай нәзек итеп кисә белмим, – дип, кызның күңелен күрер иде Гөлсем апасы. Дөрестән дә, пионер лагеренда ашчы ярдәмчесе булып эшләү Асия өчен чын тормыш мәктәбе булды. Токмачларын кисеп бетергәндә, кызның уйларын бүлеп, әнисе килеп керде.

– Булды дамы, кызым? Хәзер тиз генә табын әзерләп куйыйк. Бик арытты. Бүген эшне бетерик, иртәгәгә калмасын дип, көнне төнгә ялгап эшләдек. Мунча да өлгерер. Рәхәтләнеп юынып чыгарсыз да ял итәрсез. Иртәгә

абыеңның Казанга чыгып китәсе бар, – дип, кызның яралы җанындагы үпкә дулкынын чайпалдырып җибәрде.

– Әни, сез гел абый турында гына сөйлисез ул, ә? Ник минем турыда бер дә уйламыйсыз? Минем дә бит Казанга чыгып китәсем бар. Үткән елдан бирле әйтәм бит, сигезенчене тәмамлагач, Казанга китәм дип. Әллә минем ниятләрем турында уйламыйсызмы? Әтинең дә, синең дә телегездә – «абыең да абыең»! – дип, кыз елап җибәрде.

– Чү, кызым, әтиең белән көн саен синең турында сөйләшәбез. Янсуарга барып укырсың, ун сыйныфны шунда бетерерсең, азрак акыл да керер дип торадырыек.

– Ник, минем акылым юкмы, җүләрме мин? Мәктәпнең стена газетасын булсын, сыйныфныкы булсын, мин чыгарам, – дип сулкылдап куйды кыз.

– Анысы шулаен шулай да, бигрәк бала гына бит әле син, бигрәк яшьсең. Аннан соң, үсә төшсәң, азрак сәер легең дә бетәр иде.

– Барыбер китәм мин, әни. Әйтте диярсең, җибәрмәсәгез, качып чыгып китәм! – Асия елаганын күрсәтмәс өчен мунча алдына керде дә ишекне эчтән бикләп куйды. Рәхәтләнеп елады кыз, күңеле булганчы елады. Әнисе мунчаны томалап, мәтрүшкәләр, әремнәр кыстырып, мунча себеркесен кайнар суга батырып куйган. Шундый да тәмле ис таралган. Бу инде үтеп барган җәй исе, көмешсыман әремнәр, болыннар, таулар алып килгән зәңгәрсу-шәмәхә мәтрүшкәләр исе иде. Туган як исе! Бу ис Асиянең күңелендә мәңге онытылмаслык булып сеңеп калачак!

Әнисе мунча мичен яңарак кына томалап куйган бугай. Кыз мунча ишеген ачып караган иде – тәрәзәдән төшкән көзге яктылык зәңгәрләнеп тора. Менә мунчага керермен дә искә исереп үләрмен әле – җибәрәсе калган икән, юкка җибәрмәдек дип үкенерсез, тик мин булмам! Әти дә елар, син дә еларсың, әни. Сәер булса булсын шунда, тик исән генә булсын иде дип еларсыз. Менә шунда гына аңларсыз сез мине!

Кыз тагын бу юлы инде үзен кызганып елый башлады. Үлеп, кара җир астына күмеп куясыларын күз алдына китереп, җаны калтырап, бу ямьсез уйларны тизрәк куып таратты. Үзеңне үтерү – зур гөнаһ. Әй, бу уйларны тизрәк онытырга кирәк. Әгәр аның белән ул-бу булса, әти- әнисе, абыйсы, эне-сеңелләре Асиядән башка ничек яшәрләр? Ярата бит аларны Асия. Җәй буе лагерьда эшләде. Әти-әнисенә ярдәм булыр дип тырышты. Шулай уйлап, тастымал белән күзләрен сөртеп торганда, әнисе ишек шакыды.

– Кызым, син мондамыни? Югалттым бит мин сине, балакаем. Мунчага керә күрмә, ис тияр, әле яңа гына томаладым. Хараплар гына булырсың. Ничек синең мунчага кереп киткәнеңне абайламый калганмын. Эзлим, эзлим, таба алмыйм. Ник башыма килеп карасын, мунча турында диюем. Асия ишекне ачты да бер сүз дәшмичә, әнисенә елап шешенеп беткән күзләрен күрсәтәсе килмичә, алма бакчасына чыгып китте.

Әнисенең:

– Бөтенләй шашты инде бу бала, Казанга чыгып китәм дип, акылыннан язды. Өеп куйганнар, ди, анда калада. Анда синдәйләр буа буарлык. Китәр, китәр, тотып торып булмас, – дип сукранып, үзе белән үзе сөйләшкәнен алма бакчасына чыгып киткән Асия ишетеп торды.

Алма бакчалары зур аларның. Әтисе мәктәптә биология фәнен укыта

иде. Шуңа күрә алар бакчасында төрле-төрле агачлар үсә. Асия бигрәк тә алмагачларны ярата. Аларның язын кияү куенына керергә әзерләнгән яшь кәләшләр кебек ап-актан киенүләрен, ә ап-ак таҗларын җиргә койганнан соң чәчкә урыннарында нәни генә яшел бөреләр күренүен, ә алмагач яннары гына түгел, бөтен ишегалды хуш исле алмагач чәчәкләре белән тулганын ярата кыз. Аклык, сафлык дөньясын кем яратмасын?!

Ә бүген дөньяда август муллыгы! Җиргә минут саен тып та тып алма өзелеп төшә. Шулкадәр күп. Әнисе чиләкләп-чиләкләп, күршеләргә алма тарата. Алмадан кайнатма ясыйлар, киптерәләр, как коялар. Күзге муллык! Әнә, алма бакчасында егерме баш умарта оясы тезелеп тора. Бакчага кергән бала-чаганы чагарга гына торган бал кортлары да басынкыланган.

Әтиләре табынга шикәр комы куйдырмый:

– Балда җитмеш төрле авырудан шифа бар, бал ашагыз. Бөтен кеше дә умарта тотмый. Өстәл өстендә бал тормаса, ашыйсыгыз килер иде әле.

– Әти, бал телне әчеттерә бит. Шикәр баллырак та әле ул. Бөтенесе песоклап чәй эчә. Ә бездә бал гына.

– Аларның баллары юк, шуңа күрә песоклап чәй эчәләр. Баллары булсамы?!

Шунда сүз өзелә.

Авылда нигәдер беркем бернинди яшелчә үстерми. Яшел суганны да Көлич, Кәвәл хатыннарыннан күкәйгә алыштырып алалар. Ә Асияләр бакчасында кишер, суган, помидор, кыяр, чөгендер, әнис – бөтенесе дә бар. Җәйләре алма төпләренә, яшелчәләргә су сибеп, түтәлләрдән чүп утап уза. Ә көзен барысын да кышка хәзерләп мәш киләләр.

Алма бакчасында Асиянең күңеле күтәрелеп китте. Әтисе юкә агачыннан ясап куйган өстәл янындагы эскәмиягә утырды да, алма исеннән исереп, уйга калды. Дөнья үзгәрә. Инде кошлар да сайрамыйлар, табигатьтә фасылдан фасылга күчеш тынлыгы.

Иртәгә абыйсы авылдан чыгып китәчәк. Бер киткәч кайтмый инде ул. Ә мин? Мин дә китәм! Иртүк абый торганчы ук торам да! Кичә үк әнисе күрмәгәндә, ятьмә букчага кирәкле әйберләрен салып куйды инде. Акча бирмиләр, имеш. Бирмәсәгез, исем китә! Гипстан катырып ясаган «песие»нең төбен тишеп, 5 сум 18 тиен акчасын әзерләп куйды. Ә автобус билеты 92 тиен тора. Аннан соң калада умырып акча эшли башлаячак. Кичке мәктәптә укып, белем алыр. Ә аннан соң университетның журналистика факультетына керер. Авыл китапханәсендәге бөтен китапларны укып бетерде бит инде, мәктәпнекен әйткән дә юк.

Әй, әгәр акча эшли башласа, әнисенә яңа кофта сатып алып бирер иде. Әтисе Теләче базарында алма саткан акчага алып кайткан яшел джемперы тузып бетте инде. Әнисе терсәк тирәсен атна саен типчеп кенә тора. Тик бер атна үтүгә ямаган җире тагын сипелеп чыга. Әнисе сукранмый гына тагын типчи. Җиделе лампа яктысында әнисенең күк йөзе кебек зәңгәр күзләреннән яңаклары буйлап агып төшкән күз яшьләрен күреп, Асиянең йөрәге парә-парә килә.

– Әни җаным, менә үсеп кенә җитим, мин сиңа әллә нинди ефәк, йон күлмәкләр, күз явын алырлык кофталар, туннар кидерермен әле! – дип антлар эчә кыз. Әнә, кибетче Илгизә апаныкы шикелле зәңгәр кофта-юбка

алып кайтырмын дип хыяллана. Менә шул хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирмиләр бит аңа! Үзләренә дә бер тамак ким буласы, шуны да аңламыйлар, – дип, җиргә төшәлгән алмаларга басмаска тырышып, сак кына атлап, өйләренә кереп китте Асия. Әнисе келәт кырыендагы чөйгә саркытырга туаруг элеп куйган, абыйсына юлга әзерләгән инде. Тавык йомыркаларын кичтән үк иске «Совет мәктәбе» журналы битләренә һәрберсен аерым-аерым төреп, катыргы тартмага тутырып бәйләп куйдылар.

– Улым, автобуста берәрсе этеп-төртеп вата күрмәсен, урын таба алсаң, уңайрак урынга куя күр. Сары майны литрлы банкага салдым, ватыла күрмәсен. Каюм абыеңнарга күчтәнәчне мул әзерләдем, улым. Мәрьям апаң: «Данир бездә торыр», – дигәние. Әйбәт булыр, аларның балалары юк. Карларын көрәп, ишегалларын себереп, утыннарын ярып булышып торырсың. Каюм абыең картайган инде, җитмешкә чыккан.

Яңа суйган тавык шулпасы хуш исле, бигрәк тә йорт токмачы белән бик тәмле иде. Тавык шулпасының үзенә күрә бер исе бар аның. Аңа кишерне күп салырга ярамый, чөнки кишер ул исне бетерә дип, әнисе, җаен белеп, лепердәтеп кенә, сүрән утта пешерә токмач ашын. Асия тәмам эштән чыгып арыган, ләкин гаиләләре белән гөрләшә-гөрләшә табын тутырып утырган туганнарына яратып карап куйды. Нинди бәхетле алар, әти-әниләре исән, үзләре ишле! Ә иртәгә җиде кешедән бишәү генә калачаклар. Үсеп җиткәч, ояларын калдырып очып киткән кош балалары кебек.

Әле һаман ул китү өметен өзми. Казан үзенең биек йортлары, якты утлары белән ымсындырып, гел үзенә чакыра. Ул хыяллар, әллә ниләр вәгъдә итеп, күңелләрен җилкендереп тора иде.

Менә шул кичне исенә төшерде Асия. Кичен абыйсы белән клуб бакчасына чыгып киттеләр. Мунчага кереп чыккач, ару-талулар каядыр юкка чыкты. Әйтерсең беләкләре өзелердәй булганчы, бәрәңге дә ташымаганнар, билләре бөгелмәслек булганчы чүпләмәгәннәр! Әниләре:

– Кызым, инде шулкадәр арыганнан соң, кая барасыз, төн йокыларыгызны калдырып, – дип сөйләнеп калды.

Әни җаным, нинди йокы, ди, йөрәгең ашкынып торганда, клуб бакчасы ягыннан Вәкил өздереп-өздереп, гармунда уйнап:

*Күл буена килсәң иде, уйларымны белсәң иде.*
*Зифа камышларга карап сагынам сине! –*

дип чакырып торганда йоклап ятып була, димени, әни! Инде бер ел буе кызыңның йөрәген бары тик бер егет кенә җылытып тора, ул – Вәкил! Буранлы көннәрдә егет Асиянең абыйсы Данир белән атналар буе Янсуарда тулай торакта яши. Ял көненә кайткач кына күрә аны Асия. Авыл балаларыконцерт яки спектакль куйганда, гармунын күтәреп килә егет. Йә Асия мәктәпнең стена газетасын әзерләгәндә килеп чыга. Алдагы ял көне турында алдан ук әйтеп куя Вәкил:

– Асия, мин киләсе ял көнне сәгать икедә мәктәпкә килермен, син дә кил, яме. Сезгә бит клубка чыгарга ярамый. Балаларга кичен кино карарга да, Казаннан килгән артистларның концертын карарга да ярамый. Карасалар, нәрсә була икән? Әзрәк күңелләрендә җыр-моңга мәхәббәт уяныр дип куркалардыр, ахры. Без, малайлар, авыл мәктәбендә укыганда, кача-поса гына

керә идек. Бигрәк тә Илһам абый белән Әлфия апа концертларын карарга. Алардагы моң, матурлык!

– Шулар кебек җырлый белсәң икән ул, Асия! – дигән иде Вәкил берсендә.

Ә кызга Вәкилдән дә матуррак итеп җырлаучы, өздереп-өздереп, гармунда уйнаучы юк. Әнә клуб бакчасындагы ак каеннар арасында зур түгәрәк уен урыны. Анда иң матур ситсы күлмәкләрен киеп, акбур белән буялган башмакларыннан ак бураннар чыгарып биюче кызлар, егетләр.

*Зәлилә булсаң иде,*
*Зәлилә күк урталарда*
*Әйләнеп торсаң иде.*
*Аллар икән, гөлләр икән, Зәлилә,*
*Гөлләр өзеп бирим сиңа, Зәлилә.*

Вәкил туктамыйча уйный да уйный. Асия Вәкил утырган эскәмиягә күз салса, Сөмбелә! Вәкил кырыена ук килеп утырган да, көлә-көлә, егеткә нидер сөйли. Ап-ак тигез тешләрен балкытып елмая. Вәкил дә аңа елмаеп җавап бирә түгелме?! Әйе, әйе, егет тә кунак кызга карап елмая! Асия йөрәгенең кысып- кысып авыртып алуын сизде. Күзе шунда Сөмбеләнең аягына төште. Кызның аякларында Асиянең төшләренә кереп йөдәткән зәңгәрсу брошкалы биек үкчәле ак туфлиләр, өстендә ап-ак ефәк күлмәк. Менә Вәкил бию көе уйнап җибәрде. Кыз урыныннан кузгалды да ак күбәләк кебек бөтерелә-бөтерелә бии башлады. Бигрәк матур итеп бии инде! Башка кызлар биюгә катнашмыйча гына, түгәрәк кырыенда басып торалар.

Асия Хәдичәттәйнең энисенә сөйләгәнен ишетеп торган иде:

– Сеңлемнең кызы бию түгәрәгенә йөри. Иллә дә матур итеп бии инде, шаклар катарлык. Калага баргач, Мәфрүзә сеңлем мәктәпләренә концертка алып барды. Әллә ниткән кункурс икән, грамыт бирделәр үзенә. Сеңлем шундый сөенде инде. Грамыт биргәч, акча бирәләрме соң дип сораганыем. Апа, акчасына караганда, дәрәҗәсе кирәк безгә, кемнеке дигәндә, безнеке бит әле ул, ди.

Авыл егетләренең күзе әнә шул ефәк күлмәк кигән ак туфлиле Сөмбеләдә бүген. Һәм Вәкилнеке дә!

Вәкил арыдым дип, гармунын читкә куйды. Әле яңа гына гармун шыгырдата башлаган Исмәгыйль гармунны алып, Чистай вальсын уйнап җибәрде. Хәйран гына шомара башлаган. Егетләр берәм-берәм кызларны вальс әйләнергә чакырып чыгардылар. Парлашып ашкына-ашкына бииләр. Вәкил каршына Сөмбелә килеп басты да үзе егетне биергә чакырды.

Әйләнә-әйләнә, түгәрәк уртасына кереп киттеләр.

Асия дә урыныннан кузгалды да акрын гына өйләренә таба атлады. Чистай вальсына...

Аның өчен барысы да бетте. Асиянең йөрәген Вәкилгә бәйләгән беренче мәхәббәтнең серле җепләре өзелде. Кызга җирдә яшәүнең мәгънәсе калмаган кебек тоелды. Хыянәт! Юк, юк! Вәкил бит аңа бер нәрсә дә вәгъдә итмәде. Очрашканда, юк-бар сүз сөйләшеп, шуннан тәм тапты, шуннан соң өзелеп- өзелеп, икенче очрашуны көтте. Вәкил ел буена аның

биленнән дә кочып карамады бит. Кулга-кул тотынышып йөрделәр, ләкин шуннан арыга бармадылар. Ә Сөмбелә әнә, чытлыклана-чытлыклана, кыз башы белән үзе Вәкилне биергә чакырды. Ә Вәкил, кызның биленнән тотты да вальска әйләнә-әйләнә, түгәрәк уртасына кереп китте, Асиянең бар икәнен дә онытты.

Кызның болай да җаны әрнеп, күңеле ашкынып тора иде. Көне буе күзеннән яше кипмәде. Ә монда соңгы өмете, җанын җылытып торучы Вәкил, аны сагынып, очына-очына, клуб бакчасына килгән кызга күтәрелеп тә карамыйча...

Кыз аптырап, үзләренең капка төбендәге агач эскәмиягә килеп утырды да күзләрен күк йөзендә аксыл-саргылт нурларын сибеп торган тулган айга төбәде. Айдан аңа чиләк-көянтәсен асып, күккә ашкан Зөһрә кыз карап тора иде. Чыннан да, игътибарыңны җыеп карасаң, бигрәк тә Асия кебек хыялыйларга айдагы таплар көянтәле кыз кыяфәтендә күренә.

Гармунны янә Вәкил алды булса кирәк, ай яктысында оеп утырган авыл өстеннән аның моңлы тавышы агыла башлады:

*Яшь наратлар көен җырлап киттең*
*Көмеш кыңгыраулы пар атта.*
*Озатып кайтам, карый-карый*
*Бөдрәләнеп үскән наратка.*

Шул моңга кушылып, җиргә шыбыр-шыбыр йолдыз коела сыман. Ул йолдызлар шулкадәр күп атылалар. Август аеның күк гөмбәзен тутырган йолдызлар Асиянең йөрәген яралап, алма исләре аңкып торган тын кичтә йокыга оеган авыл урамнары өстенә, күктә утлы эзләр калдырып, коелалар да коелалар.

Гармун тавышы тынды. Тагын «Зәлилә» уйный башладылар.

Асия өйләренә керәсе итте. Шунда кемнеңдер урам буйлап, Асияләргә таба йөгереп килгәне ишетелде.

Дөпе-дөпе.

Дөпе-дөпе.

Капка келәсенә үрелгән генә иде:

– Асия, тукта!

Вәкил тавышы! Асиянең йөрәге төшеп киткәндәй булды, сүз әйтерлек тә хәле юк иде. Вәкил, еш-еш сулап, кызны кочагына алды.

– Мин, мин сине кереп киткәнсеңдер дип уйладым. Шундый курыктым. Иртән иртүк китәсем бар, күрешмичә калсак?! – Вәкилнең кайнар сулышы Асиянең яңакларын, муенын пешерде. Кызның күзләреннән агып төшкән яшьләр егетнең битләрен чылатты.

– Син кайчан юкка чыктың соң, эзлим-эзлим, таба алмыйм?

– Үзең бит... Сөмбелә белән... Миңа күтәрелеп тә карамадың. Әйе шул, Сөмбелә – шәһәр кызы, өстендә ефәк күлмәк, туфлиләре зәңгәр брошкалы! Аннан соң ул кыю, минем ише куркак түгел.

– Әй, җүләркәем минем, сөеклем минем, миңа ниемә ул Сөмбелә, үзе сагыз кебек ябышты бит, әйдә икәү биибез дип! Кыз кеше чакыргач, ничек чыкмыйсың инде? Күлмәге дә, үкчәле туфлие дә кирәк түгел! Мин сине,

бары тик сине генә яратам, бала чагыңнан бирле яратам. Хәтерлисеңме, син Тереклектә кер чайкаганда, безнең хоккей алкабыз синең аяк астына килеп төште? Кулларың салкыннан кып-кызыл булган иде, күгәрчен тәпие кебек. «Ярый әле алкагыз бәкегә төшмәде, инешкә чумасың була иде», – дип, алкабызны безгә аттың һәм елмайдың. Үтердең мине шул елмаюың белән, йөрәгемнең иң түренә кереп урнаштың. Мәктәптәге бөтен кызларны синең белән чагыштырып карыйм, тик синдәйләр юк, җаным, юк һәм булмаячак та! – дип, Вәкил шашып-шашып, кызның битләреннән, күзләреннән үбә башлады.

– Мин дә, – дип, көчкә иреннәрен тибрәтеп әйтә алды кыз. – Мин дә сине яратам! – дип, янә кабатлады.

Әй, син, мәхәббәт, беренче мәхәббәт, җаннарны айкап, йөрәкләргә килеп керәсең дә, моңа кадәр тыныч кына оеп, йоклап яткан хисләрне уятып, әллә кайларга, еракларга-еракларга, моңарчы белмәгән, аңламаган дөньяга алып кереп китәсең. Бу дөнья сиңа таныш түгел, ниләр бар анда, син әле белмисең. Бәлки, белмәвең белән бәхетлесеңдер дә, ә әлегә, бүген, бу минутта син бәхетле, юк, син генә түгел, икегез дә шундый бәхетле. Әле генә «хыянәт» дип өзгәләнгән җаның сөйгәнеңнең куенында эреде, тәмам юкка чыкты. Бу дөньяда сез икәү генә бар икән бит, башка беркем дә юк икән. Сандугачлар, инде көз киләсен тоеп, сайрауларыннан туктап, Вәкил белән Асиянең җаннарына күчеп, яратам, яратам, дип чутылдыйлар, бер-берсенә кушылып, йөрәкләр бергә, бер ритмда тибеп, яратам, дип пышылдыйлар. Күктәге ай гына якты нурларын сибеп: «Әй, сез, җүләр гашыйклар! Бу сихри кичне мәңге онытмагыз! Саф хисләрегезгә төреп, йөрәгегезнең түренә, беркем дә үрелеп карый алмый торган почмагына яшереп куегыз. Гомерләрегез буена җаннарыгызны җылытып торачак бу кич! Иң беренче үбешү, вәгъдәләр бирешү! Онытмагыз беренче мәхәббәтегезне, онытмагыз», – дип, моң түгә. Күктәге йолдызлар да сезнең яклы булуларын сиздереп күз кысалар. Әнә, бакчада, хуш ис таратып, тып-тып итеп, алма коела. Бакча тып-тын, шундый тынлык. Хәтта Асия Вәкилнең йөрәк тибешен ишетә:

– Вәкил, ә мин синең йөрәк тибешеңне ишетәм, шундый каты тибә!

– Чынлапмы, чынлап та шулаймы?

– Әллә ышанмыйсыңмы, җаным? Минем йөрәгем дә шулай, нәкъ шулай тибә.

– Асия, вәгъдә бир син миңа. Беркайчан да, беркемгә дә мин сине көнләмәм диген. Бер-береңә ышанмагач, нинди мәхәббәт була инде ул?!

– Ярар, Вәкил, гафу итә күр мин җүләрне, яме. Зинһар, кичерә күр. Ә син иртәгә Казанга китәм, дисең. Кайда урнашасыңны, укырга кая керәсеңне хәл иттеңме соң?

– Асия, минем хыялым – музыкант булу. Әти мәрхүмнең мине «әргән тоткан итеп» күрәсе килмәгән иде. Әнине беләсең инде, үзеңә кара, улым, үзеңә гомер итәсе, яраткан, теләгән җиреңә кер, диде. Әле мин укырга кереп урнашканчы әйтмичәрәк торам. Әгәр имтиханнарны бирә алмасам, уңайсыз булыр. Ә син ни эшләргә уйлыйсың соң? Янсуарга бармыйм, дисең инде? Син дә Казанга килсәң, бик яхшы булыр иде. Гел бергә булыр идек.

– Белмим, белмим, әти белән әни аяк терәп, каршы төшәләр. Ә минем китәсем килә, шәһәрдә эшкә урнашып, аларга булышасым килә.

Тик алар мине аңламыйлар. Син әле бала гына, калада юкка чыгарсың, имеш. Аларның рөхсәтеннән башка китсәм, әти-әнинең хәер-фатихасын алмыйча... – Асия төртелеп туктап калды.

– Анысы шулай инде, синең әти-әниең – авылда дәрәҗәле, билгеле кешеләр. Аларны рәнҗетеп чыгып китү ярамас. Безнең әтинең ниндилеген беләсең. Аның явызлыгын бөтен авыл белә, гомер буе әнинең канын эчеп яшәде. Үлеме дә үкенечле булды. Ә мин аны барыбер сагынам. Сеңлем Нурия белән икебезгә гомер бүләк иткән кеше бит ул. Ач-ялангач итмәде. Кансыз кеше иде, ләкин ул безнең әти иде. Шундый холыксыз булып тууына ул, бәлки, гаепле дә түгелдер. Аңа бирәр явыз кешенең җаны иңгәндер кебек тоела миңа. Кем белә инде аны? Шул турыда уйланам мин. Төннәр буе уйлап ятам. Шуңа күрә әти-әниеңнең рөхсәтеннән башка чыгып китмә инде син, ничек булса да аларның хәер-фатихасын алырга тырыш.

Алар аерылышканда, сызылып таң беленеп килә, яңа таңны каршылап, берсен-берсе уздырып, әтәчләр кычкыра башлаган иде инде.

– Керим инде, – диде Асия, – әни уянып, сыер саварга чыкканчы кереп ятарга кирәк. Төне буе кайда йөрдең дип ачуланырлар, – дип, Асия урыныннан кузгалды.

– Минем синнән аерыласым килми, – диде Вәкил, – гомерем буе синең янында булыр идем, чын әгәр!

– Хуш, Вәкил, сау булып тор. Бәлки әле мин дә синең артыңнан ук Казанга чыгып китәрмен. Син дә, абый да анда булгач, шәһәр миңа тагын да якынрак, яктырак булып тоелыр.

***

Асиянең күзенә йокы кермәде. Иртәгесен абыйларын шәһәргә – зур тормыш юлына озатасы. Вәкил белән бергә китәрләр инде. Ә Асия кала. Инде унбиш яшенә җитеп тә, әле кайда укырын белми. Әнә Вәкил дә, әти-әниеңнең фатихасын алмыйча чыгып китә күрмә, ди бит. Әйе шул, әти-әнисе – авылда дәрәҗәле кешеләр. Вәкил бүре ботарлаган явыз әтисен әле һаман да сагынып яши. Әти минем музыка буенча китүемне теләмәгән иде, шуңа күрә аның рухын рәнҗетәсем килми, ди.

Әнисе уянып чыкты, чиләкләр чылтыраган тавыш ишетелде. Асия торып чыкканда, әнисе инде сыер саварга утырган, чиләк төбенә зеңгелдәп, сөт төшкәне ишетелә. Әнисе әкрен генә сыерны шелтәләп ала:

– Түчә, тукта инде, чабаланма, савып бетерим, рәхмәт төшкере. Болыннарга чыгып, тагын сөт җыясың бар лабаса! – дип, әллә сыер белән, әллә үз-үзе белән сөйләшә.

Кыз, абзар капкасына сөялеп, әнисенә карап басып тора. Матур аның әнисе, зәп-зәңгәр күзләре әллә күк йөзенең зәңгәрлеген алганнар инде? Алар әллә нинди, гел еларга гына торалар кебек. Күзләре кебек зәңгәрсу юка яулыгы йөзенә килештереп, матур итеп бәйләп куелган. Кыз әнисенең эшсез торган вакытын хәтерләми. Аның көндезләрен ятып торганын да күргәне юк. Биш баласын, авыру ирен, ун ел буе акылын югалтып, улы белән килене кулына калган каенанасын кеше көнләшерлек итеп тәрбияләде. Авыл халкы аптырый иде, ничекләр җитешә бу Нурания? Өйләрендә шылт иткән тавыш

юк. Балаларын гөл итеп киендерә. Барысы да яхшы укыйлар. Шулай инде, әниләре нинди, балалары да шундый. Бала-чага өйдәгесен күреп үсә инде ул. Аларны, алай бул, болай бул дип, үгет-нәсихәт белән генә үстереп булмый. Өйдә тәртип булганда гына, балалар тәртипле булып үсәләр. Аннан соң аларны махсус тәрбияләп үстерергә вакыты бармыни аның?

Озак карап торды Асия әнисенә. Юк, юк, ул әнисен рәнҗетеп чыгып китмәячәк. Аннан соң, әгәр бу эшне эшләсә, Вәкил ни әйтер?

Инде әнисе сыерны савып бетереп килә. Чиләккә сөт зеңгелдәп түгел, шаулап төшә башлады. Әнисе, урындыгыннан кузгалып, ишеккә таба атлаганда, моңсуланып, капка баганасына сөялеп басып торган кызын күреп алды.

– Әнекәем, кызым, ник шулай иртә торасы иттең? Кичә бигрәк соң кайттың түгелме? Бар, кереп ятып тор, йокың туймагандыр.

Асия дәшмәде. Әнисенең кулыннан сөт тулы чиләген алып, сепарат аертырга кереп китте. Чиләк өсте болыт кебек күбекләнеп тора, үзеннән шундый тәмле ис килә.

– Ашарга әзерләп, абыеңны уятырга кирәк. Кичтән этиең сөт машинасын белешеп кайткан иде. Күкчәгә кадәр Инсаф абыең белән барырсыз, дигәниек.

Асия аптырап калды, тукта, чү, әнисе «барырсыз» дип әйтте түгелме? Асия куе керфекләр уратып алган өмет тулы күзләрен әнисенә төбәде.

– Ник, кызым, әллә кире уйладыңмы? Казанга китмәскә исәпләдеңме? Әгәр Янсуарга барып укырга уйласаң, без этиең белән бик шат булыр идек.

Тукта, кыз ялгыш ишетмиме, эти-әнисе Казанга китәргә рөхсәт бирә түгелме соң?! Ул, тораташтай катып калган хәленнән чыгып, чиләген сепарат өстәленә куйды да әнисен кочып алды.

– Әни, рәхмәт сезгә, мин сезнең йөзегезгә беркайчан да тап төшермәм. Чын мәгәр, беркайчан да!

Аннан соң сикерә-атлый, өйләренә кереп китте. Вак-төяк әйберләрен тиз генә җыйнады. Сөт машинасына өлгерергә кирәк. Ләкин әнисе, бар әйберен җыйнап, үтүклисен үтүкләп, пөхтәләп, юлга әзерләп куйган иде инде.

– Әни җаным, нинди генә рәхмәтләр әйтим сиңа, тәки этине күндергәнсең бит. Ничекләр итеп кенә үгетли алдың икән?

Аяк очларына басып, этисен уятмаска тырышып, кече якка чыгып барганда, этисе тамак кырып куйды:

– Үз дигәнеңә ирештеңме? Бар соң, чыгып китеп кара, азрак Лаеш шулпасы чөмерерсең. Тик Янсуарга укырга барырга соң булыр. Кара аны, калада нәсел черетеп, азып-тузып йөрсәң, авылдашлар каршында безнең йөз суыбызны каралтсаң, авылга кайтып керәсе булма, сиңа басу капкасы ук ябык булыр. Әниеңә рәхмәт әйт. «Китеп карасын соң, бик елый бит бала, әгәр кире әйләнеп кайтса, РОНО мөдире белән сөйләшерсең, мәктәпкә алырлар әле», дип, сине яклады. Әнә, Казанда идән юарсың, рәхәтеңә чыдый алмасаң.

Әтисе башка бер сүз әйтмичә, тынып калды.

– Ярар, эти, ярар, рәхмәт сиңа, яме. Мин беркайчан да сезнең йөзегезгә оят китермәм, эти, – дип, Асия әнисе җыеп куйган киемнәрен алып, ишегалдына чыгып китте. Әйберләрен барлады. Юк, әнисе бер нәрсәсен

дә онытмаган. Бар булган кием-салымын, пөхтәләп гәҗиткә төреп, ятьмә сумкасына салып куйган. Асиянең чыгып китәргә дип, яшереп куйган әйберләрен дә табып алган әнисе.

– Кызым, әтиең уянганмы, аны-моны әйтмәдеме, бик каты бәрелмәдеме?

– Юк, әни җаным, әйбәт кенә йөрергә кушты.

– Ярар ачуланмагач, – дип, әнисе сүзен тәмамламакчы иде, – аннан соңында, – дип дәвам итәсе булды. – Кызым, мин инде сиңа бу сүзләрне әйтмәм дә дигән идем, үзең дә беләсең булыр. Анда Казанда итәк-чабуларыңны җыеп йөри күр, балакаем. Егетләр сүзенә карап, хараплар була күрмә. Йөзеңә кара ягылса, мәңге бәхетсез булырсың. Кеше теленә менә күрмә. Андый-мондый хәл булса, мин әтиеңә нәрсә дип әйтермен? Үзеңне дә, мине дә бәхетсез итәрсең.

Асия әнисенең куенына сыенды.

– Әни җаным, ни сөйлисең син, ниләр генә сөйлисең соң син, әни?! Минме ул эшкә баручы, сезнең, минем кадерлеләремнең, йөзенә кара ягучы?! Атна саен кайтып йөрермен, сагынырмын бит мин сезне, әни, өзелепләр сагынырмын.

Әнисенең зәңгәр күзләреннән кызын яратуы, аның өчен хәсрәтләнүе зәңгәр моңга әйләнеп, күз яшьләренә кушылып ага иде.

– Әйдә, абыеңны уятыйк, тиз генә чәйләп алырсыз да кузгалырсыз. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

Әзерләнеп, ашап-эчеп чыгып киткәндә, әти-әнисе капка төбенә чыгып озатып калдылар.

– Хәерле юл сезгә, хәерле сәфәр! Инде бездән аерылып, ялгыз башыгыз гомер итәргә, үзегезнең гомер китабын язарга зур юлга чыгып барасыз. Юлларыгыз уң булсын, балалар! Нигезегезне, әти-әниләрегезне, эне-сеңелләрегезне онытмагыз! Без сезне сагынып көтеп торырбыз, хатларыгыздан өзмәгез.

– Кызым, – диде әтисе, Асия янына килеп. – Бигрәк тә яшьсең әле, балалыгыңнан яңа чыгып киләсең. Әле канатларың да ныгымаган, ялгыз очар өчен көчле канатлар кирәк. Ярый әле, яныңда абыең бар. Туганлык җепләрен өзә күрмәгез, бер-берегез өчен терәк булып яши күрегез, кызым. Авылдан без сезгә ярдәм итеп торырбыз, хәлдән килгәнчә инде, хәлдән килгәнчә. Син минем катырак әйткән сүзләргә үпкәли күрмә, синең өчен борчылып әйтүем. Улым, сеңлеңне ташлама, күз-колак була күр. Бәхетле булыгыз!

***

Казан үзенең урам тулы халкы, дыңгыр-дыңгыр килеп йөргән трамвайлары, троллейбуслары, ара-тирә узып торган машиналары белән каршы алды үсмерләрне.

Барысы да каядыр ашыга-кабалана. Әнә абыйсы да:

– Асия, миңа бүген тиз генә институтка барырга кирәк. Син Яңа Бистәгә Әхәт бабайларга үзең генә бара тор инде, – дип, институтка китеп барды.

– Ярар, абый, – диде кыз, зур калада ялгыз башы басып калуыннан куркып. Аның Казанга икенче тапкыр килүе иде. Беренче килгәндә, Әхәт абыйсының балалары Фирая, Фәрит белән елга порты яныннан кәҗәләренә әрекмән, чүп үләннәр җыеп йөргәннәрен хәтерли. Аннан соң шәһәргә

кергәндә, сул якта күренеп калган аэропорт һәм самолётлар исендә.

Авыл өстеннән зәңгәр күкне ярып, кошлар кебек очкан самолётларны җирдә күрү бәхетенә ирешкән кыз, авылга кайткач, дус кызларына сөйләгән иде:

– Ул самолётлар шундый да зур икән, күктә генә шулай кечкенә булып, кошлар кадәр генә булып күренәләр. Ә җирдә ул корыч кошлар әкәмәт тә зур икән. Үз күзләрем белән күрдем, валлаһи, билләһи менә.

Әле Казанны бер мәртәбә дә, бигрәк тә күкне ярып очкан самолётларны күрмәгән балалар аһ итәләр.

– Ялганлама сана, алар өй хәтле булгач, тимер булгач, ничек күккә күтәрелә алалар соң? Алар кош түгел, тилгән түгел бит.

– Белмим шул, – ди Асия. – Мин белмим, ләкин аларның юл буйлап йөгергәннәрен, аннан соң очып киткәннәрен автобус тәрәзәсеннән үзем күрдем. Әтидән, алар канатларын какмыйча гына ничек оча алалар соң, дип сораган идем, эти әйтә: «Аларның моторы бар, шуңа керосин салалар да, мотор эшли башлый. Аннан соң шул безнең йорт хәтле самолётны күккә күтәрә», – ди.

– Синең әтиең барысын да белә инде ул, – ди балалар. – Аның кебек күп укыган кеше безнең авылда юк та әле ул.

– Карагыз әле, – ди күрше кызы Хәмидә, – самолётлар болытларга ышкылып-ышкылып оча торгач, аларның канатлары тузып бетә торгандыр инде, имә?

Хәмидә Асиядән өч яшькә кечерәк, ул әле икенче сыйныфта гына укый.

– Юктыр, безнең укытучы апа әйтә, болытлар шул ук яңгыр, кар инде, ди. Алар йомшак булгач, самолет канатын туздырмый инде ул.

– Әй, самолётка утырып, күкләргә менсәң иде ул, кызлар, име? Авыл өстеннән болытлар арасында очсаң иде, язларын өздереп-өздереп сайраучы тургайлар кебек. Юк, булмас, анда бай кеше балалары гына оча торгандыр. Алар бик бәхетледер, – дип, Асия берничә җиреннән ямаулы күлмәгенең ямауларын яшеребрәк куйды. Инде аягындагы сандалилары да искереп кечерәю сәбәпле, әнисе аларның башларын кисеп алган, һәм кызның бармаклары иреккә чыккан иде.

Менә шуларны искә төшерде Асия вокзалга кайсы якка китәргә икәнен уйлап, Арча кырында басып торганда. Абыйсы кулына язып тоттырган кәгазь кисәген дә кая куйганын онытан иде. Югыйсә абыйсы әйтте:

– Асия, адресымны югалта күрмә, мин сине озатып йөри алмыйм. Сиңа бит кичә генә китәргә рөхсәт бирделәр. Зинһар өчен, игътибарлы була күр, – диде. – Иртәгә мин синең яныңа килермен, сине кай тирәгә урнаштыру турында туганнар белән сөйләшербез, – дип, хушлашып китеп барды.

Бабасының энесе Әхәт абыйлары вокзал янында гына тора. Элек торган баракларын сүткәч, ике бүлмәле фатир алганнар иде. Водоканалда эшләгән абыйлары бишенче катта, ә әнисенең энесе икенче катта яши. Адресларын белә Асия, ә анда бара торган трамвай номерын онытты. Әллә дүртенче, әллә алтынчы.

Тукта, әнә бер татар апасы килә түгелме?

– Апа, әйтегез әле, вокзалга кайсы трамвай белән барасы?

– Чего тебе надо, чёртова деревенщина, чаплашка! – дип акырды татарга

охшаган юан хатын. Асия, йөзенә шаулап кан йөгергәнен тоеп, үзенең бу хатынның ачуын чыгарырдай нинди сүз әйтүен аңламыйча, аптырап калды. Алансуда аннан берәр кешенең кайда торганын сорасалар, Асия яки берәр авылдашы, һич кыенсынмыйча, кирәк җиргә хәтле озатып куяр иде. Ә монда тик торганда, «чаплашка» дип сүгеп аттылар. Деревенщинасы авыллыгына ишарә булса, «чаплашкасы» ни дигән сүз икән инде аның? Рус теле укытучысы Рәис абыйлары: «Асия, синең рус телең начар түгел, кагыйдәләрне дә яхшы беләсең», – дигән иде диюен. Ләкин «чаплашка» дигән сүзнең мәгънәсен белми. Андый сүзнең бөтенләй дә очраганы булмады. Хәер, авылда телевизор да юк, руслар да ике генә гаилә: Михайло абый гаиләсе белән Николай абый гаиләсе, алары да татарча сөйләшәләр. Кайдан беләсең инде аны дип уйлады кыз. Һәм кая барырга белмәсә дә, ятьмә сумкасын, чемоданын күтәреп, билгесезлеккә таба атлады. Каршысына очраган кешеләрдән сорарга оялды, тагын сүгеп китәрләр дип тә курыкты. Озак барды, инде менә поезд юлына килеп чыкты. Өйлә вакыты җитте булса кирәк, кояш кыздыра. Һавасы да монда авылдагы кебек хуш исле, тәмле һава түгел. Бу ис аңа бөтенләй дә таныш түгел. Шәһәр исе кызның сулышына каба. Көне дә, җәй ахыры, димәссең, әллә нинди эссе бер көн булды. Кызның йөзеннән тир тамчылары тәгәри дә тәгәри. Инде туктамый ага башлады. Тирләү бер хәл, эчәсе килә Асиянең. Өйләрендәге алны-ялны белми кайнап торган җиз самавырлары күз алдыннан китми.

Әлсерәгән кыз тукталыштагы тимер эскәмиягә килеп утырды. Эссе кояш астында тәмам кызган утыргыч ботларын пешерде. Әтисе әйткән «Лаеш шулпасы» шулайрак башлана микәнни? Кызыктыргыч шәһәр тормышы кызган тимер утыргычы белән кыздырудан башланды бит әле. Беренче көннән үк, өйдәгеләрнең юрамышларын раслап, тилебәрән орлыгы ашаган сарык бәтие сыман Казан урамында кая барырга белми аптырап тор инде, йә! Җебегән нәрсә! Нәрсә, ул бер тиле хатынның сүзеннән хушсыз калдымыни соң әле? Деревенщина, имеш. «Авыл гыйбады» дигән сүз бит инде ул. Әгәр авыллар итен, икмәген үстереп бирмәсә, ул хатын да кышлаган тана кебек симермәс иде. Шуның сүзеннән коелып төшеп, аптырап утырган мин кем соң?

Асия кипкән иреннәрен ялап куйды да үзенә таба килүче егетне күреп, русчалатып дәште: «Ыскажите, пожалыста», – дип сүз башлады. Шактый культурный килеп чыкты бит әле бу. Егет тә киң итеп елмайды. Кыз янына тимер эскәмиягә килеп утырды:

– Йәле, йәле. Белик әле бу чибәр кызга ниләр кирәген.

– Сез татар егете икәнсез. Миңа вокзал ягына барырга кирәк иде. Кайсы трамвайга утырасы икәнен белмим.

– Әйдә, сеңлем, әүвәл танышыйк әле. Мин Газиз исемле булам. Сине кем дип белик? Күрәм, Казанга беренче тапкыр килүең, ахрысы.

Асия кинәт каушап калды. Бәрәңге чүпләгәндә яргаланып беткән куллары, итәге бөгәрләнеп өлгергән бөрчекле күлмәге, Казан урамнарында йөри-йөри каралып беткән брезент чүәкләре өчен оялды. Тыгыз автобуста төелешеп килгәндә, иртән генә агарткан ул чүәкләр тапталды инде. Ә бу егет энәдән-җептән генә киенгән кебек. Киемнәре матур, килешле. Кыска җиңле зәңгәрсу күлмәк кигән. Чалбар балаклары ипи кисәрлек итеп үтүкләнгән.

Аягына кигәне ялт итеп тора. Кара эш тимәгән куллары, тырнаклары соң...

Асия үзе дә сизмәстәй, кулларын йодрыклап, тырнакларын яшерде.

– Асия мин, Асия исемле.

– Кайсы вокзал кирәк соң сиңа? Тимер юл вокзалымы, аэровокзалмы, автовокзалмы?

– Миңа автобуслар вокзалы кирәк. Аэропорт янындагы вокзал. Безнең шул тирәдән Митрофанга әрекмән җыйганыбыз бар.

Егет тагын тигез ак тешләрен җемелдәтеп көлеп җибәрде.

– Митрофан дигәнегез әрекмән ашыймыни?

– Ие инде. Шундый яратып ашый. Эт эчәгесен дә ашый әле ул.

– Кызык. Эт эчәгесе нәрсә соң ул? Этнең эчәгесен ашыйлармыни? Ишеткәнем юк иде.

– Ю-у-у-у-к инде. Эт эчәгесе түгел ул. Шундый үлән ул. Уралып-уралып үсә. Шәмәхә чәчәк ата. Нигә ул үләнне шулай атаганнарын белмим.

– Алай икән. Ә нигә Митрофан дигәнегез үлән ашый? Ипиегез юкмыни?

– Юләрме соң син, Газиз? Ничек инде Митрофанга ипи ашатасың, ди? Ипи үзебезгә дә җитми әле. Ипи салганда бәрәңге кушабыз. Шулай итсән, бәрәкәтлерәк була. Кәҗәгә ипи ашаталар, ди, берәүләр.

– Ә-ә-ә, кәҗәмени ул? Мин бит Митрофанны кеше дип торам. Эт эчәгесе ашый дигәч, бөтенләй аптырадым. Мин әйтәм, бу кыздан ераграк булырга кирәк. Эчәгесен ашагач, этнең үзен нишләтәләр икән, дип уйлыйм. Андый үлән турында ишеткәнем дә юк иде, – дип, егет көлеп җибәрде.

Асия дә егеткә кушылып көлде.

–Үзем дә инде. Башта ук Митрофанның кәҗә икәнен әйтмәдем. Минем балачакта Казанга килгәнем бар иде. Абыйларның кәҗәләре бар. Митрофан. Кәҗәгә шундый кушамат такканнар. Абыйның балалары белән Елга порты янындагы аланлыктан әрекмән, эт эчәгесе җыя идек. Ә анда ничек барасы икәнен онытканмын. Ул чакта бала гына идем әле мин.

– Хәзер зур үстеңме инде?

Асия күзләрен тутырып, егеткә карады.

– Миңа инде 15 тулды. Казанга эшкә керергә дип килдем. Аннары кичке мәктәпкә укырга керәчәкмен.

– Хәзер мин сиңа абыеңнарга ничек барасын аңлатам. Бөтенләй икенче якка киткәнсең бит син, Асия. Елга портына җиткәч, абыеңнарны табам дисең инде син?

– Табам. 5 катлы йортта яшиләр алар. Мехчылар урамында. 1нче йорт, 16 нчы фатир. Анда барып җитсәм, тучны табам инде.

– Алай икән. Күп катлы йортта Митрофан кайда яши соң – балконнарындамы? – Газиз тагын көлеп җибәрде.

– Ай, белмим шул. Элек сарайда тора иде. Хәзер кайда тора торгандыр.
Газиз Асияне троллейбус тукталышына кадәр озатып куйды:

– Ярый, сеңлем, хуш-сау бул. Уңышлар юлдаш булсын сиңа.

Казан белән, гомере шунда узачак шәһәр белән елый-елый таныште кыз. Тукайның «Пар ат» шигырен гел кабатлап йөрде. Хыялында балкып, үзенә дәшеп торган башкала мәрхәмәтсез юан хатыннары, миһербанлы чибәр егетләре белән каршылады. Умырып-умырып акча эшләп, эти-

әниләренә булышу турындагы хыяллары түргәрәк күченде. Тәмам чәлпәрәмә килде дип булмый әле ул хыялларны. Чигенделәр генә.

Алар урынын кайда яшәргә, ничек тамак туйдырырга, өскә нәрсә кияргә дигән көндәлек ихтыяҗлар яулап алды. Әти-әнисен тыңламады шул.

Асия, барыбер, авылга кайтмаячак. Казанда калачак. Әгәр тугызынчы сыйныфка алсалар, төнлә берәр кибеттә идән юар ул. Тамагын туйдырырлык кына эш табар әле үзенә.

– Где прописка? – Эх, шушы аяусыз сүзләрне! Каян алсын ул прописканы кыз? Сигезенчене бетергәнлегенә таныклыгы – аның пропискасы. Ике генә дүртлесе бар. Юк шул, таныклыкны кулларына да алып карамыйлар. Эшкә урнашу да хыял булып кына кала. Ярый әле, абыйсы институтка керә алды. Ул зур кеше булачак.

Асия Казан урамнарында килмешәк хөкемендә йөреп тора. Мәшәкатьләнеп эзләп тапкан Әхәт абыйларында да кызга урын юк икән.

Әти-әнисе авылга кире кайт дип, юкка гына үгетлиләр. Абыйсы да алар сүзен сөйли. Авылдан чыгып киткәндә, Вәкилне күрмәде. Менә кемнең үгет сүзе Асиягә тәэсир итә алыр иде. Нәрсәдер булган инде аңа. Асия аны белми китте.

**Дүртенче бүлек**

Латыйфа йокысыннан уянып, йомшак ястык, түшәкләр өстендә озак уйланып ятты. Үзенең заяларга узган гомерен җәлләп, улы Вәкилнең аның язмышын кабатлап, җаны сөймәгән кеше белән яшәвен, өенә кайтып керәсе дә килмичә, төн җиткәнче клубта юк эшен бар итеп утырып, соң гына өйгә кайтып керүен, ә кайтып керүгә хатынының елап, ирен таларга ябышуын һәм өйдәге бетмәс-төкәнмәс тавыш...

– Йа Раббым! Булса да булыр икән шул кадәрле сабырсызлык, әдәпсезлек, затсызлык! Латыйфаның бәгырьләреннән өзелеп төшкән Вәкилен нинди генә сүзләр белән битәрләми, затсыз килен! Әллә ниткән, Латыйфа гомерендә дә ишетмәгән сүзләр белән русчасын-татарчасын кушып сүгә.

– Син клубта тегенең белән, моның белән... Әстәгъфирулла!

– Тукта, Сөмбелә, әнине уятасың. Минем бит эшем шундый. Менә авыл яшьләре белән концерт программасын әзерләдек. Көндез эшләп булмый бит ул эшләрне! Үзең беләсең, яшьләрнең кайсы эштә, кайсы укуда.

– Ә син минем турыда, туачак балаң турында уйламыйсыңмы соң, оятсыз зат! Мин чәчәктәй яшьлегемне харап итеп, шушы Алла каргаган авылга килдем. Ни суы, ни бәдрәфе юк. Ни газы! Уф, уф, уф! Кемгә кияүгә чыктым мин! За колхозника! Ужас! Нинди биюче идем бит мин! Китәм, иртәгә үк китәм! Живи в своей дыре, со своей мамой и сестрой-деревенщиной! И үзеңнең сарыкларың, сыерларың белән. Иртәгә үк китәм, – дип кабатлый. Әгәр туачак балаң кирәк булса, син дә минем белән китәргә тиеш. Обязан. Там у нас трёхкомнатная ленинградка! Ванная, душ! Или оставайся. И забудь про нас!

– Туктыйсыңмы син, Сөмбелә, юкмы?! Әгәр китәсең килсә, юлыңа ак җәймә, – дип пышылдап кына әйтә улы. – Әни белән Нуриягә тел тидерәсе

булма. Алар хәтле булырга әле бик күп кирәк сиңа. Минем әнидә булган сабырлык, әтигә булган хөрмәт мең хатын-кызга җитәрлек. Мин бит сине барып алмадым, үзең кайттың лабаса...

Менә бу ызгыш, җәнҗал көн саен кабатланып тора. Бер көн калмыйча.

Кичә иртән маллар карарга чыккач, улына әйтте Латыйфа:

– Вәкил! Тормышыңның бер дә рәте-чираты юк. Әллә, улым, калага китеп карыйсыңмы соң? Хатының әти-әнисе янында азрак кеше рәтенә кермәсме? Сине җәлләп, йөрәкләремнән каннар тама, улым. Сөмбеләне дә кызганам. Ул бит, улым, калада үскән, безнең тормышны белми. Авыр аңарга монда, улым! Рәнҗетмә хатыныңны. Туачак балаң хакына гафу итә күр! Бәлки, балагыз тугач, үзгәрер, Алла боерса. Бәхетең булсын, улым! Минем язмышны сез дә кабатламагыз. Кит син Казанга. Әгәр авылда каласы булсагыз, Нурия белән мин комачауласак, без әбиеңнәр өенә күченербез. Уйлап кара әле.

– Әни, син нәрсә, минем йортка керүемне телисеңме? Миңа нибары унсигез яшь тула. Мин хәзер Сөмбеләгә йортка кереп, гаепле кеше кебек яшәргә тиешме, әни?!

– Шулай, улым, гомереңдә бер ялгыш адым ясыйсың да соңыннан үксеп еласаң да юк. Ни эшләмәк кирәк? Балаң ятим үсмәсен дисәң, барысына да түзәсең инде ул. Үзең күреп тордың лабаса, сез сыңар канат астында үсмәсен дип, мин күпме тилмердем. Ялгыз канат белән кагынып очып булмый, балам. Шуңа күрә мин сиңа башка киңәш бирә алмыйм. Үзеңә кара! Ләкин болай яши алмыйсың, Нурия белән безгә дә авыр! Һай, авыр! Тавышлы йорттан фәрештәләр кача. Шуңа күрә, үзегез хәл итегез инде сез, балам. Син ничек әйтсәң, шулай булыр. Минем бит сезне бәхетле итеп күрәсем килә. Сине дә, Нурияне дә шундый бәхетле итеп күрәсем килә минем, улым! Матур итеп, бөтен йоласына туры китереп, кыз сорап, никах мәҗлесләре үткәреп, туйлар ясарбыз дип уйлаган идем дә бит... Тик ни эшләмәк кирәк, бигрәк кеше хурларына калдык. Авылда кеше теленә мендек. Сөмбеләсе дә: «Әгәр миңа өйләнмәсә, көчләде», – дип, төрмәгә утыртам мин аны, дип янады бит. Мин Вәкилдән йөкле дип, авылда даныңны чыгарды. Әйтми калса, ни була инде? Болай да авыл хатыннары өйләнешкән көннән аен-көнен санап тора...

Латыйфа алъяпкыч итәген йөзенә күтәреп, күз яшьләрен сөртеп алды. Вәкил башын иеп, абзар капкасына сөялеп, озак торды.

– Әни, гафу ит мине. Мин ул көнне беренче тапкыр коньяк эчтем. Сөмбелә алып кайткан иде. Кыстый-кыстый эчерде һәм...

Вәкил төртелеп, тукталып калды. Соң инде. Нишләмәк кирәк?

– Мин, әни, бернәрсәне дә үзгәртә алмыйм. Шундый тормыш турында хыялланган идекмени без?

– Асия белән дисеңме?

– Әйе, әни, Асия белән. Яңа елны бергә каршыларбыз дигән идек, ләкин менә бу хәл килеп чыкты. Әни, ул мине беркайчан да гафу итмәячәк инде. Их, әгәр тормышны өр-яңадан башлап булса икән ул!

– Юк, улым, ул кыз кеше тормышын бозуга мәңге бармаячак. Синең балаңны ятим итеп, Асия үз бәхетен табар, дисеңме? Оныт инде син аны, мәңгелеккә оныт. Бәлки әле тормышыгыз рәтләнеп китәр. Балагыз тугач,

Сөмбелә дә үзгәрер. «Өметсез шайтан», – ди, улым. Өметеңне өзмә.

Шундый авыр сөйләшү булган иде кичә Вәкил белән әнисе арасында. Инде бүген тагын Вәкил эштән кайтуга, шул ук галәмәт башланды. Латыйфа үзенең йоклап ятмавын сиздереп, бисмилласын әйтеп, икенче ягына әйләнеп ятты.

– Әнине уяттык, тагын әнине уяттык, – диде Вәкил, уңайсызланып.

– Ну и что, заснёт ещё. Если маму жалко, иди, анаңны кочаклап ят!

Вәкил дәшмәде, ишетеп ятты Латыйфа, улы торып китте дә хатынына:

– Иртәгә үк Казаныңа илтеп куям. Баламны ташламам. Әзер булып тор. Мин бу сүзләрдән соң синең белән бер минут та тормаячакмын. Шушы кадәр оятсыз булырга кирәк бит. Нинди сүзләр сөйлисең.

Вәкил ишекне акрын гына ачып чыгып китте.

Сөмбеләсе үкереп елап калды.

Мич артындагы зәңгәр җирлеккә кызыл чәчәкләр төшкән чаршау артында тыелып кына Латыйфа елады.

– Йа Раббым, бер Аллам! Ни ди бит, анаңны кочаклап ят, – ди. Нәрсә сөйли бит, ничек телләре әйләнә?

Латыйфа үзе каенанасын түр башындагы сәкедә, йомшак ястык, түшәкләр өстенә ап-ак җәймәләр җәеп, тәмле ризыклар ашатып, тәрбияләп, соңгы юлга озатты. Мишарабның әти-әнисе киленнәренә рәхмәтле булып, хәер-фатыйхаларын биреп, Алансуның чәчәкле зиратына әти-әнисе янына барып урнаштылар. Үләренә берәр көн кала каенанасы:

– Кызым, мин сиңа килен дип әйтә алмыйм, кызларымнан да якын син миңа. Сиңа истәлеккә колак алкаларымны бүләк итәсем килә, минем төсем итеп киярсең. Мин бүгеннән калмам, китәрмен инде, – диде.

– Рәхмәт, әнкәй, бик зур рәхмәт сиңа. Мине шулай үз иткәнең өчен рәхмәт! – дигән иде Латыйфа. – Тик әллә ниткән үлем турындагы сүзләр сөйләмә инде. Синнән башка өебез буш калыр. Йортыбызның нуры, өебезнең күрке бит син, әнкәй, җаным!

– Әй, кызым, мин бит синең ничек газапланып гомер иткәнеңне күреп торам. Безгә килеп, тәмуг утларында янып яшәдең ләбаса. Кичерә күр инде безне. Минем улымны да гафу ит. Шундый булып туганына ул гаепле түгелдер күк миңа. Аңа берәр явыз кешенең җаны иңгәндер дә, шул таштай җаны минем улымны әшәкелеккә өндәп торгандыр. Ни генә булса да, бала бит. Бәгырь ите. Җаным тыныч булып китмим, Латыйфа. Алай дисәң, балаларың үстеләр инде, калкындылар. Бигрәкләр дә тәртипле, матур булып үсеп киләләр, Аллага шөкер! Алар Мишарабтан сине рәнҗеттермәсләр.

– Әнкәй, җаным! Бер дә кайгырма. Мишараб та ул кадәр үк ерткыч түгел инде. Аның да әйбәт яклары да күп. Ач-ялангач итмәде. Мал таба белде. Явыз дигәч тә... – дип, каенанасын тынычландырган иде Латыйфа.

– Юк, Латыйфа, мин барысын да күреп тордым. Дәшмәгәч тә... Рәхмәт сиңа, өйдәгесен урамга чыгарып түкмәдең. Улымның начар якларын яшереп яшәдең. Тик без капчыкта ятмый шул. Инде менә картымны тәрбияләп, карап соңгы юлга озаттың. Әткәй-әнкәй дигән сүзне тәсбих урынына тездең. Без сиңа хәер-догабызны калдырып китәбез. Вәкилеңә үзең шикелле сабыр, уңган-булган, кече күңелле, кешелекле хатын насыйп итсен, Ходаем.

Икенче көнне Латыйфа кулында җан бирде каенанасы.

Ә үз килене: «Бар анаңны кочаклап ят!» – ди. Бу соңгы сүзне ирләргә әйтергә ярыймы инде? Улы кайларда йөри икән, Раббым, бер Аллам! Өенә кайтып керәсе килмичә, йортсыз-җирсез кеше кебек урамда эт типкесендә йөрсен инде, йә. Ни эшләп кенә бетәрләр? Иртәгә үк Нуриясе белән әбиләре йортына күченерләр. Бәлки, икесе генә калсалар, тормышлары рәтләнер. Ипле генә яши башларлар. Их! Асия белән бергәләп укырга китмәделәр.

– Әни, сине калдырып китә алмыйм, әтинең үлеменнән соң сиңа бик авыр булыр, – дип, бер елга авылда калырга булды бит Вәкил. Аннан соң бу клубына эшкә керүе тагын! Сөмбеләсе дә тәмам сагызлар булып ябышты. Чистый ташы кызган булган икән. Үзеннән биш яшькә кече егеткә, гомерендә хәмер кабып карамаган, әле үсмерлектән генә чыгып килүче егеткә коньяк эчерт инде син. Тегесенең дә егет буласы килгәндер, күрәсең!

Латыйфаның күзенә йокы төшмәде. Күз яшьләре чишмәдәй акты да акты. Җанына җыелган рәнҗешләрен, кайгы-хәсрәтләрен юып төшерергә теләгәндәй акты.

Әле тышта караңгы иде. Латыйфа торды да, юынып, маллар янына чыгып китте. Урамда шундый рәхәт иде. Инде кышкы суыклар сынган. Һавадан яз исе килә. Ярата Латыйфа март ахырларын. Инде түбәләргә рәт-рәт булып тезелгән боз сөңгеләре очыннан тамчы тама. Тып-тып... Өйлә вакытында бигрәкләр дә тиз тыпырдаша ул тамчылар, кышның күз яшьләре. Тиздән-тиздән туган якларын сыктап-сагынып, бәбкәләр үстерергә, нәселләрен дәвам итәргә күчмә кошлар кайтыр. Аларның күбесе Ялантау болынына, куәтле канатларына ял бирергә төшәрләр. Йорт казларын ымсындырып, аларның да язгы салкынча һаваны көчле- куәтле канатлары белән телә-телә очкан чакларын исләренә төшереп кайтыр ул яз кошлары.

Әй, шундый да рәхәт булыр инде. Ә сентябрь ахырларында Латыйфаның оныгы: «Мин тудым, мин бу якты, матур дөньяга яшәр өчен тудым. Әти белән әнинең ул гөнаһларында минем ни эшем бар», – дип, дөньяга килер. Улмы, кызмы – барыбер. Утыз биш яшендә сөеп- сөелеп туя алмыйча тол калган Латыйфаның оныгы. Гомер буе йөрәгендә җыелып килгән бар назын оныгына бирер. Тусын гына. Исән-имин булып, дүрт ягы да төгәл булып туа гына күрсен! Ул бала бик матур булыр, чөнки әти-әнисе бик матурлар! Ул бала, Вәкиленә охшап, җыр- моңга мөкиббән булыр. Алда әле шундый рәхәт көннәр булыр. Вәкил белән Сөмбелә дә матур гына тормыш итәрләр. Алла боерса, шулай булыр. Шулай булырга язсын!

Латыйфа сыерын саварга абзарга керде. Кичтән Вәкиле әзерләп куйган башакны улакка салып, сыер җиленен җылы су белән юып, саварга утыруы булды, улының:

– Әни, бигрәк иртә torгансың! – дигәненә сискәнеп китте. Түрдәге имән бүкән өстендә улы утыра иде.

– Әстәгъфирулла, улым, син ни эшләп монда утырасың? Әллә төнне абзарда чыктың инде?

– Юк, әни. Кире клубка киттем. Әле генә кайттым, әле өйгә керәсем килми. Әни, син кичә ишеттеңме?

– Нәрсәне, Вәкил? Юк, мин йоклый идем. Бер сүз дә ишетмәдем, улым, ни булды соң?

– Ишеттең, әни, ишеттең. Мине борчымас өчен генә әйтмисең. Мин синең тын алуыңнан ук сизәм.

Латыйфа дәшмәде.

– Әни, кичерә күр мине, зинһар, гафу итә күр. Мин аның бу сүзләреннән соң инде йодрыкларымны әзерләп куйган идем...

– Кит булмаганны, улым, көмәнле хатынга түгел, буаз сыерга да сугарга ярамый. Аннан соң, улым, хатын-кызның бала көткән вакытта күңеле нечкәрәк була инде ул. Гафу ит инде син аны. Туачак балаң хакына гафу ит. Улың яки кызың әтисез үссә, бик авыр булыр.

– Әни, минем дә үзең шикелле интегеп яшәвемне телисеңме?

– Юк, улым, мин синең бик бәхетле булуыңны телим дә бит... Тик ни эшләмәк кирәк?

– Әни, без бүген китәбез. Мин ат белешеп кайтам да. Сөмбеләне өенә илтеп куям. Ә үзем тулай торакта торып, берәр эш эзләрмен. Йөк ташучы булып булса да урнашырмын. Ходай ташламаса, дуңгыз ашамас әле. Миңа уку турында онытып торырга туры килә. Гаиләне туйдырырга кирәк булачак бит.

Латыйфа дәшмәде. Иртүк күңелендә матур уй-хисләр уяткан яз исе минуты, секунды белән юкка чыкты.

– Раббым, бер Аллам, кайларга гына барып урнашыр Вәкиле? Сөмбеләләргә йортка кермәсен. Ул егетлек түгел. Кайчан үз фатиры булыр? Акча кайдан юнәтер? Көзгә бозауларын суеп сатсалар, азмы-күпме акча булыр булуын, тик сыерлары бозаулаганга да бер ай гына. Әле аңа бозау көрәйгәнче, күпме ашатырга кирәк.

– Ярар, улым, – диде Латыйфа, башын абзар капкасына терәп, уйга калган Вәкилгә карап. Баш ярылып, күз чыкмаган. Вакыт үзе духтыр ул, үзе дәвалый, син дә алай җебеп төшмә. Тормыш алга бара. Туктап тормый. Дөнья көчлеләрне ярата.


Көз көне Асия белән бергә укырга чыгып китәргә җыенган Вәкил, кыр казлары Алансуга яз алып кайтканда, кайчандыр авыл егетләренең һушларын алган Сөмбелә һәм туачак баласы белән авылдан чыгып китте.

Латыйфа капка баганасына сөялеп, ямансулап, Вәкилне олы юлга озатып калды:

– Хушыгыз, балалар! Хәерле юллар сезгә, гомерләрегез бәхетле, бәхетләрегез гомерле булсын!

– Сау бул, Латыйфа апа, – диде килен. Аның авызыннан әни дигән сүзне ишетмәде гомере буе кагылу-сугылуда яшәгән хатын.

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Рәшит
Бәшәр

# КӨЕК ИСЕ КИЛӘ КЫЙТГАЛАРДАН...

## Кара урман

*Заманалар авыр, еллар ябык...*

Бик борынгы җыр булса да, өр-яңа! Хәзергечә!
Озата бара татарны бишектән кабергәчә.

## Җәлилчеләрне уйлап

Көек исе килә кыйтгалардан, чор җилләре яман исәләр.
Бүген инде заман залимнәре халыкларның телен кисәләр.

## Җаһиллек

Нинди җаһил заман бу?! Адәмнәргә юк бәя...
Кадерсез мәгыйшәттә каберсезләр күбәя.

## Дөресе шул

Күзгә төтен җибәрәләр. Куанабыз.
«Тел бетми ул, рух исән!» – дип юанабыз,
Әкрен-әкрен ишелә бит гөлле нигез,
Авыша өй. Шуны күрмәс дивана без.

## XXX гасыр башы

Җилдәй очты ак чаптар, юлларга тузан ятар.
Кояш баешларында шәйләнә сәйяр татар.

## Ахырзаман

Җир кабыгы ярылганмы, тирәнгә кача сулар.
Туфан булып, берәр көнне бәреп чыгачак шулар.

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; А.Алиш, Ш.Галиев, И.Юзеев, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Соңгы корбан

Җирнең бөтен ямьнәре берьюлы бетәчәк бер.
Соңгы аккошны чалыр көннәр дә җитәчәк бер.

## Матриархат

Нечкәбилләр берүк зарланмасын, аларга бит мәйдан киңәя.
Чалбар кигән кызлар арткан саен балитәкле ирләр күбәя.

## Куркыныч төш

Таң атканчы бөтен былбыллар беттеләр дә үлеп... Үлде җыр.
Җырсыз илдә шәфкать калмады, тузан булып очты... Үлде җир.

* * *

Империя сырхаулаган саен илдә
Арта бара матәм көннәре.
Хәрабәсе асларында тагын
Өзлектерер икән кемнәрне?

## Мәхшәр

Кабер арты кабер казыла шул...
Сугыш мәйданнары киңәя.
Туучылар артып торган саен
Үтерүчеләр дә күбәя.

## Таш мәгарәдә табылган язу

Болай бармас, үзгәрәчәк дөнья.
Бәндәләре килер тәүфыйкка.
Кара пәрдәләрне этеп куеп,
Ак пәрдәләр эләр офыкка.

***

Яэҗүҗ-мәэҗүҗ басты дөньясын.
Кара җилпәзәсен җәя Иблис,
Томалыйм, дип, көннең яктысын.
Ә мин... Мин күрәм кояш балкышын
Һәм ишетәм гөлләр алкышын.

***

Килде заман. Инде син дә, фиргавен,
Музейларда дөрләп янасың.
Илләр кичә сират күперен,
Цивилизация ашый баласын.

***

Этеш тә юк, төртеш тә,
Сугыш та юк, суеш та –
Бар да гүзәл булгандыр
Дөньялар яралганда...
Күңелләргә шом керә
Офыклар каралганда.

## Кадерсез

Милләттәшем, туганым,
Илдә бармы кадерең?
Тибелеп яшәсәң дә,
Илдә булсын каберең!

## Әверелеш

Күккә ашса Җаным таң алдыннан,
Таң алдыннан кабат тусам алай-болай,
Киң җиһанны үлеп яратканга
Озын гомер бирер миңа янә Ходай.

## Иблис портреты

Пеләшен сыпыра җил. Керфекләр сап-сары.
Йон тырпаеп чыккан изүдән.
Җанымны өшетә салкын йөз. Ике иблис
Карап тора ике күзеннән.

## Читтә

Күзләремә төшә таң шәүләсе,
Чәчкә исе аңкый... Ил ерак.
Ил кояшын эзләп тилмерәме,
Сулык-сулык тибә гел йөрәк.

* * *

Күкрәгемә әнкәм сыенды,
Таң сызылды илдән киткәндә.
Һәм аҗаган яшьнәп уйнады,
Чәчкәемне җилләр сүткәндә.
Моңсу әнкәм калды тын ярда.
Ерак инде бар да... Үткәндә.

* * *

Их, чабарга иде атларда
Ефәк җилләр искән якларга...
Кире кайтып малай чакларга,
Кибән төпләрендә йокларга
Ефәк җилләр искән якларда!

## Аклык эзләп

Агарталмый дөнья карасын
Өметемне тәмам югалтсам,
Икенче кат яшәп китәрмен,
Кыр казлары төшкән күл тапсам...

## Шигырьсезләр

Шигырьсезләр үрчи барган саен
Чын аһәңе сүзнең үзгәрә.
Нур биеми бәндә йөзләрендә,
Кояш сүнә сүнек күзләрдә.

## Бушлык

Өзелде агачыннан,
Яфраккай тынсыз калды.
Соңгы кош очып китте,
Буш бакча моңсыз калды.

## Мин

Бер гөнаһсыз сабый баладай
Көлеп уянамын иртән мин.
Гомеремнең ямьсез көннәрен
Йөрәгемә күмеп йөртәм мин.

## Алмаш

Әле генә туган иделәр,
Кыскардылар инде юрганнар.
Үсеп җитте татар оланнар,
Чит-ят телдә сөйли торганнар.

## Туганнар

Бәйрәм-мазарда да күрешми,
Бер-берсенең хәлен белешми.
Чәр-чәр килеп судта талаша
Ата салган йортны бүлешли.

## Яшәү-мизгел

Күзләрнең сөртеп яшен,
Яңа чыккан кояшка
Елмаеп өлгермисең,
Йөрәкне суга яшен.

## Җәй башы

Кояш сүнә әнә. Изри тән.
Суына инде, тоныклана
Агачларга кунган җылы нур.
Төнлә кырау төшсә авылга,
Ояда кош ничек җылыныр...

## Биләүдәге сабый

Бертуктаусыз тибенә,
Ирешмәкче ireккә.
Бу аның иң беренче
Заявкасы – ирлеккә.

## Киңәш

Чит-ят җиргә күзең кызмасын,
Авыш йортың рәтлә иң элек.
Чүп үләне күмгән басуны
Гөл бакчасы яса. Иген ик!

## Оҗмахтагы сабый

Оча инде нурлы киңлекләрдә,
Вакыт үлчәмнәре үзгәрде.
Ачык тәрәзәдән ара-тирә
Өй эчендә калган уенчыкка
Төбәләдер сабый күзләре

## Тургайларга мәдхия

Иген белән бергә тургайлар да
Шытып чыга бездә буразнадан.
Басу түрендә үк тургайга да
Һәйкәл куелырдыр берәр заман.

## Яшьлек

Яшь кыз килә карга батып – сер тулы аклык.
Күзләрендә язны күрәм – никадәр сафлык!


## Капка төбе. Таң алды

Егет сылуны кочкан.
Сылу яшь әле. Бик яшь.
Күзен ачып карарга
Оялып тора кояш.

## Горурлык

Бәхетле мин, Күкләр астында
Татар атлы тырыш халкым бар.
Көлеп яшәргә дә бу җирдә,
Сөеп яшәргә дә хакым бар!

*«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» әдәби конкурсы*



Сәгыйдулла Хафизов

# БАСЫНКЫ БАСТАМ

ПОВЕСТЬ

**1**

Көлсу курпы чәчле башын эш җаена селеккәләп, Бастам карт лапаста ат камытын төзәтеп утыра. Өстәлендә яткан очлы без, кайчы, пычак, тегәрҗеп сапланган озын камыт энәсен сөякчел бармакларына буйсындырып, сүтелгән-какшаганны инде рәтләп бетереп килә...

Тагын кайсы җирендә кимчелек калды икән дип, ул камытны баш өстенә күтәреп, җентекләп күз йөртеп чыкты, тик аны өстәлгә куймады, ә җайлап кына башыннан киеп, җилкәсенә утыртты. Бахбай исе, әче тир исе борынын ярып керде. Ир затын юкка гына атка тиңләмиләр икән шул. Ир-ат, янәсе... Бу уйдан Бастам кеткелдәп көлеп куйды: «Камытын кигәч, арбасын да тартып карарсың инде, хет юаныч булыр үзеңә».

Әй, булган икән вакытлар, юанычны Бастам эзләмәгән, ә ул үзе һәртөрле кызык-мызык очрагы булып, ул вакытта әле карга канатыдай кара чәчле, тулган ай сыман түгәрәк һәм якты йөзле ирне үзе эзләп килеп, күңелен күргән... Элек тә шулай лапаста әйбер-мазарны көйләргә утырса, улы яисә кызы аның култык астыннан башын тыгып, сораулар яудырырга, тыймасаң, эш кораллары тирәсендә кулларын уйнатырга керешерләр иде... Йә булмаса, купшы койрыгын болгап, Актүше килеп керә дә хуҗасының әйберләрен иснәштергәндәй итә. Ә иркә Мияубикә инде тез өстенә үк сикереп менә дә сырпалана башлый: «Җитәр, янәсе, юк-бар белән изаланырга, мине сыйпа!»

Бүген исә көлсу курпы чәчле баш янәшәсендә газиз балалары, песи-эт мазар юк-югын, мәгәр йөрәк типкәндә, сине һич ташламас юлдаш – Вакыт бар. Өйдә артык тавышлана, йокларга ирек бирми дип, хатыны Розалия лапас диварына чыгарып элгән борынгы зур сәгать лап-лоп килеп йөреп маташа. Бу сиңа куян йөрәге сыман келт-келт типкән электрон сәгать түгел, герле, шайба-гайкалы чылбырын тартып күтәреп тормасаң туктап калуы да ихтимал. Шулай да күзгә-башка чалынмаган вакыт дигән нәрсәне санап, үтәсе юлын атлап үтсә, бу карт сәгать ифрат шәп суга: «Даң, даң, даң..» Бастамның хәтта зиһене томалангандай була.

---

Сәгыйть ЛАШМАНЧЫ (ХАФИЗОВ) (1945) – *язучы, филология фәннәре кандидаты; Җамал Вәлиди исемендәге премия лауреаты. «Гомерем фасыллары» китабы авторы. Башкортстанның Кушнаренко районында яши.*

Чынлыкта аптырыйсы юк, карт кешенең хәтер сукасы кайда йөрсен? Үткәндә инде, башыннан кичкән тормыш кишәрлегендә. Яшьләр генә һаман алга карый, план-ният кора. Әйтерсең, тормыш алар өчен иксез-чиксез марафон, чабасы да чабасы... Тик кеше дигәнең чабыш аты түгел, уйланасы барыбер уйланыла... Атап әйткәндә, күзне йомып, томырылып йөгергәндәге байтак гамәлләр өчен сызланулар, үкенүләр картлыкта килә. Хәтер, кибеткә, конторга кисәтүсез килгән ревизор шикелле тикшерә, хаталарны таба да үз хөкемен чыгара. Нишлисең, адәм гомере табигатьтәге сыман төрле фасыллар тезмәсеннән гыйбарәт дисәләр дә, асылда ныклы бер түгәрәк йомгак ул. Сабый чак, яшьлек еллары, өлгергәнлекне алыштырырга әзер торган картлык – барысы бергә укмашкан. Хәтер кылы кай тирәдән зыңгылдатып тавыш бирсә дә, йөрәгеңә килеп кадала. Аның өчен вакыт, фасыллар бүленеше юк.

Ниһаять, эшеннән канәгать калып, ул муеннан камытны салды. Аны җирән кашкага кидереп, арбага җигеп, басу-кырлар буйлап каядыр җилдерәсе иде дә бит... Аты инде юк шул.

Вакыт галиҗәнаплары аңа да үз сәгатен сугып, хөкемен яңгыратты. Мәрхүмгә карата авыр туфрагы җиңел булсын дип әйтү килешә микән? Ә сагыш хисен тыеп булмау хак. Ат – ир канаты бит! Элек ихатасында ат заты булмаса да, өендә шамаил, дога тоткан кеше күзгә бәрелмәслек бер урында ат дагасын да беркетеп куйган... Нигез исән-имин булсын, ызбага бәхет иңсен дигән. Әлегә картның кул астында дага юк югын, мәгәр өйдә, үз почмагында ат камытын элеп куячак ул.

Шулчак картның уйларын бүлеп, йорт ягыннан тавыш ишетелде:

– Бастам, керәсеңме инде, сусагансыңдыр?.. Күпме утырырга була, иске-москы төзәтеп?

Карчыгының тиктомалга әрләве Бастамның мазасына тиде:

– Кил әле монда, нәрсә такылдыйсың син? – Һәм шул мизгелдә үк лапаска башын тыккан Розалиягә карап өстәп куйды:

– Иске-москы төзәтү түгел бу, ә җирсенү белән шөгыльләнүем! Ишеткәнең бармы бу сүзне? Илаһи кәлимә бит бу. Җир-суны, ил-көнне сагыну, җуелган асылыңны сагыну, бергә гомер иткән чын дусларыңны юксынып хатирәләргә бирелү ул җирсү, белдеңме? Җирсенү – кеше бизәге ул!

– Сездәгесен чынлап та белмим, ә безнең якларда «җирсү» дигәндә, ярсуны, кызып китүне күздә тоталар. Бигрәк юкка-барга җирсеп торасың. – Карчык сүзне беткәнгә санап, өй тарафына юнәлде. – Кер, чәем суына.

Карт та җавапсыз калмады:

– Аллага шөкер, басынкы Бастам дисәләр дә, син әйткән җирсү дә бар миндә, тик чыгырдан гына чыгарма.

**2**

Бастам Уразов байтак еллар үзләренең Зирекле авылындагы сигезьеллык мәктәптә хезмәт укытучысы булып эшләде. Кайберәүләр бу шөгыльне һәрбер агач юну, тимер эшкәртү остасы да башкара ала, дисәләр дә, ул, мыек кабартып килгән егет, эшкә Бөгелмә каласындагы бик мәшһүр индустриаль-педагогия техникумын тәмамлап кайтты. «Балаларыбыз тумас борын картая», – дип көенгән авыл халкы, инде картайган, әйле-шәйле йөргән укытучылар арасына ачык йөзле, итагатьле һәм җегәрле яшь белгеч керүен бик хуплады. Инде яшь укытучының ата-анасына килсәк, икесе дә мәктәптә эшләп, лаеклы ялга чыккан картларның куанычларына чик-чама булмады:

– Иншаллаһ, нәсел педагоглар династиясенә әверелә бит!

Чынлап та, юрау юш килер сыман, Бастам Уразовның укыту-тәрбия эшенә кереп китүендә бер кыенлык булмады. Сөйләме гади, аңлаешлы, куллары да оста аның,

шәкертләренә дә таләпчән була беләә. Күп ир-ат нәкъ шул үзара мөнәсәбәтне җайга сала алмаганга укытучылыктан кача да бит...

Яшь педагог эшкә керешкән алтмышынчы елларда мәктәпләрдә академик Мирза Мәхмүтов ысулы кулланыла иде. Ягъни теге яки бу фәндә проблемалы хәл-әхвәл корып, дәрестә аны бергәләп хәл итү. Шәкертләрдә зирәклекне, тапкырлыкны үстерүгә йөз тоткан мөгаллимнәр аны кайнар яклаcа, кагыйдә, бирем ятлау белән дәрес үткәреп килгәннәр бу ысулны күрә алмадылар. Ул хәтта байтак мәктәп җитәкчеләре – директорлар, завучлар өчен дә баш казасы булды. Чөнки укытудагы яңа ысулны үзләштерү хакында югарыга даими рәвештә хисап бирергә кирәк. Хезмәттәш зирәк булса, иҗади эшләсә, куаныч та бит, янәшәңдә андыйлар булмаса, отчётыңны ничек язасың?

Зирекле мәктәбе директоры Фәндәвис Галиевич нәкъ шул проблемалы укыту елларында яңадан тугандай булды, байтак хезмәттәшләренә аның мөнәсәбәте кискен үзгәрде, кырысланды. Җен алыштырдымыни үзен. Әмма чал чәчле, орденлы фронтовик кешене кешедән аера белә иде. Яшь әле, танау асты да кипмәгән дип тормады, Уразовка бик җылы мөнәсәбәттә булды. Бу түрә белән гади эш башкаручы арасында гына була торган кечелекле бер бәйләнеш иде... Дәресләрдән соң, директор, җаен туры китереп, хезмәт укытучысын бергәләп мәктәп ихатасын карарга чакырды. Әйтик, яз җиткән, җир кардан арчылып килә, мәктәп хуҗалыгы тәртиптәме? Юк инде, күзгә кадала торган нәрсәләр байтак: әнә язгы су ермаклар, чокыр-чакырлар калдырган, тегендә-монда чүп-чар ауный... Бастам иртәгә бишенче сыйныфларны җыештырырга алып чыгармын, дип уйларга өлгермәде, Фәндәвис Галиевич кулы белән урам ягындагы рәшәткәләргә ишарәләде:

– Күр әле, дустым, койма янтайган, кыйшайган, авыл безне мәсхәрә итәргә дә күп сорамас. Нишләтергә икән? Мөгаен, баганалары черегәндер.

– Фәндәвис абый, менә карагыз әле, моның баганасы гына түгел, җепсәсе дә, тактасы да черегән бит. Хан заманыннан калган бу... Йорт салган кеше хәзер койманы буяулы калайдан коя. Нык та, матур да. Сайдинг, диләр аны.

– Шулаймыни? Сайдинг дисеңме? Директор бер мәл сораулы карашын укытучы егеткә текәп торды. – Дустым, алайса уйла әле, шул койма проблемасын тиз арада хәл итеп булмасмы икән?

Егет алдына нинди мәсьәлә куелганын аңлады. Эш уйны гына түгел, дәртне дә кузгата бит. Мичкә каен пүләнен ташладылармыни? Бастам тиз арада эшләрнең планын төзеде һәм койма өчен кирәкле материалларның исемлеген язып, хуҗаның рөхсәтен алгач, завхоз Җиһангир кулына китереп тә тоттырды: «Абзый, зинһар озакка сузма, миңа шушы материалларны кайтар!»

Ниһаять, барысы да әзер. Шәкертләргә эшне төшендереп бирәсе генә калды.

– Укучылар! – диде остаз, шактый дулкынланып. – Сез үткән дәресләрдә калай, тимер һәм башка материаллар белән эш башкардыгыз, тәҗрибә тупладыгыз. Инде теоретик әзерлекне практикада кулланып карау вакыты җитте. Шунысы куанычлы, мәктәп җитәкчелеге безгә ихатабызга сайдинг койма кору бурычын йөкләтте. Безнең өчен бу зур сынау. Ышанам, һәрбер укучы үзенең сәләтен ачар, осталыгын күрсәтер. Әйдәгез, алъяпкычларыгызны ябыгыз, эш бияләйләрен алыгыз да алга! Шәкертләр «Ура!» кычкырып, урамга атылдылар. Алар звеноларга бүленеп эшләде. Берничәсе агач койманы сүтсә, икенчеләре эш мәйданын чистартты. Ә зуррак сыйныфлар баганалар өчен чокырлар казыды. Ә турыдан-туры остаз кулы астында эшләгән дүртенче звено тимер баганалар утыртты, җепсәләр ябыштырды да шуларга сайдинглар беркетте. Хоттабыч карт әмере белән торгызылган кебек яшел буяулы койма санаулы сәгатьләр эчендә калкып та чыкты.

Сигезенче сыйныф «атаманы» Ленар урамга ук йөгерде:

Ай матур! Абый, валлаһи, мондый койманы күргән юк иде. Без – молодцы!

Тирә-яктагылар исә, Ленарны куәтләп, «Ура!» кычкырдылар. Бастам үзе дә күмәк иҗтиһад җимеше өчен ихлас шатланды. Әмма шул ук вакытта укытучы буларак ирешкән уңышын да ачык төшенде. Хезмәт дәресләрендә проблемалы укыту менә шулай «сюрпризлы» булырга, эшкә дә бәйрәм рухы өстәргә тиеш! Хезмәтнең тормышта кешеләргә сөенеч тә тудырырга мөмкин икәнен бу предметны укыткан кеше күрсәтмәсә, ачмаса, тагын кем ачар?

Үз хезмәтенең мөмкинлекләрен ачык күзаллаган педагог зур башлангычлардан курыкмады. Мәктәптә хуҗалык эшләре калыккан саен Уразов аны хәл итәргә алынды. Зирекле мәктәбенә әле заман архитектурасы килеп җитмәгән, ул ике бина, ашханә һәм Уразов эшләгән мастерской түбәсе астында көн күрә. Яңгыр яуса, яисә язгы-көзге пычраклар башланса, алар арасындагы сукмаклардан үтеп йөрмәле түгел... Кемнәрдер пычрак ташырга күнеккән, мәгәр хезмәт укытучысы алдында янә бер эш калыкты. Бу техничкаларны чыгырыннан чыгарган бәладән ничек котылырга? Фәндәвис Галиевич белән киңәшләшкәч аңлашылды. Моны хәл итү кулдан килмәстәй эш түгел икән. Укытучы бер төркем шәкертләре белән Ямәлкә тавы итәгенә барып, таш җыйды. Колхоздан машина сорап алып, аны кайтардылар һәм таш «мастерлары» җиң сызганып эшкә тотынды. Тротуарны коеп куйдылар. Чүәктән генә йөрсәң дә була хәзер. Мәктәпнең үз спорт мәйданчыгы да шулай барлыкка килде.

Шулай итеп, бик кызыклы хәл килеп чыкты, проблемалы укытуның иң шәп үрнәкләрен физика, математика, тарих яисә тел-әдәбият дәресләрен алып баручылардан көткәннәр иде, ә ул элек балта, көрәк сабы ясаудан ерак китмәгән мастерскойда гамәлгә ашырылды. Хәзер инде мәктәп директорының гади бер хезмәт укытучысын ни өчен якын һәм үз итүе ачыкланды шикелле.

Иң мөһиме, яшь укытучының остазлык сыйфатын, күркәм кешелек гадәтләрен балалар, ягъни шәкертләре тойды. Вакыт үтү белән мәктәпне инде тәмамлап, тормышта үз урынын тапкан укучыларыннан да, педагог үз адресына җылы сүзләрне еш ишетте:

– Абый, билләһи, геометрия, алгебра кебек фәннәрдән башта нәрсәләр калгандыр, бер Алла белә, әмма сезнең дәресләрдән алганнар безгә һәр эштә бисмилла сыман кирәкле. Рәхмәт, Бастам Сираевич!

**3**

Әйе, тормышта да үз урынын тапты ул, яраткан кызына өйләнеп, гаилә корды, тупырдап торган ул һәм ифрат сөйкемле кыз баланың атасы булды. Бәлки инде Бастам Уразовка хезмәт баскычларыннан югарырак күтәрелергә, олпатланырга да вакыттыр?

Бу хакта аңа алтмыш яшен тутырып, бик зурлап юбилей үткәргән Фәндәвис Галиевич әйтте:

– Бастам энем, лаеклы ялга чыгам, директор урынына синнән лаеклырак кеше юк, килеш, иртәгә үк мәгариф бүлегенә Шәмгуновка шул тәкъдим белән барам.

Хезмәт укытучысы өчен бу һич тә көтелмәгән сүз иде:

– Фәндәвис абый, миндә бит техникум дипломы гына, оныттыгызмыни? Хәзрәт, укымышың азрак, диярләр... Хезмәт укытучысының директор итеп күтәрелгәнен күргән юк. Кеше көлдермик!

– Соң энем, Макаренко университет бетергәнме? Син мин әйткән белән килеш. Ә Шәмгуновны ризалату – безнең эш. Мәктәптәгеләр сине күтәрү ягында, хур булмассың!

– Рәхмәт, Фәндәвис абый, тик каршымын, күңел тартмый.

– Ярар, бүген кайт, уйлан, хатының белән киңәш, ә иртәгә ризалыгың белән кил. Бел, бу синең өчен шанс!

Бастам карт тормышының бу мизгелен бөтен вагы-төяге белән хәтерендә тота.

Мәгәр ул вакыт өенә кайткач, директор тәкъдиме хакында Розалиясенә бер сүз дә ычкындырмады. Үзе дә киләчәге хакында алай ук тирәнгә төшеп уйланмады. Үз язмышы белән килешкән иде инде ул: ашау байдан, үлем Ходайдан...

Иртән эштә күрешкәч, Фәндәвис абыйсы яхшы хәбәргә өметләнеп, аны ачык йөз белән каршылады:

– Тәвәккәллибезме?

– Юк, булмый, Фәндәвис абый. Татар түрә булса, чабатасын түргә элә. Түрдә хезмәт укытучысы булып каламмы? Аннары нәрсә укытам? Нишлисең, Хак Тәгалә миңа гомер буе шул бер лямканы тартырга боерган инде. Бурлак сыман...

Моны көтмәгән Фәндәвис Галиевич ут сыман дөрләп кабынды:

– Һай, энем, шул чаклы авыр сөякле, тискәре адәм булырсың икән, сине трактор да кузгата алмас... Тик бел, дөнья һаман бер көе бармый ул... Дөнья куласа – әйләнә дә бер баса, диләр аны.

Синең кебекләр һаман лямка тартыр, ә җилкуарлар, этрәк-әләмнәр кәнәфиләргә, җитәкче урыннарга менеп утырыр. Менә шунда үкенерсең син!

Бу сүзләр дә күңеленә уелган, алар ирне кайта-кайта уйландырдылар. Чынлап та Бастам өлкән кешенең тәкъдимен кабул итсә, аның тормышы башкача көйләнгән булыр иде. Холык кеше бизәге генә түгел, ул аның язмышын да көтелмәгәнчә әвәләп куя шул.

Икенче яклап, карт башка хакыйкатьне дә таныды. Теге яки бу җитди адымны ясарга җыенганда, кешенең артында үткәне, замана тора. Язмыш чабуы шулар кулында. Укытучы кеше җитәкчелек дилбегәсен кулына алырга теләмәгән икән, димәк, аңарга күңел ныклыгы җитмәгән, шикләндергән нәрсәләр күп булган. Хәер, текәлеп карарга лупа кирәкми. Бастам: «Без – октябрь баласы», дип җырлап үскән буын вәкиле. Шуның өстенә аның укытучылар баласы икәнен дә өстик. Ата-ана халык алдында еш нотык тота иде: «Җәмәгать, хөкүмәт өчен балаларыбызны укыту-тәрбияләү – бик җаваплы вазифа. Патша безнең балалар өчен мәктәпләр дә ачмаган. Ленинга рәхмәт! Ул яшь буынга туган телдә белем һәм тәрбия бирер өчен, руслар белән беррәттән, безгә, изелгән халыкларга да бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Моның кадерен белик!»

Педагогик хезмәткә әзерләгән техникум да егетне төрле яктан чарлаган икән. Нәкъ шул һөнәри әзерлек аркасында яшь укытучы Бастам Уразов бик кыю рәвештә академик Мирза Мәхмүтовның проблемалы укыту алымын үзенә таяну ноктасы итеп алды да бит. Бу, аныңча, укытуны камилләштерү чарасы гына түгел, ә тулаем өлгергән социализм дип аталган җәмгыятьне үстерүнең универсаль юлы иде. Проблема туа, калка икән, аны хәл итү юлларын табарга кирәк! Бастамның иманы камил, зирәк акылга, иҗтиһадка юл ачып хезмәт иткәндә, авыллар һәм шәһәрләрнең йөзе күзгә күренеп күркәмләнер, кешеләрнең рухи, матди тормышы күпкә яхшырыр иде. Тик, ни галәмәт, болай килеп чыкмады шул. Өлгергән проблемаларны күреп алу, хәл итүдән бигрәк, җәмгыятьтә әзергә-бәзер яшәүчеләр өере калыкты. Утка май сипкән кебек ил өстендә демократлар, либераллар һәм тагын әллә нинди ят бәндәләрнең лозунглары, чакырулары яңгырый башлады. Һәм Рәсәй һич көтмәгәндә хәтәр үзгәртүләр, яңартулар белән кызыл чиккә килеп җитте. Ныклы, колачлы тәрбия эшләре алып барылса, ил бу хурлыклы хәлгә төшәр идемени? Тарихи мәл һәркайсын сискәндерде, аеруча ул укучыларны куркытты. Әхлаки-рухи кыйммәтләр алмашынып, акча-капиталны культ ясаган заманда кемдә күңел ныклыгы калсын? Укучы һаман да укучы инде, сыйныф каршына басып, дәрес бирерсең, уйларга, фикер йөртергә өйрәтерсең, ә менә хезмәттәшләреңне нәрсәгә өндәрсең, кая алып барырга омтылырсың әйдаман? Шул уйлардан чыгып, Фәндәвис абыйсының тәкъдимен кире какты да инде

Бастам. Мәгәр хөрмәтле фронтовикның җилкуарлар, әтрәк-әләмнәр хакында әйткәне дөрескә чыкты. Алар Рәсәйдәге милли мәктәпләрнең асылын, санын корытып, байтак талантлы педагогларның башына җитеп, дәүләт мәгарифен көрчеккә терәделәр.

**4**

Бастам карт исәп-хисап кешесе түгел, чутларга яратмый. Шулай да берчак зиһенендә калкып чыккан сорауга чутлауның кирәге чыкты. Мәгарифтә ул күпме булган?.. Җитмеш өчнең август аенда эшкә килде, туксан дүртнең сентябрендә эштән китте. Җәмгысы егерме елмы? Хәтсез генә икән!

Педагогика – ачык өлкә. Бу сиңа шахтага төшеп, ялгызың катлам эчендә казыну яисә капитан Немо кебек океан киңлекләрендә ялгыз гомер кичерү түгел. Педагогика гыйлеме остазның маңгай күзен ача һәм аның каршысындагы затның эчке дөньясын күрү мөмкинлеген бирә. Педагог сокланасына соклана, имлисен имли, кәкресен турайта... Әлеге һөнәр кешесе дә арыш-бодай үстереп килгән игенче сыман. Ихластан эшләсә, уңсын дип тир түксә, аның үстергәне дә матур, мул. Ә инде ата-анага, «ите – миңа, сөяге – сиңа», дип шарт куеп эшли торган тәрбияче булса, бу – тик сабый җәфалаучы. Мондыйларга кибетче, бухгалтер, таксист кебек акча санарга яратучы һөнәр иясе булырга кирәк. Әмма педагоглар арасында кемнәрне генә күрмәде Бастам Сираевич: беркатлылар, хыялыйлар, үҗәтләр, юләрләр, хәтта җилкуарлар, комагайлар, явызлар да бар. Алар ышаналар, изге, мәрхәмәтле ният япмасы, шыксызлыкны каплый бит ул. Тымызык күлдә шайтаннар ишәя дигән әйтем сыман, нәкъ болгавыр, караңгы елларда әлеге оятсызлар артты...

Зирекле мәктәбе көтмәгәндә фаҗигале икътисад дулкыны – оптимизация җәтмәсенә эләкте. Бу көннәрдәге халык белән хакимият арасында купкан низагны онытып буламы? Бигрәк тә район мәгариф бүлегендә инспектор Карачурина белән булган әңгәмә вагы-төяге белән карт хәтеренә сеңеп калды.

Төс-башка ифрат чибәр бу туташ эшкә башкала университетында аспирантура бетереп килгән икән. Хәзер хезмәтеннән бушаган арада бик бирелеп диссертация яза, диделәр. Кабинетына дәшеп алган хезмәт укытучысы белән дә ул зыялы кешеләрчә сөйләште:

– Бастам Сираевич, күкләрдән җиргә төшеп сөйләшеп, аңлашып алыйк әле. Кемнәрдер педагогны үз заманыннан, ким дигәндә, 30-40 ел алдарак яшәгән зат итеп күрергә тели. Янәсе, алар кыласы гамәлне бүген кыла, кешеләрдә үстерәсе сыйфатны хәзер үстерә... Менә шулай иткәндә, тормыш ал да гөл була, имеш. Утопист булырга мин дә риза, әгәр чабудан бер парадокс тотмаса... Укытучы да заман тегүчесе теккән тунны кия, аның тәлинкәсендә дә пешкән аш... Ул да әллә каян күктән төшми... Ул да башкалар кебек үк үзеннән дә югарырак сикерә алмый шул. Димәк, философ әйткәнчә, объектив сәбәпләр бездән көчлерәк булып чыга. Таныйбызмы шул хакыйкатьне? Танысак, чыр-чу килмичә, Зирекле мәктәбенә күз салыйк. Бүгенге госстандарт таләбеннән ерак, хан заманыннан калган өч-дүрт бина. Санитария-гигиена таләпләре үтәлми. Монда уку-укыту, тәрбия эшләре алып бару оят хәтта. Димәк, бу мәктәп ябылырга тиеш. Инде хөкүмәт заман таләпләренә туры китереп, яңа мәктәп салыр иде, авылыгызда демографик хәл үтә дә мөшкел, балалар саны елдан-ел кими. Бу сезнең халыкның үз язмышына битараф булу нәтиҗәсе... Ике исәп – бер хисап, килеп чыга: Зирекледә мәктәп бөтенләй ябыла, укучылар башка мәктәпләргә күчә, педагогларларга эш эзләргә кирәк!

Инспектор туташ беразга тын калды. «Сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел, юкка гына диссертация язмыйдыр бу, әнә ничек барысын да оста дәлилли бит», дип нәтиҗә ясады хезмәт укытучысы. Тик исем шәрифләре генә бик килешеп

бетми үзенә, «Варисә», имеш. Ялгышканнар, аңа берәр чәчәк исеме ята төшәр иде. Роза, Рәйхан, Миләүшә, Ландыш... Әйе, нәкъ менә «Ландыш» бу туташка килешкән исем... Урманда җир яңа гына кардан арчылган. Тирә-як көзге яфрак, былтыргы үлән белән капланган. Ә яшел яфраклар арасыннан күз явын алырлык ак энҗе бөртекләредәй чәчәкләр ачылып килә... Бу чегәннеке кебек чем-кара күзле, аксыл чәчле табигать баласын Ландыш дисәң, җисем отар гына иде шул. Мәгариф Ландышы! Мәгариф балкышы кебек яңгырый.

Инде хәзер төп сөйләшү предметына килик, Уразов әфәнде. Без сезне бик булдыклы педагог, хезмәт укытучысы итеп беләбез. Шәмгунов коллегиаль утырышта сокланып сөйләде. Сез корган хезмәт мастерское ифрат бай икән. Унбиш укучыга исәпләнгән класс-бинада агач, тимер эшкәртү эшенә тәгаенләнгән бөтен корал да, станоклар да бар, ди. Җитәкчебез кадр буларак, сезне сакларга, үсәргә ярдәм итешергә чакырды.

Бастам Сираевич, район мәгарифе сезгә ике мөмкинлек тәкъдим итә: беренчесе – Хуҗәмәт сигезьеллык мәктәбенә, икенчесе Иваненко мәктәбенә күчеп, эшегезне дәвам итү. Анда унберьеллык мәктәп икәнен беләсездер, шәт... Уйланыйк, кайсын сайлыйсыз?

Укытучы күптән инде звонок көтеп утырган сабый хәлендә иде, сорауны ишеткәч, тәмам коелып төште. Барысы да уен кебек кенә тоелган иде, тормышында проблемалы бик кискен хәл килеп чыккан икән бит. Ничек чишәргә?

– Варисә Шаһиевна,бәлки бу мәсьәләне калдырып торырбыз?

– Юк, Шәмгунов бүген үк хәл итәргә кушты. Ул алга, бик еракка карап эш итә торган җитәкче. Мин шәхсән сезнең өчен Хуҗәмәт мәктәбен кулай саныйм. Ул авыл сезгә бик якын, укучыларыгыз да шунда барыр, дип уйлыйм. Хезмәт мастерское да шулай ук аерым бинада, аулак урын. Дөрес, материаль базасы Зирекледәгечә түгел, шактый фәкыйрь, әмма бу хәл итәрлек мәсьәлә, минемчә. Милекне үзегез белән алырсыз. Эш коралларын һәм җиһазларын. Транспорт кытлыгы тумас, кәгазь-документ кирәксә, анысы да булыр. Ачыклап әйткәндә, Зирекледәге мастерской – мәгариф мирасы. Аның язмышын без хәл итәбез.

Инспектор янә беразга туктап калды, су эчеп куйды. Хезмәт укытучысы да сүзнең кая таба барганын чамалады. Эчке тавыш исә хәлгә ачыклык кертте: «Мирас түгел, рейдерлык диләр моны, туташ, замана педагогикасына да үтеп керә микәнни бу пиратлык алымы? Ә инде монысы сезне һич бизәми. Мине дә бизәмәс бу кыңгыр эш. Начальник кушты дип, Зирекле мәктәбе милкен Хуҗәмәткә ташып кара, авылдан ук куарлар... Илтәсең икән, үзең илт, кеше кулы белән утлы күмер тотма, Варисә туташ...»

Исем кешене үзгәртә шул, чеп-чи җәмгыять баласы итә. Җисеменә төсмерләр бирә, сыйфатлар өсти. Гарәп исемнәре җенес категориясенә буйсына икән. Рустагы сыман, Варис-Варисә...

Кем варисы соң бу? Шиксез, атаныкы! Һәм дә Шаһин Шаһ варисы. Варисә Шаһиевна... Варисә Шаһи... Болай атаганда, бу чибәр олпатлана, бер башка калка. Ул ил, дәүләт эшлеклесе, сәясәт кешесе сыйфатларын ала. Рәсми, таләпчән, үз сүзен үтәтергә бик ярата бугай... Варисә Шаһи... Тик барыбер педагогика кешесенә бик ярәшеп бетми бу исем... Нәрсәседер килешми...

– Уразов иптәш, мине тыңлыйсызмы? Сез каядыр киткән кебек... Йә, Хуҗәмәткә барасызмы?

– Варисә Шаһиевна, анда вакансия бармы соң? Ачыклап әйтмәдегез бит әле...

– Әйтмәдеммени? Хезмәтне укыткан Мөшәрәпов өч ел элек эшкә алынган булган. Сынау белән, әлбәттә. Чөнки махсус белеме юк. Пыяла кисү остасы булгач, тәрәзәләр ясагач, алганнар моны. Әмма тәрбияви-дидактик осталык юк бит! Кыскасы, яңа директор Сәмигуллин Мөшәрәповны озату ягында. Сезнең килгәнне

генә көтә. Сәмигуллинны сез беләсездер, дип уйлыйм. Аның бер кардәше безнең хакимияттә эшли, юк-бар кеше түгел. Сезгә дә файдасы тияр...

– Мөшәрәпов башта китсен, хөрмәтле инспектор, ә аннан соң мәктәпләрен карагач, мин дә әйтермен, бараммы, юкмы? Уйлап-уйлап торам да, Варисә Шаһиевна, миңа, мөгаен, Иваненко варианты кулайрак булыр!

– Сезнең ихтыярыгыз! – диде инспектор салкын гына һәм әлеге мәктәп хакында бераз мәгълүмат биргәч, сүзен очлап куйды: – Беренче сентябрьне, белем бәйрәмен, Иваненко мәктәбендә каршыларсыз, дип ышанам. Эшегездә уңышлар телим, Уразов иптәш!

Бастам, әлбәттә, әлеге көнне көтеп ятмады, булачак эш урынын барып күрергә теләде. Шуның өстенә фельдшер булып эшләгән хәләл җефете Розалиягә дә эш кирәк бит.

Ир уку елы төгәлләнгәнче үк ерактагы Иваненко авылына юл тотты... Мәктәпкә чакырылмаган кунак булып барып кермәссең бит, алдан кисәтергә кирәк. Инспекторга шалтыратты ул:

– Варисә Шаһиевна, эш хакында анык сөйләшү өчен Иваненкога баруым. Зинһар, директорын кисәтегез!

Борынгы рус саласы урман-сулы, кыр-болынлы, иркен сулышлы табигать кочагында ята икән. Ызбалар «Барыня ты моя, сударыня ты моя»га биеп китәргә әзерләнгән түтәйләр кебек, һәркайсы текә карап, түшләрен киереп торгандай. Мәктәп тә ерактан ук балкып тора. Ике катлы, заманча проект белән салынган. Укучылар саны кимесә дә, моңа оптимизация җилләре кагылмас. Юлчының күңеленә яктылык иңгәндәй булды. Эшкә алсалар, шартлар хакында артык сатулашмаска кирәк дигән карар белән мәктәп ишеген ачты. Әнә Бастамның әти-әнисе артык сайланып тормаган, мәгариф кайда кушса, шунда барып эшләгән бит. Өй, каралты салып та мәшәкатьләнмәгәннәр, мәктәп биргәнгә канәгатьләнеп, иҗтиһад дәртен укытуга, тәрбия эшенә багышлаганнар. Улының, «Ашау – байдан, үлем – Ходайдан» дигәнне бик еш тәкрарлавына аптырап, Сара апа берчак әйтеп тә куйды:

– Бастам, әллә бу әйтемне бездән ишетеп, күңелеңә салдыңмы син?

Шулай ишекне тик изге ниятләр белән ачты-ачуын, тик үкенечкә каршы, директор ханым командировкага киткән булып чыкты. Чыгарылыш сыйныфларда дәүләт имтиханнары барган чакта нинди командировка икән ул, дип аптыраса да, чит-ят кеше буларак, сорашырга кыймады. Тормыш бит ул, бәлки, гаиләсенә кагылышлы берәр хәл килеп чыккандыр дигән уйга килде. Укытучылар бүлмәсендә мөдир генә иде.

– Хөрмәтлем, сезгә Уразов дигән кеше килә дип, мәгарифтән шалтыратмадылармы?

Шактый ук юан гәүдәле ханым куркулы күзләре белән Бастамга текәлеп торды:

– Сез кем соң? Директор нигә кирәк?

– Мин шул Уразов булам инде. Эш хакында сөйләшергә килдем.

Ханым башта елмайды, аннан көлеп үк җибәрде:

– Эш эзләүчемени? Ә без сезне берәр тикшерүче дип уйладык. Куркыттыгыз. Ә нинди предметны укытырга җыенасыз соң?

– Хезмәт.

– Хезмәт? Иптәш, сезгә ялган мәгълүмат биргәннәр. Бездә хезмәт укытучысы бар инде, ул китәргә җыенмый да.

Йөрәге авыру адәм бу сүзләрдән соң йә егылып китәр, йә йөрәген тотып, аты-заты белән сүгенер иде. Бастам мәгәр үзен тыныч тотты.

Вәт Варисә Шаһи! Диссертация язып ята диген. Ә үзенә йөкләтелгән эшне җиренә җиткереп үтәргә кирәклеген оныткан булып чыга.

Килгәч-килгәч, ичмасам мастерскоен күрим дип, секретарь кыздан бикле ишекне ачтырып, уку бинасына күз салды. – Әстәгъфирулла, бу балаларны хезмәткә өйрәтү урыны түгел, дуңгыз араны бит! Идән тулы чүп-чар. Топтыгинныкы кебек өстәл, урындыклар аунап ята... Эш кораллары әллә бар, әллә юк. Тик берничә шкаф күзгә бәрелеп тора. Ә диварлар шыр ялангач.

Бастам, тәмам аптырап, секретарьга эндәште:

– Бу тар, кысан бүлмәгә ничә укучы сыя соң? Хезмәт дәресләрендә ни белән шөгыльләнәләр укучылар?

– Бездә хезмәт дәресләрен бүлеп укыталар бит. Кызлар башка урында тегү, чигү, кулинария серләрен үзләштерәләр...

Сыйныфны бүлгәләгәч, укытучыга да тулы ставка тәтеми инде... Ир күңеленә шом йөгерде.

Килүдән ни мәгънә? Шул вакыт бинага тирләп-пешеп, тыны кысылып шактый зур корсаклы чал ир килеп керде һәм Бастам каршына килеп басты:

– Син Уразовмы? – Ирнең авызыннан сасы ис бөркелде.

– Әйе, нәкъ үзе...

– Алайса сыпыр моннан! Юкка килгәнсең... Мин эштән китмәдем һәм китәргә җыенмыйм да!

– Мин дә сезнең урынны яулап алып, монда эшләргә җыенмыйм. Мәгариф юкса юлланма әзерли, барып күрим әле дип сугылдым. Танышыйк булмаса.

– Мин Козлов, – диде бераз тынычланган карт.

– Әйтегез әле, Козлов, минем килгәнне кем хәбәр итте сезгә? Мәктәптә бит мине белмиләр.

– Иптәш, сез монда прокурор кебек төпченеп йөрмәгез. Телегезне тиз кыскартырлар. Мин Әфганда кан койган хәрби офицер. Пенсиягә чыксам да, эшлим әле. Тагын бер кат әйтәм, Иваненко ягына карыйсы да булма. Аңладыңмы?

Исерек белән сүз көрәштерүдән мәгънә юк иде, Бастам ишеккә таба атлады. Кыз да Бастам белән чыгу юлына борылды:

– Абый, сез мондагылар белән бәйләнмәгез. Чынлап та китегез, әллә нәрсәләр булыр...

– Сеңлем, мин һаман бер нәрсәгә төшенә алмыйм. Пенсионер, эчкече һәм укытырлык кеше түгел икән, нигә аны директор эшеннән куып чыгармый?

– Абый, сез миннән әйтергә ярамаганны әйттерәсез. Бу Козлов бит аның ире.

– Чынмы? Вәт ишетмәсәң – ишет!

– Бу Козловтан барысы да туйган инде. Тик ул, чынлап та, китәргә теләми. Акчаны ул барысыннан да күбрәк ала. Виктория Авдеевнаның үзеннән дә. Аның ирен эштән җибәрергә теләвенә беребез дә ышанмый. Алар тик комедия коралар... Хәзер үзегезнең нинди уңайсыз хәлдә калганыгызны аңлыйсыздыр инде. Сезне Иваненкодан ваз кичтереп, Козлов әле тагын берничә ел акча эчендә йөзәчәк. Директор һәм аның яраннары моңа һич каршы түгел. Менә комедиянең финалы кайда, абый кеше!

...Бастам карт хәзер шикләнми инде. Иваненко мәктәбендә аның катнашлыгында уйналган вакыйга чынлап комедия булган. Тик аның режиссёры кем соң? Мәгариф башлыгы Шәмгуновның Зирекледәге хезмәт укытучысына карата бирелгән әмерләреннән кер эзләргә кирәкмәс. Боерыкларны башкаручылар, аларны җил уңаена карап үзләренчә үзгәртүчеләр дә бар бит әле. Инспектор Карачурина Бастам тирәсендә ник интригалар корды, нәрсә исбатларга теләде – аңламады ир. Ләкин педагог алдында бу чибәр ханым бөтен эчке дөньясы белән ачылды. Чынлап та нигә аңа күз талдырып, еракка карарга? Затлы тун, тәмле аш, калын кесә хакына аның педагогика мәнфәгатьләрен генә түгел, иманын да сатарга әзер икәненә Уразов үзе шаһит булды бит. Әйе, мәгарифтә барысы да ачык, тугрылык

та хыянәт тә. Намуслы ирләр тыштан ялтырый, эчтән калтырый торган замана педагогикасыннан ерак булырга тырыша. Басынкы Бастам Сираевич та беренче сентябрьне, белем бәйрәмен эшсез кеше сыйфатында каршылады. Ни аяныч, Уразовлар гаиләсендә укытучылар династиясе бик кыска гомерле булып чыкты.

**5**

Кулы бик күп эшләргә ятса да, Бастам даими хезмәт урынын бик озак эзләде. Дөрес, көнлекче булсаң, авылда эш муеннан. Кемнеңдер өй түбәсен ябарга, кемгәдер тәрәзә куярга кирәк, кемдер су насосы куярга кеше эзли. Түләү хакы да яхшы, рәхим итеп килеш кенә. Тик хезмәт укытучысы шәкертләреннән оялды. Әйтерләр, син абый дәресләрдә бик матур сүзләр сөйләдең, ә үзең «акчаны бик яратасың икән ләбаса! Көнлекчеләрне халык, гадәттә, «шабашник» дип атый. Бастамның мондый адәм кыяфәтенә керәсе килмәде. Теләге колхозга, яисә башка берәр кооператив хуҗалыкка, дәүләт учреждениесенә эшкә урнашып, авыл халкы, җәмәгатьчелек белән бергә яшәү ягында булды.

Эш эзлим дип, теге сертотмас үрдәк кебек ниятеңне гавамга таратмассың бит! Беркем белән дә киңәш-фәлән тотмады, моны балалары Наил белән Гөләндәмгә дә белдермәде, башта хәтта хатыныннан да чын максатын яшереп, авыл хәлләрен белешеп, урап кайтыйм әле, дип кенә чыгып китә иде ул.

Үзләренең «Бүләк» колхозы өлгергән социализм чорында гына гөрләп яшәп яткан икән. Ир иң элек әрәмәлек ягында, аулакта урнашкан техника паркына килсә, анда элек малайлар күзен кыздырып торган «тимер атлар шәһәрчеген түгел, комбайн, трактор хәрабәләрен, ташландык сабан, чәчкечләр тезмәсен генә күрде ул. Монда соң җир сөреп, ашлык чәчүче кеше калмаганмы әллә дип аптырады Бастам. Шулвакыт янына мотоциклга атланган яшь ир заты килеп туктады:

– Саумысыз, Бастам Сираевич, сезгә дә тимер-томыр кирәк булдымы?

– Техника паркы хәзер шулай металлолом базына әйләнеп киттемени, энекәш? Төзек трактор, комбайн калмадымы?

– Әй, аптыратмагыз, Бастам абый. Хәзер бит һәркем үзенә бирелгән техниканы ызбасы кырында тота. Урлашалар.

– Приватизация ясаганнармыни?

– Әллә тагы... Моны сезгә механик Сөләйман абыйдан сорарга кирәк инде.

«Тимер атлар» тирәсендә гәп корудан файда юк иде, бүленәсе бүленгәндер. Югыйсә элеккеге хезмәт укытучысының комбайнда эшләргә дә, тәгәрмәчле һәм чылбырлы тракторларны йөртергә дә хокукы, ягъни таныклыгы бар бит.

Бастам ферма ягына борылды. Әмма күперне үтеп, калкулыкка күтәрелә башлагач та, аның күңеленә шик төште. Ферма ягы һәрчак сазлы, чокыр-чакырлы була иде. Ә хәзер тап-такыр, күптән йөрмиләр, димәк. Инде заманында Ямәл тавы ташыннан әрмән ирләре корып киткән галәмәт озын абзар янына якынлашкач, ир араннарның буш икәнен шәйләде. Җилләр генә сызгыра. «Хезмәткә дан» исемле район гәзитенең сводкаларында һәрчак савым буенча алдынгы урыннарда торган ферма юкка чыккан булып чыкты. Күрмәсәң – күр, Бастам, авылыңдагы хәлләрне! Мәктәпне япмасалар, башка укытучылар белән син дә, Зиреклене «Потёмкин авылы» ясап мактар идең, мөгаен.

Ир йөрәге чәнчеп куйды. Басу-кырларга да күз саласы килде аның. Йөзен кыр җиле сыйпап узды, борынына яшь үлән, чәчәк исләре килеп керде. Бодай, борчак та чәчәк ата... Игеннәр өлгереп, урып-җыю эшләре барган фасылда кырлар ямен тасвирлап бетереп булмыйдыр ул. Тик китаплардагы сокландырган Нәфисәләр, Сөмбелләр, Айсылулар бармы бүген?

Элек елга, чишмә буйлары, тау битләре бала-чага тавышы белән чыңлап тора иде. Ә хәзер табигатьнең бу почмагында да үле тынлык. Хәтта элеккечә янчык

тотып, дару үләннәре җыеп йөрүче карчык-корчык та юк. Арба тартып, кәҗәсенә үлән-печән алып кайтучы бабай сыңары да күренми.

Авылның хәлен белешергә чыккан ир тәмам бетәшеп кайтып егылды:

– Зирекле беткән бит!

Мәгәр иренең уфтануына Розалия дәшми кала алмады:

– Һе, яңа белдеңме, авыл бетмәсә, мәктәбегезне япмаслар иде. Монастырьдагы монахлар сыман йомылып яттыгыз ласа. Авылны коткаручы ир табылмады. «Ашау – байдан, үлем – Ходайдан» – син яраткан әйтем түгелме, җанкисәк? Тик байларыгыз кайда соң хәзер?

Берничә көн үтеп, ис-аңга кигәч, Бастам үзләренә алты чакрым ераклыктагы башкорт авылы Ишлегә юл тотты. Монда элек мактаулы җиләк-җимеш питомнигы бар иде. Озак еллар башлык булып торган Илморза Каюмовны Зирекледә «Җәннәт бакчасы»ның хуҗасы итеп хөрмәт итәләр һәм бигрәк тә яшьләр, ул чакыргач, эшкә бик теләп баралар иде. Бакчада җимеш-җиләк белән сыйланасың, учка акча дигәне дә тама... Җиләк-җимеш пешкән чакта эшче кешегә һәрчак кытлык, эш бирсәләр, машина белән йөрермен, дип уйлады ир.

Шөкер, питомник исән-сау булып чыкты... Тик ул элек дәүләт карамагында булса, хәзер эшмәкәр кулына калган икән... Юантык кына ир уртасы кеше Бастамны ачык йөз белән каршы алды:

– Эш эзлисезме, агай? Бар бездә эш, тик башта һөнәрегезне әйтегез. Таныклык-фәлән бардыр бит? – Әмма хуҗа кеше хезмәт кенәгәсен алып, аның битләрен актарып карагач, ачык йөзе кинәт сүрелде: – Алай икән... Шофёр, экспедитор, исәп-хисап кешесе булсагыз, берсүзсез алыр идем. Укытучы кирәкми, мәктәптә дә вәгазьләреннән туйдым.

Кантурда эш кәгазьләренә кул куйдыртып, бер кыз бөтерелә иде, шуның көмештәй чыңлаган тавышы колакларны иркәләде:

– Һай, Идият Гәрәевич, шундый чибәр абыйны кире борасызмы? Ал, ал, безгә бригадир ясап куй! Укытучы кеше тәртип ярата ул! Гаделлек тә булыр...

Ир кызның бу сүзләрен ничек бәяләргә белми тора иде, нәчәльник кинәт теш аркылы сыгып чыгарды:

– Ш-шут-ка!

Эш эзләүче ир Ишле питомнигыннан да китек күңел белән кайтты. Мәгәр ниятkә кул селтәү урынсыз иде. Яңа көн тугач, Бастам машинасын яхшылап карады да урман эчендәге Күтәрмә авылына юл тотты. Монда зур гына леспромхоз бар, бәлки эш дигәнең шунда табылыр?

Озын юл үтеп, Күтәрмә җиренә килеп кергәч, Бастам шаккатты, элек кечерәк бер заводныкы кебек гөрләп торган корылмалар, пилорамнар, төрле агрегатлар, механизмнар тынлыкка чумган. Чыш та юк, пыш та... Капкасыз койма янында эт оясы бар икән. Бастам килеп: «Һәй, кеше бармы?» – дип сөрән салгач, аннан чылбырын сөйрәп, аюдай зур, йонлач маэмай килеп чыкты да өрә башлады. Ниһаять, әллә каян мылтык тоткан бер карт пәйда булды:

– Полкан, тукта! Күрмисеңмени, бүре түгел, кеше! – Бастамны ул баштан-аяк күздән кичергәч, кырыс кына әйтеп куйды: – Нишләп монда йөреш? Запрет зона бу!

– Адаштым, юл күрсәтүче кирәк! – дип, теленә тәү килгән сүзне әйтте ир.

– Булыр-булыр, арт яктан килгәнсеңдер. Анда үземнең дә юлдан язган бар. – Карт озын торбалы бинага төртеп күрсәтте: – Әнә Уфа юлы, шунда чык, күрсәткечләр юнәлешеңне тиз таптырыр.

– Рәхмәт, абзый, монда берәр нейтрон яисә газ бомбасы ташлаганнармы югыйсә, дип шүрләп калдым. Кеше заты беркайда күренми. Ни булды?

– Ни булсын, банкротлык галәмәте. Хәзер шулай бит, өстәгеләр үзләренә

кулай булмаган предприятиене финанс көрчегенә китереп териләр дә корбан итен бүлешә башлыйлар.

Карт ялгызлыктан туйган булса кирәк, тыңлар кеше тапканга сөенеп, эчен бушатты:

– Әле без, Алланың рәхмәте, байтак яшәдек. Күрше-тирә леспромхозлар исә 10-15 ел элек җан тәслим кылдылар бит. Иван Сергеевич дилбегәне тартып тотмаса, без дә беткән идек. Урыны оҗмахта булгыры... Башы эшләде. Польшага такта озаттык, аннан алма җибәрделәр. Ә без аны калада сатып, акча эшләдек. Бартер шулай коткарды.

– Ә соң, абзый, бу хәрабәләр эчендә ялгызың гына дөнья көтмисеңдер бит? Этең бар-барын...

– Эт минем шәп, самый урманныкы! Тирә-якта бүреләр ишәйде бит, өерләре белән килә. Вак-төяк этне буалар да сыртларына салып алып китәләр. Ә бу көчле, йөрәкле. Бүренең үзен чинатып баса. Килергә куркалар. Син дөрес әйтәсең, Полкан миңа чын иптәш.

Заманында Күтәрмәдә халык күп иде, тик эшсез калгач, калага сыптырды. Мин генә, юләр, бүрәнә була торып, урманга кирпеч ташыдым, өй салдым. Хәзер сатып та булмый, сүтә дә алмыйм үзен. Ятам каравыл акчасына алданып.

– Алай икән... Абзый, монда нинди эш башкардыгыз соң?

– Экономист идем. Дипломым да зурдан, башкаланыкы... Нишлисең, югарыдагылар бәхет дигәнен кызгандылар бугай, яудырмадылар...

– Абзый, түз, кеше башына нинди генә афәтләр килми... – Бастам, картның хәленә кергәндәй, кулына кагылып алды: – Бирелгәне түгел, яуланганы мәртәбәлерәк! Шагыйрь әйтмешли, яшәргә тик яшәп өйрәнәбез!

Ир күрсәтелгән олы юлга төшеп куалый башлагач, машина гөрелтесен баса төшеп әйтеп куйды:

– Педагог, менә сиңа проблемалы ситуация, хәл-әхвәл. Рәхим итеп чиш! Без, беркатлы зыялы, ил-көндә берәр ЧП килеп чыкса, халыкны гаепләдек, адәмнәр тегенди, адәмнәр мондый, тәрбия җитми, янәсе. Аннан үзебезгә ябыштык, дәрвиш сыман үзебезне кыйнадык, камчы белән генә түгел, аркан белән ярдык – кешеләргә тәрбия бирә белмибез, имеш. Юк, ак эт бәласен кара euкә ташлау гадәте бу. Ә балык башыннан чери... Өстән череп төшә. Шул хакыйкатьне аңламый торып, проблемаларны хәл итәргә була дип хыялланма да син, педагог!

Өйдә берничә көн балтасы суга төшкән кебек йөргәч, Розалия дә иренең хәлен аңлады булса кирәк:

– Куянлыдагы Илфир кырына барып кара. Фермер ул, эшләре әйбәт кенә бара, диләр, бәлки эшкә алыр. Безнең авылныкы бит ул, мөгаен, укыткансыңдыр да. Хәтерләмисеңме?

– Фамилиясе ничек?

– Ялалов булса кирәк.

Заманында шундый фамилияле ир авыл советында секретарь булып эшләгән иде. Илфир шуның улы булып чыга, күрәмсең...

Укучы буларак, ул аны хәтерендә җанландыра алмаса да, Бастамның күңелендә чаткы кабынды: «Барырга кирәк, авылдаш та булгач, бәлки мәсьәләне хәл итәр фермер».

Әйе, юраган юш килде, Илфир шул секретарьнең улы икән. Хуҗалык та мирас булып, әтисеннән калган аңа. Тик атасы чандыр гына гәүдәле булса, улы ифрат озын буйлы икән. Колгадай укучы укытучының хәтерендә калмый булмас иде, әмма танышкач аңлашылды. Бастам укытуга керешкән елны Илфир сигезьеллыкны инде тәмамлаган булган.

– Бастам Сираевич, хәлегезгә керәм, бик кыен хәлдә калгансыз. Тик кая, ничек

урнаштырыйм соң? Безнең эш сезгә ят өлкә, ят һөнәрләр дөньясы бит. Шуның өстенә эшче көчләр белән штат тулы, берсеннән дә зарланмыйм, Ходайга шөкер!

– Ярый алайса, Илфир, алда да эшләрең уңайлы барсын, – дип, Бастам авылдашына кул сузган иде, күңеле кителеп китмәсен өчен генә әйтим дигәндәй, фермер салкын гына әвәләп куйды:

– Дипломлы укытучы була торып, көтү көтмәссең бит инде...

– Сыер көтүеме?

– Әйе!

Көтүчеләре олы юлда машинасы белән авариягә эләгеп, хәзер больницада ята икән. Аяклары сынган, ди.

– Көтүче булырга җиңнәрен сызганып торучылар бар-барын, әмма куярдайлары юк. Бер тәкъва мәчет картына малларны ышандырган идем, куыш ясап яткан бу, намазга оедым, ди. Бу оеган, ә бандитлар бик затлы нәсел сыерын суеп алып киткәннәр. Каен посадкасында башы, тояклары, карыны гына торып калган. Акырып елыйсылар килде. Трудовой договор тутырмаган идек, теге оятсыз үзе миңа бәйләнә башлады: «Мәчеткә фитр сәдакасы бирмәгәнсең, биргән булсаң, Аллаһу сиңа җәза җибәрмәгән булыр иде», – ди юньсез.

Сыерларны әлегә савымчылар чиратлашып көтәләр икән. Илфир бу хакта әйткәч, нишләптер Бастамга текәлеп торды:

– Көтүче табылса, хакыннан тормас идем...

Әмма укытучы затының моңа исе дә китмәде:

– Һай, дускай, борчылма, сыерларың булгач, көтүчесе генә табылыр... Әле менә бер мал-мөлкәтсез калып та, өметне өзгән юк Гудбай!

Һәм ул, машинасын кабызып, кайтыр юлга төште.

«Бу Ялаловлар сарык тиресе ябынган бүреләр ләбаса! Атабаш сәвит милкен, халыкныкын имеп, фермерга әйләнгән. Ә улы авылда чын алпавытка әверелмәкче. Ил-көнгә игелек күрсәтелмәгәч, тешләрен ыржайтып, явызлык баш калкыта, каракныкын бур урлый», дип ярсып уйланды ул.

Ярый, эш тәтемәде... Күңелдә генә нindidер юшкын калды.

«Авылдаш уйлагандыр инде, бу да укытучы, дигәндер... Нишләп барысы да кире килә соң аңа? Кемдер эштән кача, ә ул аны эзләп тә табалмый. Нишләп?»

Ир күңелендәге бу сорау өргән шар сыман бүселде, машина эче кысан булып китте. Ул машинасын сүндерде дә төшеп, җиргә басты. Үргә менеп җиткән икән, тирә-юнь уч төбендәге кебек ап-ачык булып күренеп ята. Әнә бу төбәкнең горурлыгы булган Агыйдел елгасы, әнә тау битендә урман-кырлар тезмәсе; әнә машиналар, автобуслар һәм тагын әллә нинди көпчәкләрне тәгәрәтеп, бер офыктан икенче офыкка йөгергән олы юл... Бу – аның төяге!

«Әйт миңа, туган җир, мин сиңа читме, үгиме? Әйе, ишетәм, җилләрең колакка пышылдый... Мин – синең туфрагыңнан яралган, чишмәң суларын эчеп үскән газиз улың... Алайса, әйт миңа сәбәп нидә соң? Ник чәчелгән иген бөртеге, кодрәтле чыршы, карагай, асыл каен агачы, яисә хуш исле болын чәчәге сыман туган җиремә берегеп, тернәкләнеп үсеп китә алмыйм мин? Әллә баш очымда нindidер явыз рух торамы?.. Кара кош козгын кыяфәтенә кереп, мине күзәтәме, яисә җирдәге иблис, албасты булып, ихлас ниятләремә аркылы төшәме? Аның миңа билгеле булмаган мәкерле планы бармы?»

Бастам күккә текәлде, ихтыярсыздан куллары йодрыкланды. Безнең хәят белән янәшә башка үлчәмдәге дөнья яшәве хак булса, ишетсеннәр:

«Юк, көчәнмә, Явыз рух! Ничек кенә ниятемә, максатларыма аркылы төшмә, мин үземнең кендек каным тамган газиз туфрагымны ташламыйм... Көтмә, син белмәгән җирсенү тойгысын иман иткән кеше мин!»

Ир кайнарланып, машинасына утырды һәм янәдән Куянлыга сыпырды.

Илфир конторында, калькуляторына баса-баса, исәп-хисап ясап ята иде. Бер киткән кешенең янәдән пәйда булуын шәйләп, сүз әйтә алмый торды.

– Мин сыерларыңны көтәргә булдым. Таңнан киләм, чыбыркыңны әзерлә!

Бастам бераз уйланып торгач:

– Бу хакта хәтта җыр да бар бит, – диде: –

*...Әнкәй таңда мине уят әле,*
*Киң даланы томан сарганда,*
*Чөйгә элгән ияремне алып,*
*Ат көтәргә барам тагын да..*

Бастамның моңлы тавышын ишеткәч тә, фермер калькуляторын онытты... Гади бер җыр гына түгел иде шул бу башкаручы өчен, җырга кушылып аның чарасызлыктан сыктаган күңеле дә елады, бушанды бугай.

– Җырда ат көтсәк, тормышта менә сыер көтәргә туры килә, дустым, – дип көлемсерәде Бастам, җырын тәмамлагач.

– Тавышыгыз моңлы, җыры да шәп, – диде Илфир, – тик ишеткәнем юк.

Ниһаять, Куянлы фермеры белән элеккеге укытучы кул сугыштылар:

– Хәерле сәгатьтә!

**6**

Бастам Сирай угылы һәмишә гаҗәпкә кала, теге вакытта ничек җилкәсенә чыбыркы асып, көтү көтәргә ризалашты соң ул? Укытучы башы белән... Ничә ел мәктәптә эшләп... Елына бер-ике тапкыр чират көтүенә чыгарга туры килсә дә, хәзерге ир заты әллә нинди сәбәпләр тапса табар, әмма кулына чыбыркы алмас. Хатыны көтүче ялларга мәҗбүр була. Элек-электән килә, көтүче – авылдагы иң хурлыклы кәсеп. Әнә, көтү көтәр кеше булмагач, елгыр эшмәкәрләр кала кибетләренә электр көтүчесе чыгарганнар. Әмма берсе дә электрон бухгалтер уйлап тапмаган. Бу шөгыльләргә вакансия дә юк.

Зирекле халкы да Бастамның Илфир фермерга көтүче булып ялланганын ишеткәч, бот чапты. Һай, замана! Билгеле, һәркем үзенчә юрады. Казан федераль университетының журналистика факультеты студенты Фәрзәнә Юзиева исә район гәзите «Якты көн»дә бик хисләнеп язылган «Хурлык тактасы» дигән мәкаләсен бастырып чыгарды. Халык аны кат-кат укып, аерым цитаталарын хәтта яттан сөйли башладылар.

«Мин кыз бала булсам да, Бастам абыйдан кадак кагарга өйрәндем. Чүкечне хәзер шәп тотам. Унлыкка, мылтыктан аткан сыман, нәкъ кирәк җиргә тондырам. Бүгенге мәгариф өлкәсендә мин әнә шул сугасы урыннарны эзлим. Хәер, сабыйларны туган телне өйрәнүдән мәхрүм итеп, Кол Гали, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, герой-шагыйрь Муса Җәлил кебек бөек әдипләребезне укучылардан читләштереп, «оптимизация дигән матур сүз артына кача-поса, мәктәбебезне ябып һәм бу яман эшнең иң соңгы рәвеше булган хәл – сөекле укытучыбыз Бастам Сираевич Уразовны көтүче хәленә төшереп, бездәге мәгариф үз-үзен хурлык баганасына кадаклап куйды».

Фәрзәнә Юзиева мәкаләсе район җитәкчеләре арасында зур шау-шу куптарган, диделәр. Хәтта редактор Шаммасовны эштән алу мәсьәләсе дә көн тәртибенә куелган икән. Әмма ала алмаганнар, чөнки илдә плюрализм, ачыклык заманы. Хәтта аерым башкалада мәйдан уртасына палатка корып, суверенитет хакына ачлык игълан иткән фидаиләр бар. «Проблема туган икән, аны хәл итәргә кирәк. Чирен яшергән – үлгән, диләр. Бүгенге җитәкчеләребез чынбарлыкны яманатлы Потёмкино авылы хәленә төшермәскә чакыра», – дигән «Якты көн» редакторы. Зирәк Шаммасов үзен-үзе аклап кала алды.

Бастам карт хәтеренә зарланмаса да, бер хәлне исенә төшерә алмады: көтүче янына кырга мәгариф башлыгы кайчан килде, гәзит мәкаләсеннән соңмы, әллә алданмы?

Бастамның эшкә керешкән мәле тасмадагы кебек ап-ачык. Әйләндерергә генә кирәк. Кояш кул ясуы күтәрелгәч тә, Куянлыга килеп төште ул. Ферманың җаваплы кешесе Зәрия туташ аңа ручка тоттырды һәм журналын ачып, кул куйдыртты:

– Менә абый, син безнең 92 сыерны кабул итеп алдың һәм кичтән 92 сыерны алып кайтып, миңа тапшырасың. Мин дә синең кебек: «Алдым», дип, имзамны куярмын.

«Алдым-бирдем» һәр көн мәҗбүри булыр, абый. Аңлашылдымы?

– Ә чыбыркы кайда?

– Әй, Гөлсинә, китер чыбыркыны! Кичә син көткән идең бит, кайда ул? – дигәч тә, каяндыр эзләп табып, Бастамга әлеге коралны китереп тоттырдылар һәм ир көтүе белән яланга юлланды.

Һай, Бастамның беренче көндә күргәннәре! Аякларың түзсен дә, нервларың шартламасын! Хәер, дөресен әйтсәң, көтүче белән укытучы, бигрәк тә уңмаганы, бер үк сандалларда чүкелә торган затлар. Сабак тыңламыйча төрлечә маймылланып утырган балалар белән йә яшел ышык урман посадкасына, йә ерактагы саргылт бодай басуына элдертергә торган азгын сыерлар арасында аерма бармы? Юк! Әлеге затларның һәр икесе дә мазаны тигез корыта. Бу Бастамның икенче көндәге ачышы булды. Ә өченче көнне Илфир аңа ат китереп тоттырды.

– Авылдаш, аякларыңа җиңеллек булыр, менә теләсәң атлан, теләсәң, арбага җик, сиңа транспорт!

Ат Бастамга беренче күрүдә үк ошады. Җирән кашка! Тегесе дә һич ятсынмый, көрән күзләрен ялтыратып, башыннан сыйпаучыга карап торды, битләрен иснәштерде. Ир түзмәде:

– Йә инде, Җирән кашка, бер кешнәп тә күрсәт инде! – дигән булды.

Бу тамашаны кызыксынып карап торган фермер әйтеп куйды:

– Уртак тел тапсагыз, көтүне бергә көтәрсез! Көзгә чаклы... Чыбыркы сөйрәп йөрмәсәң дә була.

Әйе, аның мәгариф башлыгы белән очрашуы да беренче тапкыр Җирән кашкага атланып, эшкә чыккан көндә булган... Ярый әле, шөкер, Шәмгунов аны чыбыркы сөйрәп, тирләп-пешеп, азгын сыер артыннан чапкан мәлендә күрмәде, югыйсә җир тишегенә кер дә кит. Хәер, карт нигә бу хакта баш вата? Башлыкның яланга кайчан килүе түгел, ә ни өчен килүе мөһимрәк, мөгаен...

Кыр юлында бик әйбәт машина туктап кычкырта башлагач, көтүче үзен чакыралардыр дип башына да китермәде. Машинадан бер ир заты чыгып, аңа кул изи башлады, димәк, үзенә дәшә. Бәй, Шәмгунов бит бу! Бастам аның янына ничек чаптырып барып җитүен дә сизми калды..

– Ну Уразов, ну Бастам, – диде ул, ирнең аттан төшүен дә көтеп тормыйча. – Холкың хакында ишеткәләгән булсам да, мондый юләрлек кылырсың дип уйламаган идем. Кешедән ишеткәч, үзем килеп күрергә булдым. Дөрестән дә, көтүчелеккә яллангансың икән шул...

– Эдуард Заһитович, эш мәсьәләсендә сез тәкъдим иткән ике вариант та барып чыкмады бит. Мин инде яшь-җилкенчәк түгел, район буйлап эш теләнеп йөрергә. Урнаштырырга теләсәгез, сентябрьгә тиклем мәсьәләне хәл иткән булыр идегез. Юк икән, юк! Фермерга бил бөгәм дә пенсиягә чыгам, исән булсак... Нәрсә, көтүче кеше түгелмени? Юкка килгәнсез, Эдуард Заһитович, мин әле кешелектән чыгарга җыенмыйм.

– Нык тондырдың, Бастам энем... Йә, тыныч кына сөйләшик әле. Әнә машинада кадрлар бүлегеннән кеше утыра. Аның папкасында документлар әзерләнгән. Син

көтүеңне тапшыр. Өеңә кереп, өстеңне алыштырасың да, Иваненкога китәбез. Директор вазифасына тәгаенләнәсең.

Килешәбезме? Син әле һаман безнең кеше саналасың. Иваненкода төпләнү өчен бер киртә дә юк. Урыс әйтмешли: «Вперёд!»

– Булмый, Эдуард Заһитович!

– Ник булмаска тиеш?

– Әгәр хәзерге кебек җыенып барган булсак, бәлки, килеп тә чыккан булыр иде. Ә мин анда бер бардым бит инде, «сукбай» булып, инспекторыгыз әйткәндер. Кеше көлдермик. Соңардык, Эдуард абый.

– Юк, һич тә соң түгел, энем. Козловлар өерен туздырдык. Директор бик зур финанс җинаятендә гаепләнә. Син хәзер бу мәктәпне күтәрүдә ярдәм итә алыр идең. Карышма!

– Эдуард Заһитович, миңа бу мәктәпнең җаваплы кешесе турыдан-туры әйтте: «Эшкә килә күрмәгез, бетерәчәкләр», – диде. Чынлап та исерек Козловның янауларын да ишеттем. Директорның бер интриганка икәнлеген ишеттерделәр. Коллективның череп таркалуын белә торып, нишләп башны кискәгә салыйм?

Һәм басынкы Бастам Җирән кашкасына сикереп менеп атланды да ялан буйлап сибелгән көтүе янына чапты.

Варисә Шаһи үзенең шефы хакында «еракка карый» дип әйтте-әйтүен, әмма Шәмгунов та үзеннән биегрәк сикерә алмый икән шул, чөнки ялгыз. Ә күтәрүчеләр юк. Чабатасын түргә элүчеләр заманы...

Нинди галәмәттер, мәгариф башлыгы белән очрашып, хезмәтенә бәйле кайбер шикләр ачыклангач, Бастамга җиңел булып китте. Җиз иләктән иләнеп төшеп калган икән, ни пычагыма кайгырырга? Димәк, укытучы, педагог булуы да ташка үлчим генә. Югыйсә эшем иясе булып заман хакында, сәясәт хакында, тәрбия кимчелекләре хакында баш ваткан булды. Хәзер инде күр, син шөреп тә, винтик та түгел, заман тәгәрмәчен әнә Карачуриналар, Шәмгуновлар әйләндерә. Кирәк икән, күтәреп алалар, кирәкмәсә, таптап узалар...

Кешенең тормышта үз-үзен дөрес бәяли алмавыннан да зуррак хата юк. Әнә хәзергә ике кулыңа бер эш – көтү. Шуны кайгырт, фермерга күбрәк табыш алырга ярдәм ит... Гаиләңне дә онытма!

Ә чынлыкта язмыш кешене кая гына ыргытмасын, ул асылын җуймый, һаман үз сыйфатлары белән кала икән!

Сирай улы тәртип ярата. Эшне җиренә җиткереп эшли. Мәсьәлә туса, уйлана: ни өчен болай, ә тегеләй түгел?.. Нинди дер хәлне чишәргә алынса, ул чын иҗатчы, канында иҗтиһад ялкыны дөрли. Әмма тыштан ул һаман сабыр, басынкы булып кала. Җиде кат үлчәп бер кат кисүчеләрнең берсе – ул!

Көтүгә чыгуның беренче көннәрендә өч-дүрт сөтлебикә Бастамны чыгырыннан чыгарды. Ярар, яшелләнеп торган урман, каен-чыршылы посадка бу азгыннарның нәфесен аздырсын да, ди. Малга да витамин кирәк бит. Әнисе бервакыт кәҗә асраган иде. Аның бәтиләре кышын туа һәм тернәкләнгәнче өйдә тоталар иде. Берьялгызы өйдә калган малай күңелен бу тояклы дуслары яулап алды. Мич артыннан чыгарылган бәтиләр пыр тузып чабышалар, тегендә-монда сикереп меңәләр, ә нәрсәдер ошамаса, тоякларын типкән булалар... Бастам аларга әнисе калдырган ризыкны бирә. Әмма иң яратканнары – юкә миннеге. Сыерларны да ниндидер тәм-том тарта бугай.

– Зәрия, син әллә сыерларыңны кәнфит белән сыйлыйсыңмы? Күзләрен ферма ягыннан аерып ала алмыйлар. – Бастамның соравы яшь савымчы Рәгыйдәнең дә колагына ирешкән икән:

– Абый, Сез дә сиздегезмени? Өч-дүрт сыербикә минем дә теңкәмне корытты бит. Тоз сипкәннәрмени, гел ферма ягына каералар. Нигә икән?

– Нигә булсын? Илфирга сөт күп кирәк, комбикормны жәлләмәгез, салыгыз, ди. Алларына капчыклап сибәм. Шул сый тел төпләреннән китми дә инде бахырларның, гел фермага тарта. Инде белдегезме? – дип аңлатып бирә Зәрия.

– Менә хәзер белдек инде. Алайса улакларын таборга илтеп куярга кирәк. Сыйлансыннар да, аннан ял итәрләр, шулаймы, Рәгыйдә?

– Шулай, шулай, Бастам абый, – дип, тегесе пичәт сугып куя.

Нигезле булгач, бу тәкъдимне фермер да хуплады. Шул көннән соң тәм-том белән сөтлебикәләрне җәйләүдә сыйлый башладылар. Чынлап та малкайлар тынычланып китте. Зәрия дә сөтнең артып китүен көтүчегә җиткерде:

– Абый, дәресләрегезнең файдасы тиде бит. Сыерларның сөте артты!

Бу чая хатынның сүзләрен күңеленә якын алмады Бастам. Мәктәптә дәресләр бирүдән туктап, малчылар, савымчылар белән аралаша башлаган мәлдән ул үзендә сәер бер тойгы уянуын сизде. Әйтерсең лә ир моңа чаклы кенәри кошчык кебек читлектә яшәгән, андагы яшәү шартларын шулай тиеш дип кабул иткән һәм шуңа күнгән...Укытучы бит ул! Аның һәр сүзе, һәр гамәле алдан уйланылган һәм әдәп нормаларына туры китерелгән булырга тиеш. Мәктәптән чыккач та, педагог тугарыла алмый: «Кара, укытучы башы белән ни сөйли бу?» Үзе укытучы, балалар тәрбияли, ә үзе ни кылана, оятсыз!» – дип әйткәннәрен ишетмәс өчен чын педагог телен һәм ихтыярын бәйдә тота.

Һәм менә Бастам Сирай улы көтмәгәндә читлектән чыкты, кысалардан аерылды. Аты-заты белән сүгенүче мал карауч Галиулла яисә башбирмәс сыерына ямьсез итеп кычкырынган Сәрвәрнең тамак яруларын ишетмәс өчен хет колакларыңа мамык тык!

Чын тормыш шулай була икән ул... Мондагысы бер көйгә, кыңгыраудан-кыңгырауга һәм төзелгән план белән бара торган романтик, педагогик хәят түгел, ә үтә драматик, кискен алмашынулар белән тулы кырыс чынбарлык... Монда яшәр һәм югалмас өчен кешегә бар сәләтен, җегәрен файдалана белергә кирәк! Тормыш – көрәш ул.

Кичәге укытучының миенә, ниһаять, бормалы шөреп кебек булып, шул хакыйкать кереп утырды. Бастам чын тормыш кануннары белән яшәүче кешегә әверелде, чөнки аның төп максаты – кешелеклеген саклау иде.

## 7

Сөтлебикәләр белән мавыгып чын дусты, хезмәттәшенә әверелә барган Җирән кашка арткы планга күчте шикелле... Югыйсә ул әллә кайчангы кәҗә бәтиләрен сагынып сөйләп ята, ә мине искә алырга да теләми дип, Бастам картка үпкә белдерер төсле.

Юк, элеккеге остаз чын дуслыкның кадерен белә. Бу хис булмаса, ул Җирән кашканың камытын имләп утырыр идемени? Нәкъ менә Җирән кашка ярдәмен тойды ул дөньялыкны танып белүдә. Сандугачлар моңын тыңлый-тыңлый, күпме сихри иртәләрне иярдә каршылады бит. Мөгаен, сыбайлы ата-бабалар да күзләрне иркәләгән рәшәле кырлар, үзәннәрнең күркен шулай түкми-чайпалдырмый, күңелләренә салып куя торган булганнардыр. Матурлыкны күз белән генә күрү җитми, аны күңел белән дә тоя белергә кирәк шул. Бер сүз белән әйткәндә, Җирән кашка Бастамны гаугалы, ыгы-зыгылы эш мохитеннән тартып алды һәм табигать баласы ясап куйды. Шунысын да онытмыйк: әлеге чаптар булмаса, Бастам халык теленә «ковбой» кушаматы белән керер идеме?

Кызык кына килеп чыкты бу хәл. Әбиләр чуагы җитеп, кояшлы җылы көннәр тезмәсе башлангач, Куянлы фермасы көтелмәгән бер хәлгә юлыкты. Сыерларга тамыразыкларны күпләп биргәч, сөт артты, ә аны кулланучыларга җиткерү

авырлашты. Глазово сөтчелек комплексына базар кирәк. Сөт файдалы эчемлек, ашамлык кына түгел, товар да. Аны сатарга да кирәк, бу исә җитештерүчеләр арасында һичшиксез конкуренция тудырачак. Базар шартларында юкка чыкмас өчен нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Атап әйткәндә, Мәчкәрә сөт заводы, кибетләр, ашханәләр, Куянлы фермасының продукциясен кире какмасыннар өчен ниндидер чаралар табарга кирәк! Хәер, берсе дә кул кушырып утырмый. Илфир һәркөн тегендә-монда шалтыратып, заказ өчен көрәшә. Савымчыларның, малчыларның уенда сөтнең сыйфатын төшермәү. Ә көтүче нәрсә эшли ала? Һәм Бастам маңгаена сугып алды. Ковбой! Син бит – ковбой. Ир сынаулы карашын Җирән кашкага текәде. Тегесе иренеп кенә, тал ышыгында солы чиләгендә чемченеп ята. «Ә син кем? Будённый аты түгелсең, Пржевальскийныкы да, гарәп чаптарына рәвешең килмәгән.

Бәләкәйсең, җирәнсең, әмма үтә дә түземле, чыдам башкорт аты син... Коеп куйган ковбой аты! Әйдә, дустым, безгә дә сәхнәгә менәргә вакыт!

Ир эштән кайткач та, хатынына әйтте:

– Иртәгә кибеткә барып, киң кырлы эшләпә сатып ал! Америка киноларында күргәнсеңдер... Джинсы күлмәк-чалбар да зыян итмәс.

– Нәрсә инде эшкә күңелем ятты дигәндә, әллә Америкага җыенасыңмы? – Розалиянең тавышында ихлас гаҗәпсенү чагылды. – Бездә берәү киткән иде, Венер исемле. Хәзер ничек кайтырга, дип елый, ди. Шуңа сыңар буласыңмы?

– Юк ла, образга керергә... Форма өчен!

– Кинога төшәсеңмени?

– Почти.

– Кинога төшсәң, режиссёрың тапсын. Миңа акча кайтарганың бармыни?

Хатын кәҗәләнсә дә, эшләпәнең менә дигәнен табып кайтты. Джинсы кием гаилә шкафында да җитәрлек. Искерә төшкән булуы әйбәт тә, иң мөһиме ирнең тәненә ятып тора. Ир көтмәгәндә, чын ковбой булды да куйды!

– Сине хәзер Голливудка җибәрергә генә калды, җаный, – дип, Розалиясе дә сокланды.

– Оператор табасы бар әле, – дип көрсенде Бастам.

– Оператор? Төшерә торганмы? Сине мактаган Фәрзәнә авылда икән әле. Шуңа әйтеп кара әле.

Сукырның теләгәне ике күз дигән сыман Бастамның да эшкә ашмастай тоелган теләге дә анык рәвеш алды. Фәрзәнә Юзиева журналистика буенча Светлогорск төбәк телевидениесенә практикага кайткан икән. Сөйкемле кыз элекке укытучысы чакыргач, бик теләп, клубка килде.

– Фәрзәнә сеңлем, чүкеч тотып, кадак кагарга өйрәнүең өчен маладис! Әмма бу чак син укыган заманча һөнәргә ихтыяҗ зуррак, тагын бер маһирлыгыңны күрсәт инде, – дип үтенде Бастам. Аннан инде булачак каләм остасын идеясе белән таныштырды.

Кызый шундук эләктереп алды:

– Шәп бу, абый, шәп! Куянлы көтүчесе халыкка безнең якның сихәтле сөтен тәкъдим итәме? Дөресен әйткәндә, миңа барыннан да бигрәк, утта янмас, суда батмас кеше образына керүегез ошый. Ковбой... Сыбайлының заманча сурәте бит бу!

Иҗат кешесенең дулкынлануы – элекке остаз өчен таныш тойгы. Өч көн үтмәде, Куянлыга Светлогорск телевидениесеннән эш группасы белән Фәрзәнә Юзиева килеп тә төште. Көтүне җәйләүгә озату мәленнән алып, кич көтү кайтып, савым төгәлләнчегә кадәр операторлар аппаратларын җилкәләреннән төшермәделәр. Блокнотын тоткан Фәрзәнә күбәләк сыман әле тегендә, әле монда талпынып, аларга туктаусыз күрсәтмәләр биреп йөрде. Барысын да төшерделәр. Берсе дә

объективтан читтә калмады. Фермадагы көтелмәгән ыгы-зыгыда, өрергәме, юкмы дип аптыраган Дүрткүз дә хәтта кинога төште.

Төртмә телле Сәрвәр эндәшмичә каламы соң?

– Элегрәк килгәннәр кем кирәк, шуны «шылт» итеп төшерә дә, салып биргәнне тиз генә йотып куеп, фермадан шыла иделәр. Сәрвәр кебекләр чутка да, исәпкә дә алынмый иде. Инде миннән дә сөйләткәч, белегез, Фәрзәнә нидер майтара, кызлар!

Фермадагы эш барышында Бастам бик күзгә-башка чалынмаска тырышты. Фәрзәнә һәм көрәк сакаллы рус ире аның белән яланда эшләделәр. Җирән кашкага атланган ковбой көнозын алар карамагында булды. Ничек килеп чыккандыр, әлегә моны тик төшерүчеләр генә белә. Хәер, азактан оператор «ковбой»ның аркасыннан сөеп әйтте әйтүен:

– Молодец! Ты очень фотогеничный! Тебе только в фильмах сниматься...

Озак тотмадылар, рәхмәт төшкерләре! Эшкә керешүләренә бер атна да үтмәде, Светлогорскийдан Фәрзәнә шалтыратты:

– Абый, иртәгә пәнҗешәмбе көнне, кичке тугызда безнең репортажны карагыз... Борчылмагыз, әйбәт, диделәр.

Ниһаять, Бастам әйтелгән вакытта телевизорлары каршына килеп утырды. Нинди сәгать булыр бу?.. Кем әйтмешли, йолдызлы сәгатьме? Ковбой Илфир сөтенә товар буларак юл ачармы, әллә киресенчә, уңышсыз чыгыш булырмы зәңгәр экрандагы Фәрзәнә репортажы?

«Карагыз әле, карагыз, Куянлыдагы көтүче ковбой булып алышка чыкканмы? Кем белән алыша? диген... Меңәр баш сыер тоткан Глазово сөтчелек комплексы белән... Табылган Дон Кихот!»

Ир карашынча, репортаж әнә шул мөһим бурычны ачыкларга тиеш иде. Ләкин экранда Урдалы тау башында иртәнге кояшны каршылаган җайдакны күргәч тә, аның тәне чымырдап куйды. Бу кем? Илфирга ялланган көтүчеме? Әллә ковбой булып киенеп, туган җирендә көнне каршылаучы сыбайлымы? Күңелгә таң җиледәй килеп кагылган көй шик калдырмый шул!

*– Әнкәй, мине таңда уят әле,*
*Киң даланы томан сарганда...*

Ну, Фәрзәнә, яраткан җырыгызны әйтегез әле абый дип, юкка сорамаган икән... Көй бик кыска гына яңгырап алса да, образ өчен ачкыч булып торды.

Әнә ковбой сыерларны санап, капкадан озатучы Зәрия журналына кул куеп, малларны кабул итә... Әнә ул Җирән кашкасына менгән килеш малларның чыклы үләнне ашауларын күзәтә. Хәрәкәттә вакыт та аяклы, әнә кояш төшлеккә дә менеп җиткән... Малчылар белән бергә ковбой да сыерлар өчен улакларга азык таратып йөри: «Ягез, сөтлебикәләр, кайсы тәм-том сезгә тансык?» Ә тәмле аштан соң бераз черем итеп алу сыер халкына да фарыз. Тик аның да чамасын белергә кирәк. Әнә җәйләүдә кырыс чыбыркы тавыш бирә һәм ковбой янә сөтлебикәләрне яланга чыгара: «Ашагыз, малкайлар, мондый сусыл, татлы үлән тагын кайда бар? Сез эчкән саф, салкын чишмә сулары фәкать бездә генә. Сезнең җиленнәрдәге сөтне меңәр баш малны сыйдырган тынчу биналарда бәйдә асралган сыерларныкы белән тиңләргә мөмкинме соң? Бу чит илдән китерелгән порошокка су кушып сөт ясау һәм ясалма товарны алдап-йолдап кулланучыларга сату да түгел. Бездәге сөт – чын-чынлап табигать бәлзәме!

Үз исәнлеге һәм якыннарының саулыгы өчен борчылган кешеләр бары тик Куянлы фермасында җитештерелгән сөтне иң әйбәт продукт санар. Аңарга Җир әнкә үстергән шифалы үләннәрне суты, бәллүр чишмәләрнең көмеш суы сеңеп, даланың сихәтле сулышы бөркелгән...

Репортаж Куянлы сөтчелек фермасы савымчыларын, малчыларын эш барышында күрсәтеп тә, югары сыйфатлы продукт өчен нәтиҗәле эш алып барылуын раслады. Иң мөһиме: ул Илфир фермерны конкурентыннан коткарды. Глазоводагы сөтчелек предприятиесе үз товарын төбәккә ташудан туктады... Шул көннән соң халык җирән чаптарга атланган Бастам Уразовны ковбой дип йөртә башлады... Ул басынкы түгел, ә канатлы Бастам булып китте. «Ир канаты ат булыр» дип, борынгылар юкка гына әйтмәгәннәр икән шул.

**8**

Хәяткә кара көз иңеп, җиргә тәүге кыраулар төшкәч тә, Илфир сыерларны көтүгә чыгармый башлады. Болын, яланнарда яңгырлар белән курпы калыкты калкуын,тик аларның суты аз. Сөтлебикәләргә туклыклы азык белән җылы түбә асты кирәк. Шуның белән Бастамның да сезонлы эше төгәлләнде дияргә була. Әйтергә кирәк, фермер сүзендә торды, эшсез калган укытучыны кыерсытмады. Ир зур канәгатьләнү белән җыелып килгән хезмәт хакын хатыны кулына тапшырды.

– Сез минем коллективны тәрбияләдегез бит, сиздегезме шуны? Сез чынлап та педагог икәнсез, ышандым. Рәхмәт! – диде фермер, саубуллашканда.

– Тәрбия ике яклы гамәл инде ул. Кем кемне тәрбияләгәндер?.. Тик мин, Илфир дустым, «тәрбия» дигән төшенчәдән инде ераклаша барам. Буш, ялтыравык сүз, яисә еракта җемелдәп торган рәшә кебек тоела ул миңа. Ә рәшәгә, үзең беләсең, таянып булмый. Шуңа да тәрбиянең нәтиҗәсе дә аянычлы булырга мөмкин. Мисалга гаиләне генә алыйк. Чын ата-ана бервакытта да ул-кызына мин сине тәрбиялим, дип әйтмәс. Ә аны үстерер, чын кеше итәр өчен ниләр кылганын санап күрсәтер. Әйе, бала үстерү бик авыр, әмма изге эш. Шуннан чыгып, мин үзем педагогикада иң мөһим сүз – «тәрбияләү» түгел, ә «гамәл, изгелек кылу» саналырга тиеш, дип исәплим. Бу фикер тагын шуның белән дә ныгытыла, без «материализм» дип аталган бушлыкта яшибез. Кешене гамәл ача, ниндилеген гамәл билгели. Фәрештәләр дә бит адәм баласының нәрсә сөйләгәнен түгел, ә кылган гамәлен язып бара. Һәм гамәл дәфтәре безнең Аллаһу каршында кем икәнебезне ачып бирә. Шул бөек хакыйкатьтән чыгып канун чыгарылган бит: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер!»

– Кызыклы фәлсәфә бу! – Илфирның да бу темага сүз куертырга һәвәслеге сизелеп тора.

– Ә соң халыктагы, «Ит изгелек – көт явызлык» гыйбарәсенә ничек карыйсыз?

– Дөрес, «Ит изгелек – көт явызлык», әйе, бар андый нәрсә, үкенечкә каршы, безнең яшәештә киң таралган. Ләкин бу үзебездән, изге гамәлне бәяли белмәүдән, мөгаен. Явызлыкның төп яшәү чыганагы – наданлык, битарафлык дип исәплим.

Тик дөньяны сафландыру, ямьләү изгелек кылучылар кулында, дустым. Мин хәзер менә шуңа ышанам!

– Мин, Бастам Сираевич, тыңлап-тыңлап тордым да шундый нәтиҗәгә килдем. Сез Урдалы тау башында юкка гына уйга чумып утырмагансыз икән. Дала җилләре Сезнең башны тагын да ныграк эшләтеп җибәргән булса кирәк.

– Әйе, табигатькә чыгып, башны җилләтү беркемгә дә зыян итмәс иде... Мондый мөмкинлек биргән өчен үзеңә дә, Җирән кашкаңа да рәхмәт! Хәзер нинди эшкә кушасың инде үзен? Сәлам күндер үзенә!

– Кемгә? – диде Ильфир, аптырап.

– Соң хезмәттәшкә, Җирән кашкага!

– Ат турында сөйлисезмени? Нишләсен? Атна азагында төркем белән иткә озатам. Заводта атлар забое эшли башлаган....

– Иткә? Җирән кашканымы? Аның бит көч-куәте ташып тора. Нишләп гомерен чиклисез?

– Ә нигә аптырарга, миңа акча кирәк. Кешеләргә түләргә, салымга, кредитны кайтарырга. Ул аранда тора, хушлашасыгыз килсә...

Бастам хуҗага ни әйтергә дә белми ишек янында басып торды. Ә күкрәгендә очып чыгардай булып, йөрәге бәргәләнде: «Ит изгелек – көт явызлык... Мин яраткан Җирән кашкага да кагыламы бу җан өшеткеч канун? Чаптар, хезмәттәшемә тиң мал, товар гынамы? Кая килеп кердең син, нарасый педагог?»

– Илфир, үтенәм, ит заводына озатма Җирән кашканы. Мин аны сатып алам... Күпме сорыйсың?

– Шулай нык кызганасызмыни? – Фермер бераз уйланып торды. – Акча миндә бер букча, дисезме? Акчагыз үзегездә калып торсын әле... Тәкъдимем бар. Агыйдел култыгыннан печән кайтарырга кирәк. Байтак, 5-6 тонналап булыр, 7-8 көнлекче ялларга торам. Безнең шабашникларны беләсең, аларны эшләтердәй аек башлык кирәк. Кыскасы, таянырлык кеше эзлим. Әгәр әлеге эшне оештырсагыз, бу өч-дүрт көнгә сузылыр, мин Сезгә чаптарны бүләк итәм. Ризасызмы?

Җирән кашканың гомере турында сүз барганда сатулашып тору оят булыр иде, ир берсүзсез әлеге эшкә ризалашты.

Бастам Сирай улы «Пошилар утравы» дип аталган әлеге җирдән Илфир фермасына печән кайтаруны вагы-төяге белән инде хәтерләми. Әмма авырлыгы күңеленә сеңгән. Елга ягыннан килгән  әче җил, палаткада төн кунулар – бер хәл. Теңкәгә тигәне яр белән печән җире арасындагы сазлык булды. Кибәннәрне машина белән алып чыгу турында авыз да ачарга түгел. Буш арба белән утрауга керергә мөмкин, әмма йөк төягәч, куласа сазлыкка чума, аны сөйрәп чыгарырга тырышкан ат юл дигәнне изеп, эштән чыгара...

– Йә, Җирән кашка,бәлки син чыдамрак булырсың? – дип, Бастам бәйдәге аты янына килде. Аның аты башкаларныкына караганда җиңелрәк гәүдәле, түземлерәк тоела. Хәер, бу мизгелдә әлеге чаптар әкияттәге дөлдел атка әверелеп, могҗиза күрсәтсә дә, ир моны гайре табигый хәл итеп санамас – печән җирән кашка арбасында ярга чыгарылырга тиеш!

Ир үз гөманына үзе ышанып бахбаена арбаның иң җиңелен җикте, сазлыклы юлга чыбык-чабык түшәтте һәм арбаны да җиңелчә генә бастырыклап, аты белән кечү алдына килеп басты:

– Әйдә, малкай, изге ният, изге гамәл тормыш тәгәрмәченә ныклык бирсен!

Ир атны җитәкләде һәм йөгерә-атлый, алга омтылды. Ат та, әйдәүчесе белән бер тән, бер җан булып, кичүгә ыргылды. Тупас күләсәләр, музыка дөньясындагы җанга ятышлы нинди аккордлар булса, шуларны кабатлап, ярга таба келтерәде. Инде нияткә ирешергә дә аз гына ара калып бара... Кинәт, тояк астында бушлык булыпмы, Җирән кашка пошкырып куйды, сөрлекте һәм алгы аяклары белән сазлыкка чумып чак егылмый калды. Ир, үзе дә сизмичә, ярсып атка камчы белән кизәнгән иде, тамашаны күзәткән  ирләрнең берсе кычкырып җибәрде:

– Атка сугасы булма, күрмисеңмени, мескен, тиргә баткан! Ташлыйк бу мәгънәсез шөгыльне. Печәнне тундыргач чыгарырбыз!

Ирләр бичара атны тугарып, сазлыктан чыгардылар да, әлеге сүзләрне кычкырган кеше кырына елышып, кайтып китү турында сөйләшә башладылар.

– Ни эшләргә? Печәнне ничек тә чыгару әмәлен табарга кирәк. Югыйсә Илфир Җирән кашканы иткә озатачак. Картайган, абына, сөртенә, диячәк...

Уйлан, уйлан, җаен тап, Бастам!

Исенә төште. Утрауның бер җирендә зифа зирекләр үсә иде. Шуларны алты атка 12 киртә ясап кисеп алдылар һәм болардан озын тәртәләр ясадылар. Тәртәләр арасына баскыч кебек итеп, агач кисентеләр беркетеп чыктылар. Шулай тәртә-чана ясалды. Хәлдән шул коткарды. Печән аз-азлап, ярга чыгарыла торды, ике машина аны фермага төяп ташый бирделәр.

– Нобель премиясе бирергә кирәк сиңа, абзый, Куянлыда әрәм булып ятасың икән бит.

Әбәдкә утырган көнлекчеләр туктаусыз аны мактадылар.

– Такташка иярebрәк әйтсәк, ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен безгә яңача яшәү юлларын табарга кирәк, егетләр. Шул! Әйдәгез, хәзер эшкә! – дип, Бастам да сүз чыбыркысын шартлатып, урыныннан кузгалды.

Шул мәлдән соң эш төркеме ныклап оешып, үзара якынаеп китте. Сөйләшкән сүзләре дә бер-берсенең күңеленә ятты. Һәм иң мөһиме, көнлекчеләр өсләренә алган бурычны уңышлы үтәп чыктылар. Бастам Сирай улы да әкият герое кебек үз өенә Җирән кашканы җитәкләп кайтып керде:

– Розалия, капканы киереп ач, өйгә мал-туар кайта!

Хуҗабикә дә үз чиратында аларны елмаеп каршылады:

– Төкле аягың белән, Җирән кашка! Синең белән бергә йортка бәрәкәт керсен!

Ир дә, хатын да ул вакытта ачык тойдылар. Бастам Сирай улы болгавыр вакытта укытучы-остаз буларак югалып калса да, тормыш айкауларында асылын җуймады. Җирән кашка – ирнең тормыш авырлыкларын җиңеп кайтуы ул. Ә җиңү, кечкенәме-зурмы, барыбер җиңү! Ул тормышны бизи, киләчәккә якты өметләр уята.

Алдагы елда Зирекле һәм Куянлы авылларын берләштергән хакимияткә башлык итеп Бастам Сирай улы Уразовны куйдылар. Зирәкледәге сигезьеллык мәктәп өчен бина салып, яңадан ачу, туган телдә укытуны дәвам итү хакимият алдына куелган бурычларның иң беренчесе иде.

Даң... даң... даң... Герле сәгать янә сугып ята. Кемдер дөньяга килә, кемдер китеп бара, димәк. Күпләр вакытны битараф, хиссез-тойгысыз бушлык, диләр. Бастам карт исә искәртүле, чаңлы вакыт тавышында хәзер күз-баш алартып, томырылып, алга чабу һәм йөгергәндәге ялгыш хаталар өчен сызланып, үкенеп, берәгәйле үткәннәрне сагыну тойгысының чагылышын бик ачык күреп ала. Шуңа күрә элекке педагог иртәләрен герле, тимерле сәгать чылбырын күтәрә дә уйлап куя. Иншаллаһ, яшәүне, дөньяны һәртөрле хәвефләрдән, бәла-казалардан акча, табыш, дан-дәрәҗә һәм рәхәт тормыш артыннан куучылар түгел, ә мән белгән, җирсенүле хисле кешеләр кавеме коткарыр!

Әмма карт уйларында артык тирәнгә  китәргә өлгерә алмый, хатынының тавышы бүлә:

– Сине күпме көтәргә була, керәсеңме инде, юкмы? Чәем суына бит...



Закир
Әкбәров

# КӨЛИМ ДИСӘҢ, КӨЛ, УКУЧЫМ...

МӘСӘЛЛӘР

## Аюча демократия

Аю ирек игълан итте! Имеш, демократия!
Малны кем урлап өлгерә, байлык та – шуңа тия.
Байлык Бурсыкка эләкте – ни гыйлләттер, ни зәхмәт.
Бурсык – игелексез җәнлек, көтмә син аннан шәфкать.
Комсызлыктан шардай булды болай да кысык күзе.
Дуңгыздай булып симерде, көн-төн мыркылдый үзе.
Урман кырып вилла салды, акланны – газон итте.
Кызармагач кызармый бит ояттан Бурсык бите.
Бассейн итте күлне ул – су кергәләп торырга.
Фахишәләр җыеп, төнен пәри туе корырга.
Чишмәдән фонтан ясады – дөньясын торсын ямьләп.
Импортный виски чөмерде, уылдык белән тәмләп.
Урманны камап алды ул бик биек койма белән.
Капкада сак: керсәң түлә, чыгасың килсә түлә.
Җәнлекләргә бетте тормыш, калдылар авыр хәлдә.
Социализмга ирешеп җитәбез дигән мәлдә.
Куян үрчеми кишерсез, Бүре – ачка каклана,
Хәер эсти мескен Төлке, Тычкан капмый акланда.
Селәүсенгә дә агач юк – төп башында утыра.
Керпе чүплектә чокына, үзе нидер укына.
Күлдән читтә иза чигә Чәшке белән бер Кондыз.
Су булмагач, калды алар ашар азыксыз, тунсыз.
Аю көн күрә Бурсыкта булып йомышчы малай.
«Яшәп тә күрсәтәбез, – ди, – ну, булдырабыз, ай-яй!»
Җәнлекләр ачулы, әмма Бурсыкка кем соң тия?!
Менә шундый була икән Аюча демократия.

Закир ӘКБӘРОВ (1947) – *шагыйрь, прозаик, журналист, педагог; Хәким Гыйләҗев, Баязит Бикбай, Илдар Юзеев исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Башкортстан Язучылар берлеге, Россиянең һәм Башкортстанның журналистлар берлеге әгъзасы; «Аллам сакласын!», «Әрем исе» китапларының авторы. Башкортстанның Күмертау шәһәрендә яши.*

## Саескан – депутат

Саесканга нидер булды, бөтенләй китте азып.
Уңган Чәүкә туганыдай җирдән эзләми азык.
Кайда басканын да белми, йә сикерә, йә ыргый.
Анда барып хәбәр сөйли, монда килеп шыкырдый.
Хәбәре дә хәбәр түгел – вәгъдә дә вәгъдә генә.
Имеш, ул депутат булса, бар кошлар файда күрә.
«Миңа тавыш бирсәгез, – ди, – әй, кошларым, белегез:
Төннәрегез тыныч булыр, якты булыр күңегез!
Җәйләрегез эссе булыр, йомшак булыр кышыгыз.
Тормыш шулай яхшыруга алынмасын һушыгыз.
Чыпчыкларның төп азыгы тары гына булачак.
Каргалар үз ояларын тик бамбуктан корачак.
Туктаусыз чебеш чыгарган инкубатор ясатам.
Тилгәннәргә чебешләрне җәлләмичә ашатам.
Күкене дә йомыркалар салудан азат итәм.
Тик миңа гомер теләсен көн саен кичен, иртән.
Сандугачка Сәхнә булмас юк-бар әрәмә талы.
Аңа атап төзеттерәм аерым концерт залы.
Гиннесс китабына кертәм карлыгачның рекордын.
Уктай атылып оча ул, мин үзем шаһит булдым.
…Сайлаудан митинг ясап, әйләндерми болага,
Кошлар дәррәү сайладылар Саесканны Думага.
Кышлар үтә, килә язлар, яз артыннан җәй җитә.
Сайлаучылар вәгъдәләрнең үтәлүләрен көтә.
Бу хикәяттән нәтиҗә чыгарып торасы юк.
Саесканнарның файдалы бер эш тә кырасы юк.

## Гадел Бүре

Ата Бүре – гадел ерткыч, һәркем белә,
«Гаделлек!» дип, каты тора, үлсә үлә.
Бугазлаган һәр Сарыкны өеренә
Бик чамалап, бик нык уйлап, тигез бүлә.

«Яшь Бүребез – миңа алмаш өер башы,
Бар урманның горурлыгы, йөзек кашы.
Акыллы да булып үсәр – мин ышанам…
Сарык башы – Яшь Бүренең ашар ашы.

Изге булды, – ди, – әнисе һәрчак уең,
Өеребезнең яме бит, – ди, – сының, буең.
Ана Бүре исән чакта – исән өер.
Рәхәтләнеп кимерерсең, сиңа – муен.

Ә сез минем дүрт көчегем, көчеккәйләр.
Кышлар үтәр, килеп җитәр ямьле җәйләр.
Таман булыр һәрберегезгә бирәр тояк,
Үсәрсез сез җитез булып, йөгереккәйләр.

Сездән арткан калдык-постык шушы килеш
Ризыгыма язса, димен, булыр дөрес.

Миңа әллә ни кирәкми, мин инде карт.
Мин ризамын, гәүдә булса минем өлеш.

…Кырыс кыш та үтеп китте, үтте зарык.
Күрше ферманың казасы – җиде Сарык.
Каршы алды язны өер исән-имин,
Баш Бүре көр, калганнары бик тә арык.

Өер менә шундый хәлдә җәйгә керде,
Ата Бүре Аюханга отчёт бирде:
«Уртачалап санаганда һәр бүрегә
Кышын төгәл берәр түшкә сарык тиде.

Мораль дип ни… язмабызның морале юк,
Бу дөньяда берәүләр ач, берәүләр тук.
Уртачалап исәпләсәң, бар да тигез,
Бар да әйбәт, рәнҗетелгән бәндәләр юк.

## Бака язмышы

Балыкларга башлык булды күлдә Бака,
Бу кызыктан күл халкының сыны ката.
«Шул да булган икән, имеш, солтан, – диләр, –
Бу эшкә соң ник кысылмый Чуртан», – диләр.
Чуртан, хәйләкәр елмаеп, җилкә кашый,
Ул бит бакадан җирәнә, балык ашый.
Баксаң, балык ашавыннан бик нык туйган.
Кол Бакасын түрә итеп үзе куйган.
Уылдыктан шәп азык юк – татлы җимеш,
Уылдык белән тукланса, файда, имеш.
Хәзер Бака көн-төн йөри балык савып:
Ташый Чуртанга уылдык савыт-савыт.
Ә Чуртан һәр ташыганны йотып куя.
Аптырарлык: шул чаклы җим кайда сыя?
Уылдыксыз үрчемидер һичбер балык.
Калмады күлдә Чуртанга бер көн азык.
Бик ачыккач, җирәнүдән, йомып күзен,
Уйлап тормый, йотып куйды колның үзен.

## Өер башы

Көлим дисәң, көл, укучым, кайгырыйм дисәң, кайгыр:
Өер башына куярга теләмәделәр Айгыр.
Куйдылар китереп Ишәкне, баш итеп Елкыларга,
Көтү риза булмаса да бу тикле мыскыллауга.
Дәшмәделәр. Имеш, Ишәк өстәге Зур Хуҗаның
Булып чыкты әллә дусты, әллә якын туганы.
Нидән башлады, дисезме? Озак уйлап тормады:
Нәсел Айгырын печтереп, эштән куып чыгарды.
Боерды Атларга иске гадәтләрен ташларга,
Ишәк кануннары белән яңа тормыш башларга.
«Кылганлы тауда тибенү – бу шөгыль – язык, – диде.

Шайтан таягы кимерү – вәт сезгә азык, – диде.
«И-һа-һа!» дип хәбәрләшү биг(е)рәк тупас, – диде,
«И-а! И-а!» дип дәшәргә – вәт сезгә указ!» – диде.
Айлар узды, узды еллар. Гомерләр уза торды.
Атка алмаш яңа буын – качырлар туа торды.
Үсмәде хәзер өердә «дөл-дөл» яу чабар Атлар,
Бәйгеләрдә ярсып җилер, ал бирмәс аргамаклар.
…Бу тарих, төшенәсездер, нәтиҗә ясау сорый:
Ишәк баш булган далада, Атның токымы корый.

## Бәхәс

Өндә булды микән бу эш, әллә инде төштәме?
Йә булмаса, сер асылы – берәр сихри көчтәме?
Очрашты суык чоланда, булып сернең төене,
Дүрт элгечтә эшсез калган дүрт иске баш киеме.
Фуражка һәм Чәшке бүрек, каракульдән Папаха,
Бейсболка да бу өчәүгә тиңләшергә маташа.
Папаха һәм Бейсболка, Фуражка, Чәшке бүрек
Арасында бәхәс купты: «Кемнең хуҗасы бөек!»
Бейсболка күкрәк суга: «Минем хуҗам – дзюдоист,
Күлгә чумса, ул – подводник, танк эчендә – танкист!
Буе тәбәнәк булса да, рейтинглары югары.
Андый хуҗа илебездә булганы да юк әле.
Чәшке бүрек көлде генә: «Бик мактанма син алай.
Синең хуҗаң минекендә булды йомышчы малай.
Сәрхуш булса да, минеке күпме эш кырды бөек.
Ил таркатып, күкрәк сукты: «Мин Бушның дусты!» – диеп.
Чират җитте Папахага: «Хуҗам чәчте кукуруз,
Буржуйларга карата ул булды һәрчак бик кырыс.
Зур җыенда туфли салып, өстәлен төйде кат-кат.
Залдагыларга янады: «Покажу кузькину мать!»
Бик күпләрнең әле һаман келә эзләп табасы –
Кайларда көн күрә икән шул Кузяның анасы.
Тамагын кырды Фуражка, бүлеп Папаха сүзен,
Мыскыллап карады аңа, күздән кичерде үзен.
Дәшмәде. Чөнки бәхәс тә тукталып калган иде.
Шул тамак кыру өчәүне шөбһәгә салган иде.
…Үтә еллар. Уза дәвер. Санап бара календарь.
Бәхәсләшүдән туктамый сәясмәннәр, галимнәр.
Баш киемнәре бәхәсе – бер мәзәк ул кечкенә.
Сөйләсәң – сүз, сөйләмәсәң, ул – кичәге төш кенә…

*«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» әдәби конкурсы*



Фирүзә
Җамалетдинова

# КЕШЕНЕКЕН АЛУ – ЯЗЫК

ХИКӘЯ

*«Ул адәмнәргә дөнья тереклеген күктән төшкән яңгыр белән чагыштырып күрсәт. Су күктән төшә дә, үләннәр аны йотып, яшәреп, үсеп китәләр... Аллаһы Тәгалә – һәрнәрсәгә көче җитүче».*
Коръән, «Кәһеф» сүрәсе, 45 аять.

***

Яңача балалар бакчасына бер төркем кунакларга ияреп, һич көтмәгәндә барып кердем. Калфак-каттәҗиле, озын күлмәкле апаларны күреп аптырарга өлгергәнче үк, каршыга очраган терекөмештәй йөгерек балалар:

– Татары пришли! – дип кычкырып җибәрде. «Приехали...» дидем, эчтән генә елмаеп. Күңелемә шом йөгерде. Җитәкчеләре алдагы көнне генә мактанды, без күп телләр өйрәтәбез, диде. Татар телен дә беләләр, диде.

Берзаман шушы балалар калфак-каттәҗиле музейларга юлыксалар, мөгаен, безне танырлар... Нигәдер, бер мизгелдә, экспонатмындыр сыман тоелып киттем...

Ә бит минем үзебезне танныйсым килгән иде. Шушы нарасыйлар йөзендә, шушы сабыйлар күңеле аша...

Бу очрашу мине үткәннәргә кайтарды. Балачагыма, укытучы исеменә лаек булырга тырышкан мизгелләргә, улымның укучы чагына...

---

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА (1960) – *шагыйрә, прозаик; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Мин әле үзебезгә яңа укытучы килгәнен ишетмәгән идем. Дөньяның бер гүзәле – Рузия апабызны яздан ук, җылы яңгырлы бер көндә, кияве кайтып алып киткәнне белгәч, бик кайгырыштык. Шулай җиңел генә укучыларын ташлый алуына да гаҗәпләндек. Ул безне, без аны бик тә ярата идек бит.

Беркөнне авыл кибетенә киттем. «Өйдә ипи беткән икән, кызым», – диде әни. Барсам – урамгача озын чират сузылган. Ерактан ул кыймылдап торган суалчанны хәтерләтә. Үзе тиз хәрәкәтләнә, кешеләр тулы янчыгын күтәреп китә тора.

Сатучы Гөлшат апа кинәт озын чиратка төбәлеп:

– Укытучыны алдан җибәрик әле, җәмәгать, – дип эндәште. Чират икегә аерылып, ят, чибәр кызга юл ачты. Ул арада аңардан кайда, кемнәргә урнашуын белешеп калучылар да табылды.

– Нәсимә апаларга урнаштырдылыр, – диде кыз тыйнак кына. – Кеше почмагында торган кебек тә түгел, үз өем сыман, Аллага шөкер...

– Әйтәм аны, Нәсимә түгәрәк өстәлен түргә күчергән! Тәрәзәсеннән күренә! Сарык суйган идек, чәем кайнаган, ашым да пешкән, кайтышлый безгә кер, сеңлем, «Бүре Сәлимәләре» дип сора...

– Рәхмәт, апа, – диде укытучы, бераз кыенсынып. – Кергән чак та булыр әле. Без авылдашлар бит хәзер...

Мин, әлбәттә, аксыл чәчле бу чибәр кыз Рузия апабызны алыштырачак, дигән уйны башыма да кертмәдем. Өйгә кайткач та: «Әти, укытучыларга ипине дә чиратсыз бирәләр икән», – дидем.

«Алайса, син дә укытучы булырсың, кызым, тик алар ипине эшләп ашыйлар», – диде әти. Әлбәттә, бу сүзләрнең мәгънә тирәнлегенә төшеп җитә алмадым.

***

Әйе, мин укытучы язмышын сайладым. Мәктәпкә беренче дәрескә кергәнче, директорым Мөбарәк Илшат улы барча кабинетларны күрсәтеп чыкты. Инглиз, француз, немец теле кабинетларының җитәрлек булуына басым ясады. Сөйләшүләрдән шуны аңладым, миңа сабыр итәргә туры киләчәк, әлегә якты уку бүлмәләре һәр укытучыга җитенкерәми икән.

Әлбәттә, чамалыйм: коридорда узган дәрес белән класста узган дәрес бердәй нәтиҗәле һәм тәэсирле түгелдер...

Беренче дәресем өч ана теле укытучысы өчен бердәнбер саналган кабинетта үтте. Моңа бик сөендем. Укучыларымны якты сыйныфта каршы алдым. Таныштым. Гел шушында укырга туры килмәячәген дә әйттем. Чөнки өлкәннәрне безгә бергәләп хөрмәт итәргә кирәк, ике укытучы да миннән олыраклар, дидем.

– Татар телен йә бәдрәф янына, йә коридорга куялар инде, апа. Ярар, нуленче дәрескә килүе авыррак та бит әле, иртән уянуы бик кыен, – дип, кулын селтәде чем кара күзле кыз бала. Әлбәттә, йөрәгем елады. Бу минем ана телемә мөнәсәбәт иде.

Бәдрәф янындагы сыйныфта, сирәгрәк булса да коридорда дәресләрем үтә торды. Балалар кимсенмәде. Алар ана теле укытучысын туган телләренә бәйле булган өчен яраталардыр кебек тоелды. Күбесе өйдә ана телендә

сөйләшә, бу хәл минем күңелемне шатлык белән тутыра иде. Мин дә кайчакта, басып дәрес тыңлаган балаларга дәфтәр ачып язарга куша алмыйм, шуңа үзебезнең һәм төрле халыкларның кешелеклелек тәрбияли, күңел кылларына кагыла торган нечкә тоем белән язылган әсәрләрен укып, фикер алышабыз. Балаларга да ошый. Дәрес беткәч тә уфтанып басып торалар. Әңгәмәне дәвам итәселәре килә.

Берзаман укучыларым үзара да татарча аралаша башлады. Ул шатлыгыма бераз күләгә дә төште: педсоветта Ралия Талиповна директорга төбәлеп:

– Күрәсезме, мәктәп нинди хәлгә җитте, Зарипова белән Хәлимова коридорда татарча сөйләшеп йөри! Туктатырга кирәк бу хәлне... Иптәш коммунистлар, сез кая карыйсыз? – диде.

Мин инде монысын көтмәгән идем. Каршы әйтсәм, башка милләт кешеләренең дөрес аңламавы бар, дәшмәдем. Башка милләтләр дә сүз куертмады.

– Инглизчә сөйләшсәләр, сез дә зарланыр идегезме, Анатольевна? – дип хәйләкәр караш ташлап алды директор. Немец теле укытучысы Евдокия Анатольевна елмаеп кына куйды.

Икенче көнне коридорда очрап, Ралия Талиповна:

– Үзләре коммунизмда бер генә тел калырга тиеш дип сөйләнәләр, үзләре тел өстенә тел укыттыралар, – дип сүз башлады.

– Коммунистлар күтәреп алмады бит әле сезне...

– Алар коммунизмга ышанмый... – диде ул, тирән әрнү аша.

– Мин менә туган телемнең киләчәгенә ышанам. Аны миңа әти-әнием, әби-бабам, халкым бирде, ә тартып алырга сезнең хакыгыз юк, – дидем катгый рәвештә. – Кешенекен алу – язык, – дип тә өстәдем.

Икебез ике якка борылып китеп бардык.

Әлбәттә, безнең арада бер сер ята. Яңа гына килеп укыта башласам да, унынчы сыйныфтагы Гөлфия исемле укучым татар теле юнәлешендә югары уку йортына керергә җыена. Ралия Талиповнаның аны үз дәвамчысы итеп күрәсе килә. Гөлфия – татар кызларының бөтен чибәрлеген, әхлагын, күркен үзенә туплаган бала. Ул бөтен фәннәрне дә җиңел үзләштерә. Олимпиадаларда мәктәпкә һәр фәннән җиңү яулап кайта.

– Миңа үпкәләмәссеңме соң, без бит дәүләтле халык түгел? Заман гел үзгәреп, алышынып тора,– дидем аңа.

– Юк, апа, туган телем – минем яшәү рәвешем ул, – дип җавап бирде Гөлфия. Бу юлны ул яратып сайлады. Мәҗбүр итсәм, язык булыр идем әлбәттә.

***

Язык... Гөнаһ... Мондый төшенчәләргә төгәл җавапны дин кешеләре генә бирә ала. Кинәт башыма бер уй килде. Әгәр дә мәктәпкә берәр дин кешесен чакыртсак? Фикеремне башта хезмәттәшләрем белән уртаклаштым. Алар кире какмады. Директорым да килеште. «Кайберәүләргә бераз акыл йокмасмы», – диде. Тәртипсез балалар һаман арта бара ласа... Өлкәнрәк укытучылар, бер-ике концерт номерыннан тыш, бернине дә үз өстенә алмады. Аларда тәҗрибә, акыл бар. Миндә – яшьлек... Бөтен дөньяны тиз арада яхшы якка үзгәртәсем килә. Бик тиз!

Хәер, өлкән хезмәттәшләрем миңа кадәр болай да күп эшләгән: нинди катлаулы вазгыятьтә дә балаларга ана телен җуярга юл куймаганнар!

Шәһәребез өчен күренекле дин әһеле бик теләп килде. Иң башта аңа сүз бирдек. Ул Аллаһы Тәгалә, җан һәм аның үлемсезлеге, тәмуг белән җәннәт турында сөйләде. «Кешенекен алу – язык», – диде. «Телне дә, җанны да кешегә Аллаһы биргән, аңа кагылырга беркемнең дә хакы юк», – диде. Кешенең әйберенә дә тияргә ярамаганын аңлатты. «Ата-анагызның нәселен, туган телегезне белсәгез, сезне теләсә кайсы милләт кешесе зурлар, ата-ананы, ана телен санга сукмасагыз – бүтәннәр дә кимсетеп карар, ул чакта сез аларны үзегез дә хөрмәт итә алмассыз», – диде. «Менә, берәр рус кешесенең үз телен белмәвен күз алдына китерегез әле. Күргәнегез бармы?» – диде. Күз алдына килмәде, әлбәттә. Шундыйрак хәлгә юлыкса, мәктәпнең рус теле укытучысы Валерия Валерьевна ник туганына үкенер иде, мөгаен... Балалар көлешеп-шаулашып алдылар да янә тынычландылар.

Савапның ни икәненә дә төшенеп калдылар кебек.

Мәктәп залында алма төшәр урын да юк иде. Башка милләт балалары да кергән. Бик күпләр басып тыңлады. Ралия Талиповнаның куркуданмы, куллары бераз калтырап тора, йөзе кара янып чыккан иде.

Кичәбез күңелле, нәтиҗәле үтте. Мәктәп берничә көнгә тынычланып калгандай тоелды.

Тик дин әһелен чакыруыбызны ошатмаучылар шактый булды. «Дин дәүләттән аерылган, монда дин кешеләре керергә тиеш түгел», – диделәр. Әлбәттә, чакыручы – мин, гаеплесе дә мин идем. Директорым – алтын бәһасе кеше, артыгын сүз куертырга ирек куймады. Коридорда әйтелгән сүзләргә исә сабыр иттем.

Завучыбыз да бәйләнчек кеше түгел, ачык чырайлы ханым. Аны беркем дә усал дия алмас. Мин дә алай әйтергә җөрьәт итмим. Тамара Васильевна дип йөртәләр үзен. Тик нигәдер, Тәслия Вәкил кызы икәнен ишеткәч, төне буена йокы алмады. Балалары да Сергей, Александра исемле. Алар татар телен бар дип тә белмиләр. Завуч кайчак дәрес барганда:

– Киләсе дәресне дә шунда гына үткәрерсез инде, – дип эндәшеп үтә.

– Сез үзегез коридорда укытыгыз, яме! – дип кычкырып кала Раил исемле укучым. Миңа бик тә кыен була.

Аңлыйм, әлбәттә: үзен якларга кирәк чагында ул һәрчак шулай һөҗүм итүчән. Әтисе үлгән, диләр. Яклаучысын югалткангадыр, мөгаен, хәсрәт аны балачагыннан аерган. Раилдән сыйныфташлары да зарланмый. Кирәге чыкса, алар өчен дә калкан була белә, диләр...

Кичәнең икенче көнендә Раил миннән:

– Апа, Сез Аллаһыга ышанасызмы? – дип сорады.

– Әлбәттә, ышанам! Дин кешесе бөтенесен аңлатты бит... – дидем.

Малай уйга калды.

– Чынлап та бар микән соң ул? – дип куйды бераздан. Аның әле шиге таралмаган иде.

Әйе, бөтенесе дә шома гына бара дип әйтеп булмас, Раил баш күтәрүчән. Аның бунтарь холкы белән бер генә укытучы да килешә алмый. Канәгатьсез кыяфәте үк куркыныч: чем кара чәчләре керпе энәләредәй үрә торып баскан, берәр этлек эшләргә күзләре ут янып тора. Дәрес барганда, теләсә

ни әйтергә, ни теләсә, шуны кыланырга мөмкин. Мәктәп формасын бар дип тә белми, берүзе әтисенең иске свитереннан йөри. Итәге тезләренә тигән, җиңнәрен дә кат-кат сызганып куя. Хәер, берүзе түгел, зур бер заводның директоры кызы мода журналыннан төшкәндәй кылана. «Аңа сүз әйтмисез бит, миңа да әйтмәгез», – ди Раил. Сумкасы да, бер фәннән дә китабы да, дәфтәре дә юк. Сорасаң – телдән, ни аңлатсаң, шуны сөйләп бирә.

Раилне тәнәфесләрдә ике бармак арасында тәмәкесе даими пыскып торган Валерия Валерьевна да тыя алмый. Мәктәптә рус әдәбиятын су урынына эчкән кеше шушыдыр. Бөтен гомерен мәктәпкә багышлаган ул. Укучыларыннан кала беркеме дә юк. Балалар да хөрмәт итә үзен. Гыйлем җыярга теләгәннәре бигрәк тә. Аңардан башка мәктәп бик күңелсез булыр иде, диләр. Тик нервылары һәрчак киеренке. Тыңлаусыз малайларның арт санына типкәнен дә күрештерәм. Раилгә бигрәк тә эләгә. Тик укытучы ничек кенә кырыс булмасын, малай үз юлыннан йөри бирә. Кайчак:

– Минем әтием дә тәмәке тартмады, – дип куештыра. – Балыкка йөри идек икәүләп. Алай-болай сез дә балык тотмыйсызмы? – ди.

Укытучының җен ачуы куба.

– Оятсыз! – дип кычкыра ул, тәмәке көлен бармагы белән идәнгә коя-коя. – Дәфтәрең юк, китабың юк, мыскыл итмәкчесең тагын! Әнкәңне чакыртам хәзер!

Ул тәмәке төпчеген чүп чиләге кырыена басып сүндереп, чүплеккә ташлый да эре-эре алдырып, сыйныфка юнәлә.

Ә беркөнне өйгә кайтырга чыксам, Раил мәктәп янында тәмәке тартып тора. «Шул гына җитмәгән!» – дип куйдым эчтән генә. Әнкәсе белсә, хәсрәтеннән үләчәк. Тик аның янына баруның бер мәгънәсе дә юк шул...

Берзаман малай беренче дәресләргә бөтенләй йөрми башлады. Әлбәттә, һәр укытучының да һич ташламасыз тәртип таләп итәсе килә. Укучылардан гел төгәл җаваплар, яхшы билгеләр көтә. Тик Раил бу сафтагыларга якынлашмый. Әнисе дә зарлана, күзләреннән канлы яшьләр тама. Әтисе үлгәч шундыйга әйләнде, ди. Иртә таңнан чыгып китә дә кайдадыр йөри. Өйдә дә кычкырыша, тыңламый, ди. Бөтен укытучы гаепли, мин нишләтим инде аны, ди. Дәресләргә дә соңарып керә икән. Беркөнне Валерия Валерьевнаны кабинетында өстеннән бикләп калдырган...

Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр, диләрме? Шул инде.

Ананың күз яшьләрен күргән саен, үземне аның урынына куеп карыйм да имәнеп китәм. Йа Аллам, бала хәсрәтеннән дә ачырак нәрсә бармы бу җир өстендә?! Тик ничек ярдәм итим соң? Укытучылар киңәшен колагына да элми ичмасам.

Шулай да, нигәдер, һәр укучым күңелемә якын. Хәтта Раил дә. Алар – милләтемнең энҗе бөртекләре. Ана телемнең, халкымның киләчәге шулар кулында! Арада ятимнәре, гаугалы йорттан килгәннәре бар. Тормыш арбасы тигез генә тәгәрәми, нишлисең...

Ул төнне мин Раил турында озак уйланып яттым. Берәр заман уртак тел табып булырмы? Бала юлдан язып бара. Чарасызлыктан йоклап киткәнмен. Тик бөтенесе дә өндә шикелле. Нәкъ Раилгә охшаган иде ул кеше. Мин аның әтисе, диде. Әтиең бик рәнҗи, дип әйтегез, диде. Күп сөйләшеп тормады, кинәт юкка да чыкты. Уянгач та, ушымны җыя алмыйча тордым. Кайдан

белгән безнең борчуларны теге дөньядагы зат? Аның әрнү тулы карашлары бик озак күз алдымнан китмәде.

Икенче көнне Раилләрдә дәресем бар иде. Ул, гадәттәгечә, кырык биш минут буена үзалдына сызгырынып, Салават Фәтхетдинов җырларын җырлап утырды.

> «Әз-мәз генә урлашмасаң,
> Яшәп булмый көч белән»

дигән сүзләре колагыма чалынса да, игътибар итмәскә тырыштым. Кыңгырау тавышы ишетелгәч тә (кабинетта үткән дәрес иде ул), Раилнең чыгып китмәвен сорадым. Ул мине ишетергә дә теләмәгәндәй, һаман җыр сузды:

> «...Мәдинә, Мөкәррәмә,
> Эчеңдәге серләреңне сөйләмә берәүгә дә».

Класста без икәүдән-икәү генә калдык.

– Нәрсә әйтмәкче буласыз? – дип, усал елмайды малай. – Акыл өйрәтмәкчеме әллә? Минем үз акылым үземә бик җиткән. Әбием гел шулай әйтә торган иде, – диде дә үзалдына кычкырып көлеп җибәрде. Аннан борынын җиңенә сөртеп алды. Шул мәлдә үк йөзе ачудан-ярсудан җыерылып куйды.

«Бигрәкләр әбиеңә охшагансың инде», диясем килсә дә, сүзне озайтмадым, әңгәмәбезнең әһәмиятен җуюдан курыктым. Беразга тынлык урнашты. Аннан ашыкмыйча гына:

– Әтиеңне төшемдә күрдем, Раил. Ул сиңа, әгәр дә үзгәрмәсәң, би-и-к нык рәнҗим, дип әйтергә кушты... – дидем.

Малайның кинәт авызы ачылып калды, күзләрен түгәрәкләндереп, миңа төбәлеп торды, аннан сабыйларча үкереп елап җибәрде.

Ике күзен йодрыклары белән уа-уа:

– Дөресме, апа? – дип сорады. Тавышы калтыранды. Гүя әрнүе минем йөрәк аша да үтте.

– Дөрес...

Ул тагын да катырак үкседе. Маңгаена тир бәреп чыкты. Үзе:

– Мин әтиемне бик яратам! Һаман яратам! – дип, йодрыклары белән партаны төйде.

– Яраткач... Рәнҗи бит әтиең... Иртән чыгып китәсең дә, әниеңне борчуга салып, кайлардадыр йөрисең икән...

Малай тынычлангандай, башын ия төште. Үзалдына гына:

– Зиратка барам мин көн дә иртән... Әти янына... – дип куйды.

Монысы миңа яшен суккандай тәэсир итте. Зиһенем таралып китте. Шулай да бар көчемне җыеп:

– Син анда башка барма, яме! Әрвахларны борчырга ярамый... – дия алдым.

– Әти шулай куштымы?

Мин дәшмәдем. Күзләремне аска төшердем. Яхшы якка ялган да ярый, дисәләр дә, ялганларга җөрьәт итмәдем.

Сыйныфта тагын тынлык урнашты. Бөтенесен берьюлы әйтеп бетерергә теләпме:

– Әтиең тәмәке дә тартмаган, – дип өстәдем.

– Мин дә тартмыйм, апа. Тәмләп кенә карадым. Валерия Валерьевнадан күреп кенә...

Инде сөйләшер сүз дә калмады шикелле. Малай үзе башлады.

– Димәк, мәчет кешесе дөрес әйткән: җан үлми икән... Димәк, Алла да бар... Әбием дә ялган сөйләмәгән...

– Әйе. Дөрес әйтте ул... – дидем, аны җөпләп.

Тышта яңгыр койды. Ачык тәрәзәдән җил уңаена әләккән тамчылар парта өсләренә сибелде. Әйтерсең алар безнең серне тыңларга, малайны юатырга телиләр иде. Ни әйтергә белмәгәнлектән, аларны учларым белән сыпырыштырып төшердем. Тәрәзәне япсам, бар вөҗүден хәсрәт ураган укучыма һава җитмәстер кебек тоелды.

Без бик озак сүзсез утырдык. Укучымның күзләре кызарып, шешенеп бетте. Холыкны дәвалау җәрәхәтне дәвалаудан авыррак, диләр. Юатмадым. Түздем. Ахырда:

– Башка беркемне дә рәнҗетмәм, апа, – диде ул, сулкылдый-сулкылдый. – Мин бит татар теле дәресләрен дә яратам... Өйдә бит без үзебезчә генә сөйләшәбез... Тик сез бу хакта беркемгә дә әйтмәссезме?

– Нәрсәне?

– Әтиемнең миңа рәнҗүен...

– Әйтмәм...

«Мәдинә, Мөкәррәмә,
Эчеңдәге серләреңне сөйләмә берәүгә дә», –

дидем мин.

– Берәүгә дә!.. – дип кабатлады ул, күз яшьләре аша елмаерга тырышып.

Икенче көнне мәктәп Раилне танымады. Кыршыла язган мәктәп киеменнән йөргән укучылар арасында аны өр-яңа костюм-чалбары искиткеч затлы итеп күрсәтә иде. «Нишләттең син малайны?» – дип сорау бирүчеләр дә булды. Әнисе дә шулай сорады. Серне чишмәдек.

Өйгә кайткач та йокларга куркып яттым. Тагын әтисе төшкә килеп керсә?.. Ул бит минем күргән-белгән кешем түгел. Үзем һаман шул хакта уйландым. Коллективыбыз шыбыр хатын-кызлардан тора. Директордан башка «күзгә кырып салырга» бер ир-ат заты юк. Ә директорның үз эше дә бик җиткән. Бала тәрбияләмәкче, гыйлемле итмәкче булып мәш киләбез. Көчебез аз, күрәсең. Ир-ат кирәк икән бит ир балаларга! Әнә, ир-ат кабердән дә тәрбияли ала...

Өстәвенә, Валерия Валерьевна безнең яшьлекне ассызыкларга ярата: «Сезнең берегез дә Бернард Шоуны укымаган! «Яшьлек – иң гүзәл чор. Аны балаларга багышлау – җинаять!» дип әйткән ул», – ди.

...Әлбәттә, коридорда узган дәресләр өчен мин үземне гаепле саныйм. Көрәшергә кыюлыгым җитмидер кебек тоела. Кем белән көрәшим? Җитәкчелектә бит – татар кешеләре. «Минем илемдә минем телем ник болай кадерсез?» дип, бөтен дөньяга шәрран ярасым, Раил кебек чарасыздан партаны төеп елыйсым килә. Тик кем ишетер икән соң? Шул бимазадан

котылыр өчен бер хәйлә уйлап таптым. Якшәмбе көнне гарәп язуын өйрәтә башладым. Игелекле эшнең иртәсе-киче юк, диләр. Бу бит безнең тарих. Халкыбыз шул язудан латинга, аннан кириллицага күчкән. Дини, дөньяви әдәбиятыбыз шул язуда сакланган. Балалар килә. Раил дә бер генә дәресне дә калдырмый. Дәфтәренә бик тырышып яза. Пөхтә дә икән үзе. Күзләрендә бәхет чаткысы ялтырый. Балачак бәхетле булырга тиеш ул!

Шунда программа буенча үтелеп бетмәгән тел-әдәбият дәресләрен дәвам итәм. Тукайны, Җәлилне аеруча яраталар. Якшәмбенең уңай ягы бар: балалар ана телен якты, яхшы кабинетларда тыңлый... Максатымның иң зуры – аларны кеше итеп тәрбияләү. Тәүфыйклы, илгә дә, кешеләргә дә мәрхәмәтле, җәмгыятькә кирәкле булсыннар. Тарихыбыздан, әдәбиятыбыздан йөз чөермәсеннәр. «-лык -лек» кушымчасын белмәсәләр дә ярый. Бу вазгыятьтә монысы иң мөһиме түгел...

***

Үзгәреш җилләре безгә дә кагылды. Илбашларын президент итте. Туксанынчы еллардан мәктәптә ана теленә күчеш кинәт башланды. Татар теле дәресләре рус теле дәресләре белән тигезләште. Аерым кабинетлар булдырылды. Хәзер инде тәрәзә кырыена сөялеп, тәмәке көйрәткәндә, Валерия Валерьевна миңа тыныч кына карап кала, кайчагында төтенен өрә-өрә: «Как там «Мукарряма?» дип сораштыргалый. Раил җырлаган җырлар аның да күңеленә уелып кергән, күрәсең.

Шулай да, татар теле дәресләренең рус теле белән тигез дәрәҗәдә укытылуы бик күпләрнең күңеленә тиде. Җитмәсә, татар теле укытучыларының хезмәт хакына унбиш процент өстәп тә куйдылар. Валерия Валерьевнаны бу хәл отыры чыгырыннан чыгарды. Үткәндә:

– Синдә бер «Мукарряма», миндә алар – унбер! Кешенең хайваннан аермасы хакында да сөйләп карыйм – нәтиҗә – ноль! Укытучы белем бирергә тиеш, ә без монда тәрбияләү белән шөгыльләнәбез, – дип кала башлады. – Ни өчен түлиләр сезгә ул акчаны? Менә миңа түләсеннәр! – дип өстәп куя аннары. Әлбәттә:

– Монысын үзегез хәл итегез инде! – дип, тиз-тиз адымнарымны ашыктырырга күнектем.

***

Ничектер, мәктәптә дәфтәрләр тикшереп утыра торгач, соңгарак калганмын. Ни күрим, алдымнан гына Раил белән Айгөл кайтып бара. Раил кызның сумкасын да күтәргән. «Чынмы соң?» дип, күзләремне ныклап ачып карадым. Малай кинәт артка борылды да мине көтеп туктап калды.

– Без Айгөл белән күршеләр бит, апа, – диде ул, акланырга теләгәндәй. Үзенең бит алмалары чөгендердәй кызарып чыкты.

– И-и, шулаймыни? – дидем, сиздермәскә тырышып. – Күрше булу ничек әйбәт. Бергә кайтасыз менә...

Башка сүз әйтергә курыктым, чөнки беләм: балачакта салынган җан җәрәхәтләре кешене гомере буена эзәрлекли. Бу мәхәббәтне җәрәхәтләргә ярамый! Әтисе белән бергә җиде кат җир астына төшеп яткан сөю бит ул! Шуннан чыгалмый тилмергәнен, газапланганын үзем күрдем ласа.

«Раббым, бу мәхәббәтне үзең сакла!» – дип пышылдадым эчтән генә.

...Шушы матур яз минем мәктәпкә багышланган соңгы язым булды. Без башка шәһәргә күчендек. Мәктәпнең, туган телемнең киләчәгенә ышанып чыгып киттем. Институтны яңа гына тәмамлаган яшьләргә ишекләр ачык иде инде.

Хәер, чит илләргә дә ишек-капкалар ачылды...

***

...Без Анталья аэропортына кергәндә, коеп яңгыр ява иде. Монда яңгырлар бик сирәк күренеш, диләр. Ниләрнедер юарга теләгәндәй, һәр тамчы сөңгедәй кадалып, кыеклап-кыеклап төшә. Күңел матур хатирәләр көтә. Чит илдә бигрәк тә, башкарак хисләр биләп ала. Рәхәтлектән кулчатырны да ачасы килми. Яусын әйдә! Җылы яңгыр ласа!

Җылы яңгыр тамчылары сыенган чәчләремне сыпыра-сыпыра, ишектән кергәндә үк таныш чалымнар күземә ташланды. Ралия Талиповна икән. Туганнарча кочаклашып күрештек. Ул инде шактый олыгайган. Кара шомырт чәчләренә ап-ак бәсләр кунган. Җыерчыклары да тирәнәйгән.

– Ышанасыңмы, мин үзем хәзер химия-биологияне татарча укытам, – диде ул, елмая төшебрәк. – Татар-рус мәктәбенә әйләндек бит. Татар сыйныфлары да күбәйде. Китәргә дә күптән вакыт җитте, югыйсә. Валерия Валерьевна да, завучыбыз да лаеклы ялда. Тик яратам шушы балаларны! Тагын кемем бар соң минем? Мәхәббәт бездән көчлерәк шул... Гөлфиябез кайтты бит инде мәктәпкә! Татар телен ул укыта.

– Ник ышанмаска! Мин үзем бөтен фәннәрне дә ана телендә укыган кеше, – дидем, алдагы җөмләләренә игътибарымны юнәлтеп. Үткәндәге күңелсез хәлләрне исенә төшерергә бер дә исәбем юк иде, үзе сүз башлады:

Теге чакта син миңа рәнҗегәнсеңдер инде, – дип куйды. – Минем гаеп түгел иде ул, замананыкы... Ничек суларга кушсалар, шулай суладык ласа без! Бер гомергә ничә төрле яшәү рәвешен тәкъдим итәләр... Чыда гына!

– Заманадан гаеп эзли башласак, күңелсезлектән башың чыкмас... Үткән-беткән... Шулай инде, чорлар кешене теләсә – коммунист, теләсә – шут итә, – дип, түгәрәкләп куйгандай булдым.

Үземнең күз алдыннан революцияләр, репрессияләр, колхозлашу – кулакларны сөрү, сугышлар, халык дошманнары эзләүләр, тагын әллә ниләр чагылып үтте. Языктан курыкмаганнар, димәк... Нигә безнең илгә генә шулай кешене гел гаепле итеп яшәтә торган чорлар киләдер? Ярый әле, алар үзгәреп торучан...

Укытучы – илнең төп сәясәтчесе шул ул! Укытучылар армиясе булмаса, Ватаныбызның бер генә кануны да тормышка ашмас, чорлар белән чорлар арасындагы чикләр бер төрлелектән тәмам җуелып бетәр иде.

...Ралия Талиповна миңа Раилнең бизнесмен булып китүе хәбәрен дә җиткерде. Күрше кызы Айгөл белән бик матур гаилә корганнар, кыз һәм ул үстерәләр икән.

– Күрсәң, һич танымас идең, гөрнәдир кебек. Әнисе дә бик куана инде, – диде ул.

Минем әле соңгы вакытта моннан да куәтлерәк шатлык хисләре кичергәнем юк иде.

– Әлхәмдүлилләһ! – дип җөпләдем аны.

***

Еллар үтә торды. Ватаным ирек, яңа үрләр яулады. Туган телем коллык газабыннан котылды. Хәтта аны башка милләтләр дә өйрәнә башлады. Яңа программалар төзелде. Мәктәп иркен сулыш алды. Чөнки укучылар эре милләт, вак милләтләргә бүленми, алар һәммәсе бертигез адәм балалары иде. Ул тигезлек миңа һәрдаим җылы тәэсирләр бүләк итеп торды.

...Ралия Талиповна белән очрашканнан соң, чемодан-арбадагы йөкләребезне тартып, аэропорттан чыгуга, безне Төркия җирендә яшь кенә ике кыз каршы алды.

– Үзебезнекеләр килде! – дип елмайды алар. Кочаклашып күрештек. – Без дә Казаннан!

– Татар кызлары әллә кайдан күренә инде, чибәрләр! – дидем мин дә, куанычымны яшерә алмыйча.

– Без – рус кызлары! Ул – Таня, мин – Лена! Монда эшлибез. Татар теле укытучыларына рәхмәт, телне яхшы өйрәттеләр. Безне эшле иттеләр менә...

Автобус йөртүче төрек кешесе белән дә алар татар телендә сөйләште. Берсен-берсе яхшы төшенделәр кебек.

Шаккаттым. Татар теле укытучылары өчен горурлануымның иге-чиге булмады. Түбәм күккә тиде! «Рәхмәт аларга!» дип кабатладым кызлар артыннан. Нигәдер, авылда ипи чиратында торуым, кешеләрнең укытучыма юл ярып, икмәк бирүләре искә төште... Әти әйтмешли, һәркем ипине эшләп таба... Минем телем дә бу балаларга ничекләр ярдәм иткән әнә... Теле барның юлы бар, дип белми әйтмиләрдер.

***

...Еллар үтте. Улым да үсеп килә. Ул коммунизм баласы түгел. Башка, ирекле чорныкы. Мәктәптә дүрт тел өйрәнә. Иң әһәмиятлесе – дүртесен дә яхшы белә. Чөнки мәктәпкә еш барам: укытучылары белән төрле телләрдә иркен аралашканын ишетәм. Ул гына түгел, бөтенесе дә шулай. Ана телен күпсенгән замананың кинәт яхшы якка борылып куюына бер яктан сөенсәм, икенче яктан көенәм дә. Озакка барырмы бу вазгыять? Бездә бит бөтенләй телсез-чукрак булуың яхшырак. Гомергә шулай килгән. Үземнең мәктәп коридорында дәрес биргән чакларым искә төшсә, тәннәрем чемердәп китә. Мондый якты класслардан тагын куып чыгармаслармы? Аллаһы Тәгалә һәркемне үз теле белән яралткан. Тигез итеп яралткан. Укытучылары – чит милләт вәкилләре аларга шуны төшендергән инде. Әти-әниләренең кайберләре оныткан булса да, балалары нәсел җебен ялгап, ана теленә кайтып бара әнә. Иң мөһиме: аларны мәктәптә кеше итеп тәрбиялиләр. Горур булырга өйрәтәләр.

– Бүген нишләдегез, улкаем? – дип сораштырам, өйгә кайткач.

– Театрга бардык.

– Автобус беләнме?

– Юк, абый такси чакыртты. Тик...

– Ни булды?

– Такси безне узып китеп. бик еракка туктады. Йөгерә башлаган идек тә, абый бүлдерде. Без аны тукталышка, менә шушы урынга чакырттык, бары шушыннан утырып китәчәкбез, диде.

– Такси борылып килдеме?

– Анысы китеп барды. Башкасы янәшәбезгә туктап утыртты...

Менә ничек үз кадереңне белергә өйрәтәләр икән! Дәүләтле кешеләрнең уе да иректе шул! Кайчандыр коридорда дәрес үткәрүем өчен тагын бер кат җаным сыкрап куйды. Әлхәмдүлилләһ, балама яхшы замана килде, дип юандым.

Беркөнне өйгә кайтсам, улым кызарып-бүртенеп, нидер язып утыра. Чәч төпләре дымланып тора. Чиктән тыш арганы әллә кайдан сизелә.

– Дәресне күп бирделәрме әллә? – дип, башыннан сыйпап кызыксынуым тагын да ачуын кабарткандай тоелды.

– Менә, Илдус аркасында... – диде ул, дәфтәренең тагын бер язулы битен ябып.

– Сугыштыгыз мәллә?

– Юк инде. Ис чыгарды... Абый килеп керде дә борынын кулъяулыгы белән каплады. Аннан бөтенебезгә яңа дәфтәр өләшеп чыкты. «Хәзер шунда меңәр мәртәбә татарча, русча, төрекчә, инглизчә «Мин бу эшне башка эшләмим», дип язабыз, диде. Менә язам... Бармагым суелды... Илдус аркасында... Төрек телен өйрәнәсе урынга...

– Илдус аркасында, дидеме? Күрче, «халык дошманы»н...

– Юк, абый аңа бер сүз дә әйтмәде. Кем икәнен сорамады да... Белмәде дә...

– Менә гыйбрәт! Бер гамәл бөтенесенә дәрес булган! Әйбәт бит инде! Мәңге онытмаслык. Яхшыга яраш, яманнан кач, диләрме?.. Шуны өйрәткән абыегыз.

– Әйе, гыйбрәт, – дип мыгырданды улым, дәфтәреннән кулын алмыйча гына һәм ашыгып язуын дәвам итте.

– Җир өстендә әхлаксыз яшәү – язык, улым, – дидем мин.

«Ирекле халыклар бөтен җәмгыятьне тәрбияләргә сәләтледер, күрәсең, алар халык дошманы эзләү түбәнлегенә беркайчан да төшмәгәннәрдер...» дип уйладым. Көфер уйларымнан үзем үк куркып куйдым, Алла сакласын, ул чорлар кабатлана күрмәсен!

Үзем ул кичтә нидер югалткан кешедәй йөрдем. Чөнки улым өйгә көн дә бер яңа хикәят алып кайта. Алардагы мәгънә тирәнлеге минем һәр күзәнәгемне урыныннан кубара. «Йә, улкаем, бүген ни сөйләделәр?» – дип көтеп кенә торам. Тик тирләп-пешеп, дүрт телдә «Бу эшне мин башка эшләмим» дип язып утырган баладан ничек хикәят сорыйсың? Дәшмәскә булдым. Улым сизде булса кирәк, урын-җирен рәтләгәндә:

– Син хикәят көтәсең инде, әни, беләм! – дип куйды. Һәм бик матур бер хикәят сөйләде.

«Сыйныфка үтә җитди кыяфәтле укытучы килеп кергән дә тактага зур итеп «берле» (1) санын язып куйган:

– Игътибар итегез, бу – кешелеклелек билгесе, кеше гомеренең барча кыйммәтләрен үзенә туплаган ул, – дигән һәм «берле» янына «ноль» санын өстәгән. Аннары:

– Монысы – уңыш билгесе, ул кешенең дәрәҗәсен бердән ун тапкырга арттыра, – дигән. Янә бер ноль өстәлгән, бусы – тәҗрибә, ул кешене йөзләтә күтәрә, – дигән укытучы.

Шулай нольләр өстәлә торган: булдыклылык, тәртип, ярату билгеләре...

Укытучы игътибарны тактага юнәлтеп, иң алдагы «берле» не сөртеп алган. Шуннан тезелешеп торган «ноль»ләргә карап:

– Әгәр дә кемдер кешелеклелек сыйфатын югалта икән, калганнары да «ноль» гә әйләнә, – дип нәтиҗә ясап куйган...»

Улым сөйләп бетерүгә йоклап та китте. Миңа тагын үткәннәремә юл ачты.

Их, мәктәпкә бәйле чорымда шушы хикәятләрне белсәмме! Менә бит тугандаш халыклар бер-берсен ничек баета!

Бу мин укыткан еллар түгел, ни әйтсәң дә. Өйгә гел яхшы хәбәрләр кайта. Укытучыларның күпчелеге ир-атлар. «Проблемаларны без үзебез хәл итәбез», – дип кенә торалар. Җыелышларда мәктәпнең илкүләм, дөньякүләм җиңү яулаган балалары турында сөйләшәбез. Ә алар барысы да җиңү яулый! Җыелыштан чыкканда, без – әти-әниләргә канатлар үскәндәй тоела. Бар ла замана мәктәпләре!

***

Мин җәйге каникулда улымның укытучылары үз иленә кайтып киткәнне ишеткән идем инде. Лена белән Таняга шул хакта әйткәч, алар безнең телефоннарны көйләп, элемтәләрне бик тиз булдырып бирделәр. Ни әйтсәң дә, үзебезнең Казан кызлары! Җитмәсә, сагынулары йөзләренә чыккан. Без аларга туган як җилләрен, туган ил сулышын алып килдек ласа. Казанны сорашалар. Очрашканда, озаклап сөйләшеп торабыз. Күбәү килдек, диләр. Үзләренең күңелләренә ошаган кибетләргә алып бардылар, шәһәрнең матур урыннарын да күрсәттеләр хәтта. Ватандашлар шул без!

Төрек кардәшләребез безне кунакка чакырды. Ахырда гаҗәеп бер аланга сәяхәт кылырга күндерделәр. Икенче көнне үк алар яныбызга килеп тә җитте.

Биек-биек таулар арасында кыргый өрекләр, төче чияләр тәлгәш-тәлгәш салынып торган, Аллаһының камиллек үрнәген чагылдырган табигать почмагы иде бу. Могҗизалар кырына эләккәнбездер кебек тоелды. Җир өстендә җәннәткә тиң урыннар бар икән лә!

– Бу куаклар кемнәрнеке? – дип сорадым Әнвәр бәйдән.

– Беркемнеке дә түгел, – дип җавап бирде ул.

Бәй, шулай икән, димәк безнеке инде, дип уйладым нигәдер. Һәм елкылдап-ымсындырып торган тәлгәшне өзеп, төче чияләрне авызыма каптым.

Тагын бер тәлгәшне алып, улымның укытучысына суздым.

– Бик тәмле. Авыз итегез!

– Юк, ашамыйм, – дип, кире какты ул. Хәтта кулын да күтәрмәде. Аннан:

– Ул бит минеке түгел! – дип өстәде. Һәм төбәлеп, күзләремә карады.

– Кемнекендер алу – язык...

Аптырап киттем. «Язык» дигән сүзне күптән искә дә алганым юк иде.

Нигәдер, мәктәп залын, үзем чакырган дин әһелен искә төшердем. Әйткән иде ул бу хакта... Бик оят булды, тәлгәшләрнең ничек кулымнан шуып төшеп киткәнен дә сизми калдым...

***

Улым мәктәпне тәмамлап чыкты. Дөньялар тагын үзгәрде. Тагын туган телем бәлагә тарыды. Янәдән өйләргә, йозаклар артына бикләнергә мәҗбүр булды. Мәчетләргә – Аллаһы йортына барып сыенды. «Язык» дигән төшенчәне аңламас заман килде.

Дөрес, бераздан яңача, өметле мәктәпләр ачыла башлады. Тик аларга балалар кайлардан җыелыр икән соң? Ана теле ул балаларның яшәү рәвеше була алырмы? Бәлки борчылуым юккадыр... Теге заманнарда, коридорда укыганнары да югалтмады бит аны – Ана телен!

***

...Менә, ниһаять, замана нәниләре тәрбияләнгән балалар бакчасында йөрим. Өмет белән җитәкләшеп.

Яңа заман шәхесләрен сыендырган коридорлар да ничектер ят тоела. Минем күңелем татар баласы эзли. Гөлфиям кебекне... Раил кебекне... Үзебезчәлекне... Күрәсең, ул кәгазьдә бардыр да. Юк, юк, болай да бардыр... Милли рух җуелмаса, мәктәпләр тагын да ачылыр...

Кинәт кенә замана балалары тәрбияләнгән кабинетлардагы язуларга игътибар иттем: һәммәсе инглиз телендә генә икән. Укый алмадым, әлбәттә. Бу язулар үткән заман кешеләренә адресланмагандыр.

Урамда исә коеп-коеп, җылы яңгыр яуды. Бәлки ләйсәндер дә? Шифалы тамчылардыр! Шуңа кулчатырымны да ачмадым. Бәлки иртәгә үк Аллаһы теләге белән япь-яшь, ямь-яшел чирәм күтәрелер... Чөнки безнең, табигатьнең хуҗасы, яралтучысы – Ул Үзе. Тере, йөгерек тамчылар хәтер булып, чал чәчләремә сарылды, асфальт юлга төшеп чәчрәп-чәчрәп китте. Дөнья юшкынын чистартырга исәпләре. Бердәм булганда, чисталыкка, сафлыкка – бер сөям! Табигыйлектә, сафлыкта язык юк!..



Зинаида
Захарова

# ЗӘЙ ҮЗЕ ДӘ ТЫНЛЫК ЯРАТА...

## Чын ярату

***(Тукайчарак)***

Без яшибез, дөнья нурлы, нинди хозур!
Берни юктыр безгә туган телдән дә зур!
Телебезгә икеләнми бир син вәгъдәң:
«Тукай теле булыр диеп, бөек кәгъбәм!»

Ана теле көннәреңне якты итәр,
Күңелеңне көр һәм дәртле, пакьле итәр!
Кайгы-хәсрәт, фаҗигагә урын калмас,
Һичкем милләт киләчәген урлый алмас!

Мәхрүм итсәң син үзеңне телебездән –
Халкыңның син киләчәген күралмассың,
Газиз туган ягыңны син сөя алмассың,
Кай тарафта, кайда кыйблаң – белалмассың!

Телебезгә күрсәтмәсәң кадер, хөрмәт,
Йөз чөерсәң, сөйләшмәсәң – ул бик рәнҗер,
Юлын кисәр! Дошманнары өчен һәрчак,
Телебез булыр, шиксез, үткен мисле хәнҗәр!

Син дустыма, киңәшем бар, кадерлемә:
Сөйсәң генә, олыласаң үз телеңне,
Белерсең син «милләт» дигән сүз кадерен,
Чын ярату да шул булыр үз-үзеңне!

Зинаида ЗАХАРОВА – *шагыйрә; «Сине генә сөям», «Нурлы җиһан», «Кем бәхетле» исемле китаплар авторы. Әлмәт районында яши.*

## Туган телем

Туган телем анам сөте белән кергән,
Күңелемә атам нуры булып иңгән.
Туган телем шундый көчле, якты рухлы,
Ялкыннары мәңге сүнмәс, ярсу уты.
Туган телем дөньяларның ямен ачты,
Аның белән хыялларым чынга ашты.
Туган телем сынап бага, сөеп карый,
Бәхет тели безгә, биек үрләр юрый.
Телем исән – юлларымда ачык ишек,
Тик ул гына талчыкканда йомшак бишек.
Туган телем исән булса, без яшәрбез,
Дөнья мөнбәренә менеп, мең дәшәрбез!

## Сүз

Ходам кылдай нечкә күңел биргән,
Тиз рәнҗимен нахак сүзләргә.
Җаным әрнеп, хаклык эзләп китәм,
Яшь шәйләнә моңсу күзләрдә.

Гафу итмәс булып бәргәләнәм,
Авыр кичерәм күңел тарлыгын.
Хакыйкатьнең кайнар сулышын тоям,
Йөрәк сизә Аның барлыгын.

Түбәнлеккә төшмим! Җавап сүзем
Тел очында кала бүленеп...
Ә күңелем кодрәтләнеп китә,
Ачу-нәфрәт кала күмелеп.

...Бумерангтай булып, яман сүзләр,
Әйләнер дә кайтыр үзеңә...
Кеше рәнҗешләре төшмәсенгә
Богау сал син яман сүзеңә!

## Беләсезме?

Хисләреңне йөгәнлә дә,
Утыр инде, кил акылга!
Сүзең көмештәй булса да,
Дәшми калу тиң алтынга.

Алтын кыйбатрак йөрде,
Дәшми калдык кирәктә дә.
Әрнеш йотып ятты көмеш
Таш яткандай йөрәкләрдә.

Кая киткән көмеш кашык,
Кайчан гына тулып яткан?!
Көмеш кимүгә юлыккан,
Шуңа аңа бәя арткан.

Кая киткән чулпылары,
Сыргалары, беләзеге?
Көмеш – алтын бәясендә!
Сез соң шуны беләсезме?

Көмешләрдәй булсын сүзең,
Алтынга тиң алар бүген!
Тел сусаган – көтә бездән:
«Халкым әйтер, диеп, сүзен!»

Көмеш алтын бәясендә,
Сез соң шуны беләсезме?
Без соң шуны беләбезме?

## Тукайны укыгыз

Укый-укый ача барам аны,
Эшләрем дә китә уңайга.
Көндәлдәге бик күп сорауларга
Җавап эзләп киләм Тукайга.

Күрсәтә ул бай хәзинә булган
Халкым йөрәгенә юл кайдан?
Заманабыз куйган сорауларга
Җавап эзләп табам Тукайдан.

Җавап кына табып калмыйм әле,
Җәүһәрләре илһам, дәрт бирә.
Үгете дә нотык түгел аның,
Иптәшләрчә бер киңәш кенә.

«Милләткә хыянәт итә күрмә!» –
Бу – Тукайның безгә таләбе.
Авыр вакытларда татарыма
Кирәк бөек шагыйрь ярдәме.

## Тамчылап...

*Тамчылап яңгыр сибәли,*
*Тамчылап уза сәгать.*
Р.Мөхәммәтшин

Бәхет гел тамчылап килә,
Хәсрәт килә ишелеп.
Башлар түбән иеләләр,
Кеше кала киселеп.

Шатлык килсен дә ишелеп,
Кайгылары килмәсен!
Борчу-хәсрәтләрдән хасил
Җан җөйләре имләнсен!

Гомер юллары кыска шул,
Мизгелгә тиң бу тормыш.
Кыска булса да, син аны
Матур үтәргә тырыш!

Матур  ничек була дисең? –
Үкенерлек булмасын!
Моң касәң бәхеткә тулсын,
Хәсрәт белән тулмасын!

Ник ыргылып чаба вакыт,
Куалармы камчылап?
Гомеркәйләр озын булып,
Үтсә иде тамчылап!

## Сорамагыз

*Сез сорыйсыз? Ә мин сөйли  алмый.*
*Аh, ул серләр шундый караңгы...*
*Сөйли алмыйм, мине кичерегез!*
*Ача алмыйм йөрәк ярамны.*
*Һ.Такташ*

Югалттым дип елап йөргән мәлдә
Юлыктым бит шундый табышка.
Ачы юксынулар шәмдәй сүнде,
Урын калдырмады сагышка.

Бәхете дә ишелеп-ишелеп килде,
Күңелдән ташыды моң тулып.
Сөйләтмәгез, берүк, төпченмәгез –
Йөрәгемдә калсын сер булып.

Күз тиюдән курку да юк түгел
(Моны инкяр итми акылым).
Күзләремнән барын белеп була,
Зинһар, сорамагыз артыгын.

## Бәхетле

*Ни өчендер Аны сүзләр сөя*
*Һәм буйсынып,  Аңа башын ия...*
Валери Тургай

Бу тормышта синең яратканың
Нәрсә, диеп сорау бирсәләр.
«Шигырь» дияр идем. Ачуланмыйм,
«Тиле икән бит син» дисәләр.

Тик ул сүзне әйтер юләр генә
Белми, димәк, шигырь тәмен ул.
Күпне югалтадыр, бик кызганыч,
Гомер кичә, күрми ямен ул.

Елата да шигырь, җырлата да,
Сүзнең тәмен тоям шигырьдә.
Җаннарыма рухи азык җыям,
Рәхмәт әйтәм, шуңа, шагыйрьгә.

Өйдә тоталмассың шагыйрьне, юк,
Айда үткәрә ул төннәрен.
Йолдызларны коча, күктә йөзә,
Җирдә яшидер тик көннәрен.

Кайда яшәсә дә исән булсын,
Шатландырсын шигыре белән.
Ул бәхетле! Аны сүзләр сөя,
Ә мин исә, ә мин... Шигырь сөям!

## Театрга илтә

*Тукталыштан күп нәрсә юк,*
*Гаҗәп!*
*Анда озак басып тору – газап!*
*Әлмәтемдә алар саны күптән,*
*Ике йөз дә илле җиде икән.*

Автобуста бик күп йөргән булды,
Тукталышлар таныш балачактан.
Киткән автобуска куллар изәп,
Булды тукталышта калган чаклар.

Хәрәкәттә – бәрәкәт диепме
Автобусы, троллейбусы чаба.
Тукталышлар кисәтәдер төсле –
Юл йөрүдә белегез дип, чама.

Дөнья буйлап без дә атлап түгел,
Томырылып гел алга чабабыз.
Дөнья куабызмы, улмы безне? –
Әллә чапмый юкмы чарабыз?

Кирәк безгә ышык тукталышлар
Саклау өчен салкын яңгыр, җилдән.
Имин еллар аша үтик юлны,
Ямьнәр табып яшик газиз җирдән.

Бер мизгелгә тукта әле, җиһан,
Әнә, күпме тукталышлар көтә.
«Театр» тукталышы, төшик, әйдә,
Римга түгел! Юллар
Театрга илтә.

## Зәй буенда

Тау артыннан кояш күтәрелә,
Төн пәрдәсен ертып, таң ата.
Әрәмәдә тынлык хөкем сөрә,
Зәй үзе дә тынлык ярата.

Агач башларына эленеп калган
Чиккән челтәр сыман ак томан.
Могҗизалы мизгелләрне кочып,
Әрәмәләр йоклый бит һаман.

Тирә-якны сискәндереп шулчак
Кәккүк тавышы яра һаваны.
Бөдрә таллар Зәйгә башын игән,
Ишетелә кошлар авазы.

Табигатьнең кодрәтеннән килә,
Бар дөньяны күмә җыр-моңга.
Вак дулкыннар ярга сер сөйлиләр,
Күпме серләр яшидер монда.

Бу могҗиза бер төш кебек кенә,
Тылсымы да иңгәндер күктән.
Зинһар, тупас кагылмагыз аңа,
Матурлыгын күңелдә йөртәм.



*Миләүшә Каһарманова – башкорт язучысы, журналист. Чиләбе өлкәсенең Аргаяш районында туган, балачагы Башкортстанның Бөрҗән районы Яңа Усман авылында үткән. Башкорт дәүләт университетының башкорт филологиясе һәм журналистика факультетын тәмамлаган. Хезмәт юлын «Йәшлек» газетасында, «Әманәт» журналында башлаган. 2015 елдан «Киске Өфө» газетасы хәбәрчесе, 2022 елда «Һәнәк» журналының баш мөхәррире итеп сайлана.*

*Шәһит Ходайбирдин исемендәге премия лауреаты (2018), Мәхмүт Кашгарый исемендәге Халыкара төрки телле язучыларның хикәяләр конкурсында икенче урын иясе (2014), Башкортстанның атказанган матбугат һәм киң мәгълүмат хезмәткәре.*

# Миләүшә Каһарманова

ХИКӘЯЛӘР

## ҖИЗНӘМ

Көнозын елап ятам, миндә берәрсенең эше булсачы! Чынында еламыйм да инде хәзер, туйдым, көчәнсәм дә, күз яшьләре дә чыкмый. Апам иркәләгән, әнием җәлләгән чакта елавы да рәхәт иде. Хәтта «теге» (исемен әйтәсем килми) килеп, аркамнан кагып, чәчемнән сыйпап маташканда да, ярсыйсы гына килгән иде. Аннан мине оныттылар. Әнием ачуланырга да уйлый башлады әле. «Тор! Өй тулы кеше, адәм көлдереп аунап ятма», – дип үтте. Торсам, җиңеләм инде, тормасам, әллә күпме нәрсәне күрми калам. Апам кияүгә чыга бит бүген! Шуңа елыйм, шуңа кайгырам. Чыга инде, «теге» килеп йөри бит, җанны көйдереп. Чәчәкләр алып килгән була. Андый чәчәкне мин апама үзем дә җыеп бирә алам. Кирәк булса, бер арба итеп өяргә була, үзебездә үсә. Бүләк иткән пудрасын да күрдем, йомры тартмада он сыман нәрсә. Биткә озак сөртеп торсаң, ялыйсы килеп китә – исе тәмле генә. Туган көненә дигән алкасы да матур… Тик барыбер апамны бирәсе килми. Кичләрен эскәмиядә бергә утырган чакларында карап кына торам да, апамның иңбашына кулын салса, шунда ук беләген этеп төшерәм. Салмасын! Аны мин генә кочаклый, мин генә сөя алам. «Балдызым усал», – дигән була, кәнфит белән алдатмакчы, акча бирмәкче. Алмыйм. Каршыдагы тау зурлык алтын бирсә дә, мин аңа апамны…

Никах укый башладылар! Ипләп кенә торып, түр якта тынып калган хатын-кыз арасына кереп китәм. Зур якта агайлар өстәл тирәли тезелешеп утырып, сакаллы мулланы тыңлыйлар. Мулла озак кына көйләгәч, кара-каршы утырганнардан «риза, риза» дип әйттерде дә, тагы да нәрсәләрдер дип, битен сыпырды. Башкалар да шулай иткәч, бу яктагы апаларга кушылып, мин дә «әппәр» иттем. Аннан апамны котлый башладылар.

Әбиләр: «Кияү котлы булсын!» – дигән булалар. Булмасын, әйдә! Яратмыйм шуны!

Бераздан сый-хөрмәт арасында онытылып киткәнмен. Кортлы бишбармак ашап, кыз бирешергә ияреп килгән балалар белән кем узышмактан кәнфит кәгазьләре җыйганда, яшьләрнең кәләшне югалтып, мине шау-шулап алып китүләре сискәндереп җибәрде. Тамак туйдырып йөрим, ә анда апам югалган! «Югалган», дисәләр дә, берәү дә артык кайгырмый, киресенчә, сунарга чыккан этләр шикелле ашкынып торалар. «Теге» дә иптәш егетләре арасында авызын колагына кадәр ерып алган да, кулы белән әрле-бирле әйдәп, кайсы яктан эзләргә икәнен чамалый. Минем ялкынлы карашымны тоеп, «Әйдә, эзләргә», – дип чакырып, җитәкләргә учын суза. Шуннан җитәкләтеп торам, ди! Янындагы апамны югалтып утыра. Аңгыра! Мин янында булсам, бер дә күз яздырмас идем.

Шулай нык югалса да югала икән кеше. Мин күпме уйнасам да, алай югалмыйм, кич төшүен шәйләү белән өйгә сыпыртам. Бу апам нәрсәгә дип алай еракка качты икән? Әллә «моннан» яшеренгәнме? Ай-һай, шулайдыр ул…

Авылның әллә ничә йортына кереп, тентү үткәргән апа-абыйларга ияреп йөргәндә, шулай уйлап, кара янам. Кергән йортларда безне алдаштырып, ишекләрен ачмый, кияүдән акча таптырып йончыталар. Җиңгәләр белән тарткалашып хәлдән тайган, йә бүләге, йә акчасы талап алынган, әмма барыбер күңелен төшермичә, кәләшен эзләгән җизни дигән кешемә карата күңелемдә җәлләүме, әллә шуның кебегрәк башка бер җылы хисме уянырга итеп, кыбырсып-кыбырсып куя, тик мин үзсүзлеләнеп, аны сизмәмешкә салышам.

Ниһаять, апаны таптык. Елга аръягындагы әбиләрнең өендә булган. Башта капка аша кергәндә, аннан ишек төбендә сатулашып, чыр-чу килдек. Кияү егетләре төенчекләрендәге аллы-гөлле яулыкларын да, яшелле-кызыллы акчаларын да таратып бетерергә мәҗбүр булды. Тупса төбендә гүләшеп, көлешеп, такмаклап биеп туйганнан соң гына, ишек ачылып китте. Җизни тиешле кешемнең артыннан мин дә омтылган идем – ишекне борын төбендә генә «шап» иттереп яптылар да куйдылар. Башта «мине күрмисезме әллә?» дигән кыяфәттә башымны күтәреп, бик салып торучыларга акаеп карадым. Тик аларның «хи-хи» дә «ха-ха» – мине бар дип тә белмиләр. Ачуымнан йодрыклап, ишекне тукмый башладым, кулымны тотып алдылар. Тибешә башлагач, күтәреп үк алып киттеләр. «Апа! Апа, мин монда!» – дип кычкыруыма авызымны капладылар. Хәлемнән килгәнчә тыпырчынып карыштым, тешләштем, боргаландым. Миңа бит болардан ычкынып, апамны коткарырга кирәк! Аны бит бикләп куйдылар… «Теге»нең белән! Ну… Айбулат! (Эчтән генә булса да, беренче тапкыр җизнәмнең исемен әйтәм). Чыгарсың әле, кирәгеңне бирәм!

Үзебезнең ихатага кайткач, үчемне кемгә кайтарырга белми, үрле-кырлы йөргәндә, «теге»нең лапас астында торган матае күзгә чалынды. Борырлык бөтен нәрсәләрен боргалагач та, ачуым басылмады, шуннан җирдән учлап туфрак алып, бензин багына койдым. Аннан бакның капкачын ябып китеп бардым.

Икенче көнне уянсам, кичәге кунаклар кайтып киткәннәр, ә «теге» матаен сүтеп салган да ремонтларга маташа. Аңа күрше абыйлар кушылган,

барысының да куллары кап-кара майда. Апам янындагы бүкәнгә кунаклаган да «теге»ннән күзен алмый карап утыра. Бу күренештән кәефләнеп, «яхшы булган» дип тантана итеп өлгермәдем, әнием:

– Кем алай итеп этләшеп йөрергә мөмкин? Күреп, кулын өзеп алырга иде шуның, – дип сукранганыннан битемә ут каба да яшерен генә «теге»ңә күз салам. Ә ул, шул сүзләрне генә көтеп торгандай, башын күтәрә дә туп-туры миңа карый. Ах! Ул бит белә! Минем эш икәнне! Куркуымнан манма тиргә төшәм. Әйтә инде! Хәзер әйтә дә минем кирәкне бирдерә. Без бит – «дошманнар». Шушы явызлыкны көтеп торганда, бу, шаян елмаеп:

– Эх, балдызымны матайда җилдертеп йөртермен дигән идем, – димәсенме! Гарьлегемнән борылдым да өйгә җилдердем.

Әткәйсез икәнлегемне тоймасам да, әткәйле гаиләләрдә нәрсәдер икенчерәк икәнлекне аңлыйм. Шунлыктан җизнәмнең (хәзер мин аны шулай атыйм, дөресрәге, әнием, сыек чыбык белән янап, шулай дип кенә эндәшергә кушты) башка балалар янда булганда килеп, сүз кушуы ошый. Ат эчерергә барганда, юаш биясенең киң аркасына атландыра да җайлап кына йөртеп алып килә. Мин түбәндә янәшәдән тәпиләгән малайларга һавалы гына карап барам. Таганнарына да бик канәгатьмен. Һавага кадәр очарга була. Көянтәгә дип, шомырт киереп куйды әле, киләсе килүемә кибеп торыр, диде. Алар апам белән күрше авылда яшиләр, быел укырга барып, киләчәктә дүртне тәмамлагач, мин дә аларда торачакмын, бездә мәктәп башлангыч кына бит.

Мин хәзер җизнәмне күралмыйм түгел, киресенчә, күрәсем килеп тик тора. Бу хисләрем ни арада шулай бөтенләй икенче якка авып киткәндер, кай арада ул мине шулай сихерләп алгандыр – белмим. Апамнан бигрәк, аны сагынам. Мәктәптән кайтам да әниемнән: «Җизнәмнәр килмиме әле?» – дип сорыйм. «Атлаган саен килеп йөри алмыйлар инде, ял көнгә бер кичкә генә урап китәрбез, дигән иде апаң», – дигәннән канатланып, буяу каләмемне төкерекләп, календарьдагы болай да кызыл ялны тагы да зурайтыбрак куям – күренебрәк торсын.

Беренче сыйныфны тәмамлаганда, апамнар безгә бәбәй белән килде, һәм улы туу шатлыгыннан җизнәм миңа сәпит сатып алган иде. Бәхеткәйләрем! Бәбәйдән бигрәк сәпиткә куандым шикелле. Әнием:

– Акча туздырып, малайлар нәрсәсе алып, – дип, ачусыз гына сукранырга уйлаган иде дә, җизнәм:

– Безнең Әминәнең характеры егетләрский бит, әби, курчак тотмый ул, өйле уйнамый, әйдә, сәпит белән юансын, – дип, тиз генә уңайга сыпырды да куйды. Ул арада мут кына итеп миңа күз кысты. Ризалыгымны белдереп, күзләремне челт-челт йомдым, күз кыса белмим бит инде – икесе дә бергә ябыла да куя.

Аннан егыла-егыла, ул сәпиттә йөрергә өйрәнүләрем! Терсәк-тубыклар тузса тузды – малайлардан калышмадым, утыргычына менеп утырырга буем җитмәсә дә, ике тимере арасына басып алып, педальләрен әйләндерәм генә! Бозауларны, казларны сәпиттә генә эзләп алып кайтам хәзер. Телне аркылы тешләп чабасы түгел, рәхәт.

Дүртенчене тәмамлап, җизнәмнәргә күченеп китү минем өчен зур бәйрәм

булды. Авылдан балалар елашып китә торган булса, мин исә чемоданымнан алда матай арбасына төшеп тә утырдым. Капка төбендә озатып калган әнием, озата барып, бер ноктага әверелгәч тә, арбадан җизнәмнең артына үрмәләп, башымдагы яулыгымны сыпырып төшереп, чәчләремне җилгә тузгыттым:

– Җизнәй, шәбрәк ку!

Җизнәм, көлә-көлә, тизлеген арттыра.

– Тагы да шәбрәк! – дип кычкырам, авыз куышлыгымны җил чалшайтканда да.

Без шулай тузан уйнатып, йөрәгем күкрәк читлегеннән ычкынып оча язганчы, матайда җилдердек.

Бу вакытта апамда ике малай иде инде. Монда укудан тыш вакытым шуларны багып, аш-су арасында булышып, мал-туар карашып үтә. Апам күбрәк балаларына уралып утыра, шунлыктан тыштагы күп кенә эшләрне җизнәм иртән эшкә чыгып киткәндә, миңа төбәп әйтеп китә. Ул кушканча итеп кенә башкарып куям. Кайта да мактап ташлый. Без апам белән сүзгә саранрак, йомыграк кешеләр булгач, андый матур сүзләрне таба да белмибез. Ә ул шундый килешле, урынлы гына итеп әйтә. Дәресләремне эшли алмый тузынганда да, җизнәм апам ачуланмаслык, мин үчекмәслек итеп аңлата белә. Ахырда, дәрес тә эшләнә, без дә – дус. Шулай ук минем мәктәптәге җыелышларыма да ул йөри. Малайлар белән сугышып-фәлән киткәндә дә, апам шикелле «үзе дә тик тормый» дип кенә куймый, ә барып, теге шилмаларны күреп, сөйләшеп кайта. Апама: «Әткәйсез, ятим, дип кыерсытып өйрәнмәсеннәр», – дигәнен үзем ишетеп калдым әле.

Мин алтыга бара торган көздә апам өченчегә бәбәй алып кайтырга әзерләнде. «Җизнәңә кыз табып бирсәмме», – дигән була миңа сердәш итеп. Миңа ни – барыбер, малае да, кызы да, кем әйтмешли – шул имгәк инде, карашырга кирәк. Апам мондый хәлдә булгач, тагы да йөгерә-чаба торган эшләр – минем җилкәдә. Беркөн эңгерләтеп кенә, кайтмый калган сарык бәрәнен эзләп йөрим. Мал тавышы килгән бөтен җирне карап чыктым. Күп урынны кешеләрнең киртә-курасы булган яктан – арттан үтәм. Берәүләрнең ялан киртәсе турысыннан тар гына тыкрыктан килә идем, бәйле торган атны танып, игътибар иттем. Киртәгә якын ук килеп, киртә арасыннан кулымны сузуга, ат та танып пошкыра-пошкыра, миңа омтылды. Җизнәм менеп йөргән соры айгыр бит бу! Туры килгән саен шакмак шикәр каптырып өйрәткәнмен. Тик бу ат монда нишли икән, аны җизнәм генә йөртә иде бит? Һәм бу йортта кемнәр яши? Җизнәм аларга туктаганмы икән? Аптырап, каранып тордым да, аттан җавап алып булмасын аңлагач, үз юлым белән киттем. Бәрәнне табып алып кайтып бикләдем дә өйгә керер-кермәстән:

– Җизнәм кайттымы? – дип сорадым.

– Юк, – ди апам кәефсез генә. – Әле өч көне бар. Нишләп?

– Болай… – Шулвакыт мине ниндидер аңлаешсыз сиземләү ат хакында сүз кузгатудан тыйды. Хатын-кыз сиземләве булган икән ул.

– Озак шул, ферма күчеп кайтса, болай куна йөрмәс иде дә, – ди апам, йөзен чытып. – Уф-ф, авыртырга уйлый әллә, вакытым бар бит әле…

Төнгә таба апам чынлап авырып китте. Билен басып, ишекле-түрле йөри. Ахырда, мине фельдшерга йөгертте. Барып, аны чакырып кайтып килгәндә,

апамның ыңгырашкан саен: «Айбулат кайтып өлгермәде бит әле… Айбулат юк…» – дип өзгәләнгәне исемә төште дә ниндидер шайтан котыртуына иярепме, ат торган йортка карап чаптым. Барып, тыкрыкка чыгып торган тәрәзәсенә таяк белән үрелеп тукылдаттым. Бер шакыдым, ике… Эчтән хатын-кыз тавыш бирде: «Кем бар анда?» Бик кыю килсәм дә, моны ишетү белән торып качарга да уйлаган идем, әмма эндәшергә көч таптым:

– Мин!

– Син кем ул?! Нәрсә кирәк?! – ди бу, ачуланып.

– Айбулат җизнәм!..

Эчтәге хатын телсез калды шикелле. Мин дә әйткәнемнән каушап торган арада, кайдандыр, өйдәнме, киртә ягыннанмы – караңгылыктан пәйда булган берәү кинәт беләгемнән тотты:

– Балдыз?..

– Апа авырый, – дип кенә әйтә алдым, җизнәмне таныгач. Исемә килгәндә, өйгә чабып кайтып җиткән идем инде.

Күктән төшкән бәхет булып кайтып кергән җизнәмә апамның куанганын күрсәгез! «Сизендеңме, Айбулат, күңелең сиздеме?» – дип, исенә төшкән саен сорый үзен юлга әзерләшкән җизнәмнән. Тегесе көчәнеп елмаеп, башын гына кага. Кая булган тасма теле? Кабалана-кабалана, аны-моны сумкага тутырган арада җизнәм, ике күзен тутырып, миңа карап ала. Карашы бахырның! Хуҗасының төшке ашка дигән икмәген урлап ашаган этнеке кебек. Йә үтерәсең, йә калдырасың дип тилмерә. Мин усаллыгымны итәм – күрмәмешкә салышам. Ул карашымны тотарга итә, хөкемемне көтә. Эндәшмәдем. Анда да, аннан соң да. Җизнәм бик авыр кичерде моны. Каты авыру үткәргән кебек чак «савыкты». Ә мин бөтен бу хикмәтле хәлнең төбендә ниндидер ярамаган нәрсә барлыгын тоемладым. Шул гына.

Апам тагы да малай тапты. Туптай йомрыланып, кулда ярыйсы гына авыр булган бәбине юындырышып йөргәнемне карап, күзәтеп утырган җизнәмә апам, гаепле тавыш белән:

– Кыз булмады инде, син кыз бала яратасың бит, – дип куйды.

Шунда җизнәмнең әйткәннәрен һич тә онытмыйм.

– Кызыбыз бар бит инде, – дип, ияге белән миңа ымлады да уенлы-чынлы итеп: – Сиңа охшап – усал, миңа охшап – егәрле, – дип куйды.

Чынлап та, бу авылда мине «Айбулат кызы» дип тә әйткәлиләр. Һе, «Айбулат кызы»… Болай ошый.

Моннан ары да, инде үзем аңлаган һәм хәтерләгән гомеремдә мин җизнәмнән аз яхшылык күрмәдем. Ул минем өчен әткәй генә түгел, терәк тә, таяныч та булды. Пошынган чакларымда чәчемнән сыйпап юата, ялгышканда, дөрес юнәлеш бирә, артык шашынганда тынычландыра, мохтаҗ чагымда – ярдәм кулы суза, юата, күндерә һәм күңелемне үстерә белде. Апам аңлый алмаган чакларда да хәлемне төшенде, йөрәгемдәгесен тоя алды. Эчкерсез, аталарча яратты ул мине. Ә мин – аны.

Бүген ул мине кияүгә бирә. Никахтан соң табында исереп киткән. Әллә шуның шаукымыннан, әллә башкасыннан – ике күзеннән яшьләре мөлдерәп түгелеп утыра. Ирексездән, үземнең алар никахындагы хәлем исемә төшә дә:

– Шулай, җизни, дөнья – куласа, – дип көләм.

Ә анын телендә тик бер сүз:
– Балдызымны… балдызымны алып китәләр…
Әй, җизнәм! Җизнәм – җиз төймәм…

# МАНДОЛИНА

Конференциянең соңгы көнендә, план буенча шулай булыпмы, әллә сөйләшер-киңәшләшер сүзләр дә беттеме, делегациягә шәһәрнең кунакчыллыгын күрсәтергә булдылар. Театр-мазарларга артык исе китмәсә дә, музейга кергәч онытылды Әлфия. Шундый урыннарны ярата ул. Архивларда чокынып, борынгы язмаларны укып, күптән онытылганнарны яңартып утырудан ләззәт таба. Әллә нишләп археолог булмаган, һич югы – тарих укытучысы.

Әле дә бәгъзеләр кебек картиналар галереясын карап чыгу белән генә чикләнмичә, борынгы әйберләр сакланган якка үтте. Башта төрле җирләрдә һәм төрле заманнарда табылган тимер-томыр, савыт-сабаны карап чыкты. Аннан музыка кораллары куелган урынга күчте. Кайчандыр ниндидер осталар кулында үз гомерен үткәреп, әле килеп шушы киштәләрдә зарыккан гармун, скрипкалар тезелгән рәтләрне сөзеп үтеп барганда, яхшырак күрергә чекерәеп кысылган күзләре шар ачылды Әлфиянең. Мандолина! Таныш… «Мөмкин түгел!» Муенын алга сузып текәлде, аннан артка чүкте – кит инде! Шул бит! Шул! Бу мандолинаны башка белән һич бутамас, меңнәр арасыннан да таныр иде ул. Ике як чигәсенә чөй кыздырып төшергән сурәтләре дә, уң як читтәге «ГӘ» тамгасы да, аннан астарак чәчкә тажы эчендәге кечкенә «Ә»дә шушы учлары белән йөзәр кат сыйпалган, бармак битләре белән меңәр кат үтелгән, уйсу-уймак урыннары да – барысы, барысы да таныш. Таныш кынамы, елап җибәрердәй якын, үз...

Әлфия, як-ягына каранып, музей хезмәткәрләрен эзләде:

– Гафу итегез! Карагыз әле, мөмкинме монда берәрсен?

– Әлбәттә, тыңлыйм. – Шул арада мөлаем бер кыз килеп тә басты.

– Бу… мандолина, кайдан?

– Тә-әк, номеры… хәзер. – Кыз тиз-тиз атлап китеп барды да, Әлфия һушын җыеп өлгергәнче, папка тотып килеп тә житте. – Тә-әк… Әһә. Әсмабикә Карагулова дигән әби шушы районда яшәгән вакытында кертеп киткән.

– Ничәнче елда?

– Әйтә алмыйм. Исеменнән башка мәгълүматлар юк.

Карап торып кына түземлеге җитмәде, рөхсәт сорап, мандолинаны кулларына алды Әлфия. Алды да, ирексездән аккан күз яшьләрен бармак очлары белән сөртә-сөртә, бала шикелле итеп күкрәгенә кысты. Аннан сыйпап, хәтта борынына якын китереп иснәп торды. Әллә, чынлап, Габит абыйның әче махорка төтене, әллә Әсма апаның исле мае сеңеп калган? Әллә хатирәләр исеме бу?

…Дәшһәтле сугышка кадәр ике ел әүвәлме, әллә өч елмы? Өч тирәседер. Авылларына озын итәге өстеннән кырмыска билен калын каеш белән өзеп буган ап-ак йөзле, кара кашлы укытучы килеп төште. Аннан алда килгән һәм

шушында төпләнеп калганнарыннан бөтенләй башка, ят иде ул. Бу үтә дә зифа буйлы, аккош муенлы, моңсу карашлы. Озын нәзек бармаклары кара каләменнән башканы күтәрә дә алмыйдыр кебек. Чәчен кабартып, җилкә чокырына түгел, түбәсенә өюе дә, күлмәк түгел, блузка-итәкләр киюе һәм озын итәге астыннан үкчәле ботинкасының очлы башы ялт-йолт күренеп йөрүе дә үзенә генә хас, мондагылар өчен ят күренеш иде.

Әлфия укытучысына бер тамаша кылган шикелле булып текәлеп утырып, дәрес үтүен дә сизми кала. Бу апа берәр әкияттән килеп төшкәндер дә, катырак җил иссә, тәрәзә аша очып чыгар да китәр кебек тоела аңа. Тик апа югалмый, янына якын ук килеп баса. Алдагы партадагылар борылып, авыз ера. Тукта, апа аңа дәшә бит.

– Әлфия, син мине тыңламыйсың бит, Әлфия, – ди икән.

– Ә?

– Өйгә эшне язып алдык, син оеп утырып калдың.

Кызара-бүртенә, тактага язганнарны тиз генә күчереп ала да башкалар уңаена китап-дәфтәрләрен сумкасына тутырып, кабаттан беләкләрен өсте-өстенә салып, тураеп утыра. Башкалар да шулай иткән, дәресләр тәмамлануга карамастан, берәү дә кайтырга ашыкмый. Күзләрен дүрт итеп, укытучыларыннан тагы да нәрсәдер көтәләр. Менә апалары кызыл тукыма белән капланган өстәле астыннан кечкенә генә түгәрәк корсаклы мандолина ала да, илһамлы карашлары белән укучыларын бер иркәләп алгач, алга иелә биреп, тырнак очларына кыстырган каты кимерчәкне кыллар өстендә биетеп алып китә. Нечкә генә гөрелдекле илаһи моң башта бәләкәй кыз һәм малайларның күңелен, аннан ургылып чыгып, иске мәктәпнең тәбәнәк класс бүлмәсен, анда да сыймыйча, кайчандыр манаралы мәчет булган мәктәпне тутыра. Әкрен генә бүлмә ишеге ачылып, анда шым гына кереп, башка класс балалары, калган укытучылар җыела. Тын да алмый тыңлыйлар. Көй артыннан көй агыла, апаларының моңсу карашы тыңлаучыларга да күчә. Онытылалар…

– Җиткәндер, – уйнаучы туктаган, хәтта китәргә җыенып торып баскан икән. Ә тамашачыларның берсе дә исенә килмәгән. Бу искәртүдән аңнарына килгәннәр, хыялый елмаешып, кузгала башлый. Барысы да ләм-мим, рәхмәт әйткән, тәбрикләгән кеше дә юк. Чөнки алай гадәтләнмәгәннәр. Урман-таулар төпкелендә яткан бу авылның табигате кебек үк кырысрак, йомыграк халкы осталар, сәләтлеләр турында үзләре булмаганда гына мактап, сокланып сөйли. Алларында барысы сүзсез тыңлап йә күзәтеп кенә торалар. Төчеләнү, очындырыр хәбәр әйтү яшенә дә, картына да хас түгел. Читтән килгән укытучылары мондый мөнәсәбәтне, бәлки, кыргыйлык дип тә уйлыйдыр, әмма уй-хисләрен сиздерми, тәүге көндә үк мандолинасын күреп калган фатир хуҗабикәсенең соравын үтәгән кебек әле дә көн дә дәресләрдән соң укучыларының теләген канәгатьләндерә. Үзе моң сөйгәч, моңга гашыйкларны да сөя, хөрмәт итә, ахры, ул.

Әсма аның исеме. Үзе кебек нечкә, йомшак, хисле генә исеме дә.

– Әсмагә тиң булырдай егет юк бездә, – дип сөйләшә Әлфиянең әнисе белән апа фатирда торган күрше Мөгълифә әби.

– Теге Хәтирәнең Сәгыйте укымышлы, диләр, кайтып төшмәс микән, – ди әби, нәрсәгәдер өметләнеп.

– Кит, алар заты гөрбиян да инде, – дип каршы төшә әнисе. – Бикле өйдә утырып сулыр.

– Әйе шул, – дип килешеп, Мөгълифә уфтанып ук куя. – Китеп барса да әрәм инде.

Чынлап шулай булдымы, әллә башка сәбәптәнме, Әсма апага егет булмады авылда. Моңа кадәр килгән укытучы кызлар Яңа елдан да калмый ияле була торган булса, чибәр мандолиначыны кияүгә чакыручы табылмады. Сәбәбе телдән әйтелмәсә дә, барысына да аңлашыла иде. Әсма апа үзенең очып йөргән кебек кенә сын-фигыле, талгын хәрәкәтләре, биючеләрнеке шикелле сыгылмалы куллары, ап-ак нәфис йөзендәге керфекләре леп-леп килеп торган болан күзләре белән авыл егетләренең «иң-иңнәре» дигәннәренә дә туры килми. Аны берәү дә сыер савып утырган яки сарык эзләп йөргән итеп күз алдына китерә алмый. Һәм бик эчләре янса да, егетләр дә мондый югары нечкәлеккә үрелә алмый, тәртип саклый иде бугай.

Яңа ел алдыннан авылга район үзәге яшьләре концерт алып килде. Араларындагы хәрби киемдәге озын буйлы егетне, әлбәттә, шәйләми калу мөмкин түгел иде. Курайчы икән үзе. Җырчы-биючеләргә курай тартып, сәхнә читендә күренә биреп кенә утырды. Ахырда хәрби комиссариат кешесе дип таныштырып, баш идерделәр. Боларның чыгышларыннан соң, күчтәнәчкә авылныкылар да бер-ике номер күрсәтте. Әсма апаның мандолинасын халык кат-кат сорап чыгартты. Уйнады да уйнады ул, нәзек кенә бармаклары ничек түзгәндер. Шунда, сәхнә читендә, итекләре идәнгә кагылган шикелле булып басып торган хәрбинең апаебызга күзен дә алмый каравын күпләр аңлады һәм киләсе ялда бу офицерның атка атланып килеп төшүенә аптырамадылар да шикелле. Әнисе хәтта: «Нәкәнис», – дип куйды.

Әсма апа белән Габит абый арасында мәхәббәт ялкыны кабынды. Икесенең парлашып, авыл урамыннан үткәне сокланып карап калыр тамаша булды. «Таһир белән Зөһрә инде болар», – дип тел шартлатты хатын-кыз.

Әлфия әнисе кичке савымга киткән кышкы озын кичләрдә еш кына күршеләрендә булды һәм Әсма апасы урынына күп очракта Габит абыйны үзе чыгып каршылады. Аннан әкият батыры шикелле чибәр хәрби белән кара-каршы утырып чәй эчкәч, җитәкләшеп, мәктәпкә баралар, анда Әсма апа зуррак балаларны мандолинада уйнарга өйрәтә. Кайтканда, яшьләр, Әлфияне уртага алып җитәкләп, йә шудыра, йә йөгертә – и, күңелле була. Туры Әлфияләрнең өенә керәләр, мичкә ягып җибәрергә кирәк. Тик бу эшне әлегә Әлфия дә, нигәдер Әсма апасы да юньләп башкара белми. Укытучысы утынны кабыза алмый, өйне төтәтеп, үзе чәчәп бетә торган булса, Әлфияне әлегә бәләкәй дип ышанып җитми әнисе. Габит абый бу мәшәкатьне тәү күргәндә, кызык итеп карап торды да учак алдына чүгәләп, икесенә дә ут кабызу тәртибен аңлатты. Башта ул сагызлы коры агачлардан пычак белән чыралар сыдырды, аннан аларны чат-чатлап өеп салды һәм, шырпы сызгач, өемнең ике ягына тагы да берничә корыны тезде. Учак гөрелдәп суырып алып киткәч, тагы бераз өстәп, капкачын ябып ук куйды.

– Аңладыгызмы? – дип сорый ул, кызларның икесенә дә алмаш-тилмәш карап. Күренеп тора: үзенә күңелле.

– Мин болай да беләм, – ди Әлфия исе китми генә. – Ә Әсма апаларның миче булмаган, ул шуңа белми. Ул ишшу сипарат әйләндерә дә белми, сыердан

да курка… Ы-ы... – Апасының тагы нәрсәләрне белмәвен хәтерли алмый тора. – Йон эрли алмый, орчыгы төшә дә китә. Ярый, икмәк ачытырга өйрәнде инде.

Бу хәбәрдән Әсма апа, елмайса да, бит очлары алсуланып чыга, уңайсызлана. Габит абый көлә-көлә, сөйгәненең биленнән кочаклап ала да маңгаеннан үбеп:

– Икмәк пешерә алгач, булды, ачтан үлмәсбез, – дип, күкрәгенә кыса. Әлфия соңыннан бу хәлне әнисе белән Мөгълифә әбисенә сөйләп кинәндерә. Өлкәннәр көлә-көлә дә, әнисе азактан: «Кит, йөрмә араларында буталып, яраган-ярамаганны күреп», – дип әрләп тә куя.

Шулай мәхәббәт һәм мандолина моңнарына гына күмелеп, кыш чыккач, яз уртасында мандолинасыз торып калдылар. Дөресрәге, Әсма апасын Әлфия мандолинасыннан яздырды. Апасын гына түгел бөтен мәктәпне, авылны яздырды ул моңнан. Ә хәл болай булды.

Әлфияләрнең алты өйдән генә торган кечкенә урамы авыл читендәге елга аръягына утырган. Җәйләрен күпер аша йөрсәләр дә, кышларын, турылап, боз аша юл салалар. Апрель башлары булса да, боз өстендәге сукмак шул килеш әле, бары тик су күтәрелгән урыннары гына ялтырап, үтә күренеп ята. Әсма апасы белән гәпләшеп кайтып килгән Әлфия, шул ялтыр боздан көндәгечә бер генә шуып үтмәкче булып, йөгереп барып керде дә, кире атлыйм дигәнче, таеп егылды, һәм егылган җире күз ачып йомганчы уелып китте. Кыз үзе дә аңлап өлгермәстән, өтеп алган салкын суга чумды һәм кире калкынганда ачы итеп чырылдап җибәрде. Шул вакыт бу хәлдән каушап калган укытучысы ярдәмгә ташланды. Тик ул бәкегә якын килә алмый, якынаям дип омтылган җире уела бара. Ахырда, бозга ятып мандолинасын сузды. Бәке читләренә чак тотынып торган Әлфия, өшегән бармакларын кинәт ычкындырып, мандолинаның корсаклы башын кочаклады да тубыкларын бәке читенә күтәрде. Чыгарга тырмашкан вакытта мандолинаны шундый көч белән тарттымы, ул укытучы кулыннан ычкынып китте. Шул секундта ук Әсма буш кулы белән Әлфиянең якасыннан эләктереп өлгерде дә, җилтерәтеп торгызып, өйгә йөгертте. Җылы мич янында киемнәрен алмаштырып җылынгач, курку һәм шатлык тойгылары үткәч, мандолиналары да искә төште. Боз астына кереп киткән мандолина…

Шул хәлдән соң моңсыз калдылар. Хәзер дәресләрдән соң дөбер-шатыр килеп, шундук кайтырга чыгалар. Мандолина түгәрәге дә эшләми. Бик гаепле сизә үзен Әлфия. Күренеп тора, сер бирмәсә дә, укытучысы да күңелсезләнә. Әнисе: «Көзгә мал суйгач, шәһәрдән берәрсе аша эзләтеп карарбыз», – дип юаткан була да, аңа кадәр ничек түзәргә? Моңсыз, мандолинасыз ничек яшәргә? Һәм бу бәладән Габит абый коткарды. Мандолина тотып килеп керде ул бер кичне. Әлфия куанычыннан сикереп торды, мандолинаны чупылдатып үпте.

– Ә мине? – дип көлде Габит абый. Бик теләсә дә, абыйны үбәргә оялды кыз.

Әсма апа мандолинаны әйләндереп-әйләндереп сыйпады:

– Кайдан алдың?

– Бер җирдән дә тапмагач, инәлеп-ялварып дигәндәй, бер скрипка остасыннан эшләтеп алдым. Ошыймы?

Әсма апа сөенеп туя алмый. Утырып, кылларын көйли. Әлфия, янда сикергәли торгач, шунда да бер кимчелек таба:

– Бу мандолинаның тегесе сыман бизәкләре юк икән.

Габит абый җилкәсен кашып тора да, «Хәзер», – дип, эшкә тотына һәм, утта чөй кыздырып, коралның ике чикәсенә бизәкләр төшерә дә серле генә итеп «ГӘ» тамгасын сала. Әсма апа хисләнеп күзәтеп утыра.

– Ә бу нәрсә? – дип ныкыша Әлфия, хәрефләргә күрсәтеп.

– Габит абыең һәм Әсма апаң, – ди офицер сөйгәненә күз кысып.

– Ә мин кайда? – дип бүлдерә боларны кызыкай. – Минем дә хәрефемне яз.

Яшьләр бер-берсенә карап елмаеша да, егет аскарак тагы да бер бәләкәй генә «Ә»не чыя.

– Ә-ә… минеке бәләкәй генә булды, – дип, Әлфия үпкәләмәкче була.

– Хәзер-хәзер. Аның каравы синеке матуррак була, – дип, Габит абый хәрефне түгәрәккә ала да тирәләтеп чәчәк таҗлары ача. – Булдымы?

– Булды-ы-ы!

Шуннан соң укытучысына яңадан – моң, ә Әлфиягә тынычлык кайтты.

Көзгә Әсма апа белән Габит абыйның туе булды. Кияүгә чыкса да, укытучылары тагы да бер уку елына авылда калды, аңа аерым йорт бирделәр. Офицер җизнәләре район үзәгенә йөреп эшләде. Укулар тәмамланганны көтеп кенә торган кебек, Әсма апаның улы туды. Башкалар укытучысыннан тартынса да, күрше яшәп өйрәнеп өлгергән Әлфия бу өйнең еш кунагы булса, бәби тугач, зур ярдәмчегә әйләнде. Яшь ананың эше күп, хәзер ул мичкә дә яга, йон да яза, бәйли дә белә. Тик барыбер мандолинага вакыт таба, бәби дә, Әлфия дә шул моң астында йоклап китә.

Аннан сугыш башланды. Яшь гаилә Габит абыйның туган якларына күченеп китәргә әзерләнә иде. Ир кеше хатынына: «Борчылма, озак бармаячак бу, җәй азагына булса да кайтып җитәрмен, минсез кузгалма», – ди дә беренче добровoлецлар отрядын алып китә. Шул китүдән бер хат, бер хәбәрсез гаип була.

Сугыш тәмамланып, тагы да бер ел үткәч, Әсма апага Сәгыйть абый яучы җибәрә. Мандолинасын чиртеп моңланган укытучыбыз аны кире кага. Сәгыйть абыйның апаебызны яратып йөрүен барысы да белә. Ике елдан, инде тәмам өметләре өзелепме, әллә атасыз үсеп килгән улын уйлапмы, Әсма апа Сәгыйть абыйны йортка кертә, игезәк кызлары туа. Ул вакытта бу хәлгә бик рәнҗесә дә, хәзер үзе Әсма яшен ике яшәгән Әлфия яшь хатынның хәлен аңлый да кебек. Тик… Әгәр дә шул «тик» булмаса…

Тагы да өч елдан Әлфиянең әнисенең йортына кичләтеп кенә Габит абый килеп кергән. Әлфия ул вакытта шәһәрдә укый иде инде. Учак ягып маташкан әнисе, көтелмәгәнлектән каушап, шап итеп урындыкка утырган. Мөгълифә әби белән алар елашкан, кайнашкан, чәй утырткан, әмма Әсма апа хакында әйтергә курыккан. Икенче яктан, беләдер, белмәсә, туры өенә кайтыр иде дип тә уйлаганнар, әлбәттә. Ахырда, Габит абый үзе сүз башлаган, Әсманы чакырып китерегез, дигән. Күршеләр иргә хәлне аңлатырга, хатынының көтеп-көтеп тә көтек булуын төшендерергә тырышкан. Агай дәшмәгән. Чакырганнар Әсма апаны. Апаебыз кергән дә абыйның кочагына егылган. Калганын әнисе белми, чыгып киткәннәр.

Күпмедер вакыттан килсәләр, Габит абый юк, Әсма апа идән уртасында катып утыра икән. Бите көл кебек, карашлары бушлыкка төбәлеп калган. Әнием аңа ташланган:

– Ни булды, Әсма сылу, суктымы әллә?

– Юк, – дигән укытучы. – Сукса икән…

– Нәрсә диде соң?

– Алып китәргә килгән.

– Ә син?

Апа бераз вакыттан соң гына җавап биргән:

– Андый бәхеткә хокукымны югалттым бит мин, апа… Чак кына сабырлыгым җитмәде… Чак кына…

Авылда Габит абыйның сугышның тәүге айларында ук каты контузия белән аңын югалтуы, әсирлектә булуы, штрафбатка эләгүе, сугыштан соң чит тарафларда мәҗбүри эшләрдә йөрүе, аннан җайлап, хәтере ачылуы хакындагы тарих телдән телгә йөртелде. Әсма апа белән булган очрашуы да, әллә әнисеннән, әллә Мөгълифә әби авызыннан чыккан булып, һәртөрле бизәкләр, өстәмәләр кушылып таралды. Аптырадылар, бот чаптылар. Берәүләр Габит абыйны кызганды, икенчеләр – Әсма апаны, Сәгыйть агайны яклаучылар да булды, тик күбрәк сугышны каргадылар. Бу хәлдән соң күп тә тормый, Сәгыйть абый гаиләсен авылдан алып киткән. Китәр алдыннан укытучым мандолинасын әниемә алып килгән һәм:

– Әлфиягә калдырып китим әле, – дигән.

– Китчәле, – дигән әнием, – кызым уйный да белми. Үзеңнең аерылгысыз нәрсәңне.

– Габитның исән икәнлеген белгәннән соң, мин бу кылларга кагыла алмыйм инде, намусым җитми, – дигән шулчак Әсма апа. Әнием мандолинаны алмаган. «Ике күз генәсеннән сагышы түгелеп коелып тора инде», – дип хәтерләр иде азактан да хушлашулары хакында. Соңыннан апаның язмышы нинди булгандыр да нинди гомер кичергәндер – белмим. Бары ире җитәкче булып, районнан районга күчеп йөргәннәрен генә ишеткән идем. Шул Әсма апаның мандолинасы иде бу. Димәк, ул үзен гафу итә алмаган, калдыра алмаган янында мандолинаны. Нинди аяныч…

Әлфия кулындагы мандолинаны иркәләп туйгач, кадерләп, кире урынына куйды. Куйды да пышылдап кына эндәште. Әйтми, эндәшми дә булдыра алмый иде ул. Кемдер аңлатырга тиеш бит аңа – мандолинага:

– Син Әсма апага рәнҗемә, яме?.. Болай ятим калуыңа ул да, Габит абый да гаепле түгел… Рәнҗемә, кичер аларны… Син – сугыш корбаны.

# ЗӘҢГӘР ТӨЙМӘ

Хафиз каеш камчысын чыелдатып өскә күтәргән генә иде, авыр имән ишек ачылып китте. Өйдәгеләр барысы берьюлы тынып, керүчегә борылды. Анда тупса аша атлап өлгергән, кергәч кенә хәлне аңлап алган, ни сәлам бирергә, ни борылып чыгып китәргә белмәгән хәлдә дәрвиш карт тора иде. Әле генә йортны күтәрердәй булып шаулаган хатыннарның йөзендә башта

югалып калу, аннан оялу, хәтта оятларыннан җир тишегенә кереп китәргә теләү галәмәте чагылды. Икесе шулай итте дә: чаршау артына яшеренеп өлгерде. Олырак хатын, ярсудан кызарып киткән йөзен яулык очы белән каплап, үрелеп, иренең һаман югарыда торган кулына төртте. Ире камчысын урындык астына ыргытып өлгерде.

– Әссәламегаләәйкүм бу-у йортк-аа! – дип, бөтен бу күренешләрне аңламаганга салышып, сузып җибәрде керүче.

Хафиз да үзен кулга алды, хәтта ки балаларча шатланып куйды:

– Вәгаләйкемәссәлам, дәрвиш хәзрәт! Әйдүк-әйдүк! Түргә үз.

Үзе хатынына бер генә карап алды, тегесе җитез кузгалып, мич алдында кырын яткан самавырны бер колагыннан эләктереп тә алды. Су тутырып утыртуына, чаршау артындагы хатыннарның берсе җәһәт кенә килеп, аны тышка алып чыгып та китте. Өлкәне урындыкка ашъяулык җәеп, анда ит һәм башка ризык тезгәнче, яшеренгән урыныннан бөтенләй яшь чырайлысы баш иеп кенә чыгып, янып яткан учакның кисәүләрен кыскыч белән суккалап, күмер төшергәч, шуларны соскыга өеп салып, көндәше артыннан чыкты.

Ирләр күрешеп, хәл-әхвәл сорашып, урындыкка утырды. Хафиз өлкән хатыны алып килеп тоттырган тас һәм комган белән кунагының кулбитен чайкатып алды. Аннан самавыр түргә килеп утырып, чәй ясалгач, хатыннарына китәргә кушып, кул изәде. Тегеләре җәһәт җыенышып, чаршау артындагы урында уйнаган балаларын алып, янкорма аръягына – бәләкәй өйгә күчтеләр.

Кунак – суфый дәрвиш иде. Аның чын исемен беркем дә белми һәм сорарга да кыймый. «Су-сак, су-сак» дип, сәер генә итеп такмаклап йөрүеннән үзен «Сусак карт» дип тә атап куялар. Авыллардан авылларга, аннан тагы да әллә кайларга туктаусыз йөреп торуыннан «дәрвиш» тә дигәннәр. Ә инде туктаган урыннарында дин тәгълиматларын һәм пәйгамбәрләрнең тылсымлы тарихларын сөйләүләреннән аның суфый хәзрәт икәнлеген дә беләләр. Һәрхәлдә, бу картны бөтен җирдә дә ихлас кабул итәләр, аның өчен һәр йортның ишеге ачык, төн уртасында да, көннең теләсә кайсы вакытында да аны ачык йөз белән каршы алалар, мунча ягып кертәләр, аш салып сыйлыйлар, аның белән бергәләп намаз кылалар һәм фатихасын алып озатып калалар. Карт үзе дә бик ипле, тәүфыйклы һәм чиста адәм. Керен юып-киптереп биргән хатыннар аның кием-салымында артык кер юклыгын, хуҗалар табын артында да кыстатып кына кабуын, юлга да бер телем икмәк һәм бер баш корыттан башка сый алмавын беләләр. Ә инде ул сайлап, ишек каккан йорт бу изге җанның тап аның өен сайлавын зур мәртәбә итеп кабул итә. Хәтта үзенең артык азыгы булмаганнар да бу бурычны намус белән үтәргә тырыша. Чөнки күпләр аны Хозыр Ильяс дип тә уйлый. Чынында Хозыр Ильясның үземе-юкмы, бу хакта берәү дә бәхәсләшми, бары картның ризалыгын алу өчен, аның сәфәренә ниндидер файда китерү өчен тырышалар. Әйтүләренчә, карт Мәккәдә дә, әллә тагын чит-ят якларда күп булган. Һәм юлының күп өлешен ул шушылай җәяү үткән.

Дәрвиш хуҗаның хатыннарын куып чыгаруыннан аның бичә-чәчәсенә нык ачулы икәнлеген аңлады. Алай дисәң, бая кергәндә үк өйдә талаш-тартыш баруын тойган иде. Нәрсәгәдер нык кыздырып ташлаган хатыннары ирне.

– Ачуны озак саклама, ул сиңа барысын кара затта күрсәтер. Ачу артында хата бар, хата артында бәла ята...

Карттан яшереп булмасын төшенә Хафиз да. Күңелен айкап торганын әйтәсе килә:

– Менә бичәләр үзәккә үтте бит, хәзрәт... Син килеп кермәсәң, чынлап тукмап ташлый идем бу юлы.

– Э-эй, энем. Тукмап кына, акыл утыртып булса, аң кертеп булса, сыердан акыллысы булмас иде. Сөйләшеп киткән булыр иде ул мал, – дип кеткелдәп көлде аңа каршы карт.

– Нишләтергә боларны, хәйран булдым?

– Тоталмагач, ни ният белән өч хатын алдың? Нәфсеме бу, әллә башка сәбәпме?

– Нәфсе дип... Өлкән хатын абыйдан калган җиңгәм иде. Ике бала белән утырып калды, ул чакта абый мәрхүм бар иде әле. Әткәй миңа, унҗиде яшьлек кенә егеткә, мин уйлап-аңлап өлгергәнче, алды да бирде. Ярый, үпкәм юк, җиңгәм әйбәт булды, үстерде мине, аның куенында ир булдым. Бөтен хуҗалыгым аның кулында, балаларны да тәрбияләп, ул карый.

– Монысын бик дөрес иткәнсең, ятим хатынны канатың астына алып, үз каныңның балаларын читкә җибәрми. Бик хуп, хуп...

– Икенче хатынымны күзем төшеп алдым. Егерме биштән үткәч, ялан ягына салабаш, күмер сатарга барган идем, шунда бер авылда бер кызны күреп, тынычлыгымны югалттым. Минем уйланып йөрүемне хатыным сизеп калып төпченде, үз җиңгәм дә инде, аңа бар серемне сөйләп өйрәнгәнмен, әйттем дә салдым. Бу уйлады-уйлады да теге кыз белән сөйләшеп карарга кушып җибәрде. Барып, эзләп табып, сүз кушсам, кыз да мине оныта алмый икән. Кайттым да яучы җибәрдем. Озакламый алып та куйдым.

– Өченчесе нәрсәгә кирәк булды, монысына күңелең яткач?

– Өченчесен мин теге ачлык елында шәһәргә сәүдәгә барганда табып алып кайттым. 13-14 яшьләрдәге генә бала иде, ачлыктан хәлсезләнеп, шәһәр читенә чыгып егылган иде. Олаучылар, аны үлгәндер дип, туктамый да үтеп китә, мин, үз башымамы инде, чанамнан төшеп, янына бардым. Карасам – тере. Күтәреп, йөк өстенә салдым да алдым. Хатыннарым багып терелтте. Коры сөяк тә төймә борын иде. Мишәр кызы булган икән, әнисе белән генә яшәгән, анысы авырып үлгән дә, бу баланы ашатыр-карар кеше табылмаган.

Шул кыз бездә йөреп буй җиткерде, бик үткер, егәрле булып чыкты. Хатыннарым кулы астында эшкә өйрәнде. Берничә елдан якын-тирәдән яучылар килә башлады. Бер урынны җайлы гына күреп, ризалашыйм дип уйлап йөрсәм, кыз мине абзар арасында тотып алып, күземә туры карап, чатнатып: «Хафиз абый, мине берәүгә дә бирмә, үзеңә ал, бирсәң дә, качып китәчәкмен, мин сине генә яратам!» – димәсенме? Артка утыра яздым. Баксаң, аның бу мәхәббәтен хатыннарым да белә, имеш. Аларга да «ятка бирмәгез», дип елаган. Хатыннарым: «Кем кулына бара әле, өйрәнгәнбез, качып та китәр, әрәм булыр, бигрәк башбаштак бит», – дип торалар. Уйлаштык-сөйләштек тә алып калдык...

– Шуннан... нәрсәсенә риза түгелсең бүген?

– Ризалыгын ризамын да... Талашалар бит. Юктан гына яу булып чырылдашалар да китәләр. Әллә нәрсә бүлешәләр шунда! Һәрберсенең үз почмагы бар, кулларында бала, аермаска, бүлмәскә тырышам – юк, сүзгә килми яши алмыйлар.

Карт һаман күзләрен кысып, хәйләкәр көлә:

– Нәрсә бүлешергә мөмкин бер ирнең өч бичәсе? Ир сөюеннән башка... Һәрберсе ярының тик үзенә генә табынуын тели.

– Ничек берсенә генә булыйм инде, хәзрәт? Алар бит өчәү икәннәрен беләләр. Үзләре булдырды, үз теләкләре белән ясадылар бу тормышны.

– И-и энем, ир уртасына җиткәнсең, бер түгел, өч бичәгә хуҗа булып утырасың, ә хатын күңелен җайга салу хәйләсен белмисең икән әле...

– Бармыни аның юллары, сере, хәзрәт? Ярдәм итә аласыңмы миңа?

– Син, энем, менә ничек итеп кара...

Базар көнне хатыннарына алып кайткан вак-төяктән башка үзенә дә әйбер алган иде Хафиз. Ярыйсы гына калын кара бәрхеттән шәһәр сәүдәгәрләренекенә охшатып тегелгән камзул иде. Хатыннар яңа киемне күреп калу белән, бер-берсеннән тартып дигәндәй алып, әйләндереп-тулгандырып карадылар да ирләренә кидереп тә куйдылар. Үзләре читкәрәк китеп сокланды:

– Әллә-лә-ә! Килешүе!

– Адәм күрке – чүпрәк, йә әле!

– Төймәләре соң, төймәләре! Асылташ кына!

Чынлап, камзулның төймәләре зәңгәр ташны көмеш кайма белән бизәп ясалган да, елкылдап, җемелдәп, балкып күренеп тора иде.

– Төймәләре товар хакына барып басты. Тегүче татар өзми дә куймый, шушы гына бара, ди. Ризалаштым инде, бер киим әле дип.

– Бигрәк әйбәт иткәнсең! – Өлкән хатыны җөпләп куя. – Байлар арасында бай булып йөрисең, ә киеп чыгарга бер күренерлек киемең юк. Менә шулай йөрергә кирәк сиңа!

Шул кичне үк зур якка ире янына кереп кунарга чираты җиткән яшь хатыны көндәшләренә зарланды:

– Алтынбикә апам көне буе сукранып тик йөрде, йә моны болай итмәгәнсең, йә тегесе ошамый. Мин аларга хезмәтчемени? Райханә көндәшем дә холыксызланды, үзенең балаларына кумәчнең йомшагын биргән, минекенә катканын тоттырган...

Ир аның сөйләп бетергәнен көтеп тора алмый бүлдерде:

– Нәҗия, син аларның бернәрсәсенә дә игътибар итмә, яме. Алар синнән көнләшеп кенә шулай итә. Чөнки минем күңелем синдә генә икәнне беләләр.

Яшь хатын авызын ачып, озын керфекле матур күзләрен челт-челт йомгалады:

– Чынмы?

– Чын, җаным. Йөрәгемдә бер син генә. Син минем өйдә иң сылуы, иң якыны миңа. Син минем карлыгачым... Минем төнбоегым...

Шул сүзләреннән соң ир торды да урындык өстендә яткан теге камзулының бер төймәсен йолкып алып, яшь хатынга тоттырды:

– Менә, матурым, сөюем билгесе! Шушыны киемеңнең иң яшерен

җиренә генә тегеп куй, берәүгә дә әйтмә. Син беләсең дә мин беләм.

Яшь хатын хисләнүдән яшьләренә төелеп, иренең куенына сыенды.

– Мин шулай дип уйлаган идем дә, мине генә яратадыр дип... Мине генә...

Йортка җайлап тынычлык килде. Хатыннарның чыр-чуы, талаш-тартышы күпкә басылды. Шулай да кайчак араларында азрак ызгыш чыгып китә-китүен. Менә бүген печәннән бер арбада төялешеп кайтып килгәндәге кебек. Балалары этешеп-төртешүгә ике яше әләгешә дә китә. Өлкәне аларны тыймакчы булып кушыла. Шул вакыт бу әйтештә җиңүче дә, җиңелүче дә булмасын аңлаган ир алга карап, дилбегә тотып утырган килеш акрын гына җыр сузып җибәрә:

*Зәңгәр төймәм кемдә – күңелем шунда,*
*Сөюемнең төсе – зәңгәрдер.*
*Кулларыңа башым салып кына,*
*Ятып торсам, дөнья сеңгердер*[1].

Бу җырдан хатыннар тына. Юашланалар. Хәтта уңайсызлык кичергәндәй булалар. Ипләп кенә иякләре күтәрелә, йөзләренә – нур, ирennәренә сизелер-сизелмәс кенә елмаю куна. Артында утырган өлкәне, урынын рәтләгән булып, иренә аркасы белән терәлеп ала. Янәшәсендәге уртанчысы, башкаларга сиздерми генә «ялт» итеп карап куя. Артта баласын тубыгында тирбәтеп килгән яше үрелеп, иренең иңбашындагы печән вагын кагып төшерә. Һәрберсе иренә үзенең монда, янында, якында гына икәнлеген белдерәсе килә. Һәрберсе эчтән теге яшерен урынга тегеп куелган зәңгәр төймәне һәм шул төймә бирелгән көнне әйтелгән ләззәтле сүзләрне исенә төшерә... Һәрберсе теге камзулның дүртенче төймәсе ни өчен җитмәгәнен һәм кайдалыгын үзләре генә белә...

...Ә зәңгәр төймәләрнең чынында ничәү булганлыгы бер Хафизга да, дәрвиш картка гына мәгълүм. Рәхмәтләрен укып бетерә алмый картка ир.

Талгын моң хатыннарны иркәли бирә:

*Зәңгәр генә төймәм – чын вәгъдәм,*
*Бизәк итеп када түшеңә.*
*Аккош кына булып керәсеңдер*
*Таң алдыннан татлы төшемә.*

[1] Сеңгер – якты.

*Алмаз Әхмәтгалиев 1981 елда Татарстанның Балтач районы Кариле авылында туган. Норма мәктәбен тәмамлагач, 96 нчы һөнәр лицеенда белем ала. 2016 елда «Хезмәт» район газетасы аның «Хыял канатларым» исемле шигырь җыентыгын бастыра. Моңарчы шигырьләре «Идел», «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни Җомга» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Кариле авылы тарихы», «Безнең гасыр авазы» китапларында дөнья күрә. «Бүгенге көндә дә иҗади эзләнүемне дәвам итәм», – ди Алмаз. Ул, чыннан да, форма ягыннан эзләнүдә, шигырьләрен әле Хәсән Туфанча каймалап яза, әле Дәрдмәнднекенә охшатырга тырыша... Кыскасы, шигырьдән берәүнекенә дә охшамаган бриллиант йөзек кашлары ясау мәсьәләсендә шигырь дәрьясының тәҗрибәләр каегында йөзә.*



Алмаз
Әхмәтгалиев

# ГАЛӘМНӘРДӘН ИШЕТЕЛӘ АҺӘҢ

## Адәм гомере – төпсез олы дәрья...

Кәгазь – болын, каләмем – ук,
Ятамын шигырь аулап.
Вак фикерләр кыймылдаша
Йомарланган битләрдә.
Һәммәсе дә карый күзгә,
Миннән кызгану даулап.
Бимазалый черки уйлар,
Бызылдап баш өстемдә.
Саллы табыш ымсындыра,
Зиһен-уемны яулап.

Кәгазь – болын, каләмем – ук,
Ятамын табыш аулап.
Әрәм көнгә эчем пошып,
Бирешмәскә тырышам.
Болын түренә текәлсәм,
Төлке сыман койрык болгап,
Кача елгыр табышым,
Үткер күзле уй-шоңкардан
Күләгәгә елышып.

## Бер уй бимазалый

Бер уй бимазалый, кайта-кайта,
Сәрхуш түгел үзем, аек та...
Йөзәм сыман кара төнгә каршы,
Дулкын сөзеп, тишек каекта –
Бер уй бимазалый, кайта-кайта.

Шомлы җилләр хәлсез җанны урый,
Ишкәгемә алар ябыша.
Бизгәк тотып, тәнем бәргәләнә,
Маяк эзләп күзем камаша –
Шомлы җилләр хәлсез җанны урый.

Агым юлы алга илтә мине,
Беләм: тиздән кояш күренер.
Ышанам мин, тәнем сулыш алгач,
Җаным яктылыкка үрелер –
Агым юлы алга илтә мине.

Шул уй изә минем күңелемне:
Бармы икән ярда камышлык?
Камыш чүккән... татар ярларында
Җил-кубызга бии шом – бушлык –
Шул уй изә минем күңелемне.

## Бабамнар шәүләсе

Аңлый алмыйм: бу минем төшемме,
Өнемдәме шулай тоела?
Кәрван-кәрван килгән болытлардан
Яңгыр түгел, тузан коела.

Галәмнәрдән ишетелә аһәң –
Элгәрләрнең яуга барышы.
Күкне кисә үткен кылычлары,
Күңелемдә чыңлый тавышы.

Җир тетрәтеп чаба атлы гаскәр –
Сөңге тоткан гаярь яугирләр.
Әйтә алар: «Артта калма, егет,
Аягүрә йокламый ирләр!»

Үткәннәрне уйлыйм горурланып,
Баш очымнан чал тарих ага...
Бабамнардан калган бу васыять
Йөрәгемдә бүген чаң кага!

## Дускаем – сандугач

Көзләрдә озаткан дускаем – сандугач
Оясын сагынып кайтмады бу язда.
Һәр таңда сайравын тыңлаган җанымны
Нигә соң урамый быел да моң-назга?

Офыклар артыннан, күкләргә төбәлеп,
Сабыйдай карашым ни көтә һаман да?
Кояшның нурыннан җир-ана җанланып,
Кап-кайнар учыма тамчылар тамганда?

Көзләрдә озаткан дускаем – сандугач
Әле дә кунмады яраткан талына...
Бары тик хәбәрсез югалган кошымның
Боз сыны тирәктә очарга талпына.

## Кош сайрады

Шәфәкъ нуры йөзне сыйпаганда,
Кош сайрады йөрәккә кунып.
Тыңладым да тирән уйга баттым,
Шушы мәлдә җан куйды туңып, –
Зарларымнан мин калдым тынып.

Бездә күкләр әле аяз икән,
Кая баксаң, шунда яз икән.
Көне буе хәлне алган эссе
Хәнҗәр түгел, тәнгә наз икән.

Ә кайдадыр кургаш яңгыр ява,
Кемдер җиңә, кемдер җиңелә.
Улы өчен дога кылганнарның
Кайгы баса нәфис иңенә.

Кемнәрнеңдер сөеп туймас ярын
Барган юлда ут ала өтеп.
Кемнәрнеңдер газиз балаларын
Тора көн дә үксезлек көтеп.

Шәфәкъ нуры йөзне сыйпаганда,
Ишеттем мин кошчык тавышын.
Тынгач җиһан минем зарларымнан,
Ишетелде чишмә агышы, –
Рәхмәт сиңа, зирәк таң кошы!

## Хәерлегә

Бу көн булыр миңа хәерлегә,
Таңнан бирле иркәли яңгыр.
Колагыма кошлар дога сайрый,
Намазлыктай колач җәя кыр, –
Бу көн булыр миңа хәерлегә.

Кая бакма, шунда Коръән нуры,
Чәчәкләрдәй бизәп сибелгән.
Бу юллардан атлап үтәсемне,
Ниятемне ничек ул белгән? –
Бу сәфәрем булыр хәерлегә.

Ни җиткерә икән бөек Раббым,
Ни җиткерә динле калебкә?
– Манарадан азан әйтелгәндә,
Гамәлеңнән җаның калыкса,
Кыйблаң табып сәҗдә кылганда,
Йөрәгеңдә иман балкыса,
Бу килмешең булыр хәерлегә!

## Яңгыр гына...

Адәм гомере – төпсез олы дәрья,
Коя аңа язмыш елгасы.
Иссә җилләр, уйнак җилләр сыйпап,
Дулкынлана күңел дөньясы –
Гөрли-гөрли килә агасы.

Килсә буран ерак котыплардан,
Тәнне кыйнап, җанны өшетә.
Тотып сала тәмуг утларына,
Читтән карап, нәрсәдер көтә –
Күк яулыйсы канатны өтә.

Бер гомергә – шатлык-кайгысы да,
Һәммәсе дә чагыла йөздә.
Бар кояшы, әрсез болыты да,
Тик шулай да бөгелмим тездән –
Яңгыр гына тамчылый күздән.

## Кайтыр идем

Киткәннән соң кайтыр идем җилләр булып,
Җилләр шаян, йөрер идем бәбкә куып.
Болыннарда ауный-ауный уйнар идем,
Ә соңыннан чалкан ятып уйлар идем.

Уйлар идем яшәгәндә кылганнарны,
Үксезләрне, бер ялгызы калганнарны.
Андыйларның башларыннан сыйпар идем,
Туган йортның ташларыннан сыйпар идем.

Киткәннән соң кайтыр идем җилләр булып...

Марсель
Бакиров

# КАРА ТАПЛЫ БӘХЕТ

## БИОГРАФИЯМ, ТОРМЫШ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ЮЛЫМ ТУРЫНДА БӘЯН

*Миңа быелгы елның декабрь аенда 90 яшь тула. Бер гасырга якын озын, ләкин яшен тизлегендә үтеп киткән вакыт аралыгы бу. Дини мифология буенча, 2 мең ел яшәгән Локман хәкимнән: «Күп елларга сузылган гомереӊ озак булып тоелдымы?» – дип сораганнар. Бу: «Бер ишеккә кереп, икенчесеннән чыккан кебек кенә булды», – дип җавап биргән. Озын-озак гомеремдә язмышыма туры килгән вакыйгалар кемгә кызыклы булсын инде дип, моңарчы үзем турында бер юл да диярлек язмаган булсам да, кайбер олпат зыялылар, бу яшь буын өчен кирәк дип кодалагач, кулыма каләм алырга булдым. Балаларым да, безнең һәм оныкларың, оныкчыкларың өчен кирәк, дип хупладылар. «Яшьләрнең сүзен янчыкка сал, картлар сүзен капчыкка сал», – дигән мәкаль бар шул. Шулай да зиһеннең куәсе, фикер сөрешенең тапкырлыгы, телнең йөгереклеге юкка чыккан гомер чигендә ярый ла синең сөйләгәннәреңне кызыксынып, хуш күреп укучы, яисә үзләрен синең урынга куеп аңларга тырышучы булса...*

### Туган төбәгем һәм шәҗәрәм




Утызынчы елларда әтием-әнием укытучылык иткән якта – Минзәләдә туган булсам да, чыгышым белән мин үземне сылу Ык елгасы буена сыенып утырган Мөслимнән дип йөртәм. Чөнки балалык чорым һәм мәктәп елларым шушы төбәктә һәм күбрәк район үзәгендә үтте. Әтием белән әнием дә тумышлары белән – Мөслимнән.

Әтием Хәернас Бәхранур улы (1898 елгы) атасы ягыннан да, анасы ягыннан да – укымышлы нәселдән. Бәхранур бабамның әтисе Вәли, Вәлинең әтисе, миңа бишенче буын тиешле Һади бабам үз мәхәлләләрендә муллалык иткәннәр. Әтиемнең әнисе Хөсникамал әбием исә булачак мәгърифәтче мөгаллим һәм язучы Закир Һади укыган һәм «Яңа әсхабе кяһәф» хикәясендә тасвирланган Тымытык мәдрәсәсендә мөгаллимлек итүче мөдәрриснең кызы була. Бәхранур Вәлиевнең балалары (әтидән кала тагын ике ир һәм ике кыз туган) төпле белем алганнар, русча да укыганнар. Күрше-күлән һәм якын-тирәдә яшәүчеләр русча адрес, белешмә кебек текстларны шулардан яздырганнар. Кепка киеп, европачарак киенеп йөри башлаганлыктан, аларны «урыс Вәли» дип йөрткәннәр. Колхозлашу, күмәк хуҗалыклар төзелү дәверендә үзгәрешләргә сизгер гаилә башлыгы Бәхранур бабам электән төзетеп һәм юнәтелеп килгән каралты-курасын, хуҗалык байлыгын үз ирке белән дәүләткә тапшырган.

Әнием Фатыйма Әүбәкер (Әбүбәкердән кыскартып алынган) кызы (1900 елгы) урта хәлле гаиләдә туып үскән, дүрт кызлы һәм ике уллы ишле гаиләдә икенче булып дөньяга килгән. Әнкәй ягыннан мин 7 буын бабамны беләм. Нәсел башында торучы Исмәгыйль Мөслимов дигән иң ерак бабамның нәсел башы, борынгыдан килгән риваять буенча, Казаннан күчеп килгән нәселгә барып тоташкан, шунлыктан Исмәгыйльнең алты улы да (Якуб, Гани, Нәҗми, Кәрим, Җиһангир һәм Әүбәкер бабамның әтисе Әюп) үзләрен Казан кешеләре дип санаганнар. Бу гаилә башлыкларының күпсанлы оныклары һәм алардан тармакланган балаларының байтак өлеше хәзер дә үзебезнең районыбызда яши.

Әниемнең әнисе – әбием Фәрхиҗиһанның чыгышына килгәндә, тумышы белән ул Сарман районына керүче, Мөслимнән 25 чакрымда урнашкан Кәүҗәк авылыннан. Бабам белән әбием ипле гаилә корып, икесе дә яшьләре 90нан артып киткәнче яшәделәр, 6 бала (4 кыз, 2 ул) тәрбияләп үстерделәр. Бабай өлкән яшендә дә гарәп, латин һәи кириллица графикасындагы текстларны шактый җиңел укучы, русчасын да ярыйсы гына сукалаучы укымышлы карт иде. Үзләренең микрорайонында яшертен генә муллалык вазифаларын башкару белән шөгыльләнсә дә, заман агышын аңлаган аксакал буларак, ул балаларын укытырга, аларга дөньяви белем бирергә омтылган. Шуңа күрә дә 1938 елда ук аның өлкән улы Хафаз абыйның кызыл дипломга Мәскәү университетының механика-математика факультетын тәмамлап чыгуына һәм төрле техникум, училищеларда директор булып эшләвенә, ә икенче улы Сәлах абыйның Актаныш һәм элекке Калинин районнарында милиция начальнигы һәм район башкарма комитеты рәисе вазифаларын башкаруына, ә кызлары Мәрьям белән Закирә апаларның – шәфкать туташы һәм табибә, әниемнең укытучы булып китүенә гаҗәпләнергә кирәкми. «Без – Мөслим балалары» дигән китапта басылган «Бакировлар нәселе» дип исәпләнгән мәкаләдә менә шулар турында сүз бара.


Әтием 30 нчы елларда шашынган «кызыл террор» афәтенә эләгеп хәбәрсез юкка чыккач һәм гаиләбез «халык дошманы гаиләсе» дип эзәрлекләнә башлагач, бәлки аз булса да хәлебез җиңеләер дип, әнкәй фамилиябезне үз атасының – Әүбәкер бабамның исеменә бәйләп, Бакиров дип алмаштырырга мәҗбүр булган. Тормышымның билгеле бер мизгелләрендә һәм чорларында ошбу бабам минем өчен әти урынына калган тәрбиячем, күп нәрсәгә өйрәткән таянычым булды.



*Тәрбия бирүдә әтиемне алмаштырган, авылда мулла вазифасын башкарган бабам Әүбәкер (1862–1953).*



*Әтием Хәернас Вәлиев (уң якта) – мәктәп директоры, математик; Сталин репрессиясе корбаны (1898–1938).*



*Әнием Фатыйма (1900–1997). 87 яше тулган вакыт. Башлангыч мәктәпләрдә 30 ел укытучы булып эшләде.*

## Икеләтә имгәтелгән балачак

Әтидән мин 4 яшемдә калганмын. Сабый чагымнан ук аерылышуга дучар ителгәнгә һәм «әтием» дип эндәшүдән мәхрүм калганга күрәдерме, хәтеремдә көзге яфрак кебек берән-сәрән эленеп калган аңа бәйләнешле «наив», самими истәлекләр дә үзем өчен бик кадерле. Шундыйлардан – мине йокларга яткырганда булган хәл итеп сөйләргә яраткан, үзе уйлап чыгарган мавыктыргыч әкият сюжеты болай.

«Бервакыт мин, улым, җәй көнне җиләкле урынга җиләк җыярга бардым. Көн бик кызу иде. Яндым, пештем, йөрер хәлем калмады. Шулчак үлән арасында бер буш мичкә ятканын күреп алдым. Кояштан качып, тиз генә шуның эченә кереп яттым. Хәл алып ята-ята йоклап киткәнмен. Уянып китсәм, мичкә авызында бауга охшаган йонлы нәрсә эленеп тора. Шуңа тотынуым, ике куллап ябышуым булды, мин яткан мичкә, җан кергәндәй булып, кузгалып китте. Кая ул туктау, нәрсәдер өстери дә өстери безне. Дөбер-шатыр килеп, ташлы урыннан үтеп киттек, нииндидер судан да йөзеп чыктык. Бервакыт мичкә кинәт икегә ярылып китте. Карасам, бу бабаңнар туры икән, ә мин ике куллап тотынган бау кебек нәрсә мичкәне сөйрәп барган бүренең койрыгы булып чыкты. Мөгаен ул, балам, узган ел бабаңнарның сарыгын ашап киткән бүре булгандыр. Шуннан мин әлеге ерткыч бүрене капка баганасына бәреп үтердем дә, тиресен тунатып, әниеңнең пальтосына яка итеп куйдырдым. Әниеңнең әле киеп йөри торган пальтосының якасы – менә шул бүре тиресе инде, улым».

Бу маҗаралы хәлне әтием миңа, һичшиксез, гади тел белән, аңлаешлы итеп сөйләгәндер. Әмма аның хәтеремә сеңеп калган эчтәлеге менә шундый, мин тәфсилләбрәк аңлатканча иде. Соңыннан мин бу мавыктыргыч әкиятне, аманәт рәвешендә дәвам итеп, бәләкәй чакларында үземнең балаларга да сөйләдем. Әлбәттә инде, бүре тиресен әниләре киеп йөргән пальтоның якасы дип, ә бабам образын аларның Туймазыда яшәгән бабалары исеменә күчереп.

Бер без генә түгел, ә күпме чордашларым һәм дә балалык еллары сугыш чорына туры килгән исәпсез-хисапсыз бездән кечерәк яшьтәгеләр дә, әтиләре һәлак булып, ятим калганнар. Бу, әлбәттә, гомер буена төзәлми торган, йөрәкне әрнетә, күңелне кимсендерә вә рәнҗетә торган яра. Ә менә сиңа һәм карындаш туганнарыңа сугышта һәлак булган ата балалары дигән аяучан исем түгел, ә «халык дошманы балалары» дигән яман исем күтәрергә туры килсә, бу инде адым саен кагылып-сугылып яшәргә хөкем ителгән икеләтә фаҗигалерәк балачак һәм шундый ук кара таплы, каһәрләнгән үсмерчак дигән сүз.

Тоталитар режим шартларында, нахак яла ягылып, әтиемнең кулга алынуы һәм «антисоветчик», «халык дошманы» дигән яман исем тагылып, 58 нче иң хәтәр маддә белән хөкем ителүе Зәй районының Югары Баграж авылында урта мәктәп директоры булып эшләгән чагында була. Мәктәпнең һәм колхозның берләштерелгән партия оешмасы секретаре буларак, ул, гадәтенчә, урып-җыю чорында басуда эшләүчеләр белән очраша. Шунда төшке аш вакытында колхозчылар белән аралашканда ул: «Уңыш әйбәт быел. Икмәк планын үтәячәгебездә шик юк. Әмма уңган дип, ашлыкны әрәм-шәрәм итмәгез. Басуда бер башак та калдырмагыз. Бу, һичшиксез, үзегезгә тиячәк өлешнең артуына ярдәм итәчәк», – дип сөйләгән.

Шушы сүзләр, кире мәгънә чыгарып, әтиемә яла ягарга, коточкыч гаеп тагарга җитә калган. Директорыннан астыртын көнләшеп, аның урынын биләргә эчтән өметләнеп йөргән хезмәттәше – мәктәпнең «завучы» әтине чаккан. Үзен шаһит буларак чакырткан тикшерүчеләргә: «Вәлиев халыкны хөкүмәткә каршы котырту белән шөгыльләнә. Басуда ул колхозчылар алдында: «Хөкүмәтнең өлеше сугылачак эскертләрдә, өелгән чүмәләләрдә, ә сезнең өлешегез – җирдә калган башакларда», – дип коткы сүз сөйләде. Башак калдырмагыз дип өндәгән булып, колхозчыларда хөкүмәткә карата ризасызлык тудырырга тырышты», – дип, ялган мәгълүмат биргән. Шул ук вакытта ул шефлык

ярдәме сыйфатында күрше авылга бәрәңге алышырга җыенган укытучыларның машина җибәрмәүләре аркасында бармый калганнары өчен дә, ялган шаһитлек кылып, этине гаепле итеп күрсәткән.

Менә шундый ялган яла, провокацион гаеп тагылу нигезендә әтиемне кулга алганнар һәм бернинди адвокатсыз-яклаучысыз «тройка» тарафыннан «советка, икмәк тапшыруга каршы агитация алып баруда» (хөкем карарында «агитация против хлебозаготовок» диелгән) гаепләнеп, бер ай эчендә Алабуга төрмәсендә атканнар. Без бу хакта «Хрущёв җепшеклеге» чорында гына белдек, ә аңынчы күп еллар буена менә-менә әтиебез кайтып килер, дип өметләнеп яшәдек.

Миндә әтиемнең Алабуга төрмәсеннән карандаш белән язылган һәм бушаган шешәнең бөкесе итеп төреп чыгарылган соңгы хаты саклана. Күрәсең, төрмәдә күзәтче-йомышчы булып эшләүче бер миһербанлы бәндә 7 айлык корсак күтәреп, eрактан килгән бичара әниемне кызгангандыр инде – шешәне бөкесе алынмаган килеш чыгарып биргән. Хатта әтиемнең соңгы әманәте, араларның озакка яки мәңгегә өзелүен сизенгән гаилә башлыгының васыяте язылган. «Сөекле Фатыймам! Мин әллә исән кайта алам, әллә юк. Мине онытма, моңа кадәр булган тугрылыгыңны сакла. Мин синең гомерлек тормыш иптәшең, дүрт balаңның һәм тиздән туачак балабызның атасы. Үземне түгел, сине мин бик кызганам. Балаларымны бик жәллим, бик сагынам. Минем хакта борчылып, үзеңне бик бетермә. Нишлисең бит, бәла-каза кеше башыннан йөри. Тиз генә кайталмасам, Мөслимгә безнең өйгә кайтырсыз. Балаларга яхшы тәрбия бирергә һәм укытырга тырыш. Минем хакка шулай эшләвеңне телим, шулай булыр дип ышанам».

1938 елның салкын гыйнвар аенда корсагы борынына менгән әниемне дүрт баласы белән моңарчы яшәгән мәктәп фатирыннан куып чыгарганнар. «Халык дошманы» хатынына әверелгән әнкәй менә-менә бала табарга тиеш булганга күрә генә, безне кайбер башка «дошман» гаилә әгъзалары кебек Себер ягына сөрмичә калдырганнар. Тиз арада яшәү урынын алмаштыру, әти-әнинең туган ягына – Мөслим районының Олы Чакмак дигән авылына кайтып егылып, эзне яшерү дә, бәлки, ярдәм иткәндер. Әзерлекле кадрлар җитешмәүдән файдаланып, Минзәлә педагогика училищесында читтән торып укучы әниемә шул авыл мәктәбенә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып урнашырга насыйп булган.

Ватан сугышы дигән бөтен ил өстенә килгән фаҗига без менә шул авылда яшәгәндә башланып китте. Мәктәпкә укырга керүем дә шул елга туры килде. Җәй башында мәктәптә эш беткәч, әнием Минзәлә училищесында укуын дәвам итеп кайта, аннары җәй буе колхозда урак уру, көлтә бәйләү, машинада ашлык суктыру кебек эшләрдә җигелеп эшли иде. Ул Минзәләгә киткән бер елны Чакмакка күченеп килгәч туган өч яшьлек энебез шифаханәдә дизентерия авыруыннан үлде, вакытында хәбәр итеп булмаганлыктан, бичара әнкәй баласын күмәргә дә кайта алмады. Кайткач кына, ире кебек нарасыеның да юкка чыгуын белеп, үкси-үкси елады.

Чакмакта чакта ук без вакыт-вакыт менә шулай үз көнебезне үзебез күрергә өйрәндек. Шәркыя исемле бертуган апам (1925 елгы, ул әтием фамилиясендә – Вәлиева булып калды) күрше Рус Шуганы авылында торып, рус мәктәбендә укыды. Гел бишлегә генә укыганлыктан, дүртенче сыйныфта бирелә башлаган бер башына Ленин, икенче башына Сталин рәсеме төшкән җиде Мактау грамотасы бар иде аның. Без исә абыем Марс (1929 елгы) белән татар мәктәбендә укыдык. Ул мине авыл янәшәсеннән агучы Ык елгасы аша салынган тәбәнәк күпердән кат-кат ыргытып, йөзәргә өйрәтте. Һәм бервакыт көзге Ык өстендә кер юа торган такта кебек сырланып торган ярымжепшек урыннан «шап-шоп» басып, арлы-бирле йөгереп йөргәндә, кинәт боз җимерелеп, суда батуым һәм могҗиза белән генә боз астына китмичә калуым да Чакмакта булды. Ә икенче тапкыр Йөзәй дип аталган турыда Ыкның аръягына чыгып йөри торган өлкәннәр артыннан кереп, су йота-йота агып китүем һәм баш түбәм генә күренеп агып

барганда, ике егетнең мине күреп коткарып калулары исә Мөслимгә барган чагыма туры килде. Үлемем «Чура батыр» дастаны герое язмышына туры килгән кебек, суга бәйле булмаганлыктан, ике юлы да мин исән калганмын.

***

Беренче сыйныфны тәмамлагач, канкойгыч сугышның икенче елында без гаиләбез белән Мөслимдәге әти үскән йортка кайттык. Сугышның фаҗигале юлдашы булган ачлык һәм кытлык өстебезгә ябырылып килгәнлектән, мохтаҗлык безнең дә баштан ашты. Чукланып беткән чабата киеп йөрү, мәктәпкә «ыспай» барам дип, әнкәйнең күтәренке үкчәле иске түфлиен киеп барып, көлкегә калу бер хәл, ә ачлыктан эч борылганда әчетелгән тозлы кәбестәдән пешерелгән аш исен иснәр өчен генә Кооператив урамындагы бердәнбер ашханә ишек төбенә барып утыру исә бөтенләй кеше ышанмаслык хәл иде. Шул чакларда мин, имеш, зур дәрәҗәле кеше булып әверелгәч, башкалар күз алдында кесәмнән төргәге белән кызыл «утызлыклар» чыгарам да иң тәмле, иң кыйммәтле ризыклар китертергә заказ бирәм, юмартлык күрсәтеп, башкаларга да алам, дип хыяллана идем.

Бу ашханә без күргән яки без катнашкан башка гадәттән тыш очрак яки хәлләр белән дә хәтердә калды. Бервакыт шуның каршына йөнтәс мамык орлыгының маен сугудан кала торган түп төялгән йөк машинасы килеп туктады. Шофёрның капкалап чыгарга дип ашханәгә кереп китүе булды, чучкаларга ашатыла торган әлеге ризыкның исен сизеп алган ач бала-чага шундук машинага ябырылды. Кайсылары тәгәрмәчкә басып яки ыргылып менеп, кайсылары иптәшеннән күтәрттереп, кузовка төялгән түпләрне кисәге-кисәге белән әләктерә һәм як-якка тая башладылар. Тәрәзәдән бу «штурм»ны күреп алган шофёр , йөгереп чыгып, балаларны кат-кат куып караса да, аларны җиңә алмаячагын аңлап, тамак ялгамыйча да китеп барырга мәҗбүр булды.

Беренче мәртәбә авызыма тәмәке алуым да, шулай ук бик тиз арада һәм гомерлеккә аны ташлавым да шул ук ашханә белән бәйле. Шунда урам яктан керә торган ишек төбендә утырганда, үпкә авырулы бәндәләр һәм «алкашлар» ташлаган тәмәке төпчекләрен җыярга булдым. Өйгә кайткач, шуларны юан итеп кәгазьгә төрдем дә суыра-суыра тартып җибәрдем. Шуннан соң башым әйләнеп һәм күңел болганып, коса-коса чирләгәнем гомер буена исемнән чыкмады. Шул мине теләсә нинди тәмәкенең, «марочный» папирус, хәтта сортлы яфраклардан төреп ясалган сигаретларның да дошманына әверелдерде.

Әниебез бу елны район үзәгеннән өч чакрым ераклыктагы Иске Вәрәш авылына укытырга билгеләнгән иде. Ул вакыты белән көн дә җәяүләп йөреп, вакыты белән шунда куна калып эшләде. Илдә коточкыч кыйммәтчелек хөкем сөргәнлектән, безнең гап-гади яки ир бала өчен табигый һәм зарури булган өмет-теләкләребезне гамәлгә ашырырга да мөмкинлегебез булмады. Абыем белән минем бик тә гармунда уйнарга өйрәнәсебез килә иде. Күршеләребез сатарга җыенган тальянны алырга мөкиббән китеп ашкынсак та, алырга көчебез җитмәде. Ә бервакыт безнең өй янында, Кооператив урамында урнашкан «Культмаг» кибетенә (ул таш бина хәзер дә исән) буяу карандашлары кайтты. Кечкенәдән рәсем ясарга әвәслегем һәм теләгем булганлыктан, мин сатарга куелган карандашларны күреп катып калдым. Экономия максатыннандыр инде, аларның тышлары лакланмаган, картон каплары өстенә дә бернинди язу да язылмаган иде. Мин кибет ябылганга кадәр берән-сәрән кергәләп торучы әни-апаларның һәм бабайларның үз балаларына яки оныкларына карандаш сатып алуларына кызыгып карап тордым.

Ул чакта әтиемнең әнисе – мине төрле догаларга өйрәткән әбием исән иде әле. Аның: «Балакаем, йә Алла, йә Алла дип мең тапкыр әйтсәң, теләсә нинди теләгең кабул була», – дигән сүзләре әле дә хәтеремдә. Мин теләгән карандашларга ия булырга өметләнеп, шул чакта төн буена шул сүзләрне кабатладым. «Иртән торуыма мендәр

астына бер кап буяу карандашлары куйсаң иде, Ходаем», – дип ялвардым. Йоклап китә башласам, үз-үземне чеметә-чеметә, йокымны качырып һәм үтенечемне кат-кат әйтә-әйтә, «йә Алла, йә Алла» дип кабатладым. Бары таң атканда гына йоклап киткәнмен. Төш вакытында уяндым да – и нәүмиз, «наив» чак диген (!) – карандашларны алырга дип, мендәр астына кулымны тыктым. Тапмагач, ышанмыйча, кат-кат әйләндереп карадым...

Шул ук елны аерым гаиләләргә генә түгел, ә районыбызга һәм аерым татар төбәкләренә афәт алып килгән хәтәр кизү чыкты. Ач халык, урып-җыярга өлгерми калган ташландык иген басуларына барып, кар астыннан чыккан камылдагы башакларны биштәрләп яки капчыклап җыя башлады. Шулардан үрәле аш яки ботка пешереп, тамакны туйдыру күмәк төс алды. Һәм шунда ук аның коточкыч нәтиҗәсе дә пәйда булды: халыкта «сиптическая ангина» дигән, авыз-борыннан кан агуга һәм тиз арада үлемгә китерә торган кизү башланганы мәгълүм булды. Бу организмны агулый торган чир ябышкан кешеләрне шифаханәләр дә коткарып кала алмады һәм көн саен дистәләп кырылган кешеләрне хәтта уртак кабердә күмәргә мәҗбүр булдылар.

Менә шул мәлне мин әлеге чир белән авыручы күрше гаиләгә туры килгән фаҗигале язмышның очраклы рәвештә шаһите булдым. Өч яшьләр тирәсендәге сабыйның ( ул ир бала иде) борыныннан кан агып чыккан килеш тузан-туфракка буялып, капка төбендә уйнап утырганы һаман да минем күз алдында тора. Шул ук көннәрдә әлеге баланың һәм аның әнисенең үлү хәбәре килеп ишетелде. Сугышка китеп, бер аяксыз әйләнеп кайткан гаилә башлыгының әнисе – әби карчык кына исән калды. Кайтуына менә шундый рәхимсез фаҗига каршылаган Ибәт исемле әлеге абыйның агач аягы белән титаклап, зиратка нарасые һәм гаилә бәхетен татымыйча дөньядан киткән хатыны кабере янына барып кайтканлыгын күршеләр уфтанып һәм тетрәнеп сөйләделәр.

Төпкә җигелеп, гаиләне тартучы газиз әниебезнең тәвәккәллеге, болай да шып-шыр калган өебездәге күзгә чалынырлык иң соңгы нәрсәләрне сатып, азмы-күпме май, йомырка юнәтүе аркасында гына без исән калдык. Әмма тиздән әтиемнең ике сеңлесе, әниебезне килен кеше карарга тиеш түгел, үзебез карыйбыз, дигән сылтау белән безне әтиебез үскән һәм аңа тиеш булган йорттан сөреп чыгардылар.

## Каршылыкларга корылган мизгелләр

Шушыннан соң без, күчеп китеп, ике ел әнкәй укытучы булып эшләгән Иске Вәрәш авылында яшәдек. Сугыш чорының «кара сакалы» монда да артыбыздан ияреп килде. «Ачка койрык чәнчеп яшәү», әнкәйнең иске юбкасыннан тегелгән чалбар киеп йөрү, укучы балалар өйләренә таралгач, парта асларыннан башкалар кимергән кишер төпләрен табып ашау – кайгым да, кечтеки генә «шатлыгым» да менә шул рәвешле очны-очка ялгау белән бәйләнгән иде. Соңрак кайбер балаларда этиләре җибәргән посылкаларда килгән авыз гармуны яки өс-аяк киеме кебек нәрсәләр күренә башлады, әмма кызыгудан ни файда – аларның берсе дә безгә – ятимнәргә тәтемәде.

Ошбу авылда ике тапкыр Яңа елны каршылау, чыршы бәйрәмен уздыру гына аеруча җылы булып истә калган. Дөрес, чыршының бөтен бизәлеше кәгазьдән ясалган чылбырлар, төсле карандаш белән сыек кына итеп буялган төрле кәгазь уенчыклар, сыер ябагасыннан әвәләп ясалган шарлар һәм ботакларга эленгән чүпрәк курчаклар белән генә чикләнсә дә, бәйрәм уен-җыр белән үтә һәм аның өйдә пешерелгән печенье өләшү белән тәмамлана торган өлеше бигрәк тә көтеп алына иде. Һәм бөтен ач баланың күзе һәркайсына өч-дүрт кенә бөртек тия торган бодай катыштырып, арыш оныннан пешерелгән печеньелар салынган чиләктә иде.

Әмма ләкин ач-ялангач булсак та, тирәлеккә ярашып, без үз күңелебезне үзебез таба белгәнбез, әй. Кыш көннәрендә юл өстенә тезеп – шәмәйле, ә инеш бозы өстендә олтанлы итеккә коньки тагып, шаралы уйный идек. Җәй көннәрендә исә, иренмичә,

ике чакрымдагы Ык буена йөреп, кармак белән балык тоту һәм тау астындагы әрәмәдә карлыган һәм бөрлегән җыю – безнең күнегелгән шөгылебез иде. Урып-җыю чорында атлы эштә үземне сынап карау да шушы авылда яшәгән чакта булды. Мин ат җигәргә өйрәндем һәм чытыр арбага көлтә төятеп, көннәр буе эскерт салучылар янына ташый идем. Кичен арбаның ике як аратасына тезелешеп утырган хатын-кызны авылга алып кайтканда, бер кызыклы хәл булып алды. Мин иң алда дилбегәнең ике җәбен ике кулыма тотып утырам. Янымда утырган урта яшьләрдәге хатын бер мәлне минем ике кулдагы икегә аерып тоткан дилбегәне бер учына җыйды да: «Менә шулай бер кулда гына тотарга өйрән, балам. Томырылып чапмаган, юыртып кына барган ат белән менә шулай идарә итәләр», – дип, миңа онытылмаслык тәрбияви сабак бирде. Кинофильмнар караганда юыртып яки салмак кына баручы җигүле ат күрсәм, мин алда утырган кешенең дилбегәне ничек тотканлыгы белән кызыксынам. Мондый кадрларны авыл тормышын белмәгән режиссёр еш кына дөрес төшертмәгән булып чыга.

Иске Вәрәштә бала чагымда үз күзләрем белән күргән һәм акыл кергәч, шул чордагы сәяси мохитне гаепләп искә алырга, хөкем итәргә туры килгән икенче бер вакыйга үтә дә гыйбрәтле һәм аяныччы. Фермада сыер савучы булып эшләүче, бик халыкчан итеп җырлый торган бер апа бар иде. Авыл үзешчәннәренең клубта район үзәгеннән килгән вәкилләр каршында барган «смотр-олимпиада» концертында бу, өздереп һәм гаҗәеп моңлы итеп, «Иске кара урман» җырын башкарды. Шунда аның «заманалар авыр, михнәтләр күп» дигән сүзләрне сузып, үрсәләнүле моң белән җырлаганда, алда утыручы ташка үлчим жюри әгъзаларының бер-берсенең колагына иелеп, «чыш-пыш» килүләре күзгә чалынды. Соңыннан нәрсә булганлыгы халыкка килеп ишетелде: бу апаны парткомга һәм авыл советына чакыртып, «авылыбызны хур иттең» дип котын алганнар һәм, утырту белән янап, үзен тыя алмыйча шашынып елау дәрәҗәсенә кадәр китереп җиткергәннәр. Мондый хәлнең, әлбәттә, илдә хөкем сөргән сәяси режимның һәм «кызыл террор» шаукымының авыл җирендәге килбәтсез чагылышы, режим ялчыларының халкыбызның демократик эчтәлекле мирасыннан кер эзләве рәвешендә гәүдәләнгәнлеге шиксез.

Ул заманда кечкенә авылларда әле радио челтәре дә, шулай ук аерым йортларга кертелгән телефон да булмаганлыктан, сугыш бетү хәбәрен авылыбызда колхоз идарәсенә куелган бердәнбер телефон аша белгәннәр. Дүрт ел буена тилмереп көтелгән шатлыклы хәбәр яшен тизлегендә бөтен авылга таралды. Ә миңа, дүртенче сыйныф укучысына, бу яңалык урамга ярымшәрә килеш атылып чыккан күрше хатынның, сөрән салып: «Сугыш беткән, сугыш беткән!» – дип кычкыра-кычкыра, арлы-бирле чабып йөрүе аша килеп җитте. Көн саен үлем-афәт алып килгән сугыш барган чорда ул, сугыш беткән көнне шушы өстемдәге бердәнбер күлмәгемне буйдан-буйга икегә аерып төшерәм, дип нәзер әйткән булган икән. Урамда шәрә бүксәсен ялтыратып һәм як-якка ачылган итәкләре арасыннан ямаулы ыштанын күрсәтеп чабулап йөрүенең хикмәте менә шунда булган икән.

Сугыш беткән көн янә дә шушы авылда яшәү дәверендә беренче тапкыр итле аш ашаган, беренче мәртәбә тамак туйган көн буларак та истә калды. Колхоз ул көнне мал суйдыртып, мәктәп балаларына сыер итеннән аш пешерткән иде. Балалар кичергән куаныч-шатлыкның иге-чиге булмады. Шул ук айда, май ахырында, мин башлангыч мәктәпне югары билгеләргә генә тәмамлап, апам кебек үк, бер башына – Ленин, икенче башына Сталин сурәте төшкән Мактау грамотасы алдым. Бу минем гомеремдә беренче башлап ирешелгән уңышларымны раслый торган иң тәүге рәсми документ иде.

## Заман чыдарга, еламаска өйрәтте

Искә Вәрәштә торганда, миннән дүрт яшькә зур абыем Марс җәен җәяүләп, кышын чаңгыда йөреп, район үзәгендәге урта мәктәптә укыды. Әлеге авылда дүрт еллык башлангыч мәктәп кенә булганлыктан, икебезгә дә йөреп уку авырга туры киләчәк дип, без кабат Мөслимгә кайтып урнаштык. Бу юлы әнкәйне район үзәгеннән 25 чакрымдагы Елга баш авылына укытырга җибәрделәр. Ә без, абыем белән икебез, иске бер ташландык өйдә үз көнебезне үзебез генә күреп яшәргә мәҗбүр булдык.

Сугыштан соңгы тәүге еллар матди һәм ашау-эчү ягыннан сугыш чорындагыдан әллә ни нык аерылмады. Әйтергә генә ансат: әнкәйнең бер айлык эш хакы бу чорда да нибары ике чиләк бәрәңгелек кенә иде. Җитмәсә, әниегез башка авылда эшләгәнлектән, бәрәңгене дә шунда утыртырга тиеш дип, безнең бәрәңге бакчасы җирен читтән килгән бер түрәгә бирделәр. «Халык дошманы гаиләсе» дигән үтергеч яман исем тагылганлыктан, без, билгеле, кайларгадыр барып, хокук даулап йөри алмадык. Үзебезнең ишегалдындагы өч сутый тирәсе чирәм җирне казырга һәм тирес тә кертелмәгән шул кечкенә мәйданнан аз гына бик вак бәрәңге алу белән ризалашырга мәҗбүр булдык.

Менә шул чакта күрсәтте инде «нужа бабай» без – ятим һәм кимсетелгән балаларга тормышның ачысын-төчесен. Кыш чыгарга дип исәпләнгән бәрәңге өй базының төбендә генә булганлыктан, без – кеше ышанмаслык хәл (!) – көненә бер мәртәбә генә ашап яшәдек. Иртән мәктәпкә авызга бер ризык та капмаган килеш китеп, биш-алты сәгать уку барышында, бигрәк тә соңгы сәгатьләрдә, ачтан эч боруга ничек чыдаганбыздыр инде. Кайткач, баздан бер уч кына бәрәңге алып менеп, шуны кәгазь калынлыгы гына итеп әрчеп, ярты казан күләмендәге суга сала идек. Һәм шул сыек суга ел да кысыр кала торган чирләшкә сыерыбыз биргән бер кружка сөт куша идек.

Ниһаять, «баба шурпасы» әзер булгач, дүртәр, хәтта бишәр тәлинкә тутырып, аз гына сөт кушудан бераз тонык төскә кергән шул шыр сыек шурпаны чөмерә идек. Корсаклар, сугыш заманында телгә кергән гыйбарәдә әйтелгәнчә, «бет үтерерлек» булып чыга иде. Безнең өчен иң татлы, иң ләззәтле вакыт – ахырда тәлинкә төбендә утырып калган, кайнаганда изелеп, элпә хәленә кергән ике-өч кашык бәрәңгене тәмләп ашау иде.

Умач – ярлылар ризыгы, диләр. Әмма безгә ул да тәтемәде, чөнки умач уу өчен он кирәк. Абыем белән янәшә басып, көрәк белән берәүләрнең 25 сутый җирен казыган өчен пот ярым арыш оны алганыбызны хәтерлим. Ул онны без ашка нибары 4-5 кашык салып туглый гына торган идек. Ә җәй көне Югары Табын ягындагы ташландык җирләргә сыерыбызга печән чабарга йөргәндә дә, хәтта хәллерәк гаиләләр бәрәңге кушып пешерә торган ипинең чыраен да күрмичә, тамак ялгарга үзебез белән сөт кенә ала торган идек. Шулай ук, исемдә, ярыйсы ук хәлле яши торган гаиләнең капчык ярым бәрәңгесе өчен ялланып, өч кубометр утынын кисеп-ярганда да, авызыбыздан өзеп җыйган сөт белән генә тукландык. Сүз уңаенда искәртим: миңа ул чакта 13-14 кенә яшь иде.

Ә ит дигән ризык ул дәвердә безнең төшебезгә дә кермәде. Хәер, «баба шурпасы» белән генә тукланып торган бер мәлне, электән сакланып калган ике кәтүк җепне сата алмыйча, базарда катып-өшеп йөргәннән соң, бер агайга ялынып, бер кисәк «итенә» алмаштыруга бәйләнешле хәл булган икән. Ләкин ул, юньсез, саран агай салкында тач май булып күренгән ап-ак сөякне майлы симез ит дип биреп, мин беркатлы мәхлукны, кычкыртып алдаган булып чыкты. Абый белән без, ике җүләр, ит авыз итәбез дип өметләнеп, әлеге кисәкне чүмечкә эләктереп, казаннан алуыбыз булды, ул шуып китеп, шапылдап, идәнгә төште. Аның кайнар суда эреп, чат сөяккә генә калганлыгын без шунда гына күреп алдык.

Хәтта искә төшереп язуы да авыр. Күрде инде безнең башлар.

***

Ләкин бала яки яшүсмернең кызыксынучан, һәр нәрсәне белергә һәвәс-ашкынучан табигатен ачлык кына баса яки үзгәртә аламыни?! Мөслим урта мәктәбендә бишенче сыйныфта укый башлаганда, тарихтан дәреслегем юк иде. Дәреслекләр ул чакта бик сирәк һәм аз гына санда басылганлыктан, сатып алырга да мөмкин түгел иде. Шунда мин елардай булып кат-кат ялынып, күршеләрнең ике елга миннән югарырак сыйныфта укыган кызларының «Борынгы һәм урта гасырлар тарихы» дәреслеген икегә бүлдерү бәхетенә ирештем. Болар, мине кызганыптыр инде, китапның борынгы тарих өлешен аерып алып, миңа бирделәр. Матур әдәбиятны гына түгел, тарихны да яратуым, мөгаен, шуннан башлангандыр.

Ә инде матур әдәбиятка тартылуыма килгәндә, ул, ничектер, стихияле төстә, ягъни баштарак үзлегемнән китап укырга әвәслегемнән әкренләп көчәеп китте кебек. Бүгенгедәй хәтеремдә: китапханәдән Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләре»н алып кайткан идем. Шул чакта мәгърифәтче әдип һәм галимнең гарәп-фарсы алынмаларыннан арындырып иҗади тәрҗемә рәвешендә эшләнгән детектив характердагы «Әбугалисина кыйссасы»н мөкиббән китеп укып чыккач, эмоциональ кичерешләремне тыя алмыйча, әдипнең портретын «чат-чат» итеп үптем. Матур әдәбиятны чын-чынлап үз итүем, арадашчым-киңәшчемә әверелдерүем аркасында, мин ике-өч ел эчендә шул заманда әле яшәвен дәвам иткән РКШның («рабоче-крестьянская школа») һәм дә район китапханәсенең латин шрифтында һәм кириллицада басылган татар китапларын укып бетердем диярлек. Һәрхәлдә, китапханәчеләрнең миңа таныш булмаган китапларны авырлык белән тапканнары хәтердә калган.

Күпләребезне магнит кебек үзенә тартып торган икенче урын – бер катлы агач бинага урнашкан район клубы иде. Ул без ташбашларны төрле тамаша сәнгате белән таныштыра торган мәгърифәт-тәрбия үзәге булды. Бәрәңге белән ертык билетлар ябыштырып яки өлгесе алынган тәрәзәдән кача-поса кереп, кинолар, концертлар һәм спектакльләр карый идек без анда. Үзешчәннәрнең һәм үзебезне укыткан укытучыларның клуб сәхнәсендә «Галиябану», «Асылъяр» пьесаларын куйганлыгы да һаман күз алдында тора.

Ә менә Казаннан театр яки концерт белән килү очраклары онытканда бер генә була торган иде. Шуңа күрә дә бер елны көтмәгәндә – академия театры түгел инде, ә курчак театры килеп чыккач, «Камыр батыр» спектаклен карарга атлыгып, бөтен район җәмәгатьчелегенең җыелганлыгына һәм түрәләрнең хатыннары белән иң алдагы рәттә утырып, шул тамашаны караганлыгына гаҗәпләнергә кирәкми.

Җиденче сыйныфта укыганда, мин глобустан – сүс сакал беркетеп һәм җиң эченнән үткәрелгән тегәр җеп белән тартканда як-якка йөри торган күзләр куеп – баш ясадым һәм, шуны киеп, мәзәкче бабай сыйфатында клубта район күләмендә үткәрелгән бал-маскарадта катнаштым. Йомгак ясаганда, икенче урынны алсам да, маскарадны оештыручылар, соңыннан бирәбез дип вәгъдә ителгән премияләрен – бала кешене төп башына утырту бик җиңел бит – бирмичә йомып калдырдылар. Янә килеп, клубта район күләмендә үткәрелгән үзешчән-сәнгать олимпиадасында зур табак кәгазьгә Пушкин портретын ясап, канаты киселгән балачак хыялымны тамашачылар игътибарына тәкъдим итәргә җөрьәт итүем дә истә калган.

Мөслимнең һәм клубыбызның шул чордагы тормышын һәм күренешен мин хәзерге заман өчен гайре табигый булган башка чараларга бәйләп тә күз алдына китерәм. Ул елларда урамнарда кичләрен һәм төн буе электр лампочкалары янмый иде, ә клуб сәхнәсен ике яклап түшәмгә асылган 30лы керосин лампалары гына яктырта иде. Болар гынамы, электр станциясе, хәтта тышта яки клубка тоташтырып салынган бинага урнаштырылган ток бирә торган генератор булмаганлыктан, кинофильмнарны вакыт-вакыт кул белән әйләндерә торган генератор ярдәмендә күрсәтәләр иде. Җитмәсә, ул

фильмнар төссез, ә кайчакта тавышсыз да була торган иде. Минем дә кино карар өчен тиргә батып, шул кул машинасын әйләндергән вакытлар булды.

Урамда һәм өйләрдә ток, ут булмауга бәйләнешле үтә дә кәмит факт искә төшә. Кооператив урамында, «Йөзәй»гә төшә торган элекке тыкрык турысында, «Шома Хәмәй» кушаматлы һәм сәеррәк табигатьле бер абый гаиләсе яши иде. Бу кушаматны юкка гына такмаганнар. Эреләнергә, үзенең мәзәк хикмәтләрен күрсәтергә хирыс, мактанчык бәндә иде ул. Аның курчак өенә охшатып буялган йорты түбәсендә репродуктор тора, шуның аша ул атна саен диярлек Казанда Фольклор йорты сәхнәсендә гармунда уйнавы язылган чыгышын тапшыра иде.

Ә бервакыт халык арасында көлкеле хәбәр таралды. Үз кадрларының ничек яшәве белән танышырга дип, боларга профсоюз вәкилләре килергә тиеш булган. «Шома Хәмәй» комиссия әгъзаларын ничек каршылаган, дисезме? Кайдандыр тапкан иске генераторын һәм хатынын өй базына төшергән дә: «Тынычны чыгарасы булма, кунаклар киткәнчегә кадәр әйләндерүеңне бел», – дип, хәләлен катгый кисәткән. Килүчеләр электр уты янып торуын күрүгә, сокланып һәм күзләре маңгайга менеп, өнсез кала язганнар һәм китәселәре килмичә шактый гына торганнар. Генераторны әйләндерә-әйләндерә, тәмам хәлдән тайган бичара хатынның баздан ялварулы тавышы ишетелгән:

– Үләм бит инде, Хәмәй. Киттеләрме инде?

Бу тавышны ишетүгә өйдәге «цивилизация»нең нинди хәйләгә һәм шома алдауга корылганлыгына төшенеп алган профсоюз вәкилләренең шул вакыттагы халәтен күз алдына китереп буладыр дип уйлыйм.

Ә хәзер, әйдәгез, игътибарыбызны «Сад» бакчасына (каян чыккандыр, районыбызның чаган агачлары утыртылган бердәнбер паркын халык шулай дип атый иде) юнәлтик. Бу бакча уртасындагы мәйданда көндезләрен волейбол уйнау, кичләрен кызларның аякларына баса-баса, танцыга өйрәнү, абына-сөртенә вальс әйләнү – безнең яраткан шөгылебез иде. Махсус спорт һәм спорт кирәк-яракларының ни икәнен белмәсәк тә, Мөслимебезнең «маркасын» – дәрәҗәсен якларга һәм сакларга тырыштык: ара ерак дип тормыйча, велосипедларда барып, шул заманда район үзәкләре булган Тымытык, Пучы-Калинин һәм Бакалы (Башкортстан) районнарының волейбол командаларын бер-бер артлы кыйратып кайттык. Безнең команда әгъзаларының берсе – мәктәбебездә соңыннан физкультура укытучысы булачак, шул чакта ук «ата спортчы» Дөфак Фәттахов иде. Ә җитәкчебез, башлап йөрүчебез – тупны каршы якка текә һәм кискен итеп бәрә белүче, бездән берничә яшькә өлкәнрәк Рәүф Гыйзетдинов, ә алдагы рәттә аңа сугарга җайлы итеп туп күтәртеп торучы уенчы – мин идем.

Спорт дигәннән, мәктәптә безне физкультурадан укыткан Мидхәт абый Гайнуллин исә (соңыннан читтән торып педагогия институтын тәмамлагач, ул тарих фәнен укыткан) безне йөгереш һәм чаңгы ярышларында катнаштыра, Ыкның Йөзәй дигән текә ярлы турысында вак калибрлы мылтыктан һәм кайчакта хәтта хәрби винтовкадан ату бәйгеләре оештыра торган иде. Шул чакларда миңа, мишеньнар бетүдән файдаланып, тушь яки кара төстәге кара белән мишеньнарны үземә ясап алып барырга туры килә торган иде. Ә әҗере – өстәмә рәвештә кат-кат атарга мөмкинлек алу иде. Моның файдасы минем өчен бик зур булды. Казан университетына укырга кергән елны ук, тирга йөреп һәм ату ярышларында катнашып, вак калибрлы мылтыктан өч торышта (ятып, тезләнеп, басып) ату буенча беренче разрядны яулау бәхетенә ирештем.

Ә инде дүртенче курсны тәмамлагач, запастагы булачак офицер сыйфатында Ерак Кабан күле артындагы хәрби лагерьда чагында исә, карабиннан, автоматтан һәм пистолеттан ату буенча ике янәшә ротада беренче урынны алдым. Сүз уңаеннан өстим: студент елларында янә гимнастика секциясенә йөрдем, парашют секциясенә йөреп, өч мәртәбә парашют белән самолёттан сикердем. Милли көрәшкә, бокска тартылу физик халәтебезгә салынган булса да, университетта ул чакта андый секцияләр эшләмәгәнлектән, әлеге спорт төрләре белән шөгыльләнеп булмады.

Аның каравы абыем Марс миңа насыйп булмаган яки көчемнән килмәгән өлкәләрдә үзен нык танытты. Һич арттырып әйтмим: ул шул чактагы Мөслим балаларының иң яраткан «кумиры» иде. Үзенең гадәттән тыш чыгышлары, хикмәтле гамәлләре белән ул барыбызга да зур йогынты ясады. Җәйләрен яшь-җилкенчәк күз алдында, су астында 2шәр минут калып, Ыкның икенче ягына чумып чыгу, дисеңме, трамплин булмагач, элекке агач күпернең иң биек корылмасына менеп баш белән суга сикерү, дисеңме, кышларын балаларны ияртеп, Иске Вәрәш һәм чаңгы күрмәгән тегермән тауларының иң текә урыннарыннан башлап үзе шуып төшү, дисеңме – бар яктан да ул безгә үрнәк булды. Мәктәп һәм район күләмендә үткәрелгән чаңгы ярышларында һәрчак беренче урынны ала иде. Һәм Казанга барып Төзелеш институтына укырга кергәннән соң да, районыбызның данын яклады: Сабантуй бәйрәме көнне «Трудовые резервы» стадионында республика күләмендә татарча көрәш ярышында, төрле районнан җыелган көрәшчеләрне бер-бер артлы сырты белән салып, Минзәлә автоколонна начальнигы, танылган батыр Иван Двоеглазов белән беренче-икенче урыннарны бүлеште. Менә шундый иде безнең «үзешчән тренерыбыз».

***

Китапханә һәм клуб безнең өчен аң-белемебезне тулыландыру, сәнгати-эстетик тәрбия алу учаклары булса, ә спорт белән шөгыльләнү физик һәм рухи яктан чыныктырса, районыбызның урта мәктәбе, һичшиксез, минем кебек «китап-белем җене» кагылган яшь-җилкенчәк өчен бөтен вөҗүдебезне биләгән һәм шәхес буларак тернәкләндергән тәрбия-мәгариф үзәге булды. Без башта күптән инде сүтелгән агач мәктәптә, алга таба ике катлы таш бинада укыдык.

Соңгысы безгә, Казанны ишетеп кенә белгән малай-шалайга, хәтта шәһәр җирендә дә иң зур бина булырлык кебек тоела иде. Шуңа күрә Казаннан кайткан кунакларга мәктәбебезне, сер бирмичә, һаваланып күрсәтүебез һәм, «анда да йортлар шушылай зурдыр инде?» – дип сораганыбызга гаҗәпләнергә кирәкми. Бер кышкы төнне янгын чыгып, шул мәктәпнең күз алдында януын без елый-елый карап тордык. Аннары укуыбызны Пушкин урамында агачтан салынган ике катлы тулай торак булган бинада дәвам иттек. Ул чакта мәктәп директоры химия укытучысы Виктор Иванов иде. Тарих укытучысы Нурдидә апа Галиева, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Бриллиант апа Шакирова безнең иң яраткан мөгаллимә-остазларыбыз булып, күңелләребезгә уелып калды. Шәхсән минем үземне тарихыбызны чын-чынлап хөрмәт итәргә һәм әдәбиятыбызны мөкиббән китеп яратырга шулар өйрәтте. Бриллиант апаның үзе укыган төрле кызыклы китапларның эчтәлеген үтә мавыктыргыч итеп сөйләгәнен авызларыбызны ачып тыңлый идек без. Янә аның язучы Габдрахман Әпсәләмовны Казаннан мәктәбебезгә чакыртуы, «Алтын йолдыз» романы буенча без, укучылар өчен конференция үткәрүе истә калган. Тере язучыны без беренче тапкыр шунда күрдек.

Ә инде мәктәп, хәтта район клубы сәхнәсендә артистларча кылана-кылана спектакльләр куюыбыз – үзе бер матур истәлек. Әзергә бәзер булып, башкалар тудырганны-булдырганны гына «имеп» яки көтеп яшәү безнең өчен ят сыйфат иде. Казан артистлары сәхнәбезгә еллар буена диярлек аяк баса алмаган шул мәлдә, онытканда бер килгән курчак театрын карарга да атлыгып бөтен район җәмәгатьчелеге җыелган заманда халыкка үзебезчә ярдәм итәргә алынуыбыз, мөгаен, менә шуның белән аңлатыладыр. Бер елны Мөслимгә кайткач, Бриллиант апа белән сөйләшеп утыруыбыз истә калган. Шунда ул: «Марсель, үзем җитәкләгән сыйныф укучылары Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын клубта күрсәткәндә, синең Хәмзә бай булып уйнаганыңны мин һаман хәтерлим бит әле», – дип әйтеп салмасынмы! Урыны җәннәттә булсын, шәп укытучы иде Бриллиант апа!

Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсе чагыштырып караганда ачыла, диләр. Бүгенге көндә бөтен уңайлыклары да булган менә дигән мәктәпләрдә укучы яшьләр чагыштырып

гыйбрәт алсын һәм тиешле нәтиҗә ясасын дип, тагын бер гадәттән тыш факт өстәп китим. Кеше ышанмаслык хәл: сәгатебез булмаганлыктан, 7 нче сыйныфта укыганда да, мин әле сәгать карый белми идем. Бервакыт тарих укытучысы Нурдидә апа укытучылар бүлмәсенә сәгать карарга җибәргәч, дәрес бетәргә ничә минут калганлыгын сәгатьнең кече теле буенча гына чамалап әйткәнлегемне хәзергәчә оныта алмыйм. Ә инде 8 нче сыйныфта укыганда классыбыз белән таш мәктәп фонында төшкән күмәк фотоны түләргә дә акча булмау аркасында алмый калуны искә төшерсәм, күңелем әрнеп, тыннарым кысылып куя.

Мәктәпкә бәйләп, тагын шуны әйтим, дим: мин 10 нчы сыйныфта укыган дәвердә янә һәркайсында утыздан артык бала укыган дүрт параллель 10 нчы татар классы бар иде, ә русча укыган унынчы сыйныф берәү генә иде! Шул елны мине унынчы сыйныфларның берләштерелгән комсомол бюросы секретаре итеп билгеләделәр. Районыбызның комсомол комитеты утырышларында мин башкарган эшебез турында отчёт бирә идем. Буыны да катып өлгермәгән без фәкыйрегезне кешегә санап, өч чакрымдагы Салавыз-Мухан авылына комсомол оешмасының эшен тикшерергә җибәрү очрагы да булып алды. Кышкы салкында чаңгы белән барып, тикшерү үткәреп, ялкау секретарьларын үземчә «кыздырып» кайттым шул чакта.

Гадел һәм намуслы кешеләр белән аралашырга туры килгәндә, мин «халык дошманы» баласы булуымны онытырга, үземне ким-хур итеп сизмәскә тырыша идем. Һәм, әлбәттә, җитәкчелеккә, совет идеологиясенә тел тидерү, «крамола» эзләү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Моңа ышану өчен мәктәбебез янып, ике катлы тулай торак бинасына күчкәннән соң, үзебез укыган бүлмәнең стенасына ябыштыру өчен даһи юлбашчыбыз Сталинның – газетадан күчереп, әлбәттә, – аягүрә басып торган рәсемен ясап барганлыгымны искә алу да җитә торгандыр. Картина ярыйсы ук уңышлы чыкканлыктан, бәйләнүче, каршы килүче булмады. Ә аннан бер ел гына элек районыбыз газетасында юлбашчыбызны күкләргә чөеп мактаган «Сталинга» дигән шигырем дә басылган иде. Әтиемнең һәм башка күп меңнәрчә гаепсез кешеләрнең репрессияләнүенә, үлеменә власть башында утыручы «даһи» затның гаепле булганлыгын мин, әлбәттә, шәхес культы фаш ителгәннән соң гына аңладым һәм Сталинны олылап, аңа табынып яшәгән нәүмиз чакларымны кат-кат каһәрләдем. Ә инде Казан университетында укыткан чорда намуслы әтиемне үтерүдә теләктәшлек иткән һәм турыдан-туры катнашып, безне ятим калдырган партия сафында мин моннан ары кала алмыйм, намусым кушмый, дип гариза язып бирдем һәм, шөкер, соң булса да акыл кереп, илдә тоталитар һәм Алласыз режим урнаштырган партиядән чыктым.

***

Яшерен-батырын түгел, халыкның күпчелек өлеше, бал-майда йөзгән партия элитасыннан һәм түрәләрдән аермалы буларак, гаять ярлы тормышта яшәде. Шәһәр җирендә инженер-техник хезмәткәрләрнең һәм эшчеләрнең хезмәт хакы гаять түбән иде. Хезмәт көненә граммлап кына икмәк алып, авылда яшәгән крестьяннарны көч җитмәслек налоглар белән буу, алардан бихисап күп ит, сөт, йомырка, йон салымы түләтү дә күп елларга сузылды. Өстәвенә, елдан-ел көчләп заёмга яздыру да озак дәвам итте. Шушындый мөшкел хәлләр хөкем сөргәнгә күрә дә – халыкның авызын томалап буламыни – фольклорда шуларны тәнкыйтьләгән сәяси-сатирик җырлар барлыкка килде һәм, телдән-телгә күчеп, халык арасында йөрде, менә шундый җырларның берничә үрнәге:

*Каһәр төшсен Николайга –*
*Ике сыер саудырды.*
*Рәхмәт төшсен Сталинга –*
*Бер кәҗәгә калдырды.*
*(вар:Кәҗәсез дә калдырды.)*

*Түрәләр түрдә утыра,*
*Ашлары бал-май гына.*
*«Салым» диеп, «заём» диеп*
*Җан алалар – «дай» гына.*

*Кичә дә салдым бер күкәй,*
*Бүген дә салдым бер күкәй;*
*Бер башыма – сиксән күкәй,*
*Шуңа асылындым, түтәй.*

Бу җырларның соңгысын үлгән тавыкны телефон баганасына асып, шуның янына ябыштыру гадәте булганлыгы мәгълүм. Димәк, коточкыч авыр шартларда яшәргә дучар булган гади халык сәяси репрессияләр, нахакка эзәрлекләүләр дәверендә дә куркып калмаган, ә җаен табып, кискен гаепләү тавышын ишеттерергә тырышкан, хәтта культ булып әверелгән илбашына тел тидерү югарылыгына кадәр күтәрелгән!

Мәгәр шәхес культының җәбер-золымын безгә, кара мөһер сугылган гаиләбезгә, үз җилкәбездә күп еллар буена һәм кат-кат татырга туры килде. Өйрәнчек хәбәрче буларак, мин «Яшь Сталинчы» газетасына мәктәп һәм укучылар тормышы, районда гы үземне кызыксындырган хәлләр турында вакыт-вакыт зур булмаган мәкаләләр җибәреп тора идем. Бервакыт үзем ясаган карикатуралар белән аерым җитешсезлекләрне фашлаган материалым басылып чыкты. Шунда район кинофикация начальнигы Садретдин Минһаҗев бер үк фильмның туйдырып бетергәнче кат-кат күрсәтелүе турындагы тәнкыйть хәбәремне укыгач, мине юлда туктатып: «Син бит халык дошманы баласы, әтиең кебек дөнья болгатасың, телеңне тыймасаң, мин сине судка биреп утыртам, малай актыгы», – дип зәһәрләнеп әйткән сүзләре һаман колак төбендә яңгырап тора кебек.

Ә икенче бер очракта район китапханәсе залыннан юка такта стена белән генә бүленгән кабинетында утыручы культура бүлеге мөдире минем үз адресына ычкындырган урынлы тәнкыйтемне ишетеп калган. Китапханә ял иткән көнне бу мине үз бүлмәсенә чакыртып китерде дә сүзен, йөземә бәреп, «халык дошманы» баласы булуымны искәртүдән башлады, һәм, этәчләнеп: «Коммунист кешегә яла ягканың өчен мин сине хөкемгә тарттырам», – дип янап, бу да өстемә ябырылды.

Билгеле, коммунист булып йөргән бу куркак, ташка үлчим түрәләрнең кәпрәеп, чыбыктай төз булып кыланып, хөкемгә тарттыру белән янавы сүздә генә калды. Ә менә бертуган апам Шәркыя белән абыем Марс тоталитар режим шартларында «халык дошманы» токымын көткән гаделсез һәм кешелексез кануннарны, большевиклар әзерләгән капкыннарны турыдан-туры үзләре татыдылар. Апам 10 нчы сыйныфны гел «бишле»гә генә тәмамлап, Казан авиация институтына укырга кергән иде. Ярты ел, ягъни бер семестр укыгач, янәшәдәге «Черек күл»дән килгән хокук саклаучы куштаннар, студентларның шәхси документларын өйрәнгәндә, апамның кем баласы булуын белеп, «синең урының монда түгел» дип, аны институттан чыгарттырдылар.

Абыем Марс исә балачактан ук очучы булырга хыяллана иде. Урта мәктәпне тәмамлагач, ике классташы белән ул Балашов шәһәрендәге хәрби очучылар әзерли торган училищега укырга китте. Әмма аны да, апабыз белән булган кебек, аяныч һәм гаделсез хәл көткән икән. Кабул итү имтиханнарының өчесен дә гел «бишле»гә тапшыруына һәм «дүртле»ләре булган ике иптәшен дә алуга карамастан, абыемны, биографиясен тикшереп «дошман баласы» икәнен белгәч, исемлектән сызып ташлаганнар. Абитуриентларның документларын тикшерү белән шөгыльләнгән Мандат комиссиясе рәисе, генерал дәрәҗәсендәге хәрби абыемның маңгаена бәреп әйткән: «Хәтерегез калмасын, без хәрби өлкә белән бәйләнгән урынны һәм кыйммәтле очкычны халык дошманы баласына ышанып тапшыра алмыйбыз», – дигән.

Әтиебез артыннан безне – ятим калган балаларын да юк итеп булмый бит инде. Укырга, югары белем алырга ашкынып торган без бахырларга балачактан ук хыялланган, өметләнеп һәм алдан планлаштырып көткән урыннар тәтемәсә дә, өчебезгә

дә хәрби көчләргә һәм дәүләткә «куркыныч янамый торган» һөнәрләр үзләштерергә насыйп булды. Апам медицина институтына кереп, санитар-врач булып чыкты. Әмма студент чагында ачка гомер асраган, өйдән бернинди дә ярдәм булмаганлыктан, хәлле кешеләрнең идәнен-керен юарга һәм иң кыерсытканы – инфекционистларга тәҗрибә ясау өчен ботына бәйләнгән чүпрәк тукыма астында бет үрчетергә мәҗбүр булган.

Төзелеш институтын кызыл дипломга тәмамлап, инженер профессиясе алып чыккан абыем да ачлы-туклы укыды. Бөгелмә тимер юл станциясенә кадәр поездда кайтырга акчасы булмаганлыктан, бер елны кышкы каникул вакытында Казан тиңенте җирдән Мөслимгә кадәр чаңгыда кайтуы барыбыз өчен дә гаҗәп бер хәл иде. Без, моңарчы чаңгыда олтанлы итек белән генә йөрергә күнеккән балалар, аның чаңгыга беркетелгән ботинкаларда кайтканлыгын күреп шаккаттык. Шәһәр җирендә конькиның да, чаңгының да махсус ботинкага тагылганлыгы киез итек һәм чабата киеп йөргән авыл бала-чагасына бик соңлап барып җитте.

Соңгы сыйныфларда укыганда, минем профессия сайлавыма да апам һәм абыем белән булган үтә гыйбрәтле һәм гаделсез хәл тәэсир итте. Аңынчы мин Казандагы химия-технология институтына, шуның приборлар төзүче инженерлар әзерли торган бүлегенә керергә җыенып йөри идем. Тик тора-бара тиешле органнар әтиемнең кем икәнлеген белгәч, мине дә чыгартып ташларлар яки бөтенләй алмаслар дигән уй өстенлек алып, бу ниятемнән кире кайттым. Мәктәпне тәмамлыйсы елны «Кызыл Татарстан» редакциясендә эшләүче якташыбыз Мөдәррис ага Мостафин белән очрашу вакытында ике арада булган сөйләшү минем Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә барачагымны хәл итте дә куйды. «Яшь Сталинчы» редакциясе белән язышып торуым, әдәбият-сәнгатьне яратуым зур йогынты ясап, тарих-филология факультетына керү өчен имтихан тотарга карар иттем.

## Шанлы һәм канат чыгарган студент еллары

Хәзерге чорда яшәүчеләр өчен ышанмаслык хәл: данлы университетыбызның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керергә дип, төрле районнардан һәм төбәкләрдән җыелган абитуриентлар саны мин барган 1951 елда бер урынга 8 кеше иде! Җитмәсә, керү имтиханнары җидәү: татар әдәбияты һәм татарча инша язу, рус әдәбияты һәм русча инша язу, тарих, география һәм немец теле яки башка чит тел. Шул чакта кабул итү комиссиясенә документларымны тапшырганда, читтәрәк торган өстәл яныннан кырыма килгән ханым аттестатымдагы шактый югары билгеләрне күрде дә: «Монда конкурс зур, әйдәгез безгә – геологлар әзерли торган безнең факультетка. Мондый билгеләр белән сез анда җырлап керәчәксез», – дип, мине кодалаганы хәтердә калган. Мин техник һәм хәрби белем алырга җыенган апам белән абыемның, «куркыныч элементка саналып», андый урында укудан мәхрүм ителүләрен оныта алмаганга, гуманитар белем алырга дигән ниятемнән, әлбәттә, кире кайтмадым.

Мөслим мәктәбе көчле булганлыктан һәм алдан ук максатчан әзерләнгәнлектән, мин имтиханнарны бик җиңел үттем дияргә була. Җиде имтиханның бишесен «бишле»гә бирдем. Немец теленнән, шул билгеләргә караптыр инде, «дүртле» куйдылар. Ә рус әдәбиятыннан аерым сорау рәвешендә Пётр Павленконың «Счастье» дигән романы эләккән иде. Татар мәктәбеннән килән татар баласының рус сүзләрен вата-җимерә шул фронтовик рус язучысының романын анализлаганын имтихан алучы доцент башын ия-ия тыңлап утырды да «бишле» куйды. Ә менә В.Маяковский иҗаты буенча язган, кайбер урыннарын кача-поса күчергән иншам «өчле»дән узмады һәм шуның аркасында беренче семестрда стипендия алмыйча җан асрарга туры килде.

Ул дәвердә институтларга кабул итү имтиханнары ике «поток»та, ягъни икенчесе беренчесеннән соң үткәрелә торган иде. Безнең «поток»тан коелып калучылар, шул мөмкинлектән файдаланып, башка институтларга таралып беттеләр.

Гуманитариягә дә күңелем яткангадыр инде, университетның үзем сайлаган филология бүлегендә артык көчәнмичә, чагыштырмача җиңел укыдым. Әлбәттә, төрле предметлар яки фәннәр буенча тәкъдим ителгән китапларны укып, бик еш китапханәдә утырырга ярата идем. Ә менә лекцияләрне язып бармыйча, күп вакыт тыңлап утыру да җитә иде кебек. Имтиханнарга әзерләнергә дип бирелгән вакытны тегендә-монда йөреп, кайбер көннәрне барлы-юклы акчага кино карап уздыра идем. Һәм иртәгә имтихан дигән көнне генә, йокларга ятарга җыенган группадашларымнан лекция текстларын алып, тулай торагыбызның «Кызыл почмаг»ына кереп утыру, төн буе әзерләнеп, лектор сөйләгәннәрне искә төшереп чыгу гадәтемә әверелгән иде. Шушы хәлнең кат-кат шаһиты булган группадашларымның мине иртәгә имтихан икәнен белдерүче «барометр» итеп күрә башлаулары, кайберәүләрнең исә, шул чактагы төшенчә белән әйткәндә, «штурмовщина» белән шөгыльләнеп кенә югары белге алып чыгуымнан астыртын гына көнләшүләре, минемчә, бик табигый һәм урынлы булгандыр.

Күпләребез өчен яшь чак – хәтер яхшы чак. Мәктәптә укыганда, үзебез белеп-төшенеп тә бетмәгән, рус телендә ятлаган шигырьләребезгә кадәр истә саклануы шул турыда сөйли. Янә килеп, университетта өченче курста чагында рус әдәбиятыннан имтиханга әзерләнгәндә, әйтик, И.Тургеневның бер-бер артлы укып чыгылган «Рудин», «Дворянское гнездо», «Накануне», «Отцы и дети», «Дым», «Новь» романнары тоныклана төшсә дә, төп геройларының, бигрәк тә чибәрлек-күркәмлекләре һәм үз-үзләрен тотышлары белән соклану үрнәге булган «Тургенев кызлары»ның вакыт-вакыт күз алдыннан үтеп китүе шулай ук табигый хәлдер. Әдәби геройларның характерлы сыйфатлары, төп сәнгати детальләр генә түгел, заманында «бишле»гә тапшырылган катлаулы политэкономия фәненең «капитал», «товар», «өстәмә табыш» кебек һәм төрле хезмәт төрләренә бәйләнешле төшенчәләр дә хәтердә шактый озак сакланды. Ә менә, ни хикмәттер, яшьлек чорын исәпкә алмаганда, кат-кат күзгә чалынмаган, якыннан аралашырга туры килмәгән кешеләрнең исем-фамилияләрен гомергә ныклап исемдә калдыра алмадым, белгәннәрен дә күпмедер вакыт үткәч оныта бардым. Бу баш миенең гаҗәеп күп информациянең бер өлешеннән арынырга тырышуы белән бәйледерме, әллә геннар, нәсел белән бәйле күренештерме, һәрхәлдә, мин исемнәргә хәтеремнең начар булуын зур җитешсезлегем итеп саныйм.

Халыкта «Кем синең дустың, мин синең кемлегеңне әйтеп бирермен», дигән акыллы әйтем-сынамыш бар. Мин үзем моны «Кем синең укытучыларың, кем булуыңны шунда әйтеп бирәм», дип үзгәртеп тә кулланам. Без үзебезне укыткан укытучылардан бик уңдык. Хатип Госман (кафедра мөдире), Латыйф Җәләй, Якуб Агишев, Ибраһим Нуруллин, Диләрә Тумашева, Мирфатыйх Зәкиев, Хәмит Ярми, Гаяз Ишмөхәммәтов кебек татар галим-мөгаллимнәре һәм Григорий Вольфсон, Любовь Савельева, Леонид Тузов, Людмила Ачкасова, Наталия Широкова кебек рус педагоглары безгә ныклы һәм күпьяклы белем биргән остазларыбыз иде.

Ул чорда татарлык һәм укырга керүчеләр арасында сайланыш шактый югары кимәлдә булганлыктан, безнең академик группабыз чын мәгънәсендә талантлар группасы иде. Арабыздан татар укытучылары, мәктәп директорлары һәм башка җаваплы урыннарда эшләүче җитәкчеләр булып китүчеләрдән тыш, Азат Әхмәдуллин, Римма Зарипова, Юныс Әминов, Фәнис Исламов һәм без фәкыйрегез кебек фән докторы яки кандидаты дәрәҗәсе алучылар, шулай ук Әхсән Баян, Хәниф Хәйруллин, Мәгъсүм Латифуллин кебек шагыйрь һәм прозаик язучылар, журналистлар чыгуы ышандырырлык итеп шул хакта сөйли.

Әмма да ләкин, алда әйтелгәнчә, артык көчәнмичә, чагыштырмача җиңел укуым һич тә көтелмәгән каршылыкларга, шул чор идеологиясе һәм тәртипләре сагалаган тыю-табулар кармагына эләккәнем булмады дигән сүз түгел әле. Тарихтан имтихан биргән чакта булды шундый бер хәл. СССР тарихыннан имтиханны доцент Г.Вульфсон

белән ассистент Е.Матвеева ала иде. Мин әзерләнеп беттем дә, чиратымны көтеп, иң алгы рәттә утырам. Группадашым Хәниф Хәйруллин шул мәлне бер соравына җавап бирә алмыйча, «төртелеп» калды. Түзмәдем, ат дагалаганда бака ботын кыстырган кебек, ике-өч сүз белән генә булса да пышылдап, моңа җавабын әйтеп җибәрдем.

Шуннан соң һич көтмәгән хәл килеп тумасынмы! Хәнифне «зачётка»сына «дүртле» куеп чыгарып җибәрделәр дә, миңа мыскыллы-усал караш ташлап, сөйләргә утырттылар. Каушамаска тырышып, җавабымны күтәренке тавыш белән сөйли башладым, ә болар минем сүзләргә колак та салмыйча, юри кычкырып, көлешә-көлешә сөйләшеп утыралар, әй. Ахырда Григорий Наумович бәхәскә урын калдырмаслык итеп кистереп әйтте: «Двойка тебе, не выдерженный молодой человек», – диде.

Шуннан соң, кышкы каникулга өйгә кайтмыйча, ике атна буена билет сорауларын кабат-кабат күздән кичереп, яттан сөйләрлек итеп җаваплар әзерләп чыктым. Бу юлы миннән имтиханны Елена Матвеева үзе генә алды. Билетка бик җиңел җавап бирдем. Сталинның Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, Кремльдә сөйләгән чыгышын да тәфсилләп аңлаттым. Сөйләп туктагач, имтихан алучы: «А что сказал товарищ Сталин в конце своего выступления?» – дип кабат төпченергә тотынды. Һәм юлбашчының: «Победил великий русский народ, победило русское оружие» дигән гыйбарәсен сүзмә-сүз китерә алмаганым өчен генә бу ханым минем югары билгеләрдән генә диярлек торган «зачётка»ма «өчле» чәпеде.

Шулай итеп, техника һәм хәрби белгечлек белән бәйләнмәгән гуманитар өлкәдә дә илдә сөргән тоталитар вазгыять һәм идеологик атмосфера үзенең вәкаләтле-догматик йогынтысын күрсәтеп алды. Минем сугышта җиңүче халык дип, русларны гына түгел, ә бөтен совет халкын санавым кыйммәткә төште. Бер семестр буена стипендия алмыйча яшәдем. Һәм иң аянычы, иң хәтәре – шул бер «өчле» аркасында мине соңыннан кызыл диплом алучылар исемлегеннән сызып ташладылар.

***

«Һәркем үзенең авырткан җире турында сөйләргә ярата», – диләр. Минем авырткан җирем әлеге дә баягы гаиләбез өстенә өелеп төшкән үксезлек-ятимлек һәм шуның аркасында кичергән ачлык кына түгел, ә үтә нык татырга туры килгән ярлылык-хәерчелек иде. Ничек түзгәнмендер: кышларын биш ел буена искереп беткән көзге юп-юка пальтода йөрү, кышкы салкыннарда иртән бер кат чалбардан Красная Позиция дигән урамдагы тулай торактан Горький паркына кадәр трамвайга барганда (ул чакта трамвай шунда кадәр генә йөри иде), туктый-туктый, өшегән тезләрне ышкып җылыту, шул транспортта билетсыз барганда, тотылып, авыр хәлләргә калулар – барысы-барысы да безнең бичара баштан үтте.

Ә бер елны кышкы каникулда билетсыз килеш поездда кайтып барганда, контролёрлар тотмасын дип, полкада тезелешеп, мине каплап утырган кызлар артында качып калуымны да әйтми кала алмыйм. Шуның артыннан ук Бөгелмәнең ягылмаган иске тимер юл вокзалында катып-өшеп, Мөслимнән ат килгәнен көтеп, төн кунарга туры килде. Бары икенче көн кич кенә ат җигеп килгән бичара әнием килеп тапты мине.

Шул ук елны, бу юлы җәйге каникул вакытында, сагынып һәм гаҗәп бер хәл итеп сөйләрлек трагик-комик вакыйгага булып алды. Мөслимдә укыган чагымда ук әле сайлау һәм төрле бәйрәмнәр вакытында үзем кулдан эшләгән плакатлар һәм лозунглар исәбенә җыелган акчага кибеткә кайткан трикотаж тукыма сатып алган идем. Ул заманда сатуда әзер күлмәкләрнең заты да булмаганлыктан, шул буйлы ак тукымадан ательеда үземә күлмәк тектереп алдым. Университетка укырга керергә дә шул бердәнбер затлы күлмәгемне киеп бардым. Ә менә сүз барган җәй көнне авылда чакта, гөнаһ шомлыгына, бауга кибәргә дип элгән шул күлмәкне бозау чәйнәде, әй. Утырып еламадым гына.

Шулай да, акрынлап, үземне тынычландырдым. Ник һәм ничек дигәндә, күлмәкнең арткы ягы гына өзгәләнеп чүбекләнгән, ә алгы ягы исән икәнлегенә игътибар иттем.

Аптыраган үрдәк суга арты белән чума, дигәндәй, югалып калмадым, пинжәк кигәч күренми дип, шул артсыз күлмәгемне киеп «сад» бакчасына танцыга йөри башладым. Ә бер көнне яңарак кына танышып, озатып йөргән кызым – күрәсең, мин «уҗым бозавы»ннан кочаклатасы килгәндер инде – «туңыбрак торам әле» дип әйтеп салмасынмы! Мин джентльменлык күрсәтеп, пинжәгемне моның иңнәренә элдем. Үзем исә, ялангач аркамны айга күрсәтеп, кыз янында гел алгы ягым белән генә бөтереләм. Янәсе, ошаткач, моның гел алдында гына биеп торам...

Казанда яшәргә андагы тәртипләргә күнегеп алгач, мин, билгеле, җае чыккан саен эшләп азмы-күпме акча юнәтү, тормышымны җиңеләйтү юлларына да игътибар бирә башладым. Кышкы чорда тимер юл вокзалына вагон бушатырга йөрдем, ә җәйләрен аркага тау кадәре утын пүләннәре яки кырыгар килограммлы ике капчык цемент салынган «подушка» асып, яр белән Иделдәге баржаны тоташтыручы тирбәлеп торган басмалар аша керә-чыга йөк ташу белән дә шөгыльләндем. Мондый авыр эшкә бик аз егетләр генә чыдый ала иде.

Бер-бер артлы диярлек килгән бөтен ил күләмендә истә калган 1953 һәм 1955 еллар без студент булган чорга туры килде. Башта үзенең чиктән тыш автократик һәм «кызыл террор»га нисбәтле эшчәнлеге белән каршылыклы шәхес буларак тарихка кергән Сталин вафат булды. Мин ул көнне дөнья беткән кебек исәнгерәп һәм кайгыга батып йөрдем, үзем кебек матәм каравылында торган группадашларымны соңыннан, истәлеккә дип, күмәк рәвештә фотога төшереп алдым. Аларның сөмсерләре коелган, кайгылы кыяфәттәге фотолары хәзер дә шул көнне искә төшереп тора. Ә икенче дата Казан университетының ачылуына 150 ел тулу белән бәйле юбилей датасы иде. Бу бәйрәм алдыннан безнең бүлекне тәмамлаган һәм Лобачевский исемендәге фәнни китапханә директорының урынбасары булып эшләгән Әбрар Кәримуллин, студент кешенең хәлен аңлаптыр инде, витриналар ясарга катнашырга мине художник итеп чирек «ставка»га эшкә алды. Көз көне башка студентлар колхозда эшләгәндә, без диаграммалар, витриналар ясап, «альма-матер»ыбызны юбилейга әзерләштек. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены аңа менә шушы юбилей уңае белән бирелде.

Егерме ике сум күләмендәге стипендия һәм вакыт-вакыт анда-монда эшләп тапкан аз гына акча исәбенә яшәү гаять авыр булса да, без үз күңелебезне үзебез таба белгәнбез, әй. Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан «Яшь Сталинчы» газетасы редакциясендә, шулай ук үзебездә оештырылган әдәбият түгәрәкләрендә һәм төрле очрашуларда катнаша торган идек, якшәмбе көннәрендә тулай торакның «Кызыл почмаг»ында, өстәлләрне коридорга чыгарып, танцылар оештыру даими гадәткә әверелде. Шул ук «Кызыл почмак»та диңгез флотында хезмәт итеп кайткан өлкәнрәк яшьтәге бер студент безне, өч егетне, «Яблочко»га – матрослар биюенә өйрәтте. Һәм без, янәшә тезелеп, үзебез янындагы Маяковский исемендәге радио-приборлар заводы клубында өздереп, шул биюне башкардык. Яшь чагында тальян телләрендә уйнарга насыйп булмаган юан бармакларыма да бәхет елмайды: Әгерҗе районыннан килгән, якын дустым булып әверелгән Юныс Әминов баянында, соңлап һәм акрынлап булса да, татар көйләрен «шыңгырдата» башладым. Һәм, әлбәттә инде, студентлар үзләре чыгара һәм каләмнәрен беренче башлап сыный торган стена газетасы «Әдәби сүз»не бизәү, факультет күләмендә чыга торган сатирик «Молния»да рәсемнәрем белән катнашу да – минем яраткан шөгылем иде.

Монда язарга онытып кала язган, бигрәк тә яшь чагында үз иткән һәм кулланырга яраткан тагын бер һөнәрем бар иде минем. Анысы – фокуслар күрсәтү, тамашачының «күзен буу» белән шөгыльләнү. Мин моңа мәктәп елларында ук өйрәнә башладым. Минем инануыйча, фокуслар күрсәтү, мәзәкләр күрсәтүче чын мәгънәсендә «кул остасы», «күз буучы» булсын, мәгәр хәрәмләшмәсен. Мөслим клубы сәхнәсендә читтән килеп чыгыш ясаган бер «шарлатан» истә калган. Афишада пропагандаланган шаккатырачак номерын күрсәтер алдыннан бу, залга эндәшеп, үзе янына кемнеңдер

чыгуын сорагач, мин атылып, сәхнәгә мендем. Ошбу «ялган гипнотизёр» алдашу-хәрәмләшү юлы белән мине «йоклатырга» җыенган икән. Залдагыларга ишеттермичә, акрын гына миңа ялына башлады бу: «Кызык булсын, мин «йокла, йоклап кит!» дип ,кат-кат кабатлагач, юри йоклап киткән булып кылан», – дип үгетли мине. Мин башта моны тыңларга булдым. Ә инде гәүдәмне ике янәшә урындык иңсәләренә яткырып, өстемә менеп басарга җыенгач, кычкыртып фаш иттем бу ялганчыны. Ничек итеп дисезме? Сикереп идәнгә төштем дә халыкка ишеттереп: «Сез гипнозчы түгел, ә чепчи халтурщик, абый», – дип, тамашачыларның күзен ачтым.

Үземнең фокусларга килгәндә, алар «ловкость рук и никакого мошенничества» принцибына корылганнар. Өченче курста укыганда, шефлык ярдәме белән колхозга бәрәңге алышырга баргач, безнең группа авыл халкына күрсәткән концертның икенче бүлеге без фәкыйрегез күрсәткән фокусларга корылган иде. Ачыклап әйткәндә, мин анда ябык конвертларга салынган хатларны уку, китапның билгеле бер битендәге тамашачы билгеләгән текстны карамыйча әйтеп бирү, ниндидер әйберләрне, «күз буып», бер урыннан икенче урынга күчерү, кулдагы «көмеш» акчаны, юкка чыгарып, икенче урыннан алып бирү, тамашачы кесәсеннән югалган нәрсәсен таптыру, кемнеңдер өстендәге күлмәген, пинжәк сәдәфләрен ычкындырмыйча, салдырып алу кебек һәм дә кәртләр, үзем ясаган төрле бутофорлар куллануга корылган башка төрле фокуслар күрсәттем.

Юклык-кытлыкны да, нахакка рәнҗетү-кимсетүләрне дә сыйдырган, шулай ук сынык күңелне канатландыра, авыр тормышны җиңеләйтә торган төрле хәлләр һәм маҗара-вакыйгалар тезмәсеннән торган биш ел, ниһаять, артта калды. Соңгы мәртәбә, группабыз белән барып, күмәк рәвештә һәм һәркайсыбыз аерым-аерым фотога төштек. Өстемдә кешелеккә кия торган костюм булмаганлыктан, альбом өчен әзерләнә торган әлеге фотоларга төшәргә мин бүлмәбездә бергә яшәүче яһүд егетенең затлы пинжәген киеп бардым. Эшкә мине журналист итеп, Уфада татар телендә чыга торган «Кызыл таң» газетасына билгеләделәр.

## Кендегебез сиңа береккән, Мөслим

Диплом алган соңгы җәйне мин туган төбәгем Мөслимдә үткәрдем. Интегеп белем алырга туры килгәнгәдер инде, университет дипломын, юлда ул-бу булмасын дип борчыла-борчыла һәм кадерләп алып кайтканым истә калган. Ул чакта Казан белән ике арада автобуслар йөрми иде. Бердәнбер юл – башта йөк төягән машинада барып, Чаллы аша пароходта китү һәм шул ук юл белән кайту. Без, хәерче студент халкының, утырып йөри торган урыны – пароходның иң аскы катындагы әчкелтем-төчкелтем исләр аңкып торган дүртенче классы иде. Шунда полкага кырын ятып, туган якка кайтып киләм, әй. Агач чемоданымда – кат-кат төреп салынган зәңгәр тышлы диплом, шулай да күңел нигәдер тыныч түгел, шомландыра, борчылдыра. И Ходаем, мин әйтәм, янгын чыгып яки ул-бу булып, бу пароход бата гына күрмәсен иде, юкса дипломым харап булачак бит, дип мазасызланам. Башыма, шундук ук булмаса да, коткару планы да килә: «Ык буенда үскән малай бит мин. Пароход бата башласа, дипломымны югары күтәреп, ничек тә бер кул белән ярга йөзеп чыга алырмын әле»,– дип, үземне тынычландырам.

Диплом, билгеле, батмыйча исән калды. Шуннан соң күп сулар акты, күп вакытлар үтте һәм без фәкыйрегезгә берсеннән-берсе дәрәҗәле башка дипломнар һәм исемнәр алырга насыйп булды. Әмма беренче дипломым барыбер Мөслим белән Казанны бәйләүче иң кадерле ядкарь – әманәт булып калды. Мөслим үзе исә – безнең өчен авыр чорга туры килгән бала һәм яшь чакның бишеге, ач- яланач булып яшәгән шартларда да кояшка таба очар өчен иңсәләребезгә канат куйган изге төбәк. Шуңа күрә дә шагыйрь исеме күтәрмәсәк тә, күңелдә шушы төбәккә багышланган шигырь юллары туа, аңа бәйле хис-тойгылар шигъри телгә күчә.

*Күпме каршы алмадым*
*Туган якның таңнарын,*
*Исән микән, таныр микән*
*Тамга салган талларым,*
*Яшьлегемә алып кайта*
*Күңел кыңгырауларым.*

*Туган якны сагынуым*
*Гомергә бетмәс инде,*
*Алтын яуган җир булса да,*
*Авылыма җитмәс инде,*
*Мөслимгә җитмәс инде!*

Мөслим төбәге – шулай ук барыбызны да бишектән үк табигатьне һәм кешеләрне яратырга өйрәткән һәм дә күпләребез өчен беренче мәхәббәтебез бөреләнгән иң кадерле як та. Беренче сөйгән ярларыбыз бик-бик якында да һәм бик ерактадыр да кебек. Урам чатыннан каршыңа йөгереп чыгар да «мин бит сине һаман көтәм», дип муеныңа сарылыр кебек. Әйе, еллар үтсә дә, күңел картаймый; туып-үскән җирнең кабатланмас манзарасы, ямьле Ык буйлары һәм таныш сукмаклар сине һаман үзенә дәшә. Йөрәктә яшьлек хатирәләре, бүгенге кичерешләр белән үрелеп, шигырь булып агыла; тансыклаган һәм юксынган күңел канатлы сүзләр булып түгелә.

*Ык буйларыннан эзләдем*
*Яшьлегемнең эзләрен,*
*Сөю-сагыну хисләремне*
*Дулкыннарга сөйләдем.*

*Сорадым мин дулкыннардан:*
*Сөйгән ярым кайларда,*
*Йөргәне бармы юксынып,*
*Без учак яккан ярда?*

*Хәтерендә сакланамы*
*Вәгъдә бирешкән чаклар?*
*Ятлар куенына кердеме,*
*Туктагач көткән хатлар.*

*Нигә дәшмисез, дулкыннар,*
*Әллә инде мин ятмы,*
*Тергезергә соң дисезме*
*Сыкрап сүнгән учакны?*

*Дулкыннарның серле шавы*
*Сагышка сала икән,*
*Тәүге яр, татлы моң булып,*
*Күңелдә кала икән.*

Таулардан мәһабәтрәк бары таулар гына була ала. Кичәге Мөслимнең үзенә генә хас матурлыгы белән дә аннан соңгы дәвердә тагын да гүзәлләнгән һәм гаҗәеп төзекләнгән бүгенге Мөслим генә чагыша ала торгандыр. Аны шулай күркәм-сокландыргыч иткән һәм республикабызның иң төзек, иң мәртәбәле район үзәкләренең берсенә әверелдергән якташларыма бик-бик рәхмәтле мин!

Районыбызның йөзен үзгәрткән санап бетергесез зур үзгәрешләргә аерым тукталмыйча, монда «Эт тыкрыгы» дигән кушамат алган үз очыбызны мисалга китерү дә җитәдер. Мондый кушамат мин анда яшәгән вакытта барлыкка килде. Пушкин урамының олы юл аркылы кисеп үткәннән соң бүленеп калган бу өлешенә язын-көзен һәм көчле яңгырлар яуган вакытта җәен дә керерлек түгел иде. Чөнки иңебрәк торган

бу башны су баса, безнең урамда яшәүчеләр һәм Ык буена төшүчеләр бер яктагы коймага яки икенче яктагы читәнгә тотына-тотына, сазга батып кына эчкә үтә алалар иде. Җитмәсә, безнең турыга җиткәч, мин тоткан Актырнак исемле этемнең вакыт-вакыт урамга өреп чыгуы да шундый кушамат тууына сәбәп булгандыр.

Хәзер исә зур урамның бу өлешенең элекке хәленнән аермасы – җир белән күк арасы кадәр. Килешле төсләргә буялган коймалар һәм нәкышләнгән капкалар, дисеңме, тәрәзә йөзлекләре челтәрләп эшләтелгән һәм верандалы төзек йортлар, өй каршында яки янәшәсендә тәрбияләп үстерелгән бакчалар, дисеңме – барысы да татарның пөхтәлеген һәм йорт-каралтысын тәртипле, матур итеп тотуын күрсәтеп тора. Район үзәгенең бу үтә тыныч һәм күркәм почмагын беренче булып җайга салып җибәргән кешенең исемен телгә алмыйча калу гөнаһ булыр иде. Ул – шул урамда яшәгән һәм ГАИда эшләгән Нариман Нәҗмиев. Машиналар белән таш ташытып һәм асфальт җәйдереп, урамны шул ялт иттерде.

Ә районыбыз үзәген тулаем төзекләндергән, – махсус юл үткәрелгән Ык ярларыннан алып, буйдан-буйга чәчәк түтәлләре утыртылган асфальт урамнары, бер-берсен уздырып салынган күркәм йортлары, зиннәтле милли стильдәге мәчетләре һәм, ахыр килеп, хәзерге таләпләргә җавап бирә торган физкультура-спорт һәм Сабантуй комплексларына кадәр – гаҗәеп киң колачлы төзелешләр һәм саллы объектларны сафка бастырып, Мөслимебезне танымаслык дәрәҗәгә җиткергән төп инициаторлар, белүебезчә, – төрле елларда хакимият башында торган Рөстәм Шәрипов, Ришат Хәбипов һәм бигрәк тә Рамил Муллин. Һәм, әлбәттә, аларга теләктәшлек иткән, бу изге эштә якыннан торып катнашкан район җәмәгатьчелеге һәм гади халык. Без, әзергә-бәзер булып һәм горурланып, туган төбәгебезгә кайтып йөрүчеләр, менә шул каһарманнарга бурычлы икәнлегебезне һәм аларның исемнәрен беркайчан да онытмаска тиешбез.

## Журналистика – чарлану-чыныгу мәктәбе

Уфа мине көтеп алган кунагы кебек җылы каршылады. «Кызыл таң» редакциясе ул чакта Карл Маркс урамындагы бинада урнашкан иде. Мине заманында Нәкый Исәнбәт белән Уфада, ә Муса Җәлил белән Мәскәүдә татар редакцияләрендә бергә эшләгән өлкән журналист Тимер Әлүк (Алюк) җитәкчелек иткән культура бүлегенә әдәби хезмәткәр итеп тәгаенләделәр. Бу тәҗрибәле, үтә таләпчән журналисттан һәм үзлегемнән мин күп нәрсәгә өйрәндем. Баштагы мәлдә информация, репортаж, тасвирый мәкалә («зарисовка»), фельетон кебек жанрларны үзләштерүдән акрынлап, зур күләмле тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр һәм очерклар язуга күчтем.

Күпмедер вакыт мине сынаганнан соң, Тимер ага Әлүк культура бүлеге өлешенә туры килгән әдәбият һәм сәнгать тематикасын алып баруны миңа тапшырды. Кулларына беренче башлап каләм алучыларның һәм язганнары өмет уята торган яшь-җилкенчәкнең әдәби материалларын анализлап җавап язу һәм уңышлыларын бастырып чыгару минем өстә иде. Шулай ук Язучылар берлеге, филармония, театр коллективлары белән бәйләнеш тоту, профессиональ язучылар һәм артистлар иҗаты белән газета укучыларны даими рәвештә таныштырып бару, ахыр килеп, үзешчән коллективларның эшчәнлеген һәм чыгышларын эзлекле рәвештә яктырту өчен дә мин җаваплы идем. Шуңа күрә дә Уфада 10 ел яшәп, Казанга аспирантурада укырга килгән чорда Башкортстан язучыларын һәм артистларын мондагы «коллегаларына» караганда күбрәк һәм яхшырак белүем бик табигый иде һәм бу хәл хәзер дә кайчак үзен сиздереп куйгалый.

Табигый инде, әдәби материаллар өчен җаваплы булганлыктан, Сәйфи Кудаш, Мостай Кәрим, Наҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, Шамил Анак, Марат Кәримов кебек шагыйрьләрнең газетабызда басылган шигырьләре безнең аша үтте. Татарстаннан



*Уфада (уңнан беренче) башкорт-татар язучы-журналистлары һәм сәнгать әһелләре арасында. Алда – композитор Әнвәр Бакиров һәм җырчы Фәридә Кудашева. 1957 ел.*

Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Әхсән Баянның шигырь тәлгәшләрен дә бастырып чыгарган булды. Шәхес культы фаш ителгәннән соң, редакциядә 30 нчы елларда репрессияләнгән язучылар да күренә башлады. Шундыйлардан исеме әдәбиятыбыз тарихы буенча яхшы билгеле язучы, Тукайның замандашы Зариф Бәшири белән берничә мәртәбә очрашканыбыз булды. Ркаил Зәйдулланың фактик мәгълүматларга таянып язып чыгуына караганда, әнисе ягыннан ул – ошбу шагыйребезнең бабасы.

Минем Казаннан, тумышы белән үзенә якын яктан икәнемне белеп, тере классигыбыз килгән саен үз итеп, аркамнан кагып уза иде. Бер килүендә, исәнләшкәч, мин аннан: «Зариф ага, безгә материал китерергә җыенмыйсызмы?» – дип, тыйнак кына итеп соравыма ул: «Әле мин, энем, истәлекләр язу белән мәшгуль», – дип җавап бирде. Үзе вафат булгач басылып чыккан «Замандашларым белән очрашулар» (Казан, 1968) дигән китабы буенча билгеле булды: бу олпат зат М.Гафури, Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан кебек классиклар белән аралашып яшәве турында бик җылы һәм кызыклы хатирәләр язып калдырган. Бу уңай белән бик урынлы тәкъдим яки сорау да туа: белүебезчә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә аның моңарчы беркайда да басылмаган шигъри повесте, романы һәм башка әдәби кулъязмалары саклана. Шуларның әдәбиятыбыз тарихы һәм хәзерге укучылар өчен дә файдалы булганнарын ачыклау һәм нәшер итү кирәклеге соралып тора түгелме?

Репрессиягә эләккән әдипләрдән янә 20-30 нчы елларда Башкортстанда бик актив булган шагыйрь Мөслим Марат белән якынлашып киттек. Аның газетабызда тоткынлыкта язган шигырьләре басылды. Ә миңа бүләк иткән фоторәсеменең артында өч строфадан торган багышлама шигыре бар. Менә ул бөтен юллары да рифмалаштырып язылган үзенчәлекле шигырь.

*«А»ны әйткәч, «б»ны әйт инде син:*
*Марсель булгач, бул син Кашен да,*
*Һәрчак сакла кеше сөю хисен,*
*Күз өстеңдә йөрткән кашыңдай,*
*Чәчең коелса да башыңнан.*

*Минем гомеремне озайталсаң,*
*Синең белән калдырам төсемне,*
*Йөздән өскә менеп картаймасаң,*
*Нигә сиңа «Марсель» исеме?!*
*Аякларың бозда да таймасын,*
*Ут эченнән көйми үтә бел,*
*Тамырларың җирдән аерылмасын,*
*Кипаристай өскә күтәрел!*

Сыйнфый һәм милли эзәрлекләү чорында «вульгар социализм», гаепсез әдипләрне чагу белән шөгыльләнгән Хәләф Наум дигән ташка үлчим «тәнкыйтьче» белән очрашуым да исемдә. Ул – заманында Сәйфи Кудашны нахакка «Җидегәнче»лектә гаепләүчеләр хорына кушылган икейөзле бәндә. Редакциягә ул, гаеп тагу, батыру

шөгылен дәвам итеп, Сәйфи Кудашның яңа чыккан шигырьләр җыентыгына кара ягып язган рецензиясен китергән иде. Мин, әлбәттә, моның шакшы, ялганга корылган язмасын, кискен тәнкыйтьләп, үзенә кайтарып бирдем.

***

Уфада яшәвемнең өченче елында, 26 нчы яшем белән барганда, мин Туймазыда яшәүче Кифая исемле кызга өйләндем. Ә аңынчы университетның беренче курсын тәмамлагач танышкан һәм дүрт ел буена аралашкан, якын бәйләнештә булган беренче мәхәббәтем белән гаилә корырга насыйп булмады. Ник дигәндә, халык «үзе юкның күзе юк» дип, дөрес әйткән бит: Уфада күпмедер яшәгәч, миңа «Хочешь ли ты на меня жениться, я тебя до сих пор люблю» дип язган кызым, Мөслимнең үзендә уңышлы кандидатура туры килгәнгәдер инде, башка кешегә кияүгә чыкты да куйды. Әлеге вариант аның карьерасына да уңай тәэсир ясады: Мөслим урта мәктәбенә ул институтта ала торган белгечлеге буенча – рус теле укытучысы булып урнашты.

Шушы хәлләрдән соң Уфадагы төрле югары уку йортларында оештырыла торган кичәләргә, танцыларга йөреп карасам да, күңелемә ошаган кыз очрата алмадым. Бер мәлне мин Туймазыга командировкага барып чыктым. Анда төзелеп беткән медицина пыяла заводы ачылуы уңае белән репортаж язарга тиеш идем.

Заводта йомышымны үтәп бетергәч, юл уңаеннан район китапханәсенә кереп чыгарга булдым (ул чакта Туймазыга шәһәр статусы бирелмәгән иде әле). Мәкънүнә атлы китапханәче ханым янындагы актив китап укучыларга багышланган витринада бер чибәр кызның рәсемен күреп, ярым шаяртып әйттем моңа:

– Иртәгә инде кайтып китәм. Тик менә шундый чибәр туташ белән танышып кына булмады...

– Рус кызы ул.Телисезме, мин сезне бик шәп татар кызы белән таныштырам, – ди бу.

Шуннан Мәкънүнә ханым картотекалар тартмасыннан бер белешмә карточка чыгарды.

– Менә ул кыз. Исеме – Кифая.

«Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына» дигәндәй, бу тәкъдим белән килешеп, шаяруымны чынга әйләндереп карарга булдым. Кызның адресын сорап алдым да, Аллага тапшырып, киттем боларның өен эзләп. Кыз кинога киткән булып чыкты. Әнисенә әйттем:

– Кызыгызга йомышым, тапшырасы әманәтем бар иде, – дидем.

Тәвәккәлләп килгәч, ризалык алып, көтәргә булдым. Ул кайтканчы ике кечкенә сеңлесе һәм энесе белән «мәш» килеп уйнап, боларга төрле хайван сурәтләре ясап утырдым.

Кифаябызның кайтып керүе булды, бер күз ташлау белән без фәкыйрегезнең йөрәген гыйшык очкыннары җилкендереп үтте. Шул кичне без урамга чыгып, озак сөйләшеп йөрдек. Эштән кайткан әтисе дә, яныбызга чыгып, кызының башын әйләндерүче әрсез егет белән танышты. Тагын бер кич очрашып, сөйләшеп йөргәннән соң, янә яныбызга чыккан әтисеннән мин кызның кулын сорарга җөрьәт иттем. Урамнан килеп кергән һәм әлегә гаиләсе белән дә таныш булмаган әтрәк-әләм хәлендәге бәндәгә кыз тоттырып җибәреп булмый бит инде. Кызның әтисе татар йоласы кушканча җавап бирде:

– Кызымны сорарга иң якын кешең – анаң килсен, балам, – диде.

Калганы ата-бабадан калган һәм хәзерге заманга яраклаштырылган традицион гореф-йолаларга туры китереп башкарылды. Туе да, икәвебезне генә өйдә ялгыз калдыру да, кияү мунчасы да булды. Иң мөһиме, мин күрү белән дөньямны онытып капланган кәләшемнең гаиләсе бик абруйлы һәм күпләргә үрнәк, намуслы гаилә булып чыкты. Фин һәм Бөек Ватан сугышларын үткән гаилә башлыгы Кәнзел Сөнгат улының күкрәге тулы орден һәм хәтта ул Җиңү парадында катнашкан каһарман икән. Төрле җаваплы урыннарда эшләп, үз көче белән гүрнәчәдәй затлы өй бетереп керүе дә аның намуслы һәм кулыннан эш килә торган ир булуы турында сөйләп тора.

Гаилә тормышым менә шундый нәселдән чыккан кыз белән танышудан башланып китте минем. Югары белем алырга өлгермәсә дә, мин аны уңганлыгы өчен хөрмәт иттем; медицина училищесына кертеп, үзе соңыннан күп еллар буе яратып эшләгән шәфкать туташы дигән профессия алдыртып чыгардым. Озак та үтми ике бүлмәле яңа фатир алырга да насыйп булды һәм бер-бер артлы ике кызыбыз туды. Эшем дә, билгеле, җай гына барды.

***

Культура бүлегендә дүрт елга якын эшләгәннән соң, әдәбиятчыларга соңыннан «Революциягә кадәрге татар сатирик журналлары» дигән темага кандидатлык диссертация яклавы белән таныш булган журналист Үзбәк Гыймадиев мине үзе мөдирлек иткән пропаганда бүлегенә соратып алды. Монда мин дөньяга карашны үстерә торган һәм халыкара проблемаларга бәйләнешле җитди материаллар белән эш итәргә һәм күләмле русча текстларны, шул исәптән Н.Хрущёвның «су буе» докладларын һәм чыгышларын, машинистка янына утырып, язып тормыйча шундук телдән тәрҗемә итәргә өйрәндем.

Аннары инде мине газетаны планлаштыру һәм гамәли яктан әзерләү, бастырып чыгару штабы булган иң җаваплы урынга – секретариатка күчерделәр. Ул чакта компьютерлар юк иде әле. Монда мин, секретариатка бүлекләрдән кергән материалларны уку һәм редакцияләү белән бергә, чираттагы номерны зәвыклы һәм күңелгә ятышлы итеп макетлаштыру һәм дә типография белән даими бәйләнеш тотып, газетаны эстетик һәм форма-бизәлеш ягыннан югары кимәлдә чыгару эшенә җитәкчелек иттем.

Безнең газета белән башкортча чыга торган «Совет Башкортстаны» газетасы арасында рәсми булмаган, кайсы газетаның эчтәлеге, укылышлылыгы белән дә, формасы, тышкы күренеше ягыннан да уңышлырак булып чыкканлыгын үзара чагыштыруга корылган яшертен ярыш бара иде. Һәм һич арттырып әйтмим: без чыгара торган газета күпчелек очракта өстенлек ала торган иде. Шул елларда әлеге татар органының тиражы 95 меңгә кадәр җитүе, әлбәттә, аның кызыклы һәм сыйфатлы булып чыгуына да нык бәйле булгандыр.

Алда, мин, бүлектә эшләгәндә, күләмле тәнкыйть мәкаләләре язарга да бик теләп алынуым турында әйттем. Шундый мәкаләләремнең шактый өлеше «Мораль темага» дигән рубрика белән чыкты. Аларны халык яратып кабул иткәнлектән, редакциягә вакыт-вакыт «фәлән-фәлән хәлне фаш итәргә Бакировны җибәрсәгез иде» дип язылган хатлар килгәли иде. Газетабызның баш мөхәррире Таһир Ахунҗанов (аннары ул Партия Өлкә комитетының идеология эшләре буенча секретаре булды) секретариатта эшләгән чагымда да шундый ук исемләп чакырган урыннарга барырга миңа бик теләп мөмкинлек бирә торган булды. Бер мәлне мөхәррир бүлмәсенә бердәнбер улларының фаҗигале үлеме белән бәйле четерекле хәлне ачыкларга мине җибәрүне сорап, мәрхүмнең Дүртөйле районының Әсән авылында яшәүче әти-әнисе килеп кергән. Таһир Исмәгыйлович, әлбәттә, каршы килмәде.

Ачыклап әйткәндә, тугызынчы сыйныфны тәмамлаган өрлектәй яшүсмер егет ат җигүле ургычта эшләгәндә, ару-талчыгу аркасында егылып, сул беләген ургыч пычагына кистергән. Сөяккә тимәгәнлектән, җәрәхәт тиз төзәлергә тиеш булган. Әмма табиблар квалификацияле ярдәм күрсәтмәүләре һәм операция ясамыйча авыруны озак караусыз калдырулары аркасында, яшь егет гангренадан һәм хастаханәдә ятканда эләктергән үпкә чиреннән үлгән. Гаепләрен яшереп калдырырга тырышып, хирурглар авыру турындагы язманы яңабаштан тудырганнар.

Бу эшнең очына чыгу һәм дөреслекне табу өчен шул чакта без фәкыйрегезгә сиксәнгә якын кеше белән очрашырга, кат-кат Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бәйләнешкә керергә, хәтта Бәләбәйдән суд-медицина эксперты китертеп, егетнең

мәетен кабердән казытып алдыруга кадәр барып җитәргә туры килде. Нәтиҗәдә егетнең вакытсыз үлеменә бары табибларның гына гаепле булулары ачыкланды. Газетада минем «Ул яшәргә тиеш иде!» дигән зур мәкаләм басылып чыкты. Үзләренең профессиональ бурычларын үтәмәгәннәре һәм фальсификациягә барып, акланырга тырышканнары өчен хирурглар тиешле һәм каты җәзаларын алдылар.

***

1965 елны Уфага университетта лекцияләр укырга студент чагымдагы диплом җитәкчем һәм остазым профессор Хатип ага Госман килеп чыкты. Бик яхшы хәтеремдә: заманында безгә ул, рус шигырь теориясенә ияреп, татарның төп традицион шигырь төзелеше руслардагы кебек силлабо-тоник, ягъни басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә чиратлашуына нигезләнә, дип өйрәткән иде. Без студент фәкыйрегез исә диплом эшебездә – шайтан котырткандыр инде – курыкмыйча, җитәкчебез белән бәхәскә кереп, аның версия-карашына каршы чыктык, телебездә басымнарның чагыштырмача зәгыйфь булуы аркасында, татар шигыре басымнарның эзлекле тәртиптә килүенә корылмый, ә юлларда иҗекләрнең үзара тигез санда килүен үз итүче силлабик төзелешкә нигезләнә, дигән караш үткәрдек һәм шуны төрле яктан килеп исбатладык. Оппонентларымнан шигырь белгече, телче Хәлиф Корбатов һәм шагыйрь Зәет Мәҗитов: «Хатип ага, шәкертегез сезне уздырган бит. Аның тикшерү нәтиҗәләре безне ышандыра», – дип, шул чакта мине бертавыштан яклап чыктылар. Соңыннан Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Татар шигыре» (1965) дигән китабында җитәкчемнең баштагы фикереннән ваз кичеп, без яклаган эзгә кайтып төшкәнлеге билгеле булды.

Күрәсең, бәлки үзе кебек үк шигырь төзелеше белән кызыксынуым һәм аерым мәкаләләремдә, шул исәптән «Кызыл Татарстан»да басылган «Шигъриятнең тәмен тирән тоябызмы?» дигән язмамда да шул ук мәсьәләне махсус кузгатуым сәбәп булгандыр инде, безнең редакция коллективы белән очрашырга килгәч, Хатип ага мине аспирантурага чакырды. Журналистлык чорымда да күңелем белән фән дөньясына һәм туган ягыма тартылып яшәгәнгә күрә, әлбәттә, мин хатыным белән киңәшеп һәм мәктәпкәчә яшьтәге ике баламны карашырга сеңлесе киләчәген, өстәвенә, әти-әнисе дә ярдәм итәчәген истә тотып, тәвәккәлләргә булдым. Шулай итеп, киләчәктә Казанга күчәрбез дигән ният белән, 33 яшемдә мин гаиләмне вакытлыча Уфада калдырып, ун ел элек үзем тәмамлаган Alma materra – бу юлы инде фән белән шөгыльләнергә дип килдем. Бу факт, билгеле, көнче бер түрәнең, Марсель Бакиров фәнгә шактый соң – 40 яшеннән соң гына килде дип, фән дөньясына аяк басуымны шактый «картайтып» күрсәтергә тырышуыннан шактый аерыла.

Әлбәттә инде, «Кызыл таң» мохитендә тәрбияләнеп һәм журналистика мәктәбен үтеп, фән дөньясына һәм профессиональ иҗат белән шөгыльләнүгә күчкән хезмәткәрләр бер мин генә түгел. Фән докторлары булып киткән, ә кайберләре параллель рәвештә әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән коллегаларым Радик Сибгатов, Суфиян Поварисов, Илдар Низамов – әнә шундыйлардан. Мондый күчеш һәм күзгә бәрелеп торган үзгәрешнең, миңа калса, җитди сәбәбе бар кебек. Аерым чыгармаларны исәпкә алмаганда, профессиональ галим һәм язучының тулы канлы иҗат гомере, профессиональ журналистның актив иҗат белән шөгыльләнгән чоры белән чагыштырганда, шактый озынрак һәм озаграк булып тоела миңа. Белмим, бәлки, мин ялгышамдыр. Әгәр шулай икән, төзәтсеннәр мине. Ләкин, ничек кенә булмасын, мондый шәхесләргә яңа өлкәдә уңышлы сикереш ясарга нәкъ менә журналистика мәктәбенең көчле йогынты ясаганлыгы шиксез.



*1972 елда кандидатлык диссертациясен яклау вакытында һәм яклау шатлыгын уртаклашуда катнашкан ил агалары белән. Сулдан уңга: диссертантның хатыны Кифая, Марсель Бакиров, Хәсән Туфан, Бакый Урманче, Диләрә Тумашева.*

## Казаным – мәркәзем кочагында

Аспирантурада ике ел вакытым кандидатлык имтиханнарына әзерләнү һәм тапшыруга китте. Философия һәм төп предметны – татар әдәбиятын чагыштырмача җиңел тапшырдым. Ә инглиз теле «кәҗә майлары»н чыгарды: озын-озын текстларны русчага тәрҗемә итеп, төнге икеләргә кадәр утыра идем. Чөнки хәрефкә ябышып ятучы, һәрбер сүзнең дөрес укылышын, сүзмә-сүз тәрҗемәсен таләп итүче үтә кырыс укытучыга эләктем. Шулай интеккәнгә күрәдер инде, фикерләремне англосакслар телендә шактый ук сукалый башлаган идем сыман. Кабызып, искә төшереп тормаганлыктан, күпчелек сүзләрнең мәгънәләре акрынлап онытылып бетте.

Уфада калган гаиләм белән даими бәйләнештә булдым. 85 сум күләмендә ала торган стипендиямнең ай саен 40-45 сумын өйгә җибәреп тордым. Бала чакта азга риза булып, талымламыйча яшәргә күнеккәнлектән, итле ризыклардан баш тартырга туры килде. Гаиләмнән вакытында хат-хәбәр алып тору минем өчен һәртөрле көйсезлекләрне баса торган үзенә бер азык иде.

Хатип ага язылачак диссертациямнең темасы итеп «Эксперименталь тикшерүләр яктылыгында төрки һәм татар шигырь төзелеше закончалыклары» дигән үтә катлаулы һәм яңгырашлы тема бирде. Аның катлаулылыгы фонетик лабораториядә башкарылачак фәнни тикшеренүләрнең осциллограф дигән махсус аппаратлар ярдәмендә эш итү белән бәйле булуында иде. Эш шунда ки, уйгур галиме Мурат Хамраев докторлык диссертациясенә нигез булган «Основы тюркского стихосложения» дигән монографиясендә «гаруз шигырь төзелеше – төрки шигърият өчен ят, ул төрки телләрдәге әдәбиятка ислам дине белән ясалма рәвештә кертелгән» дигән тамырдан ялгыш караш үткәреп чыкты.

Шигырь төзелеше ул арба артына тагылып йөри торган дегет чиләге хәлендәге вакытлыча, ягъни кирәк булганда гына файдалана торган ни-нәрсә түгел. Төрки телле поэзиядә Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» («Бәхет гыйлеме») поэмасыннан ук (XI йөз) башлангыч ала торган бу система төрки классик шагыйрьләр иҗатында 900 ел буена кулланылып килгән. Димәк, музыкаль-метрик характердагы гарәп гарузы йогынтысы төрки гарузның формалашуы һәм табигый рәвештә яшәве өчен

уңай җирлек булган. Менә шушы хәлне, ягъни гарәп-фарсы телләренә һәм гаруз шигъриятенә хас аерым сыйфатларның төрки гарузына да хасмы икәнлеген махсус аппаратлар белән тикшереп ачыклауны, алда әйтелгәнчә, Хатип ага безгә йөкләде.

Тикшерү нәтиҗәләре, әлбәттә, гаҗәп кызыклы булып чыкты. График яктан гаруз үлчәмендә иҗат ителгән һәм гаруз таләбе буенча ярым көйләп, өзеп-өзеп укылган татар шигырьләрендә дә озын һәм кыска иҗекләрнең, чыннан да, тиешле озынлыкларда чиратлашып килүе исбатланды. Бер уңайдан мондый шигырьләрне гаруз таләбенчә әлеге методика белән укыганда һәр «стопа»-афаилнең беренче яки икенче иҗегендә (–́ ∪ – –, ∪ –́ – –) музыкаль басымнар калкып чыкканлыгы ачыкланды. (Мәсәлән, Тукай шигырьләрен шулай укыганда: «Тата́р бит мин, үзе́м дә чын тата́рмын»; «И́ туган тел, и́ матур тел, ә́ткәм-әнкәмнең теле»). Һәм иң мөһиме: еш кына сүз басымнары белән тәңгәл килми торган мондый басымнарга корылган мелодиканың гаруз ритмының саклануына өстәмә куәт бирүе билгеле булды.

Әмма диссертация текстын кафедрада тикшергәндә, фәнни җитәкчем белән диплом эшемне яклагандагы кебек фикер каршылыгы килеп чыкты. Билгеле, Хатип ага телебездә озын һәм кыска иҗекләр чиратлашуына корылган, гаруз шигырь төзелеше барлыкка килүе өчен уңай алшартлар булганлыгын исбатлый торган безнең тикшерүләрне бик хуплап каршылады. Шул ук вакытта ул төрки гарузның гарәп-фарсыларда эшләнгән гаруз теориясе һәм бигрәк тә фарсы поэзиясе йогынтысында формалашканлыгын кискен рәвештә инкарь итү юлына басты. Мәдрәсәләрдә укытылган «гыйльме гаруз» турындагы теоретик хезмәтләрнең һәм өйрәтүләрнең асылда беренче башлап гарәпләрдә эшләнгәнлегенә күз йомып һәм «йогынты – читтән, җирлек – үзебездән» дигән безнең мәсләкне кире кагып, ул «төрки гарузны төрки халыклар үзләре тудырган», дигән үтә берьяклы ялгыш караш тарафдары булып чыгыш ясады. Хәтта аны традицион аталышыннан үзгә исем белән – «ачык иҗекле шигырь» дип атады. Моның төп сәбәбе, һичшиксез, атеизм идеологиясе хөкем сөргән совет чорында ислам динен киң дөньяга тараткан гарәпләр мирасыннан һәм ислам культурасыннан читтәрәк торырга һәм ике арадагы традицион элемтәләрне танымаска, урап үтәргә тырышу белән бәйле иде.

Фәнни җитәкчем хезмәтемне тикшергәндә, кат-кат әйләнеп кайта-кайта, мине дә шул үзе яклаган сәяси-субъектив кысага кертергә тырышты. Тәнәфескә, бераз хәл алып керергә чыккач, Мөхәммәт Мәһдиев белән Зәет Мәҗитов: «Синең нәтиҗәләрең дөрес, үзең ишетеп тордың, без синең яклы. Карашыңны үзгәртмә, нык тор», – дип дәртләндереп, миңа теләктәшлек белдерделәр. Мөхәммәт Сөнгатович тикшерү вакытында хәтта: «Мин музыкаль ноталарга кадәр төшерелгән эшне беренче тапкыр күрәм. «Мировой» хезмәт бу», – дигән иде. Вафат булганчы якын кешем, фикердәшем булган, Хатип ага белән дә дустанә мөнәсәбәт саклаган Нил Юзиев та, кафедрада ясаган төпле анализына өстәп, гарәп-фарсылар йогынтысыннан баш тартырга ярамаганлыгын искәртте.

Кафедра утырышында үз юнәлешен үткәрү барып чыкмагач, карашымны үзәрттерү өчен Хатип ага көтмәгәндә икенче төрле адым ясады: авторефератыңны мин кушканча төзәтмәсәң, кул куймыйм, дип кырт кисте. Хәтәр кисәтү иде бу. Җитәкченең кулы куелмаса, автореферат басылмаячак. Димәк, яклау да булмаячак!

Мин бу яңалыкны кафедра әгъзаларына җиткерергә булдым. 30 нчы елларның «сәяси иләге»ннән котылып калган һәм хәзер дә Алласыз идеология шартларында, ул-бу булмагае дип, як-ягына каранып яшәгән ошбу дәрәҗәле агабызның холкын-психологиясен шактый дөрес чамалаган Мөхәммәт миңа шул чакта акыллы киңәш

бирде: «Син аны, кул куймасагыз, обкомга барам, Хатип ага, дип куркыт. Шыр җибәрер – шундук кул куяр», – диде ышанычлы тавыш белән.

Мин шулай эшләдем дә. Башта, җөрьәт итеп, җитәкчемә фәнни даирәдә йөри һәм бәхәскә урын калдырмый торган фикерне әйттем. «Укучы җитәкчесен генә кабатласа, яңалык алып килмәсә, үсеш булмый, диләр бит, Хатип ага», – дип ычкындырдым. Һәм сүземне куәтләп: «Әнә, Муса Җәлил иҗаты буенча атаклы Мәскәү галиме Леонид Тимофеев җитәкчелегендә диссертация яклаган Воздвиженский – ул Г.Ибраһимов исемендәге институтның фәнни хезмәткәре иде – үзенең яңа басылып чыккан китабында, килешмичә, фәнни җитәкчесенең ялгыш фикеренә карата тәнкыйди фикерен белдергән. Ә китапка мөхәррир булган фәнни җитәкчесе, белә торып, шул фикернең дөньяга чыгуына юл куйган», – дидем.

Хатип аганың иренен тешләп эндәшми торуын һәм һаман ризалашмаска җыенуын күреп, Мөхәммәт Сөнгатович өйрәткән «бомба»ны ыргыттым:

– Кул куймасагыз, мин обкомга барам...

Шуннан соң нәрсә булганлыгы аңлашыла торгандыр. Автореферат басылып чykканнан соң, фәнни даирә диссертацион хезмәтемне дәррәү рәвештә хуплап каршы алды. Башкортстан Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан эшемә бирелгән тышкы бәяләмәдә: «Хезмәт үзәк проблемага төрле яклап килүе, оригиналь ачышлары белән кандидатлык диссертациясенә куела торган таләпләрне нык узып китә», дип ассызыкланган иде. Беренче оппонентым Гали Халит исә үзенең бәяләмәсендә:«Кандидатлык диссертациясе өчен хезмәтнең тел һәм шигырь мөнәсәбәтләрен өйрәнүгә багышланган беренче бүлеге дә җиткән булыр иде. Ләкин бу һич тә хезмәтнең калган өлеше артык дигән сүз түгел», дигән карашын белдерде. Янә килеп, Ленинград университеты профессоры, гарәп-фарсы телләре белгече Габдрахман ага Таһирҗанов эшемә бәя биреп, факультетка җибәргән тексты аша: «Автореферат буенча фикер йөрткәндә, хезмәт докторлык дәрәҗәсенә лаеклы», дип язылган һәм башкаларның карашы белән аваздаш булган фикерен җиткерде.

Менә шуннан соң кафедрада ошбу хезмәтне докторлык диссертациясе итеп яклатырга кирәкмиме икән, дигән мәсьәлә кузгалды. Әлеге уңай белән Хатип ага: «Әгәр шулай эшләргә булсак, үтенечебезне аңлатып һәм рәсми ризалыкларын сорап, Мәскәүгә – ВАКка («Высшая аттестационная комиссия») хат белән мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу хәл үзеннән-үзе яклау вакытының шактый озакка кичектерелүенә китерәчәк», – дип, алда нәрсә көткәнлеген ачып салды. Мин, кырт кисеп, әлеге вариантка каршы икәнемне әйттем. «Насыйп булса, докторлык хезмәтемне киләчәктә эшләрмен», – дип, үземнең карашымны белдердем.

Диссертацияне яклау тарих-филология факультетының махсус советы утырышында тиешле югарылыкта үтте. Залда яклау барышын тыңлап утыручылар арасында – мөгаен, Хатип ага дәшүе буенча килгәннәрдер инде – татарның олпат затларыннан Хәсән Туфан, Мөхәммәт Гайнуллин, Бакый Урманче, Гази Кашшаф та бар иде. Соңыннан алар шатлыгымны уртаклашу мәҗлесендә дә катнаштылар һәм нотыкларында хезмәтемне хуплап сөйләделәр.

Киләчәктә әдәбият һәм шигърият өлкәсендә яңа хезмәтләр тудырачагыма өмет баглаган Хатип ага мине үз кафедрасында калдырырга булды. Өстәмә урын юллап, кече фәнни хезмәткәр вазифасында эшкә урнаштырды. Алда мин студент чакта язган диплом эшем хуплангач, җитәкчемнең соңыннан без яклаган эзгә кайтып төшкәнлеген

искәрткән идем инде. Диссертацион эшем фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан алкышлап каршыланганнан соң да шундый ук хәл кабатланды. 1973 елда нәшер ителгән «Шигырь төзелеше» дигән яңа китабында Хатип ага баштагы карашын үзгәртте. Ягъни без яклаган мәсләкне – төрки гаруз формалашуга гарәп-фарсыларның йогынты ясаганлыгын танырга мәҗбүр булды. Шул ук вакытта аерым төрки халыкларда (үзбәкләр, азәрбайҗаннар, уйгурлар, татарлар һәм өлешчә башкортларда) гаруз шигырь төзелешен үзләштерү өчен уңай һәм охшаш алшартлар булганлыгын ачу юнәлешендәге аның үз табышларын да, һичшиксез, танырга кирәк.

Әлбәттә инде, университетның татар әдәбияты кафедрасындагы уку-укыту өлкәсенә мөнәсәбәтле хезмәт юлымны мин төрки-татар шигырь төзелеше буенча махсус курс укытудан башладым. Әмма тора-бара мин, шигырь төзелеше белән генә канәгатьләнмичә, студентларны шигырьнең идея һәм поэтик эшләнешенә үтеп керергә, ягъни шигъри әсәрне авторның иҗат стиленә, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләренә бәйләп аңларга өйрәтүгә аеруча зур игътибар бирә башладым. Мондый типта укытуның булачак укытучыларга һәм каләм тибрәтүчеләргә, шулай ук культура-сәнгать өлкәсендә эшләячәк яшьләргә гамәли файдасы турында сүз озайтып торуның кирәге юктыр. Белүебезчә, студентлар курс яки диплом эше яклаганда үзләре өйрәнгән шагыйрьнең әсәрләрендәге эпитет-метафораларга һәм чагыштыруларга, кагыйдә буларак, тукталмыйча калмый. Шунда син алардан: «Мондый сурәтләү чаралары бөтен шагыйрьдә дә бар бит, сез санаганнарның аермасы, гомумән, сез өйрәнгән шагыйрьнең сурәтләү үзенчәлеге нәрсәдә соң?» – дип сорасаң, күпләр, җавап таба алмыйча, югалып кала. Ошбу фактлар үзләре генә дә шигъри сүзнең эстетик куәтен һәм шагыйрьнең үзенә генә хас тавышын танып белү юнәлешендә кат-кат тулыландырылган һәм камилләштерелгән махсус курсымның файдалы булганлыгын раслап тора.

Әмма вуз педагогы һәм лектор буларак, минем үсүем һәм җитлегүем тора-бара бер-бер артлы «Әдәбият белеменә кереш», «Әдәбият теориясе» һәм бигрәк тә «Татар фольклоры» дигән күләмле үзәк курсларны үзләштерү һәм шуларны, рухланып, күп еллар буена укыту белән бәйле.

*(Ахыры киләсе санда.)*

# АК ЧӘЧӘКЛӘР КЕБЕК...

## ЯЗУЧЫ АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ



Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты диюгә, күңелгә «Ак чәчәкләр» җырының сүзләре килә. Гәрчә, язучы әдәбият мәйданына «Соңгы өмет» хикәясе белән килеп керсә дә. Автор әсәрен үзәк өзгеч җырдан башлап китә:

*«Баш куям тезләреңә лә,*
*Яшь коям эзләреңә».*

Беренче җөмләнең, башлап китүнең проза өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын Айгөл Әхмәтгалиева бик нечкә тоемлый. Җырның бәгырьгә үтеп керә торган сүзләре белән укучы дикъкатен җәлеп итә дә бүгенге авыл тормышының гыйбрәтле күренешләрен нечкә психологик алымнар һәм төгәл тотып алынган детальләр ярдәмендә тасвирлый. Язучының теле матур, сыгылмалы, образлы.

«Соңгы өмет» хикәясенең тәмамлануы дә тетрәндергеч: «Гөнаһлы бәндәләрнең күбәюеннән әрнеп, җир елый идеме, әллә күкләр Шәмсенур әбине шулай күз яшьләре түгеп, соңгы юлга озаталар идеме – аңламассың. Чөнки адәм балаларының берсе дә еламый иде». *(«Казан утлары», 2002, №2, 128 бит.)*

Язучы чынбарлыгыбызга үтеп кергән ямьсез гадәтләрнең, гөнаһлы гамәлләрнең артуына борчыла. Әле кайчан гына авыл татарның бишеге, теле, традицияләре саклану урыны дип санала иде. Автор соңгы җөмләсе белән кешеләрнең иманга килүенә өмет бирми, «кешеләрнең берсе дә еламый».

А.Әхмәтгалиева җәмгыятьтәге рухи, әхлакый кыйммәтләрнең җуелуы өчен борчыла. Тормышның матди ягы яхшыра барган саен, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәт, ихласлык, ярдәмләшү сыйфатларының кимү сәбәпләренә җавап эзли.

А.Әхмәтгалиева – беренче чиратта хикәяче. Әдәбиятның әлеге катлаулы төрендә – прозада – үзен иркен хис итә. Күпсанлы әсәрләрендә чынбарлыкның катлаулы, каршылыклы мәсьәләләрен калкытып куя, шулар эчендә замандашыбызның уй-кичерешләрен, теләк-омтылышларын ача.

Язучының беренче китабы – балалар өчен язылган «Болытта җиләк үсә» (2008). Китап 9 хикәяне үз эченә алган. Балалар өчен язуның ни дәрәҗәдә җаваплы икәнен автор тоя һәм аңлаешлы, матур тел белән, һәр күренешне ихлас итеп тасвирлый.

«Бакчага әтиләр бәйрәменә әнисе барды. Төсле кәгазьдән ясалган бүләкне бүтәннәр әтиләренә тапшырды, Айдар әнисенә бирде» *(«Егет кеше», 14 б.)*. Яралы йөрәктә ни барын ничек сизәргә дә, аңа ничек ярдәм итәргә?! Олылар алдына куелган җитди сорау бу.

Язучы авылның табигатен белеп, яратып тасвирлый, укучының игътибарын күренешләргә юнәлтә.

«Үләнгә яткач, болытлар гел миңа таба йөзгән кебек күренә икән. Авылга кайтмасам, аларның шундый ак, мендәр кебек кабарынкы булуларын күрмәс идем әле менә. Мамык кебек йомшактыр, яңа сауган сөт кебек җылыдыр алар. Шуларның өстенә утырып, аякларны салындырып, безнең шәһәр өстеннән очып кайтырга иде» *(«Болытта җиләк үсә», 35 бит)*.

Язучының «Өч тәңкә» исемле хикәясе *(«Синең өчен яшим», 2011, 167 б.)* күләме белән зур да түгел. Хикәядә барыбызның да йөрәген әрнеткән балалар ятимлеге, аларның елдан-ел арта баруы сурәтләнә. Үзенең психологик тирәнлеге, геройларның эчке дөньясын, кичерешләрен сәнгатьчә тәэсирле чаралар белән ачып бирүе ягыннан ул повестька тиңләшерлек.

Төркиядә узган М.Кашгарый исемендәге халыкара бәйгедә икенче урынны алган «Капка» хикәясенең төп мотивлары – дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәүче татарлар тормышы, катнаш гаилә, «әти» сүзен дә татарча әйтергә теләмәгән бала. Бүген дә актуаль теманы яктыртуы, геройларның эчке кичерешләрен бирә белүе белән автор откандыр да. «Капка» хикәясе, язучының оста драматург та булуын күрсәтеп, Яр Чаллы һәм Оренбург театрлары тарафыннан сәхнәләштереп, үзенең тамашачысын тапты. 2023 елның 15 февралендә А.Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы театры бу пьесаны казанлыларга да тәкъдим итте.

«Балам-багалмам» хикәясендә наркоман оныгы тарафыннан үтерелгән Сания әби фаҗигасен «Кем ул?», «Өзелгән гөл» әсәрләрендә дә автор геройларының эчке дөньясын, үкенү, сызлануларын тетрәнерлек итеп тасвирлый.

Әдибәнең иҗатына бәя биргән әдәбият галиме, тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗановның фикерләре белән килешми мөмкин түгел. «А.Әхмәтгалиеваның сурәтле дөньясы турында сүз алып барганда, әсәрләрнең тел-стиленә игътибар итми мөмкин түгел. Актаныш ягының ягымлы сөйләменә нигезләнгән тел бай аһәңле, урыны белән сыгылмалы, кирәк урында кырыс яисә күп бизәкле. Урынлы кулланылган диалекталь сүзләр, вакыйга-күренешләрне бөтен тулылыгында күз алдына бастырырга ярдәм иткән сурәтләр әсәрләрдән синең күңелеңә күчә, озак вакыт озатып бара». *(«Мәйдан», 2013. «Өмет хисе сүнмәсен» мәкаләсе)*

Яшүсмерләр өчен язылган «Мин гашыйк булдым» китабы үз эченә «Минем әтинең кызы» повестен һәм җиде хикәяне үз эченә алган. Аларда яшүсмер малайлар һәм кызларның катлаулы, шул ук вакытта якты хыяллар белән сугарылган күңел дөньясы чагыла. Әсәрләр белән танышкач, тормыш матурлыгына, гашыйк булып яшәүнең, күңел аклыгы һәм кичерә белүнең бәхеткә илтә торган якты юл булуына ышанасың. Әтиләре исән булып та, төрле сәбәпләр аркасында ятим үсәргә мәҗбүр ителгәннәрнең язмышына битараф түгеллеген тагын бер кат раслый автор.

«Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» китаплары бер-бер артлы дөнья күрде.

А.Әхмәтгалиеваның «Бәллүр богау» повесте иҗат кешеләре, театр сәнгатенә хезмәт итүчеләр тормышының бер сәхифәсен ачуы белән игътибарны җәлеп итә. Кеше психологиясен ачуда, күңел кичерешләрен барлауда автор яңа алымнарга омтыла. Вакыйгалар өч катламда барып, Фаягөл әбинең хәзерге уйланулары белән үткән гомер юлын хатирә буларак күз алдына бастыруда чагыла һәм моңа оныгы Азаматның артист буларак, үзен эзләве, борчулы-икеләнүле уйлары килеп кушыла. Фаягөлнең артистлык тормышы ил-халык тарихыннан аерылгысыз. Башкаладан читтәге Актау халык театрын оештыру, ачлы-туклы хәлдә төрле михнәтләр аша туган халкыңа хезмәт итү сурәтләнгән урыннар татар халык театрлары тарихы буларак кузаллана.

«Тузганак керфеге» повесте Гөлсәйдә карчыкның туган авылы Усайга канакка кайтуы белән башлана. Реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган әсәр икәнлеген искәртеп, автор «авылдашым Гөлфәгыйдә апа Юлышевага багышлыйм» дип язган. Колхозлашу еллары, Бөек Ватан сугышы, аннан соңгы татар авылы, аның эшсөяр кешеләрен автор ятатып яза.

«Ул балта белән кизәнгән саен, һәр күзәнәгендә яшәү суты әкренләп кибә барды. Мин толым очларының җиргә якынаюын тоям, әле генә җил кочагында иркәләнеп назланган гәүдәм авыртудан түгел, тамырларымнан аерылуның котылгысыз икәнлеген аңлаудан суырыла, сызлана, куырыла. *(«Таллыкүлдә былбыл бар», 5 бит)*. Повесть әнә шулай башлана. «Тамырларымнан аерылуны» авыр кичергән каен агачы образы аша автор, төп герой – Шамилнең, әтисенең авылны онытуларын, иң якын кешеләренең каберләрен дә белмәүләрен, шул фаҗигане бик соңлап кына аңлауларын тасвирлый.

«Үткәннәреңне барла. Ашыгасың, тукталып уйланырга бер генә минут та вакытың юк, шулаймы? Тик син минем яныма киләчәксең, барыбер киләчәксең бит!» *(Шунда ук. – 6 бит)*

Әсәрдәге вакыйгалар нәкъ «каен әйткәнчә» бара да инде.

Тормыш тоташ көрәштән һәм сынаулардан тора. Югалту һәм табыш белән дә сыный ул, мәхәббәт һәм хыянәт белән дә, бәхет һәм бәхетсезлек белән дә... Ничек кенә булса да, ак күңелле, якты күңелле Кеше булып каласы иде. Китапларга тупланган повесть һәм хикәяләрдә әнә шул теләк чагыла.

Мәхәббәт, тугрылык, сабырлык турында язылган әсәрләр бик күп. Айгөл Әхмәтгалиеваның «Ак читек» повестенда Нургаян белән Зәйтүнәнең мәхәббәте тасвирлана. Яратып өйләнешкән, беренче уллары туган гаиләгә бәла килә – Зәйтүнәнең аркасына погрузчик авып, яшь хатын аяксыз кала. Автор уйлап чыгарган да, идеаллаштырып бирергә тырышкан әдәби геройлар түгел алар.

Автор Зәйтүнәнең матурлыгын сокланырлык итеп тасвирлый. Язмыш сынавында ире аңа зур терәк, таяныч була. Аның чын ир-атларга хас түземлеге, ныклыгы гаилә бәхетен саклап калырга ярдәм итә. Вакыйгаларның тормыш чынбарлыгына таянып язылганын Айгөл Әхмәтгалиева очрашуларда еш кабатлый. «Ак читек» повестена бәя биреп, уңай якларын күрсәтеп, тәнкыйтьче Дания Заһидуллина болай дип яза: «Әкиятләрдәгечә уңай һәм тискәрегә аерылган геройлар, шушы ак һәм карага бүлеп бәяләнгән дөнья схематик тоела» *(«КУ», №3, 2018)*. Әмма геройларның чын тормышын якыннан белгән укучылар бу бәя белән килештеләр микән?

«Кичке таң» повесте (2020) киң катлау укучыларга исәпләнгән. Асылда, повесть мәхәббәт, кешеләргән ярдәм итеп яшәү, мәрхәмәтлелек хакында. Әсәрнең Айгөлнеке икәнен белдерә торган бер үзенчәлек – ул дин фәлсәфәсе. Аның әсәрләрендә Аллаһка ышану, иман ныклыгы хакында еш чагыла. Бу повестька да автор эпиграф итеп «Аллаһка кайта торган көннән куркыгыз» дигән «Бәкара» сүрәсенең 281 нче аятен китерә. Әсәр дәвамында дин фәлсәфәсен укучыга җиткерү төп герой Тимур Айдарович образы аша башкарыла. Автор табиблар хезмәтен үзәккә куя, повестьның икенче эпиграфы аның реаль нигезе булуга ишарә ясый. Язучының үз геройларының эчке дөньясын, фикер-кичерешләр агышын тасвирлый белү сәләте сокланырлык. Иң яшерен, иң нечкә тойгылар да, рухи халәт-омтылышлар да чигү чиккәндәй, ак кәгазьгә төшерелә. Повестьның чын мәгънәсендә безгә булган гаять матур табигать сурәтләренең кеше күңеленә аваздаш тасвирлануы да психологизмны тирәнәйтү чарасына әверелә.

Үзе дә тынгысыз иҗат кешесе булгангамы, Айгөл Әхмәтгалиева шактый гына күләмле әсәрләрен мәшһүр шәхесләргә багышлаган. «Дулкыннар» (Фарсель Зыятдинов), «Хәния» (Хәния Фәрхи), «Без барабыз, ул килмәс» (көрәшче Фәйзелхак Әхмәтҗанов) повесте әнә шундыйлардан.

«Туташ» романы татар театрына нигез салучыларның берсе, беренче хатын-кыз артистка Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның бәхетле дә, фаҗигале дә язмышын чагылдыра. Роман бер гасырны диярлек колачлый. Ил, милләт тарихына тәэсир иткән вакыйгаларны үз эченә сыйдырган. Россиядәге революцияләр, гражданнар сугышы, шәхес культы, Бөек Ватан сугышы һ.б. вакыйгаларны сурәтләгән картина буларак кабул ителә. Урын да киң: Казан, Оренбург, Уфа, Ижау...

Әсәрнең кереш өлешендә автор безне Сәхибҗамал белән гадәти булмаган шартларда таныштыра. Чистайда урнашкан психоневрологик диспансерга яңа авыру карчык китерәләр. Шул минуттан укучыны бер сорау борчый башлый: ни өчен, ни рәвешле ул бирегә килеп эләкте соң?

Айгөл Әхмәтгалиева героиняның эчке халәтен күрсәтүдә матур алымнар тапкан. Укучы, үзе дә сизмәстән, Сәхибҗамал белән бер мохиттә яши, күпме юллар үтә, күпме вакыйгалар эчендә кайный, шул чорның алдынгы карашлы кешеләре белән очраша. Автор бит үзе дә шул юллардан йөргән, күпме әдәбият өйрәнгән, архивларда булган, кемнәр белән генә очрашмаган! Әсәр гаҗәеп зур хезмәт нәтиҗәсендә барлыкка килгән. «Туташ» романы белән Айгөл Әхмәтгалиева олы драматик характерлар тудырырга да, татар халкы тарихын колачлап бәяләргә дә сәләтле булуын күрсәтте.

Проза жанры белән беррәттән, Айгөл Әхмәтгалиева каләмен пьесалар, сценарийлар, шигырьләр язып та чарлый. «Сагынган чакларымда» (2018) китабына 7 пьеса кертелгән («Ул бит кичә иде», «Күз нурларым», «Сагынган чакларымда», «Баш куям тезләреңә», «Бәхет агачы», «Түгәрәкнең чите юк» «Ачкыч кайда?»). Алар Яр Чаллы, Уфа, Оренбург, Казанның Г.Кариев исемендәге театрларында куелып («Яратып туялмадым»), тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде.

Айгөл Әхмәтгалиева сценарийлары нигезендә төшерелгән телевизион фильмнар (режиссёры Нурания Җамали) экраннарда еш күрсәтелә.

Габдрахман Әпсәләмов әсәре буенча куелган «Ак чәчәкләр» фильмы һәм анда яңгыраган җырлар күпләрнең күңелен яулады. «Җылы эзли җаннар», «Синең күзләр», «Мәхәббәт хакына» – барысы да кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, мәхәббәтне, кешелеклелек сыйфатларын тасвирлый, яхшылык җиңәчәгенә ышануга этәрә.


Язучы, драматург, журналист Айгөл Әхмәтгалиева иҗатының төп үзенчәлеген билгеләгәндә, «Ак чәчәкләр» җырының кушымтасын искә төшерү урынлы булыр.

*«Ак гөлләрдән җан җылысын алып,*
*Йөрәкләргә саласы иде.*
*Ак чәчәкләр кебек ап-ак булып,*
*Саф күңелле каласы иде.»*

Авторның геройлары күп кенә әсәрләрендә нәкъ җырдагыча яши дә.

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА**

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕКЛӘР




Хәзерге вазгыятьтә татар теле өлкәсендә эшләүче белгечләрнең бурычы – җәмгыятьтә телебезгә булган ихтыяҗны күтәрү, аның кулланылышын һәм дөрес кулланылышын тәэмин итү. Эшкәртелгән әдәби тел иң элек сүзлекләрдә туплана һәм саклана. Чуваш белгечләре Николай Ашмарин сүзлеген чуваш телен саклаудагы ролен югары бәялиләр, хәзерге вакытта чуваш теленең ул сүзлек дәрәҗәсендә сакланмавын, телне торгызуда бу сүзлекнең роле зур булуын әйтәләр. Әлбәттә, бүгенге глобальләшү чорында татар теле дә зур югалтулар кичерә. Туган телдә, ана телендә сөйләшү, бигрәк тә яшьләр арасында, хәтта авылларда да кими бара. Телне өйрәнүне гаиләгә йөкләгән чыгышларны еш ишетергә туры килә. Әмма безгә татар теленең өйдә кулланылган сөйләм теле дәрәҗәсендә генә саклануы җитми, аның бай язу традицияләре, гасырлардан килгән эшкәртелгән әдәби формасы бар. Хәзерге вазгыятьтә язу традицияләрен, әдәби телне югалту куркынычы көннән-көн үсә бара. Туган телне тәшкил иткән лексик база телнең формалашу үзенчәлекләрен, шул телне кулланган халыкның тарихын, аның дөньяны танып белүдәге логикасын, цивилизациясе дәрәҗәсен ачып бирә ала, ягъни миллиятнең ачылышы, халыкның рухияте, мәдәнияте, теленең үзенчәлекләре, эшкәртелү дәрәҗәсе, аның сыгылмалылыгы сүзлекләрдә тупланган әдәби телен билгеләгән сүзләре аша чагылыш таба. Аңлатмалы сүзлекләр исә – телдәге башка сүзлекләр арасында иң мөһиме һәм иң кыйммәтлесе. Алар халыкның матди һәм рухи үсеш юнәлешләрен, яшәү рәвешен, мәдәниятлелек дәрәҗәсен, башка халыклар белән икътисади-мәдәни бәйләнешләрен, аның бөтен тарихы барышында тупланган сүзләре аша күрсәтә ала, чөнки тупланган сүзлек хәзинәсе шул телдә сөйләшкән халыкның иҗтимагый эшчәнлеге, яшәеше, аның буыннан-буынга күчә барган тәҗрибәсе белән турыдан-туры үрелеп бара. Сүзлекләр аерым бер фәнни даирә өчен генә түгел, ә киң даирә – татар телендә сөйләшкән, аны камилрәк өйрәнергә теләгән кулланучылар өчен төзелә.

Җәмгыятьтә мондый төр сүзлекләргә ихтыяҗ халыкның тел культурасы билгеле бер дәрәҗәгә ирешкәннән соң гына барлыкка килә ала. Бер яктан, шул телдә сөйләшкән халыкның тел хәзинәсен туплап, аны нормалаштыру зарурияты җитлегергә, ә икенче яктан, телне лексикографик тасвирлау өчен тиешле күләмдә сүз байлыгы тупланып җитешкән булырга тиеш. Милләтнең аңлатмалы сүзлеге төзелгән булу үзе үк аның югары мәдәниятка ия булуын күрсәтә.

Татар лексикографиясендә аңлатмалы сүзлекләр төзү эше шактый бай һәм ерак тарихка ия. Беренче тапкыр татар телендә тулы аңлатмалы сүзлек төзү идеясе Казан университетының гарәп һәм фарсы телләре белгече профессор Франц Эрдман тарафыннан 1829 елда тәкъдим ителгән. Ул үзе аның 12 параграфтан торган программасын эшләгән. Анда сүзләрне бирү тәртибе, кайсы телдән алынуы, сүзләрне сайлап алу принциплары, мәгънәләрне аңлату һәм аларга мисаллар, фразеологизмнар бирү каралган булган. Программада татар сүзләрен рус һәм латин телләренә тәрҗемә итү дә күздә тотылган. Аның бу проекты университет советында тикшерелгән һәм уңай бәя алган, ләкин ул чорда кадрлар җитешмәү сәбәпле, бу идея тормышка аша алмый калган. Хәзерге вакытта Франц Эрдман документлары Казан университетының Н.Лобачевский исемендәге китапханәсендә сирәк китаплар бүлегендә 4391 нче номер белән саклана. Франц Эрдман тарафыннан беренче тапкыр татар теленең тулы лексикасы белән фәнни кызыксыну, аны аңлатмалы сүзлеккә туплап бирү ихтыяҗы барлыгы көн тәртибенә куелган.

Бу зур, җаваплы эшкә, беренче булып, үз чорының алдынгы карашлы фикер иясе, зур галим, мәгърифәтче Каюм Насыйри алынган. Телче буларак ул тел белеме һәм сүзлекләр төзү эшендә шулкадәр күп, катлаулы һәм бик тә әһәмиятле эшләр башкарган ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, ул хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та калмаган. Аның татар теленең сүзлек составын туплап өйрәнүгә багышланган әһәмиятле хезмәтләреннән берсе «Ләһҗәи татари» – татар теленең ике томлык беренче аңлатмалы сүзлеге. Сүзлекнең I томы (226 бит) – 1895 елда, II томы (106 бит) 1896 елда университет типографиясендә басылып чыккан. К. Насыйри – гарәп, фарсы, төрек сүзләре урынына язма телдә татар теленең үз сүзләрен куллану кирәклеген беренче күтәреп чыккан галим. Татар теле эшләнмәгән булуы белән генә йоклаган хәлдә, фикерне тапшыра алуда бер генә телдән дә ким түгел дигән ул (Насыйри, 1974: 33). Фән теле – гарәп телендә, шигърият теле фарсы, госманлы төрек телендә булган чорда, аның язма тел татарның үз теленә нигезләнергә тиеш дигән заманыннан күпкә алдынгы карашлары замандашлары тарафыннан кискен тәнкыйть ителгән, кире кагылган. К. Насыйри төзегән ике томлы «Ләһҗәи татари» – телебезнең бай, куллану мөмкинлегенең киң булуын беренче дәлилләгән сүзлек. Бу сүзлек татар телендә генә түгел, ә бөтен төрки телләр тарихында беренче аңлатмалы сүзлек булуы белән дә әһәмиятле.

XX гасыр башында аңлатмалы сүзлекләр төзү эше яңа бер баскычка күтәрелгән. Ул халык хәтереннән җуйдырылган татар тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият белгече, педагог Җамал Вәлиди исеме белән бәйле.

Җ.Вәлиди җәмгыятьтә барган үзгәрешләр беренче чиратта сөйләм теленә, аның лексик составына тәэсир итүен күрә. Телдәге үзгәрешләр иҗтимагый вакыйгаларга бәйле рәвештә сикерешләр белән үсүен әйтә. 1905, 1917 елгы революцияләр чоры – «мөддәте ягыннан кыска, ләкин мәгънәсе ягыннан зур булган ара» телдә бик күп үзгәрешләр китереп чыгаруын, ә бу үзгәрешләр язма әдәби телдә чуарлык барлыкка килүгә сәбәпче булуын дәлилли. Шул сәбәптән яңа чор әдәби телен нормалаштыру бурычы барлыкка килүен күрә, ә бу эшне татар теленең тулы аңлатмалы сүзлеген

төзүдән башларга кирәклеген әйтә. К.Насыйри сүзлеге төзелгән чорда татар теленә төрек, гарәп, фарсы телләре йогынтысы зур булу сәбәпле, анда алынмаларның күплеген анализлый. Революцияләр чорында язылган өндәмә, прокламация, листовкаларның, газеталарның теле аңлаешлы булсын өчен, гади халык теленә якынаюын, русчадан китерелгән тәрҗемәләр аша телдә рус сүзләре күбәюен, әдәбиятка килгән яңа буын каләм осталарының да күбрәк гади халык телендә язуын күзәтә. Аларны телнең сүзлек составын нык үзгәрткән төп сәбәпләр дип билгели. Кыска вакыт эчендә телнең ике дәвер теленә әверелүен әйтә. «Лөгать китаплары – үзләре язылган дәвернең көзгесе булырга, ягъни шул вакыттагы телне төгәл чагылдырырга тиеш» дип, телдәге үзгәрешләрне эченә алган яңа «Татар теленең тулы сүзлеге»н төзү кирәклеген дәлилли. Шул нигездә сүзлекнең беренче томы 1927, 1929 елларда ике кисәк булып басылып чыга. Җ.Вәлиди татар лексикографиясе тарихында беренче булып сүзлек төзү эшенең фәнни принципларын эшли. Иң элек эшне картотека җыюдан башлап җибәрә. Сүзлекне аңлатмалы итеп төзү әдәби телне нормалаштыруда кулайрак булачагын әйтә. Сүзлекчәне туплаганда, галим биреләчәк сүзләрне лексик һәм грамматик мәгънәләргә бүлеп карауны шарт итеп куя. Җ.Вәлиди бары лексик мәгънәгә ия сүзләр генә сүзлектә теркәлә ала дип басым ясый. Фигыль бирелешенә махсус туктала. Аларның юнәлеш формаларын тулысынча күрсәтеп, төп фигыль аша аңлату кирәклеген әйтә. Кайбер юнәлеш кушымчасы алган фигыльләрнең мөстәкыйль мәгънә белдерүенә игътибар итә. Сүзлектә бу мәгънәләрне аерып күрсәтү кирәклеген әйтә. Аерым мөстәкыйль фигыльләрнең, ярдәмче фигыль функциясенә күчеп, тезмә фигыльләр ясый алу мөмкинлеген дә барлый һәм аларны аерым тел берәмлеге буларак терки.

Күренгәнчә, Җ.Вәлиди бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган зур фәнни хезмәт яза. Ул беренче тапкыр аңлатмалы сүзлекләр төзү принципларын эшли. Бүгенге көндә дә Җ.Вәлиди билгеләгән принциплар аңлатмалы сүзлекләр төзүдә нигез булып кала. Сүзлек, авторның әйтүенчә, 1925 елга китап булу дәрәҗәсенә җитешкән булса да, аның хаксызга репрессияләнүе сәбәпле сүзлек материаллары да кулга алына һәм юкка чыгарыла, икенче том шул рәвешле чыкмыйча эзсез югала.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү эше Җ.Вәлидидән соң бары 1950 елларда гына кабат яңара. Ул чорда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Тел, әдәбият һәм тарих институтында Гаян Сафуанович Әмиров җитәкчелегендә лексикография бүлеге оеша. Аңлатмалы сүзлек төзү буенча Нәкый Исәнбәт, Фазыл Фасеев яңа проектлар тәкъдим итә. 1958 елда, «татар теленең сүз байлыгын тормышның барлык өлкәләреннән дә мөмкин кадәр тулырак җыеп алуны тәэмин итү» максаты белән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык» эшләнә. Аны тел белгече Ф.Фасеев төзи, күренекле тел галиме, профессор Латыйп Җәләй редакцияли. Сораулыкта аңлатмалы сүзлектә тупланырга тиешле сүзләр дүрт тематик төркемгә бүлеп карала: «1. Табигать; 2. Кеше; 3. Җәмгыять; 4. Танып белү һәм фәннәр». Иң беренче максат итеп аңлатмалы сүзлек төзү өчен аеруча мөһим булган картотека базасын туплау эше куела. Бу эшкә җәмәгатьчелек тәртибендә Татарстан, Башкортстан республикалары, Пермь, Ульяновск, Куйбышев өлкәләрендәге татар мәктәпләре укучылары һәм укытучылары, студентлар, тел белән кызыксынган аерым кешеләр тартыла. XIX-XX гасыр татар әдәбияты классикларыннан, иҗтимагый-сәяси әдәбияттан, башка халыкларның күренекле язучыларының тәрҗемә әсәрләреннән, кайбер закон, указлар, мәктәп дәреслекләре, татар телендә язылган сәяси һәм фәнни-популяр хезмәтләрдән, татар халык авыз иҗаты әсәрләреннән иллюстратив материал җыю эше башланып китә. Бу эш 1958

елдан алып 1963 елга кадәр эзлекле дәвам итә. Нәтиҗәдә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел бүлегендә миллионлап сүздән торган картотека базасы туплана. Сүзлекнең инструкциясе 1964 елда басылып чыга. Анда алда төзеләчәк сүзлекнең төп принциплары эшләнә һәм турыдан-туры сүзлек төзү эше башланып китә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең I томы – 1977 елда, II томы –1979 елда, III томы 1981 елда басылып чыга. Ул татар әдәби теленең XIX–XX гасыр эчендә гомумкулланышта булган сүз һәм фразеологик байлыгын туплап бирә. Аны эшләүдә танылган тел галимнәре Искәндәр Абдуллин, Фуат Ганиев, Мөгафә Мөхәммәдиев, Галимҗан Ахунҗанов, Рифкать Әхмәтьянов, Шифа Ханбикова, Камил Сабиров, Солтания Вахитова, Фәтхия Газизова, Лена Гайнановалар катнаша. Сүзлек Ләйлә Мәхмүтова, Мөгафә Мөхәммәдиев, Камил Сабиров редакциясендә дөнья күрә. Үз вакыты өчен саллы, эчтәлеге һәм эшләнеше белән мөкәммәл булган бу аңлатмалы сүзлекнең төзелеп басылып чыгуы гомумтюркология күләмендә татар лексикографиясенең яңа зур уңышы, янә бер югары баскычка күтәрелүенең ачык дәлиле булып тора. Хәзерге вакытта да сүзлек киң кулланышта булуын дәвам итә.

Аңлатмалы сүзлекләрне төзү үзенчәлеге шунда, алар үзләрендә теркәлгән һәр сүзнең мәгънәсен яки мәгънәләрен аңлатып бирү максаты белән эшләнә. Ике яки аннан да артык сүз ярдәмендә ясалган күпсоставлы атамалар (кушма һәм тезмә сүзләр) һәм фразеологизмнар да мондый төр сүзлекләрдә аңлатмалары белән урын ала. Гадәттә, мондый сүзлекләрдә сүзнең кулланылыш даирәсе күрсәтелә, гамәлдәге кагыйдәләр нигезендә һәр тел берәмлегенең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре нормалаштырыла. Алынма сүзләрнең бары тик шул телдә кулланылган мәгънәләре генә китерелә. Күпмәгънәле сүзләрне шәрехләгәндә, аның бөтен семантик кыры исәпкә алына. Мәгънәләрнең бирелеш тәртибе аларның әдәби телдәге кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнә, мәгънәләр арасындагы логик эзлеклелек һәм генетик бәйләнеш мөмкин кадәр сакланырга тырышып урнаштырыла. Конкрет мәгънәләр абстракт мәгънәләрдән алданрак бирелә. Сүзнең күчерелмә мәгънәләре дә туры мәгънәдән соң китерелә. Аерым очракларда, максатка ярашлы рәвештә, әдәбиятта еш очраган диалекталь, борынгы сүзләр, мәгънәне тулырак ачу өчен кайбер сүзләрнең кулланыштан төшеп калган беренчел искергән мәгънәләре күрсәтелә. Әлбәттә, тел ул иксез-чиксез дәрья кебек, аның барлык сүз байлыгын тормышның бөтен өлкәләреннән тулысынча җыеп бетерү мөмкин түгел һәм шул ук вакытта тел туктаусыз үсеш-үзгәрештәге җанлы организм да. Шуңа күрә аңлатмалы сүзлекләр, бер яктан, тулылыкка омтылсалар, икенче яктан, үзеннән-үзе чикләнергә мәҗбүр була, чөнки бу төр сүзлек тел үсешенең аерым бер этабын – үзе төзелгән чорны гына чагылдырырга тиеш.

Соңгы алты томлык аңлатмалы сүзлек җәмгыятьтәге катлаулы мәсьәләләрне күздә тотып төзелгән. Өч томлык аңлатмалы сүзлек фәнни әйләнешкә кереп киткәннән соң, җәмгыятьтә татар тел үсешенә тәэсир итәрлек зур вакыйгалар булып узды. Ул республикадагы тел сәясәте, татар теленең Конституциядә дәүләт теле дип беркетелүе белән башланган иде. 1992 елның 8 июлендә Югары Совет Татарстан телләре турындагы законны раслады. Рус һәм татар телләре Татарстанда дәүләт телләре дип игълан ителде. 1994 елның 20 июнендә бу законны тормышка ашыру юлларын билгеләгән «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы» кабул ителде. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы халыкара мәйданда да, ил күләмендә дә татар халкының активлашуы, бу чорның сәяси-икътисади, иҗтимагый, мәдәни һ.б. күптөрле вакыйгаларга бай булуы, фән-

техниканың сизелерлек алга китүе, милләтебезнең халыкара элемтәләр, багланышлар, үзара аралашуларны шактый нык арттыруы белән аерылып тора. Милли активлыкның көчәюе белән бәйле вазгыять беренче чиратта сөйләм теленә йогынты ясады. Тормышта булган үзгәрешләр иң элек телнең сүзлек составында, аның лексик системасында чагылыш тапты. Тел үз мөмкинлекләре исәбенә дә (мәс., алгарыш, барлама, беркетмә, кертем, колакса, көнүзәк, күчермә, суыткыч, таньк, тукталыш, туңдырма, ышанмалык, эшмәкәр, юллама һ.б.), искергән сүзләрне торгызу (мәс., әдернә, багавыл, байса, даруханә, җепкыр, йот, кизү, салым, тамгаханә һ.б.) һәм диалектизмнар (мәс., аклан, аукан, ашык, әнәчә, әпә, әптәчи, багу, байкау, игәч, converting кактөш, очсыз, пима, рәеш, ырам һ.б.) исәбенә дә баеды. Сүзләрнең кайбер мәгънәләре үзгәрде, йә аерым сүзләрнең мәгънәләре киңәеп (мәс., байтар, бәйге, кавырсын, көндәш, мөнбәр, тугра, шәкерт һ.б.) кулланышка кереп китте, йә кайбер мәгънәләре төшеп калды, кайбер гарәп һәм фарсы сүзләре (мәс., аять, әбәдән, әбәди, әҗнәби, җөмһүрият, иганә, икътисад, рәсүл, сөннәт, табиб, шәкел, шәрех һ.б.) кабат кулланышка кайтты, Европа телләреннән яңа сүзләр (мәс., акция, байкер, байт, бармен, биржа, бонус, ваучер, девальвация, дотация, дивиденд, дилер, ипотека, корпорация, кросс, менеджер, референдум, фермер, фирма һ.б.) керде. Лексик составта яңа сулыштагы зур катлам барлыкка килде. Табигый ки, бу үзгәрешләрне яңа сүзлекләрдә, бигрәк тә аңлатмалы сүзлектә чагылдыру кирәк иде. Бу бурычны үтәү максаты белән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан яңа алты томлык аңлатмалы сүзлек төзелеп, кулланышка тәкъдим ителде. Сүзлекне төзүдә И.И. Сабитова, О.Н.Галимова, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров, А.Ә. Тимерханов, Э.И. Сафина, Г.Г. Саберова, Ф.Ф.Гаффарова, Р.Р Абдуллина, А.М. Сәгыйтова, А.Ф. Гайнетдинова, Ф.М. Газизова, Г.Р. Сәмирханова, Л.Ш. Шәмсетдинова, Ф.А. Кушлекова, Ю.Ф. Борһанова, Г.Д. Фәтхетдинова, И.Җ. Едиханов катнаштылар, сүзлекне редакцияләүне Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров, Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова башкарды.

Соңгы төзелгән алты томлык аңлатмалы сүзлек алдагы өчтомлыктан беренче чиратта үзенең күләме, тупланган лексик берәмлекләрнең, фразеологизмнарның саны белән аерылып тора. Әлеге яңа зур сүзлекнең бурычы хәзерге татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән лексик байлыгын һәм фразеологиясен мөмкин кадәр тулырак туплап чагылдыру; гомуми кулланышта булган сүзләргә, тотрыклы берәмлекләргә, аларның мәгънәләренә, мәгънә төсмерләренә мөмкин кадәр тулы һәм төгәл аңлатмалар бирү; кулланылышка кереп киткән яңа сүзләрне яки сүзләрнең яңа барлыкка килгән мәгънәләрен ачыклау; аларның грамматик табигатен, стилистик төсмерләрен дөрес билгеләү; кулланылыш үзенчәлекләрен барлау; матур әдәбияттан, иҗтимагый-сәяси, публицистик, фәнни-популяр язмалардан, фольклор әсәрләреннән, дәреслекләрдән, вакытлы матбугаттан алынган мисаллар белән дәлилләү билгеләнә.

Алда чыккан аңлатмалы сүзлекләрдән аермалы буларак, алтытомлыкта татар теленең күп составлы лексик берәмлекләре (тезмә сүзләр), компонентлары аерым язылса да, мөмкин кадәр тулырак туплап бирелгән. Алдагы сүзлекләрдә аналитик юл белән ясалган сүзләр беренче сүз принцибы белән баш сүз оясында китерелгән иде, анда да тулысынча түгел, чикләнгән күләмдә генә иде. Ә бу аңлатмалы сүзлектә алар мөстәкыйль тел берәмлеге буларак исәпкә алынган һәм алфавит тәртибендә үз урыннарында китерелгән, чөнки алар баш сүз мәгънәсе белән һич уртаклыгы булмаган өр-яңа төшенчәне атыйлар, үзләре мөстәкыйль лексик берәмлек булып торалар. Төрки телләргә хас булган борынгыдан килгән сүз ясалышының аерым бер төрен билгелиләр. Алар күбесенчә ботаникага (мәс., ак әрем, ат кузгалагы, аю баланы, әби чәче, бабай

баш, бака сакалы, баллы чәчәк, давыл чәчәге, елан көпшәсе, ишәк колагы, каз үләне, камыр агачы, пәри уты, саз җиләге һ.б.), анатомиягә (мәс., балан бармак, баш капкачы, казык теш, күз алмасы, оча сөяге, тез капкачы, сукыр эчәк һ.б.), зоологиягә (мәс., ак аю, баба кош, байгыш күбәләге, гөберле бака, дала мәчесе, диңгез козгыны, елак карчыга, ефәк күбәләге, зәһәр елан, кайры корты, камыш тургае, көяз тургай, кыр тавыгы, тәвә кошы һ.б.), күк җисемнәренә (мәс., Җидегән йолдыз, Иләк йолдыз, Киек Каз Юлы, Тимерказык йолдызы һ.б.), төрле авыруларга (мәс., бума ютәл, бүре уы, көзән җыеру, күкрәк бакасы, күрә карау, тамак бакасы, тамыр чире, тимгелле тиф һ.б.), элекке эш коралларына (мәс., әби кабасы, буй пычкы, гөбе таягы, каба агачы, камыт бавы, көре кылычы, тәкә чана, төрән сабан һ.б.), кул хезмәте белән бәйле эшчәнлеккә (мәс., көлтә бавы, кузла җөе, кырык теш һ.б.), мифологиягә (мәс., абзар иясе, арыш анасы, йорт иясе, кыр атасы, су анасы һ.б.), этнографиягә (мәс., җанаси кертү, каз өмәсе, карга боткасы, кендек әбисе, килен төшерү, коба җыры, тәвәккәл бүрек һ.б.) караган халык атамалары. Елдан-ел кулланыштан төшеп онытыла барганга күрә халык атамаларын сүзлекләрдә теркәп калдыру зур әһәмияткә ия. Ботаника, зоология атамалары үзләренең классификациясе – семьялыклары, отрядлары күрсәтелеп бирелгән. Сөйләшләрдә бу атамалар төрлечә әйтелгәнгә аларның русчага тәрҗемәләре китерелгән (зәрдә ... русчасы: сныть; баба кош ... русчасы: пеликан; бәртәс ... русчасы: язь; бөгәлчән ... русчасы: слепень; илек ... русчасы: косуля һ.б.).

Татар телендә ярдәмче фигыльләрнең, исем һәм башка сүз төркемнәренә караган сүзләр белән килеп, тезмә фигыльләр барлыкка китерүе сүз ясалышының аерым бер төре булып тора. Сүзлектә исәпкә алынып алфавит тәртибендә китерелгән тагын да зур бер катламны шушы калып белән ясалган тезмә фигыльләр тәшкил итә (мәс., аза кубу, азат итү, аймыл булу, ант итү, ах-ух килү, әҗе-гөҗе килү, әрәм-шәрәм итү, бар кылу, боз сугу, бүләк итү, быт-быт килү, ваз кичү, вәгъдә итү, вәйран булу, гаҗиз калу, газап чигү, гаиб булу, гамәл итү, гөр килү, ду кубу, жу итү, җик чигү, камыт сугу, карар кылу, каза кылу, кизү тору, кым-кырыч килү, мәҗбүр итү, насыйп булу, ният кылу, тар-мар итү, юк итү, юш килү, ярдәм итү һ.б.). Аларны мөстәкыйль сүз буларак алфавит тәртибендә үз урыннарында күрсәтү, һичшиксез, тел байлыгыбызны тулырак ачыклауда сүзлекнең уңышлы ягы булып тора. Бу берәмлекләр телебездә һәрдаим тулы мәгънәле мөстәкыйль сүз буларак кулланылсалар да, моңа кадәр сүзлекләрдән читтә калып килгән. Димәк ки, телебезнең байлыгы да тулысы белән чагылып бетмәгән булып чыга.

Конверсия күренеше дә, ягъни бер сүз төркемендәге сүзнең икенче бер сүз төркеменә күчеп, шул сүз төркеменә хас функция үти алу үзлеге, әлеге хезмәттә эзлекле рәвештә һәм киң чагылыш тапкан.

Фигыльләр сүзлектә төп юнәлеш формасында теркәлгән, фигыль юнәлешләре телнең грамматик төзелешенә караган булу сәбәпле махсус күрсәтелмәгән. Татар телендә кайбер фигыль юнәлешләре өстәмә лексик мәгънәгә ия. Андый фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә түбәндәгечә китерелгән: беренче грамматик мәгънәсе төп фигыльгә җибәреп күрсәтелгән, ә лексик мәгънәләргә аңлатмалар бирелгән (мәс., ашалу ф. 1) төш. юн. к. ашау (1 мәгъ.)...; 2) кояш, җил, су яки башка нәрсәләр тәэсиреннән бозылу, үзгәрү. ...; 3) кыршылу, кырылу, ышкылу, тузу. ...; кайралу ф. 1) төш. юн. к. кайрау. ...; 2) күп ышкылудан ялтырап тору. ...; 3) күп ышкылып яки нык кысудан кыршылу. ...; 4) күч. үткенләнү, шомару; күпне күреп тәҗрибә туплау. ...; һ.б.).

Алты томлык аңлатмалы сүзлекнең тагын бер яңалыгы – кайбер мөстәкыйль фигыльләрнең, башка мөстәкыйль фигыльләр белән килгәндә, ярдәмче фигыль


функциясенә күчеп, тезмә фигыльләр барлыкка китерүен күрсәтү. Сүзлектә тезмә фигыльләр ясауда катнаша торган фигыльләр буларак алу, ату, бару, бетерү, бетү, бирү, җибәрү, җиткерү, җитү, йөрү, калу, карау, керү, килү, китү, кую, салу, тору, төшү, узу, утыру, чыгару, чыгу, язу, яту сүзләре китерелә. Алар тезмә фигыльләрдә төп фигыльгә өстәмә яңа мәгънә төсмере алып килә, аның мәгънәсен ачыклый төшә, конкретлаштыра (мәс., җитдиләнеп китү; кисәтә килү; көчәя бару; куркып тору; күреп калу; оялып кую; укып бару; яктыра төшү һ.б.). Сүзлектә тезмә фигыльләрнең мәгънәсенә бирелгән аңлатмада төп игътибар нигез фигыль мәгънәсен ачыклауга түгел, ә ярдәмче фигыльнең нигез фигыльгә нинди йогынты ясавын, гомуми мәгънәгә нинди өстәмә кертүен аңлатуга юнәлтелгән (мәс., кабатлап чыгу башыннан ахырына кадәр (бөтенесен дә), яңабаштан кабатлау ...; кайтып йөрү һәрвакыт, даими, гел кайту ...; күтәрелә бару торган саен ныграк күтәрелү ...; кычкырып кую кинәт, бер тапкыр кычкыру ... һ.б.) Кайбер тезмә фигыльләр компонентларының мәгънәләре суммасын тәшкил итәргә дә мөмкин: алып бетерү, йоклый башлау, ә күпчелек тезмә фигыльләр төп мәгънәгә яңа төсмер өстиләр, сөйләүчегә үз фикерен төгәлрәк, ачыграк белдерергә ярдәм итәләр: аптырап калу кинәт аптырау, югалып калу; әйтеп ташлау кинәттән, көтмәстән, әйтергә тиеш булмаганны әйтү; белдереп бару һәрберсенә, һәр очракны, даими белдерү; бүлеп чыгу бөтенесен бүлү, һәрберсенә дә бүлү; җанлана төшү беркадәр, бераз җанлану; кызарып китү кинәт, капыл кызару; күзәтеп йөрү һәрвакыт, даими күзәтү; һ.б. Бу фигыльләр тезмә фигыльләр ясаганда гына ярдәмче фигыльләргә әйләнәләр, ә аерым кулланганда мөстәкыйль фигыль, лексик берәмлек булып калалар. Бер нигездән ясалган бу тезмә фигыльләр сүзлектә алфавит тәртибендә аерым-аерым китерелмичә, семантик бәйләнешен күздә тотып һәм төп мәгънә уртаклыгын исәпкә алып, үзе ясалган төп фигыль оясында ярдәмче фигыльләрнең алфавиты белән теркәлгән. Сүзлектә тезмә фигыльләрне мондый рәвештә күрсәтү, һичшиксез, уңай күренеш. Тезмә фигыльләрне төп фигыль оясында бирү ярдәмче фигыльләрнең төп фигыль семантикасына ясаган йогынтысын күзәтергә, әйтергә теләгән фикерне төгәлрәк тапшыру юлларын ачыкларга, татар телен өйрәнүчеләр өчен татар теленең байлыгын, аның эчке мөмкинлекләрен тулырак ачарга һәм файдаланырга ярдәм итәр дигән караштан чыгып эшләнгән.

Аңлатмалы сүзлекләр милләт тормышында һәм яшәешендә мөһим роль уйный. Ул шул телдә сөйләшүче халыкның белемен арттыруга, сөйләм культурасын үстерүгә хезмәт итә. Шуның өчен дә аны лаеклы рәвештә милләтнең мәдәниятлелек билгесе дип күрсәтәләр. Сүзлекләр – туган телнең бихисап зур хәзинәсе, аның танып белү коралы, милләтнең интеллектуаль үсешендәге күрсәткече. Аңлатмалы сүзлекләр үзенең укучыларын сүзләрне дөрес язарга һәм сөйләмдә урынлы кулланырга өйрәтә, туган телләрен тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итә.

**Фирая ГАФФАРОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТАТАР МУЛЛАСЫ – СОЛТАН КУНАГЫ

XIX гасыр азагы – XX гасыр башында Россия империясенең төрле төбәкләреннән хаҗга барган татарларның сәяхәтнамәләре (гадәттә, аларны хаҗнамә дип йөртәләр) соңгы елларда шактый гына табылды һәм бүгенге хәрефләр белән басылып чыкты, шулар арасында, әйтик, Шиһабетдин Мәрҗани, Гали Чокрый, Галимҗан Баруди, Муса Ярулла Биги кебек зур шәхесләрнең юлъязмалары да дөнья күрде. Инде менә шул кызыклы, хәтта маҗарави текстларга тагын бер әсәр өстәлде: Буа имамы шәйх Нургали бин Хәсәннең (1852–1919) 1906 елда Истанбул аркылы Хиҗазга ясаган сәяхәте турындагы язмалары табылды. Бу әсәр моңа кадәр билгеле булган хаҗнамәләрдән һәм эчтәлеге, һәм тел-өслүбе, һәм төзелеше ягыннан шактый үзгә булып тора, бердән, ул чәчмә әсәр итеп гарәп телендә язылган, соңрак шигъри әсәрнең бер өлеше буларак, татар телендә басылган. Икенчедән, бу әсәр хаҗнамәдән киңрәк булып, бары тик Хиҗаз сәяхәтен генә тасвирламый, тагын өстәмә бик күп урын һәм вакыйгаларны да үз эченә ала.




Нургали бин Хәсәннең (Нургали Хәсәнов) биографиясе һәм эшчәнлеге бүгенге көндә яхшы гына өйрәнелгән дип әйтергә була: Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында аның тормыш юлы турында фоторәсемнәре белән берлектә татар һәм рус телләрендә кечкенә күләмле китаплар басылды һәм интернет челтәренә куелды[1]. Әмма гарәпчә юлъязмасының тәрҗемәсе һәм татарча әсәренең тексты Төркиядә басылып чыкты[2]. Бу эшне башкарган кеше – Өмәр Хакан Өзалп – Төркиядә татар мәдәниятен, аеруча дини әдәбиятын таныту өлкәсендә шактый өлеш керткән шәхес: ул «Ризаэддин Фәхретдин: Казан белән Истанбул арасында бер галим»[3] исемле китап авторы, шулай ук Габдерәшит Ибраһим, Муса Биги, Риза

[1] Амишов Р.И. Дин галиме Нургали Хәсәнов: тәрҗемәи хәле. Казан: ПФ «ГА РТ» нәшр. 2022. 44 б.

[2] Nurali bin Hasan. Sultan Abdülhamid'in Sarayında Bir Tatar Müderrisin İstanbul, Bursa ve Surre Alayı ile Hac Hatıraları (1906-1907). Arapçadan tercüme: Ömer Hakan Özalp. İstanbul, İşaret Yayınları, 2021, 486 s.

[3] Ömer Hakan Özalp. Rızaeddin bin Fahreddin: Kazan'la İstanbul Arasında Bir Alim, İstanbul, Dergah Yayınları, 2001, 480 s.

Фәхретдин кебек галимнәрнең аерым хезмәтләре[4] аның тарафыннан гарәп графикасыннан яки госманлы теленнән бүгенге төрек теленә күчерелеп нәшер ителде.

Нургали бин Хәсән белән бәйле төрек телендә чыккан китап 486 (!) биттән гыйбарәт, гәрчә Өмәр Хакан Өзалп бәйнең исеме китап тышлыгында «гарәпчәдән тәрҗемә итүче» дип, тыйнак кына күрсәтелсә дә, чынлыкта аның тарафыннан, тәрҗемәләрдән тыш кына да, гаять күпкырлы эш башкарылган: китапка саллы кереш сүз язылган, Нургали бин Хәсәннең һәм улларының биографиясе барланган, китапларының һәм мәкаләләренең бай библиографиясе тупланган, хәзрәтнең госманлы туфракларына аяк баскач танышкан, күрешкән, сөйләшкән бихисап күп шәхес турында мәгълүмат бирелгән, аның белән берлектә сәяхәт иткән улы Гыясетдиннең төрек телендә басылган мәкаләләренең исемнәре, чыганаклары күрсәтелгән, госманлы архивларыннан кызыклы документлар табылган. Татар имам-мөдәррисенең сәяхәте китапта шул кадәр кызыклы һәм мавыктыргыч итеп тасвирланган ки, бер әдәби әсәр, хыялый роман укыган кебек онытылып укыйсың. Чынлап та, кайбер урыннарда Нургали хәзрәтнең язганнарына ышанасы да килми: 1906 елда Буа якларыннан Истанбулга килгән гап-гади бер татар дин эшлеклесе, солтан II Габделхәмиднең сараенда ике айга якын кунак була, сарай әһелләре белән берлектә рамазан ифтарларында, тәравих намазларында катнаша, солтан тарафыннан иң дәрәҗәле орденга лаек дип табыла, алай гына да түгел, хаҗ сәфәренә хәлифәнең Мәккә-Мәдинәгә җибәргән алтын-көмеш тулы сүррә кәрваны белән бергә бара! Китапны укыганда, менә ичмасам, Буа мишәре, дип ничә тапкыр әйтелгәндер, санамадым, әмма кульязмада китерелгән вакыйгаларның төш кенә яки хыял җимеше түгеллеген дә автор тарафыннан китерелгән фактлар, исемнәр, детальләр раслап тора.

Нургали хәзрәт юлга улы Гыясетдин белән бергә 1906 елның июль ахырында чыга. Сәяхәтенең максатын башлангычта хаҗ бурычын үтәү дип күрсәтми ул: Бохарада туып, яхшы дини тәрбия алган, Коръәни-Кәримне яттан матур итеп укырга өйрәнгән улын Истанбул Дар әл-мөгаллиминенә (укытучылар хәзерли торган уку йортына) урнаштыру, бер уңайдан үзенең аяк-кул буыннарын дәвалау өчен Бурса шәһәренә термаль сулы мәшһүр мунчаларга барып кайтуны планлаштыруын әйтә. Буа – Сембер-Казан – Мәскәү – Петербург маршруты белән башкалага килеп, монда Император сараен, Эрмитаж музеен, Петергофны карап, Милли китапханәдәге Госман Коръәнен күреп, өч мәчетендә дога кылып, җомга көнне җирле мөселманнарга вәгазь укып, кунак ашларына йөреп чыкканнан соң, Петербург җәмигъ мәчетен төзү проблемасы буенча ахун Гатаулла Баязитов белән фикер алыша, Габдерәшит Ибраһимов, Муса Бигиевләр белән күрешә. Шәһәрдә яшәгән мөселманнарны русларның Василий Иваныч дип атап йөртүләренә, үз милли яки дини киемнәрен кигән мөселманнарга ят күз белән карауларына ачына, Истанбулга баргач, моның нәкъ киресен күрдек, ди: бер урында егерме төрле кыяфәттәге кеше – Бохара чалмасы, татар кәләпүше, төрек фәсе, рус шапкасы кигәннәр даими очрап тора, беркемнең беркемгә исе китми, ди.

Кара диңгезне рус пароходында

[4] Kalem ve Kılıç Üstadı Şeyhülislam İbn Teymiyye ve Mücadelesi, Rızaeddin bin Fahreddin, Tatarca'dan Türkiye Türkçesi'ne çevirme: Ömer Hakan Özalp. İstanbul, Özgü Yayınları, 2007, 208 s. Abdurreşîd İbrâhîm.Âlem-İ İslâm ve Japonya'da İslâmiyet'in Yayilmasi (Cilt: 1, 2. Tam Takım) Türkistan, Moğolistan, Mançurya, Kore, Çin, Singapur, Hindistan, Arabistan. Hazırlayan: Ertuğrul ve Ömer Hakan Özalp. İstanbul: İşaret Yayınları, 2019; İlahi Adalet, Mustafa Sabri Efendi–Musa Carullah Bigiyef, Pınar Yayınları, İstanbul, 1996, 362 s. (Osmanlıca ve Tatar Türkçesi'nden notlarla sadeleştirme: Ömer Hakan Özalp). Өч китаптан гыйбарәт: a) Yeni İslâm Müctehidlerinin Kıymet-i İlmiyesi (15-252);
b) Rahmet-i İlahiye Bürhanları, Musa Carullah Bigiyef (253–341);
c) İnsanların Akîde-i İlahiyelerine Bir Nazar, Musa Carullah Bigiyef (343–362).

кичеп, исән-имин Истанбулга килеп җиткәннән соң безнең юлчылар «Кырым» мосафирханәсенә урнаша. Нургали хәзрәтнең шәкертләренең шәкерте булган һәм Сембер якларыннан 1901 елда Төркиягә килеп, илаһият факультетында укучы якташлары Хәлим Сабит (Шибай) (1883–1944) аларга мәчет һәм мәдрәсәләр, төрбә һәм музейлар, суфи тәккәләрен һәм китапханәләр күрсәтеп йөри. Хәзрәт соңыннан Бурсага барып дәвалана. Андагы кызыклы урыннарны карап йөри, Дагыстанлы шәйх Мөхәммәд Алмалы белән шәйх Шәрәфетдинне зиярәт итә. Монда шуны да әйтергә кирәк: Нургали бин Хәсән суфичылык белән турыдан-туры бәйләнеше булган кеше, әле Бохарада укыган чакта ук нәкъшбәндия тарикатенә кереп, үз якларында ишан-шәйх булып китә, Истанбулга килгәч, Идел-Урал буйларында да дәрәҗәсе гаять зур булган шәйх Әхмәд Зыяэддин Гөмешханәвинең хәлифәсе белән күрешә, башка тарикать әһелләре белән сөхбәт итә. Язмаларыннан күренгәнчә, Нургали хәзрәт бу сәяхәтендә өйсез, фәкыйрь дәрвишләрдән башлап, мәгариф министры, шәйхелислам, хәтта падишаһның үзенә кадәр бихисап күп кеше, галим-голамә белән очраша, язмаларыннан сизелеп торган сурәтләү тоныннан аның һәр җирдә үзен тыныч, тыйнак, үз-үзенә ышаныч белән горур тотуы аңлашыла. Алай гына да түгел, госманлы шәйхелисламлыгында ир белән хатынның аерылышуы, ислам динен соңыннан кабул иткәннәрнең сөннәт ителүе, тарикатьләр, яңа ай тууны билгеләү юллары кебек кайбер четерекле темалар буенча үз фикерен, хәтта фәтваларын да белдерә, бәхәсләшә. Шул ук вакытта Урта Азия һәм Россия мөселманнары арасында бик таралмаган кайбер дини традицияләрне тасвирлый, мәсәлән, махйа – Рамазан аенда мәчетләрнең ике манарасы арасында җеп сузып, аларны кандил яки электр уты белән «Хуш килдең, Рамазан!» дип бизәү; хәтим (хәтм иңдерү) – Коръәни Кәримне яки бик атаклы тәфсир яки хәдис җыентыкларын башыннан азагына кадәр тулысынча укып-укытып бетергәннән соң оештырыла торган мәрәсимнәрне сурәтли.

Татар мулласының солтан сараена юлы садразам Фәрид Паша белән очрашудан соң ачыла: баш вәзир бер әңгәмәдән соң, Нургали хәзрәтне үз өенә ифтарга чакыра, шул форсаттан файдаланып, тегесе аңа үз кулы белән падишаһ исеменә язган гаризасын тапшыра. Бу гаризада хәзрәт һәр җомга көнне оештырыла торган сәламлык алайына кушылып, солтан-хәлифәнең җомга намазын кыла торган процессиягә катнашырга ризалык сорау була. Җомга сәламлыгы дип аталган бу вакыйга Истанбул халкына һәм шәһәр кунакларына солтанны күреп сәламләү, ул намаз кылган зур мәчет янына җыелып тамаша кылу мөмкинлеге генә түгел, ә бәлки солтанга һәм югары идарәчеләргә гади халыкның гозер-үтенечләрен турыдан-туры җиткерү форсатын да бирә торган чара була, солтанга да халыкның тормышын, хәл-халәтен азмы-күпме күрү мөмкинлеге туа. Хәмидия мәчетендә оештырылган шундый сәламлыкка катнашкан Нургали хәзрәт бу вакыйганы җентекләп тасвирлый: хәлифәне саклаучы гаскәрләрнең киемнәре, мәчет ишегалдында тезелгән гаилә әһелләренең һәм бюрократларның торышы, марш уйнаучы музыкантлар, азан әйтүче мөәзиннәр, үзе өчен аерылган бүлмәгә баскыч буйлап солтанның күтәрелүе һ.б. күренешләр шактый детальле бирелгән. Мәчеткә кергәч, Нургали хәзрәтне аңа хезмәт итү өчен куелган гарәп нәкъ солтанның бүлмәсе каршына бастыра (махсус аерылган бүлмәсендә солтан-хәлифә җәмәгатьне күрә, әмма намаз кылучылар аны күрми). «Намазның сөннәт өлешен бетердемме-юкмы, хәтерләмим, теге гарәп килеп, мине мәчеттән алып чыгып китте, – дип искә ала үзенең язмасында хәзрәт. – Нинди гаеп эш кылдым икән, дип уйлап торганда, без солтан күтәрелгән баскыч буйлап, югарыга таба менә башладык. Баскыч буенда намаз кылучылар миңа: «Нинди бәхет, солтан сине үзе белән намаз кылырга чакыра», дип кызыгып калдылар». Чынлап та, солтан татар мулласына шәйхелислам

белән берлектә намазның фарыз өлешен кылырга боерган булып чыга. Моннан соң да гаҗәеп хәлләр дәвам итә:

*Намаздан соң чыгарылдым,*
*Капка янына куелдым,*
*Дога-и җәһр итеп калдым,*
*Чыкканда ул шаһиншаһы,* –

дип яза ул үзенең татарча әсәрендә, ягъни падишаһ мәчеттән чыккан вакытта Нургали хәзрәтне капка буендагы иң күзгә ташлана торган урынга бастырып куялар ки, аның изге теләкләр теләп торганын солтан берничек тә күрмичә кала алмый һәм, нәтиҗәдә, ул солтан фаэтоннарының берсе белән сарайга ифтар мәҗлесенә кунак буларак китертелә. Шул килгәннән ике айлап сарайда яшәп калган Нургали хәзрәт солтанның күп кенә илтифат һәм бүләкләренә лаек була, аңа көндәлек һәм бәйрәмчә киемнәр тектерелә, сарайдагы ифтар мәҗлесләренә, берничә тапкыр җомга сәламлыкларына катнаша, солтан хозурында оештырылган, шунлыктан «хозур дәресләре» дип аталган дини бәхәсләрне һәм зур галимнәрнең чыгышларын тыңлый, солтан китапханәсендәге кыйммәтле әсәрләрне карый, шулай ук Топкапы сараенда «Изге әманәтләр» дип аталган бүлектә саклана торган Пәйгамбәрдән калган «хырка-и сәгадәт»не барып күрү насыйп була. Шул арада улының укырга керү мәсьәләсе дә уңышлы хәл ителә.

Иң кызыклы моментларның берсе – солтан II Габделхәмиднең татар мулласына улы белән берлектә хаҗ кылып кайтырга тәкъдим итүе, диңгездә куркыныч хәлләр була калса, укыр өчен «Хизб әл-бәхр» исемле догалык китабын бүләк итүе һәм хәтта юл масрафлары өчен беркүләмдә акча бирүе. Хаҗга бару өчен аңа вариант тәкъдим ителә: берсе нормаль хаҗилар йөри торган юл белән, икенчесе – падишаһның сүррә алайы дип атала торган махсус конвое белән Мәккә-Мәдинәгә бару. Хаҗ юлының никадәр авыр һәм куркыныч икәнен ишетеп белгән Нургали хәзрәт, әлбәттә, икенче вариантны сайлый, чөнки изге урыннарга хөрмәт йөзеннән ел саен солтан тарафыннан җибәрелә торган алтын-көмеш, кыйммәтле бүләкләрдән гыйбарәт булган сүррә хумаюнын һәм хаҗга баручыларның зур кәрванын гаскәр саклап бара, шуңа күрә вәхши чүл бәдәвиләренең һөҗүме аларга куркыныч булмый. Икенчедән, солтан-хәлифәнең кунагы буларак, Нургали хәзрәтне һәм улын барган һәр җирдә ашау-эчү, калу урыны, дөя һәм юл кирәк-яраклары белән тәэмин итәләр, алар зур шәһәрләрнең башлыклары белән рәсми очрашуларга катнаша, изге урыннарны рәсми делегация белән берлектә зиярәт итү мөмкинлеге туа. Әйтик, Кәгъбәнең эчен кереп карау гадәти хаҗига бөтенләй мөмкин булмаган бер хәл саналса, Нургали хәзрәткә исә аны да күрү насыйп була.

Хаҗ юлчылыгын да хәзрәт тәфсилле генә сурәтли: Өскедардан төрек пароходы белән юлга чыгалар, сүррә алайы Родос утравында, Бәйрүттә, Дамаскта тукталышлар ясап, җирле рәсми идарә вәкилләре тарафыннан каршылана, юлчылар бераз ял итеп, шәһәрләрне карап йөргәннән соң, бөек хөрмәт белән озатып җибәрелә. «Падишаһның мосафиры» буларак кабул ителгән Нургали хәзрәт өчен әллә нинди ябык ишекләр дә ачыла, бик күп тарихи-дини истәлекләрне күрә, бу якларда торып калган бохаралы, дагыстанлы, казанлы шәехләр, гыйлем ияләре белән күрешү дә аның өчен әһәмиятле була. Хиҗаз тимер юлының салынуы, бар ислам галәменең бу эштә госманлы хәлифәгә ярдәм итүе темасы да аның язмаларында урын ала. Изге Мәккә һәм Мәдинә туфракларында хаҗ кылуы, кайтышлый Җиддәдә чиккән михнәтләре һәм авырып китүе, Акдиңгездә купкан фыртына вакытындагы куркулары – болары башка хаҗиларның да күргән кыенлыклары булганга, монда аларга тукталып тормыйм. Сәяхәтләре вакытында Нургали бин Хәсән һәм улы Гыясетдин дүрт диңгез: Кызыл, Ак (Эгей дә керә), Мәрмәрә, Кара диңгезләр һәм Истанбул (Босфор), Чанаккале (Дарданелл) бугазларын, Сүәеш каналын кичәләр. Истанбулга әйләнеп кайткач, Нургали хәзрәт солтан Габделхәмид

белән көрәшеп, үзенең рәхмәтләрен белдерә, алып кайткан бүләген – кыйммәтле тәсбихләр һәм үзе язган һәм Буадан китерткән гарәп телендәге биш китабын тапшыра. Солтан аңа ватанына кире кайтып киткәнче сарайда калсын, дип әмер биргәч, ике атна улы белән берлектә сарайда яши, зур галимнәр, Пекин мөфтие һ.б.лар белән әңгәмәләр кора. Нургали хәзрәтнең бу хәтле озак төрек илендә кунак булып ятуына туган яклардагы таныш-белешнең, әлбәттә, эче поша: «Казан мөхбире» газетасында (1906 ел, № 177) аның турында чеметкеле язма басылып чыга, анда «Буа мөдәррисенең Истанбулдан кайтачагы юк, өендә ике хатыны, баласы һәм сыеры ач, мәдрәсәсендә унтугыз шәкерте бүген-иртәгә, урын булса, мөгаллим булып китәргә әзер тора. Мөдәррис кайтмаса, бик тиздән мәдрәсә ябылачак», диелә.

Ниһаять, солтаннан рөхсәт алып, Нургали хәзрәт кайтыр юлга чыга, Кара диңгез аркылы Севастопольгә җиткәч, Кырымга китә, Бакчасарайда Исмәгыйль Гаспралы белән күрешә һәм Зынҗырлы мәдрәсәсен зиярәт итә. Аннан Мәскәүгә, аннан да Сембергә исән-сау кайтып ирешә. Вокзалда аны икенче улы Ибраһим һәм бик күп мөселман каршы ала. Бу сәяхәттә күргәннәрен ул, өенә кайткач, гарәп телендә яза һәм «әл-Гаватиф әл-Хәмидийә фи әс-Сәяхәт ән-Нурийә» исеме белән 1907 елда Казанда Матбага-и Кәримиядә бастыра. Вәгъдә иткәнчә, китабының бер нөсхәсен II Габделхәмидкә юллый, солтан да аның тәрҗемә ителүен тели. «Чит җирләрдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул» мәкале Нургали хәзрәт өчен туры мәгънәсендә әйтелгән кебек: солтан хәтле солтаннан кадер-хөрмәт күргән хәзрәт, туган якларына кайткач, үз мәсләктәшләре тарафыннан «Йолдыз», «Кояш», «Әл-ислах» кебек татарча вакытлы матбугат битләрендә мәдрәсәсендәге уку-укыту тәртипләре белән бәйле төрле гаепләүләргә дучар була, «урта юл»ны тотарга теләгән бу мулланы кадимчеләр дә, җәдитчеләр дә үз араларында күрергә теләми. Өстеннән язылган ялган шикаятьләр аркасында 1912 елда Нурия мәдрәсәсенә һәм Нургали хәзрәтнең өенә жандарм тентүе оештырыла, ләкин бернинди зарарлы нәрсә дә табылмый. Улы Гыясетдин дә Истанбулда укуын тәмамлап, Буага кайткач, әтисе янында икенче имам булып эшли башлый, 1914 елда имамлыгы да рәсми рәвештә раслана. Икенче улы Ибраһим (1895–1937) Буада кала, совет чорында «Нурия» мәдрәсәсендә укыта, мәчеттә имам булып эшли. Мәдрәсәнең исеме Нургали исеменнән «Нурия» булып, хәзрәт үзе монда 1886 елдан эшли башлый һәм 1919 елда вафат булганга кадәр, 35 ел буе дәрес укыта, икейөзләп имам, унлап ахун, күпсанлы мөгаллим һәм мөдәррис җитештерә. Болар арасында тарихчы Һади Атласи, язучылар Зариф Бәшири, Гомәр Толымбайский, Ярулла Вәли, журналист Фатих Мортазин кебек танылган шәхесләр дә бар. Әтиләренең дингә һәм милләткә хезмәтен ике улы дәвам иттерә. Олы улы Гыясетдин Истанбулда укыган вакытта «Сират-ы мөстәкыйм», «Төрек йорды», «Туран» кебек газета-журналларда күп кенә мәкаләләр бастыра, төрекчә чыккан китапта болар турында төпле материал бирелә. «Нурия» мәдрәсәсе 1930 елда ябыла.

Нургали хәзрәт үзе 58 еллык тормышын шигъри юллар белән аңлату максатында 1912-1913 еллар тирәсендә Оренбургта «Дин вә мәгыйшәт» матбагасында «Илле сигез ел. Гасырда җәвәлан» исемле китап бастыра, анда балачагы, Казанда һәм Бохарада укуы, Буада имам һәм мөдәррис булып эшләве, суфичылык белән бәйле эшчәнлеге белән беррәттән, госманлы Төркиясендә күргәннәрен дә яза. Китапның шул бүлегеннән кайбер өзекләр китереп, ачыклама бирик:

*Хилафәт дийарына бардым,*
*Һәммә бөекләрне күрдем,*
*Хозурларга кабул улдым,*
*Тәшәккүр итәм Аллаһка*

(Хәлифәлек иленә бардым, һәммә бөек затларны күрдем, солтанның хозурына кабул ителдем, шөкер итәмен Аллаһка).

*...Мәшәих, мөфтиләр илә*
*Гарәпчә гөфтәгү кыйлдым,*
*Җавап-вәгъдәләрен алдым,*
*Тәшәккүр итәм Аллаһка.*

(Шәйхләр, мөфтиләр белән гарәпчә әңгәмә кордым, аларның җавапларын, вәгъдәләрен алдым, шөкер итәмен Аллаһка).

Монда шуны искәртәсе килә: Нургали хәзрәт, Төркиягә баргач, күбрәк гарәпчә сөйләшә, госманлы төрекчәсен аңлау бераз уңайсыз була, күрәсең. Камил дәрәҗәдә төрки-татар, гарәп һәм фарсы телләрен белүенең сәбәбен хәтта солтан Габделхәмид тә сорый, ул татар теленең туган теле булуын, гарәпчәне дини китаплардан, фарсычаны Бохарада укыган вакытта өйрәнүен әйтә.

*...Мәгариф назиренә кердем,*
*Угыл әмрене арз иттем,*
*Гүзәл вәгъдәләр алдым,*
*Тәшәккүр итәм Аллаһка.*

(Мәгариф министрына кердем, улымның теләген җиткердем, яхшы вәгъдәләр алдым, шөкер итәмен Аллаһка).

*...Бурсага да сәфәр кыйлдым*
*Күкерт суында утырдым,*
*Олуг Мәсҗеддә күп булдым,*
*Тәшәккүр итәм Аллаһка.*
*...Сарай ифтарыны кылдык*
*Шәриф-и Мәккәләр илә,*
*Хозурга керде баш кятиб*
*Ни ула әмер-е солтани.*
*«Минем җәмгыятемә керсен,*
*Тәрәвихе эда кылсын*
*Маийәттә дога кылсын!» –*
*Чыгарды әмер-е солтани.*
*... Хумаюн сүррәсе илә*
*Хиҗазга бара хаҗ итә,*
*Калыр углы илә монда*
*Булып миһман-и солтани.*
*...Ничә кәррә мине сорады*
*Ки «Рәхәттә улын» диде,*
*«Мосафирсың минем», диде*
*Хавасс-и заиф-и солтани.*
*..Хәдимдән сандыгы алды,*
*Әле илә миңа бирде,*
*«Һәдиям бу сиңа», диде*
*Беренче рөтбә Госмани.*

(Хезмәтчедән сандыгын алды, үз кулы белән миңа бирде: «Бүләгем бу сиңа, – диде, – беренче дәрәҗә Госмани ордены»).

Шуны да әйтергә кирәк, Нургали хәзрәт Бакчасарайда И.Гаспралы белән күрешкәндә, бу орденның Россиядәге кыйммәте турында сораша, аның киңәше буенча Россия министрлыгына мөрәҗәгать итеп, госманлы орденын ватанында тагып йөрергә рөхсәт ала.

Сүзне йомгаклап, «Солтан Габделхәмид сараенда бер татар мөдәррисенең Истанбул, Бурса һәм сүррә алайы илә хаҗ хатирәләре (1906-1907)» исемле китапка Өмәр Хакан Өзалп тарафыннан язылган кереш сүздән кайбер сөземтәләрне китерәсе килә:

«Арадагы ераклыкка карамыйча, Казан Госманлы империясенең соңгы дәверендә Истанбул белән тыгыз һәм җылы мөнәсәбәтләрен үстерә алды. Бу мөнәсәбәтләр аеруча шушы өлкәләрдә күренде:

1) Татарлар балаларын Госманлы иленә җибәреп, мәдрәсәләрдә, Дар әл-фөнүн, мөгаллим мәктәпләрендә һәм башка уку йортларында укыттылар. Дар әл-фөнүннең илаһият факультетында укыган Хәлим Сабит Шибай, Закир Кадири Уган, «Мөлкия»дә укыган Фатих Кәрими, Хәрбия мәктәбендә укыган Йосыф Акчура, Габдрахман һәм Салих бин Мөхәммәд кардәшләр, Дар әл-мөгаллиминдә укыган Хәмид Зөбәер Кошай һәм без монда телгә алган Гыясетдин Хәсәнов, Габдеррахман һәм Габделхалик әфәнделәр, Истанбулда гарәп әдәбияты дәресләре укыган Шәһәр Шәрәф, Буа имамы Габдулла мулла Гобәйдулла улы, Ш.Мәрҗанинең улы Борһанетдин Мөхәммәд (Истанбулда җиде ел белем ала), шулай ук аның улы Габделхәмид, хокук бүлеген тәмамлаган Габбас бин Әшрәф, Дар әл-мөгаллиминнең физика-химия бүлеген бетергән Касыйм Шәриф әфәнде, Дар әл-хиләфәт әл-галия һәм Мәдрәсәт әл-мөтәхассисиндә укыган Кыйваметдин Бурслан, Сөләймания мәдрәсәсендә укыган Имаметдин бин Гыйсмәтулла,

Истанбул дар әл-фөнүнендә укыган Зиннәтулла Нәүширван һәм Казаннан Мөхәммәд, Вәгыйз, Сибгатулла, Габдулла һәм Шакир әфәнделәр, Байтар (ветеринария) мәктәбендә укыган Габдулла әфәнде, Камил Мотыйгый Төхфәтуллин, француз телен өйрәнергә килгән Галимҗан Идриси, Истанбулда идади мәктәбен һәм Дар әл-фөнүннең табигать белемнәре бүлеген бетереп, Багдадта мәктәптә укытучы һәм мөдир ярдәмчесе булып эшләгән Мөхәммәд Хәнәфи әфәнде, Истанбулның Мәктәб-е солтанисын бетергән, «Тарих-и ислам» китабының авторы Госман Җәлилләр әфәнде, Ист анбул Инас солт ани мәктәбендә укыган Атбасардан Гөлсем Рәхими – болардан берничәсе генә. Моннан тыш, Измир, Бәйрүт, Мәккә-Мәдинә кебек җирләрдә укыган Казанлы шәкертләр дә бар әле.

2) Казанлылар Истанбулда «Русияле ислам таләбә җәмгыяте», «Татар җәмгыяте хәйриясе», «Русиядә сакин мөселман төрки-татарларының хокукларын яклау җәмгыяте», суфи тәккәләрендә һәм мосафирханәләрендә, Мәдинәдә Казан татар мәдрәсәсен корганнар; «Төрек йорды» кебек вакытлы матбугатта һәм «Төрек оҗагы» кебек оешмаларда әһәмиятле роль уйнаганнар.

3) Мирза Салих Кәримов һәм улы Мөхәмматгали Кәримов, Хаҗи Исмәгыйль Абдушев, Харис Солтанов, сәгатьче Минһаҗеддин, Капалы чаршыда Казанлы Хаҗиәхмәд әфәнде һәм улы Ибраһим кебек татарлар Истанбулда сәүдә иткәннәр, магазиннар ачып, ширкәтләр корганнар.

4) Татарлар, Төркиядә җирләшеп яки озак кына вакыт калып, Госманлы империясендә һәм Төркия җөмһүриятенең башлангыч елларында төрле дәүләт органнарында, аеруча университет кебек мәдәният белән бәйле өлкәләрдә эшләгәннәр: Йосыф Акчура, Габдеррәшид Ибраһим, Зиннәтулла Нәүширван, Хәлим Сабит Шибай, Хәмид Зөбәер Кошай, Садри Максуди Арсал, Рәшид Рәхмәти Арат, Зәки Вәлиди Тоган, Габделкадыйр Инан, Закир Кадыйри Уган, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Кывамеддин Бурслан, Габдулла Баттал Таймас, Фуад Туктар, Касыйм Шәриф, Фатих мәдрәсәсендә мөдир Гыйззәтулла әфәнде, Сөләймания мәчетендә эшләгән Әхмәд әфәнде, нәкъшбәндия тарикате шәйхе Хафиз Мөхәммәд әфәнде... Болар янында тагын әле армиядә субай булып хезмәт иткән, казыйлык һәм мөдәррислек вазифаларын башкарган күпсанлы казанлы шәхес бар, ди Өмәр Хакан Өзалп әфәнде. Ул санап киткән бу шәхесләрнең байтагы, ни кызганыч, безгә бөтенләй билгеле түгел. Озак еллар Буа имамы, «Нурия» мәдрәсәсенең мөдәррисе булып, татар мәгарифенә үз өлешен керткән Нургали бин Хәсәнгә һәм аның улларына багышлап кыйммәтле, чын дәрәҗәсендә гыйльми хезмәт хәзерләп бастырган Өмәр Хакан Өзалп әфәндегә монда зур рәхмәтебезне белдерәбез, бөртекләп җыйган материаллары, кулланган архив һәм вакытлы матбугат документлары, беренчел чыганак буларак, мәгариф тарихыбызны өйрәнү өлкәсендә гаять зур әһәмияткә ия. Тиз арада хәзрәтнең гарәпчә кулъязмасы тәрҗемә ителеп, татарча язган шигъри әсәре белән берлектә татар укучыларына да тәкъдим ителер һәм фәнни әйләнешкә кереп китәр, дигән өметтә калабыз. Тарихыбызның бер парчасы булган мондый шәхесләр онытылмаска тиеш.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы,*
*Россия Фәннәр Академиясе Шәркыять*
*институтының әйдәп баручы фәнни*
*хезмәткәре.*

## Миргазиян Юныс хатлары

*6 август, 1980 ел.*

Хөрмәтле Марсель туган!

Сезнең каршыда мин ялганчы булып калдым.

Инде билет алып куйган идем. Вокзалга бару өчен күтәрелә алмадым: йөрәк һәм радикулит. Эшемә берничә көн алдарак чакырдылар. Казанга бару да бернинди нәтиҗә бирмәс иде. Бару белән әйләнеп кайтырга туры килер иде. Кышын тагын ял алмакчы булам (бу минем узган елгы ялым иде). Шул чакта Сезне күреп, иркенләп сөйләшә алырмын дип өметләнәм.

Проза бүлегендә яшьләр эшләве мине бик куандырды. Алтмыш тирәсенә җитеп килсәм дә, ни сәбәптер яшьләр белән уртак телне тизрәк таба алам.

Мин әсәремне тулысынча эшкәртеп (әлегә шулай тоела), Союзга Илдар Юзеев һәм Сафия Абдуллина исеменә җибәрдем. Суктыргач, шуның бер нөсхәсен Сезгә тапшырырга тиешләр. Шалтыратып белешергә җай тапсагыз, тагын да әйбәтрәк булыр иде. Игелек җирдә ятмый, диләр. Сезнең яхшылыкларыгызны онытмас идем.

Әсәргә нинди яңалыклар керде:

1. Геройның сөйгән яры ачыкланды. Аның уйларын, хисләрен өстәдем. Бу кирәк иде.

2. Аяз Гыйләҗев күрсәткән барлык пунктларны үтәдем: штаб офицерлары икегә бүленделәр.

3. Сәйриннең кайбер фикерләрен Максим Майнагашевка бирдем. Гел татарлар гына акыллы фикер әйтәләр дип уйламасыннар өчен.

4. Аяз бу әсәрне Сент-Экзюпери иҗаты белән чагыштырган. Мин ул язучыны белә идем, ләкин әсәрләрен укыганым юк иде. Аязның фикеренә мин ике куллап ябыштым һәм Экзюперидан цитаталар бирдем. Бу милли тарлыктан чыгып, укучының күзаллавын киңәйтергә ярдәм итәчәк.

5. Әсәрнең исемен үзгәрттем. «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» Һәм «Сугыш һәм тынычлык мөнәҗәте». Бу исемнәрнең икесе дә калырга тиештер дип уйлыйм мин. Бер-берсен ачыклыйлар алар.

6. Посвящение өлешендә «сугышның соңгы көннәрендә үтерелгән» сүзе бар. «Үтерелгән» сүзен калдырсагыз иде. Соңгы вакытта татар язучылары бу мәгънәне әллә нинди төче сүзләр белән алыштыра башладылар: «дөнья куйды» – гаҗәеп ялгыш фикер. Кеше бит дөньяны култык астына кыстырып йөрми. Сугышта кеше вафат булмый, аны үтерәләр.

7. Тагын бер үтенечем бар: редакторлар минем җөмләләрне сызып ташларга яраталар. Һәм ни сәбәптер, шул язмышка иң яңа, иң оригиналь фикерләр эләгә. Гәрәй Рәхим «Табу һәм югалту»ны редакцияләгәндә, шундый фикерләрнең берсенә дә тимәде. Гәрәй Рәхимгә булган ихтирамым шулкадәр зур минем.

8. Сүзләрнең калганын очрашкач сөйләшеп бетерербез дип өметләнәм.

*Ихтирам белән, Миргазиян Юныс.*

**П.С.** Шушы хатны конвертка салу белән самолётка китәм. Машинкада суктырганнан соң кулъязманы укый алмыйм инде. Бик үкенечле. Нишлисең бит! Басылырга язган булса, гранкаларны укый алырмын дип өметләнәм.

**П.П.С.** Ликовскийны Ялчинскийга әйләндердем. Сезнең исемегезне бирдем укчырадистка. Аның нинди милләттән булуы турында баш ватучы булмас дип уйлыйм. Ул егет нәкъ – «историческая общность советского народа» вәкиле.

***

*8 июнь, 1981 ел. Мәскәү.*

Марсель дус!

Соңгы очрашудан сөйләшүне дәвам итәм.

Сез 1982 елда 6 табак басарга була, дидегез. Башта мин бу сүзләргә әллә ни әһәмият бирмәгән идем. «Юлда уйланулар» – 12 табаклы әсәр, әйтик, редактура вакытында 2 табакка кыскарды, ди, андый кыскарту зыян китерми, әсәр әдәби кыскартудан ота гына. Минем 25 ел өйрәнеп, җәфа чигеп язган нәрсә яртылаш кына дөнья күрә дигән сүз түгелме соң бу?

Беренче мәртәбә мин «Казан утлары»нда 1963 елда басылдым. Шуннан соң туктаусыз язам һәм журналда дүртенче мәртәбә басылуым. Димәк, уртача 6 елга бер мәртәбә басылам. Һәм шунысы кызык: ике санда бары тик «Тозлы җил» әсәре генә басылды. Ә бит дүртәр санда подряд басылучы авторлар да бар. Әгәр Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләренә урын бирү өчен кыскартыла икән «Юлда уйланулар», бу очракта бер сүзем юк. Әле нефтяниклар, КамАЗ турында <…> ысулында халтура оештыручылар били күбрәк журнал битләрен.

«Биектә калу»ны язар өчен мин 11 ел авиациядә хезмәт иттем һәм хезмәттән соң 25 ел сюжетны уйлап йөрдем. «Юлда уйланулар» өчен 25 ел гомерне диңгез сукбайлыгына тапшырырга туры килде. Минем 20 ел язган күләмне <…> ишеләр ике елда сыпыртып ташлыйлар.

Марсель, без болай сөйләшик: әсәр тыгыз һәм әдәби яктан камил булсын өчен никадәр кирәк, шулай кыскартылсын. Урын юк, басылуы кыйммәт дип кыскартуга мин риза түгелмен. Басылмасын. Мин тамагымны башка юл белән туйдырам. Кайвакыт басылмаган әсәр тирәнрәк эз калдыра. Чын укучы андый әсәрләрне ихтирам итә. Сезгә кайнар сәлам, иҗат уңышлары, сәламәтлек, җан тынычлыгы телим һәм агачтан сәнгать әсәре тудыру буенча Сезне ярышка чакырам.

Кулыгызны кысып, ихтирам белән, Миргазиян Юныс.

Аязга, Кояшка, Ренатка, Рәдифкә һәм башка егетләргә кайнар сәлам.

**П.С.** «Автопортрет»ны алдым. Профессиональ рәссамнар әйбәт бәя бирәләр. Күрми китүегез кызганыч. Әдәбиятны ташласам, бу шөгыль тулысынча көчне, сәләтне суырып торачак.

***

*23 гыйнвар, 1982 ел.*

Хөрмәтле Марсель дус!

Фәрваз Миңнуллинның обзорында Синең турыда укыдым. Мин Сине нәкъ шулай күрә торганнардыр дип уйлап йөри идем. Чыннан да бит Син ничектер әле кичә генә Париждан күчеп килгән шикелле күренәсең. Алла бирсә, исән-сау тагын бер-ике ел яшәп булганда, мин Синең турыда бик кызык нәрсә язарман дип өметләнеп йөрим. Синең үзеңә охшашлы итеп, рәссам, шагыйрь – татарның Оскар Уайльды турында.

Озын юлга әзерләнәм. Һиндстан ярыматавы тирәсендә тугыз порт һәм Сингапур, Гонконг-Нагасаки-Манила, аннан соң Төньяк Европа – Лондон, Роттердам-Һамбург-Бременһафен. Һәм шул арада, исән булсак, берничә мәртәбә. Шул сәяхәтнең очында якты йолдыз, маяк сурәтендә Казан каласының изге утлары күренеп тора һәм, Алла бирсә, Синең буын язучылары белән Татарстанны урап чыгу – «хрустальная мечта моя такая».

Хәерле булсын, «Биектә калу» турында – ләм-мим юк. Димәк, ул үз эшен эшләгән. Телгә алырга куркалар булса кирәк. Бу хәл Сиңа булган ихтирамымны тагын да арттырды.

«Юлда уйланулар» турында сорарга куркам. Мин тәкъдиргә ышанам. Беләм, Синең канга бер генә уч түгел, бер җилпуч тоз салачаклар аның өчен. Язасы килми. Исәп –

көндәлек дәфтәр алып бару турында. Инде утыз ел хыялланам: өч бит язам да ташлыйм.

Яңа ел белән котлыйм.

*Кулыңны кысып, ихтирам һәм ярату белән, Миргазиян Юныс.*

***

*7 апрель, 1982 ел.*
*т/х «Художник Куинджи»*

Марсель дус!

Сезнең хат күптән килгән булган, ниһаять, уку бәхетенә ирештем – зур рәхмәт. Сез «Биектә калу»ның укучыда нинди тәэсир калдыруын бик оригинал һәм акыллы аңлаткансыз. Мәзәк булып китте: <…> тәрбияләгән укучыдан әсәреңне хуплауны көтү үзе бер ахмаклык бит, уйлап караганда. Әдәбият – катлаулы нәрсә.

«Сызгыра торган уклар»ның басылуына ихлас куанам. Андый әсәрләр басыла торсын иде әле. Сезнең әсәрне дә тизрәк укыйсы килә. Атилла Расих Ямашев турында һаман яза икән. Аның шулай суза, озайта белүе өчен мин бернинди премияне дә кызганмас идем. Ямашев турында язарга «ялкынлы революционерлар» сериясенә миңа тәкъдим иткәннәр иде. Атилла Расихның эшен белгәнгә күрә баш тартырга туры килде. Барыбер аныкын алмаганнар. Нindидер Юхма язган Ямашев турында. Без шулай бер-беребезгә юл бирмичә, комачауларга ифрат оста инде.

Марсель, «Юлда уйланулар» нинди хәлдә? Ул әсәр китап булып 1983 елда чыгачак. Аңа кадәр журналда басыла алырмы икән? Ул әсәр, минемчә, яшь укучыларга ошарга тиеш. Журнал өчен яшьләр аудиториясен яулау бик актуаль эш бит.

Июнь айлары тирәсендә ял алырга исәп. Ял вакытында Казанга бару турында хыялланам.

*Хуш. Кайнар сәлам, иҗат уңышлары мул һәм куанычлы булсын.*
*Кулыгызны кысып, Миргазиян.*

***

*16 июнь, 1982 ел.*
*Малеевка.*

Марсель туган!

Азнакай мәсьәләсендә мин Сезне уңайсыз хәлгә куйдым шикелле – гафу итегез. Ничектер авыру сүзен кузгатырга да кыен, чөнки бу дежур аклануга әйләнде. Ялга кайткан саен шулай була – адаптация дигән булалар врачлар. Минемчә, ял бәхете өчен атна-ун көн тора алмыйча яту корбан кебек тоела.

Менә Малеевкада. Кави атлы Казан шагыйре бар монда. Калганнары чебен карчыклары.

Марсель дус, «Юлда уйланулар»ны эшкәртәсе бар дигәнгә мин ышанып йөрим – ул чыннан да шулаймы? Гадәттә, бу сүзне бастырырга теләмәгәндә кулланалар. Минем энем ул әсәр турында Ринат Мөхәммәдиевтан сораган, ә Ринат андый әсәр редакция портфелендә юк дип җавап биргән. Димәк, Сез аның турында сүз кузгатмагансыз, планга кертмәгәнсез булып чыга. Эшкәртү турында да конкрет: ничек, кайсы урынын нинди юнәлештә эшкәртү кирәк дип әйтмәдегез бит һәм аны Сез әсәрнең язмышын сорагач кына әйттегез бит әле. Минем кулда аның бер нөсхәсе дә калмады.

Нәшриятта кульязма Рәис Даутовта ята. Ул аны бәлки редакцияләп бетергән булса кирәк. Рәхим итеп, шуның белән сөйләшә алмас идегезме? Ул Сезгә редакцияләнгән нөсхәсен бирсә?

Әгәр эшкә чакыртып алмасалар, Малеевкадан соң Казанга, әлбәттә, барам инде. Ул чакта Сезнең ялга китеп баруыгыз ихтимал. Ярый, хәерле булсын инде...

Барлык дусларга, редакция сотрудникларына, Ринатка, Рәдифкә кайнар сәлам.

*Кулыгызны кысып, Миргазиян Юныс.*

***

*29 апрель, 1983 ел.*
*Мәскәү*

Марсель дус!

Очрашуны оештыруыгыз өчен кабат рәхмәт. «Украина»дан кайту белән «КУ» эзләп укырга керештем һәм Гыйләҗев мәкаләсе белән «Лорка илендә»не тын да алмыйча йотып куйдым.

Аяз үзенең шәхеслеген тагын күрсәткән, Аязлыгына экзамен һәм мәйдан тоткан. Синең очерк ихлас ошады. Лирика, информация, фикер – органик рәвештә катнашкан. Хәтта уйлап куйдым: «Мин башлап җибәргән күргәннәргә (тормышка, яшәүгә) рецензия жанрын менә кем дәвам иттерергә тиеш»...

Минем күптәнге хыялым – Татарстанны аркылыга һәм буйга җәяү үтеп чыгу, шул турыда әсәр язу. Бәлки минем бу авантюраны икәү башкарырбыз, ә?

Очеркта ике ялгыш таптым: «тәртә кумсаң»не Гоголь әйткән, испан бию «фламенко» дип атала, фламинго – кош.

Әдәбият турында фикер алышуга минем дә катнашасы килә. Белмим нишләргә? Катнашасы килә, ә язасы килми.

Марсель, «Миргазиян абый кушты», – дип, Аязның кулын кысып, йодрык белән кабыргасына төрт әле. Аңа әйт: «Бу акт Аязның абруен түгел, премия үз абруен күтәрде! Төрле алашаларга биреп, премия йөзен пычраткан, иманын югалта башлаган иде. Хәзер инде аның йөзе яктыргандай булып китте».

*Сәлам белән, Миргазиян.*

***

*Мәскәүдә Камал артистларының башкала тамашачыларына театрның ничек уйналырга тиешлеген күрсәтеп йөргән чор,*
*июль, 1983 ел.*

Хөрмәтле Марсель туган!

Театрның беренче спектакле «Монда тудык, монда үстек»кә бармасам, Казанга кайта идем. Инде кайтып булмаячак. Шунлыктан күп үтенечләрне хат аша гына белгертергә туры килә.

«Казан утлары»ның машинисткасына бурычлы булуымны онытмадым. Әгәр Туфан Миңнуллин үтенечне өстенә алмаса, почта аша Сезгә җибәреп хәл итәчәкмен.

«Дөнья гизү гыйлеме» әсәренең өченче китабын (беренчесе – «Тозлы җил», икенчесе – «Теләп алынган давыл») тәмамлап ятам. «Таңда Босфор аша» дип исем куйдым. Шуны 1984 ел планына кертеп булмас микән?

Мәскәүгә килү мәсьәләсе ничек хәл ителде? Килү һәр очракта Сезнең өчен кирәк нәрсә.

Ял бетеп килә. Шулкадәр урыннан кузгаласы килми – аяк тартмый.

«Юлда уйланулар» турында җылы, әйбәт сүзләр ишетелә башлады. Рәхмәт Сезгә. Без бергә тырыштык, Сез аны бастыруга күп көч түктегез. Куаныч уртак булсын.

Терминнарда, исемнәрдә шактый гына хаталар ычкынган. «Рамана» түгел, «Рамона», «Багра» – «Бачра», «штанг» – «штаг» һ.б. Димәк, вёрстканы укырга кирәк булган.

«Казан утлары»ның алтынчы санында Сезнең гаҗәп матур шигырьләр басылган. «...Агыла да болыт агыла» – шедевр. Гомумән, «Гибралтар...», «Севилья»дан соң Испания турында язу искиткеч авыр булачак. Испаниянең рухын аңлау белән генә чикләнмәгәнсең. Шигырьнең яңгыравы, сулышы һәм тәме дә нәкъ испанча. Бәлки шушы шигырьләр янәшә басылганга әсәремә төшкән нур аңа җылылык биргәндер дип уйладым.

*Ихлас ихтирам белән, башкалада очрашу көтеп, Миргазиян Юныс.*

# ТЕЛЛӘР БЕЛҮ – КЕШЕНЕҢ ИҢ ЯХШЫ СЫЙФАТЛАРЫННАН

***Казанның «Адымнар» полилингваль комплексы киләчәк буынны тәрбияләүгә, яңа заман шартларында белем бирүгә алдынгы карашы белән аерылып тора. Укучылар өчен камил шартлар тудырылган «Адымнар» комплексы директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, педагог Айдар Шәмсетдинов белән әңгәмә кордык.***

**– Бүгенге көндә «шәхси чикләр» дигән терминны кулланырга яратабыз. Сөйләшүне дә шуннан башлыйк әле. Кем ул бүгенге көн укытучысы? Аның шәхси тормышка хакы бармы яки ул тәүлек буена администрация, ата-аналар, укучылар белән элемтәдә булырга тиешме?**

– Укытучының буш вакыты булырга тиеш, ләкин бүгенге көн укытучысына ул җитми. Мавыккан кеше үз кызыксынуларына барыбер вакыт таба ала, әлбәттә. Әгәр дә укытучы бер ставкага гына эшләсә, ул кадәр үк тыгыз да булмас иде. Ләкин безнең икътисади шартлар катлаулы булып кала.

Гомумән, хәзер Россия күләмендә дә, Татарстанда да укытучыларга кытлык бар. Укытучы булырга укыган яшьләр дә мәктәпкә килергә бик ашыкмый. Шул сәбәпле укытучыларга өстәмә сәгатьләр алырга туры килә, федераль үзәктән билгеләнгән проектлар да көннән-көн өстәлеп тора, мөгаллимнәр җитәкчелегендә сыйныфлар булуын да онытмыйк. Шуңа күрә хәзерге вакытта мәктәпкә укытучылык һөнәренә битараф булмаганнар гына килә. Бу җәһәттән бүгенге көн укытучылары үз эшенә мөкиббән, мөгаллимлекне кәсеп итеп түгел, ә яшәү рәвеше итеп кабул иткән кешеләр булып чыга.

**– «Адымнар» мәктәбе – бүгенге көннең мәгариф системасында иң популяр, телгә кергән уку йорты. Директор кешегә мәктәпнең абруе, даны турында да уйларга кирәк.**

– «Адымнар»да 446 хезмәткәр эшли, 4000гә якын укучыбыз, аларның 8000гә якын ата-анасы бар. Җавап таләп иткән сораулар, чишелешен көткән мәсьәләләр һәрвакыт туып тора. Әгәр Аллаһы Тәгалә шундый вазифаны биргән икән, димәк, юкка түгел, һәм мин халкыма хезмәт итәргә тиешмен дип уйлыйм.

**– «Адымнар» – күп телләр өйрәтә торган мәктәп. Полилингваль система ул ана теленә нигезләнеп, чит телләр өйрәнүгә йөз тота. Сездә татар теле нигез телме?**

– Безнең төп ике юнәлешебез бар. Гариза биргән вакытта ата-аналар уку траекториясен дә сайлап алалар. Беренчесе – күп телле, без аны татар телендә белем бирү корпусы дип атыйбыз. Ул Бондаренко урамында урнашкан. Әлеге мәктәптә төп укыту теле – татар теле. Димәк, башлангыч мәктәптә, математикадан кала барлык фәннәр дә татар телендә укытыла. Әлбәттә, хәзерге вакытта Казан шәһәре шартларында хәтта саф татар гаиләләреннән дә балалар туган теленнән читләшеп бара. Кызганычка каршы, чынбарлык шундый. Баланы күпме өндәсәң дә, моны гаиләдә генә контрольдә тотып булмый. Ләкин без кабул иткән укучыларның 99 проценты саф татар гаиләсендә тәрбияләнсә дә, чын мәгънәсендә ике телле балалар дип әйтер идем мин. Балаларның бит шактый күп өлеше татарча аңласа да, теле ачылмаган. Без хәзерге вакытта менә шундый чынбарлык белән эшлибез. Биредә без Казан федераль университеты белән дәреслекләр төзибез. Мәсәлән, «Адымнар» татар теле дәреслеген алыйк. Ул хәзерге белем бирү системасында моңарчы булмаган өр-яңа продуктыбыз, чөнки әлеге дәреслек туган телләреннән читләшкән балаларны күздә тотып, үз вакытында ата-аналары бирә алмаган күнекмәләрне исәпкә алып, лингводидактик принципларга нигезләнеп эшләнгән. Шушы дәреслек ярдәмендә без, кайбер очракларда чит телне укыту принципларына нигезләнеп, балаларны яңадан милли сафларга кайтарабыз. Безнең буын кешеләре, авылдан шәһәргә укырга килгән вакытта,

гомумән алганда, русча сөйләшми иде. Соңрак руслашу тенденциясе күзәтелә башлады. Хәзер инде без балаларны, киресенчә, мөмкин кадәр татарлаштырырга тырышабыз. Ул укыту процессында гына бара дигән сүз түгел, без, мәктәп буларак, укучыларны төрле чараларда да катнаштырабыз. Мәсәлән, узган елны «Юллар чатында», «Минтимер һәм аның дуслары» дип исемләнгән гаилә форматындагы ике зур нәфис фильм төшергән идек. Максаты, әлбәттә, татар теленә кызыксыну уяту. Аудиоспектакльләрнең дә укучыларга йогынтысы зур булырга тиеш. Безнең сайтыбызга күз салсагыз, анда дистәгә якын татарча аудиоспектакльләр эленгән. Без аларны үзебезнең мәктәптә, тавыш яздыру студиясендә эшлибез. Ата-аналарның күбесе балаларын мәктәпкә машина белән йөртә. Укучы, мәктәпкә барганда, бу язмаларны тыңлый ала. Татар телен үстерү максатыннан, татар теле укытучылары белән һәр аудиоспектакльгә кагылышлы сораулар әзерлибез. Әти-әниләр исә, шул сораулар нигезендә, балалары белән әңгәмә кора ала. Гомумән, ул аудиоспектакльләр безнең сайтыбызда урнаштырылган һәм аны һәрбер кеше кулланырга мөмкин. Анда «Бремен музыкантлары«, «Мэри Поппинс», «Бәләкәч һәм Карлсон» кебек әкиятләрне табарга була. Ни өчен без нәкъ менә халыкара дәрәҗәдә танылган әкиятләрне сайлыйбыз? Чөнки бу әкиятләр белән танышу өчен рус теле бердәнбер чыганак булырга тиеш түгел. Мондый проектлар күп булган очракта балаларның татар теленә ихтыяҗы туачак.

**– «Полилингваль система ул – телне өйрәнү генә түгел, башка фәннәрне өйрәнү чыганагы да», – дисез бер әңгәмәдә. Мондый уку рәвешенә укучы шактый әзерлекле булырга тиеш.**

– Чынлап та, һәрбер тел – ул белем алу, башка фәннәрне өйрәнү чыганагы да булырга тиеш. Мәсәлән, мин төрек телен, инглиз телен өйрәнәм, һәрдаим төрек телендә китаплар укыйм. Димәк, шул китаплар аркылы мин төрек телемне шомарта барам. Һәрбер телнең куллану урыны булырга тиеш. Шул очракта гына тел өйрәнүебез юкка булмаячак. Балаларны мөмкин кадәр чит телдә дә укытырга тырышабыз, ләкин бар сыйныфлар да фәннәрне чит телдә өйрәнә дип әйтә алмыйм. Мәсәлән, 7 нче сыйныфларның инглиз телендә биология, география, математика дәреслекләре бар. Ләкин бер шарт – бу системаны кертү өчен укучыларның чит телдән нигезле белеме тупланган булырга тиеш. Чит телләрне өйрәнү кешене мөмкин кадәр төрле яктан үстерә һәм баета. Мин бу мәктәпкә 2007 елда яшь директор буларак килдем һәм без аны гади микрорайон мәктәбеннән инглиз телен тирәнтен өйрәнүче мәктәпкә әйләндердек. «Нигә кирәк инде ул?» диючеләр дә табылды. «Нәтиҗәсен берничә елдан күрерсез», дигән идем ул вакытта. Әлбәттә, тел өйрәнү – гаҗәеп катлаулы һәм бу һәрбер баланың да кулыннан килә торган эш түгел. Ләкин без баланы тел ягыннан үстерәбез икән, аның бөтен интеллектуаль мөмкинлекләрен ачарга тырышабыз.

**– Урта сыйныф укучылары мәктәпкә кабул ителгәндә, нинди сынаулар аша уза? Сынауны үтә алмаган балалар бармы?**

– Мәктәп ачылган елны без балаларны әңгәмә уздырып, сайлап алган идек. Хәзер дә сәләтле балаларга ишегебез ачык. Безгә укырга кергәндә, таләпләр бар, әлбәттә. Бондаренко урамында урнашкан мәктәпкә кабул итәбез икән, укучы татар телен яхшы белергә тиеш. Шулай ук рус теле, математика һәм инглиз теленнән дә сынап карыйбыз. Июнь башында һәм август ахырында укырга теләк белдергән балаларны кабул итү комиссиясе эшли. Гариза биргән укучылар арасында күбесе – әлбәттә, сәләтле балалар. Ләкин кире каккан очраклар да шактый. Балалар бит төрле ситуацияләргә эләгә. Мәсәлән, башта аның укуга мотивациясе зур булып, яшүсмерлек чорына кергәч, ул мотивация юкка чыгарга мөмкин. Гаиләдә дә төрле проблемалар килеп чыга. Ләкин бала укырга килә икән, без аңа 11 нче сыйныфка кадәр белем бирәбез.

**– Полилингваль мохиттә уку-укыту системасы укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә башка мәктәпләрдән ни дәрәҗәдә аерыла?**

– Бу кайсы корпус булуыннан тора. Бондаренко урамында урнашкан мәктәпкә керсәгез, татар мохитен сизеп алырсыз. Без аны булдырырга, мөмкин кадәр үстерергә тырышабыз.

Әгәр дә бала чит телне тирәнтен өйрәнә икән, ул башкалардан бер башка югары була, чөнки аның алдында яңа киңлекләр ачыла. Мәсәлән, мин 10-11 сыйныфларда инглиз телен сәнгатьчә укыту дәресләрен алып барам. Мин аларга еш кына: «Сез үзегезнең никадәр бай булуыгызны аңлап бетермисез. Әгәр дә сез Бернард Шоуны, яки башка инглиз классикларын оригиналда укыйсыз икән, бик зур байлыкка ия буласыз», – дип әйтәм. Аны бит теләсә кем укый алмый. Күпләрдә бер телдән икенче телгә иркен күчә алу, башка халык мохитен аңлау мөмкинлеге юк. Без – татарлар, кимендә ике телгә ия. Әгәр дә без инглиз телендә укучыларыбызны алсак, аларның бит күбесе – татар милләтеннән. Федераль университеттагы профессорларга күз салсак, аларның да күбесе – татарлар.

**– Уку программасыннан тыш, укучыларга нинди түгәрәкләрдә шөгыльләнү тәкъдим ителә?**

– Безнең күп телле мәктәп булгач, икенче телне укытуны да саклап калдык. Без моны сыйныфтан тыш эшчәнлек кысаларында да алып барабыз. Мәсәлән, бер корпуста – испан теле, икенчесендә исә гарәп һәм төрек телләрен үзләштерәләр. Ни өчен нәкъ менә шушы телләр дигәндә, чөнки нәкъ менә алар татар теле мохитен ныгытуга булышлык итә. Минемчә, татар зыялысы өчен шушы телләрне белү шарт булып торырга тиеш. Бездә шулай ук нәтиҗәле эшләүче кытай теле укытучыларыбыз да бар. Якын арада Корея иленнән делегация килергә тиеш. Хәзерге көндә Корея мәдәниятенә битараф булмаган яшьләребез бик күп. Димәк, укучыларның кимендә өстәмә ике тел өйрәнү мөмкинлеге бар. Безнең укучылар белемне үзләштерәләр һәм аларның никадәр күп тел белүенә мин һәрвакыт сокланып карыйм.

**– Сезнең укучылар өчен интернатта яшәү мөмкинлеге дә каралган.**

– Интернатта яшәүче укучыларыбыз да бар, ләкин аларның саны зур дип әйтмәс идем. Интернатта яшәүчеләр өчен, әлбәттә, бик яхшы шартлар тудырылган. Кимендә өч йолдызлы кунакханә дәрәҗәсендә дип әйтергә мөмкин. Анда күпчелек Казаннан читтәрәк урнашкан бистә яки шәһәрдән ерак булмаган районнардан килгән балалар яши. Мәсәлән, Әтнә, Биектау, Кукмара. Ераграк җирләрдән килгән укучылар юк, чөнки безнең инде республикада алты комплексыбыз бар. Алар бөтен республика географиясен каплап ала. Ул комплекслар Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Актанышта урнашкан.

**– Мәктәптә тиешле белем бирү, киләчәк буынны тәрбияләү өчен, югары уку йортлары да тиешле дәрәҗәдә эшләргә тиеш, чөнки нәкъ менә университетлар мәктәпләрне яшь кадрлар белән тәэмин итә. Фәннәрне чит телдә укыта алырлык белгечләр киләме?**

– Килә, әлбәттә. Без федераль университетлар белән бик тыгыз эшлибез. Директор урынбасары һәм мин үзем дә фән комиссиясе әгъзасы булып торабыз. Студентларны без башта практикага җәлеп итәбез. Берничә телдә укыта алырлык укытучыларыбызны да федераль университет әзерли. Әлбәттә, аларның укыту дәрәҗәсе бөтен телдә дә бер төрле дип әйтеп булмый. Ләкин укытучының теләге бар икән, без аны үстерәбез. Бу елны без 16 яшь укытучыны мәктәбебездә каршыладык. Әгәр яшь белгечләр безгә килә икән, алар бездә калалар. Алар сынап, сайлап алына. Без аларны һәрберсенең күңелен күреп, үзебездә үстерергә тырышабыз. Быел да үзебезнең бәйрәмебез кысаларында һөнәри бәйгегә йомгак ясаган идек. Һәм шушы бәйгедә катнашучылар арасында яшь белгечләр күп иде.

**– Яшь укытучыларны сайлап алганда, нинди сыйфатларга игътибар итәсез?**

– Аларның һәрберсе дә директор белән әңгәмә уза. Әлбәттә, яшь укытучы үз фәнен яхшы белергә тиеш. Икенчедән, педагогикадан да белемнәре нык булуы зарур. Әгәр дә ул, мәсәлән, уку-укыту теориясен белми икән, кызганычка каршы, моңа кадәр инде күп мәртәбә кабатланган хаталарны ясарга мәҗбүр булачак. Вакыт белән педагогика белеменең стандартлары да үзгәрә. Хәзерге яшь белгечләр, 1980-90 нчы елларда университет тәмамлаган укытучылар кебек, фәнннәрне нык үзләштермиләр. Мәсәлән, еш кына инглиз теле укытучысы булып килгән яшь белгечнең инглиз теле әдәбиятыннан

белемнәре шактый зәгыйфь икәне ачыклана. Ләкин укытырга теләге бар, балаларны ярата, В.А.Сухомлинский, Я.Корчак һәм үзебезнең милли педагогларны атый ала икән, без ул белгечне үстерергә әзер. Безнең мәктәптә бик көчле методик завучларыбыз эшли.

**– «Адымнар» мәктәбе укытучылары Татарстанның билгеле режиссёры Нурания Җамали белән спектакльләр дә куйды. Кәгазь эшенә чумган укытучыларны ничек сәхнәгә алып менәсез? Мондый теләк-ихтыяҗ каян барлыкка килде?**

– Без хәзер монда сөйләшкәндә, яңа спектакль репетициясе бара. Туфан Миңнуллинның «Саташу» әсәрен куячакбыз. Анда мин ата ролен башкарам. Безнең үз төркемебез бар. Сәхнәгә чыгу бит ул укытучыны да баета. Беренчедән, хезмәттәшләрең арасында кайнап яшәгәндә, бер-береңне төрле яктан ачу мөмкинлеге бар. Монда төп максат нәрсәдә? Мәктәп укучыларының ата-аналары татар теленең никадәр мөһим булуын аңларга тиеш. Без спектакльләрне сәхнәгә чыгасы килгәнгә күрә генә куймыйбыз. Гомумән алганда, гаиләләрне мәктәптә булган чараларыбызга җәлеп итү максатыннан эшләнә бу эшләр. Ата-аналар тамашачы буларак киләләр, карыйлар. Без спектакльне атна дәверендә уйныйбыз, соңыннан берничә ай узгач, тагын әйләнеп кайтабыз. Һәм ата-аналарның барысы да спектакльләрне карап чыга. Моңа өстәп, без әле төрле-төрле концертлар да оештырабыз. Салават Фәтхетдинов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Ришат Төхвәтуллин һәм башка танылган җырчылар, артистлар мәктәбебездә чыгыш ясый. Бары тик бер максат белән, укучылар, гаиләләре белән килеп, кимендә ике сәгатькә татар мохитенә чумсын дигән теләк белән эшләнә торган проект бу.


**– Республика һәм Россия күләмендә укытучылар арасында бик күп бәйгеләр уздырыла. Мондый бәйгеләрнең педагогик эшчәнлеккә йогынтысы. Бер яктан караганда – тәҗрибә алышу, икенче яктан – укытучының бик күп көчен һәм вакытын ала торган процесс.**

– Һөнәри бәйгеләрдә катнашу укытучыны һәрвакыт төрле яктан баета. Бу елны без комплексыбыз күләмендә «Ел укытучысы» бәйгесен үткәрдек. Димәк, безнең шәһәр күләмендә узачак бәйгедә катнашасы укытучылар билгеләнде. Мин үзем 2002 елда Идел буе районының ел укытучысы исеменә лаек булып, Казан күләмендә узган бәйгедә икенче урынны яулаган идем. Кызганычка каршы, ул вакытта бәйге республика күләмендә ике елга бер генә мәртәбә үткәрелә иде. 2016 елда исә мин Россия күләмендә уздырылган «Иң яхшы мәктәп директоры» бәйгесендә көмеш диплом белән бүләкләндем. Укытучы, андый бәйгеләрдә катнашкан вакытта, үз дәресләренә башка күзлектән карый башлый. Анда аларның үз җәмгыяте барлыкка килә һәм һөнәри яктан аралашу, тәҗрибә уртаклашу укытучыны һәрвакыт баета. Мәсәлән, узган елны Казан күләмендә узган «Ел укытучысы» бәйгесендә рус теле укытучыбыз Лисина Екатерина Петровна беренче урынга лаек булды. Татарча да сөйләшә, чөнки Зәй шәһәрендә үскән кыз. «Мин бәхетле, чөнки татар теле укытучым үз эшенә битараф булмады һәм безгә төпле белем бирде», – ди ул.

**– Киләчәккә күз салсак, ун елдан соң «Адымнар» комплексын сез ничек күзаллыйсыз?**

– Күптелле укыту өлкәсендә бу комплекс яңалык дип әйтеп тә булмый. Әлбәттә, мәгариф өлкәсендә үсеш булырга тиеш. Ләкин безнең үзебездә дә, сәяси аренада да үзгәрешләр булырга тиеш. Без педагогик идеяләребезне туплап барабыз. Киләчәктә аны рәхәтләнеп республика күләмендә дә тарата алыр идек. Биредә эшләнгән һәрбер продукт – уникаль. Әлбәттә, укыткан вакытта эшнең йогынтысын хәзер үк күреп булмый. Инглизләр әйтмешли, «a teacher affects eternity, no one knows when his influence stops». Ягъни сез беркайчан да укытучының йогынтысы кайчан бетәчәген әйтә алмаячаксыз. Киләчәктә безне яшьләр алыштырыр. Киләчәктә дә бу кирәк булачак бер проект, чөнки тел белү – кешенең иң яхшы сыйфатларыннан дип саныйм.

Әңгәмәдәш – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.**



*Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах (1928–2004). А.Биктимеров фотосы.*



*Нурихан Фәттах драматург Туфан Миңнуллин белән СССР язучыларының VIII съездында. 27 июль, 1986 ел.*



*Казан университетында бергә укыган иптәшләр белән. Сулдан уңга: доцент Сәгадәт Ибраһимов, язучы-галим Нурихан Фәттах, шагыйрь Зәет Мәҗитов, ТКН директоры Гарәф Шәрәфетдинов, галим Мирфатыйх Зәкиев. Уку тәмамланып, 30 ел узгач, Аккош күлендә очрашу. 4 июль, 1981 ел.*



*Нурихан ага хатыны Руфинә ханым белән. 25 апрель, 1965 ел.*

*Каләмдәшләр, яшьтәшләр. Аяз Гыйләҗев (сулда) белән Нурихан Фәттах. 1995 ел.*





*Шәүкәт Галиев һәм Нурихан Фәттахка – 70, Ринат Мөхәммәдиевка 50 яшь тулу уңаеннан Казан Кремлендә Президент Минтимер Шәймиев белән очрашу. 10 декабрь, 1998 ел.*

*Гадел Кутуйның тууына – 120 ел*

# КАЙТЫР БУЛМАСАМ, БУ КАДӘР САГЫНМАС ИДЕМ...



Халкыбызның рухи дөньясында җуелмас эз калдырган язучы, шагыйрь һәм драматург, журналист, хәрби корреспондент Гадел Кутуйның (1903–1945) тууына – 120 ел.

Әдипнең исеме Татарстан радиосы тыңлаучылары өчен аеруча кадерле, чөнки аның иҗат юлының шактый өлеше шушы радио белән бәйле. 1930 елларда ул биредә мөхәррир булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Тау ягына тарихка «Казан каймасы» дип кергән оборона сызыгын төзергә җибәрелә. Кайбыч якларында шулай ук радио хезмәткәре Җәүдәт Фәйзи белән бер фатирда торалар. Композиторга атаклы «Башмагым» музыкаль комедиясен язу идеясен окоп казучылар бригадиры Гадел Кутуй бирә. Үзенең «Рөстәм маҗаралары» повестен исә ул радиодан уку өчен дип яза.

Фронтка аны Татарстан радиосы коллективы озатып кала. Утлар-сулар кичеп исән калган батыр сугышчы, туплар тынгач, 1945 елның июнендә авырудан вафат була, Польшаның Згеж шәһәрендә җирләнә. «Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем. Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!» дип яза ул үзенең «Сагыну» нәсерендә, ләкин тәкъдир башкачарак хәл итә.


Татарстан радиосы Гадел Кутуйның юбилеен зурлап билгеләп үтәргә җыена. Бу көннәрдә радиотыңлаучылар, язучылар һәм әдәбият галимнәре катнашындагы оригиналь тапшырулар белән беррәттән, фонд язмалары да хәрәкәткә китерелә. Әдипнең шигырьләренә иҗат ителгән җырлар аерым бер концерт итеп туплана. «Команда – алга!» (З.Хәбибуллин музыкасы), «Илкәемә» (Ж.Фәйзи), «Туган ил» (М.Рахманкулова), «Туган илемә» (М.Мозаффаров) кебек җырлар тыңлаучыларыбыз күңеленә хуш килер дип өметләнәбез. Гариф Галиевның Гадел Кутуйга кагылышлы истәлекләре (рус телендә), Фәйзулла Туишевның «Кутуйга багышланган марш»ы шулай ук тапшыруларыбызны бизәп торыр. Ә инде әдипнең әсәре буенча М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт драма театрында 1977 елда куелган «Тапшырылмаган хатлар» спектакленең (режиссёры Р.Исрафилов, композитор Р.Хәсәнов) радиоварианты ел саен эфирга кабатлап бирелә.

Юбилей көннәрендә язучының шушы ук әсәренә нигезләнгән «Неотосланные письма» монооперасы да халык күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. Дүрт кисәктән торган әлеге операның музыкасын композитор Анатолий Луппов иҗат иткән. Әсәрне танылган җырчы Гөлнара Мурзиева Татарстан дәүләт симфоник оркестрына кушылып башкара. Дирижёр – Вадим Венедиктов.

Ә журнал укучылар игътибарына без Гадел Кутуйның «Сагыну» дигән данлыклы нәсерен тәкъдим итәбез. Аны галим һәм язучы Фоат Галимуллин укый.

*Риза Ишморатның тууына – 120 ел*

# ФИДАКАРЬ ӘДИП



Драматург, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Риза Фәхретдин улы Ишморатның (1903–1995) тууына 1 ноябрьдә 120 ел тулды.

Риза Ишморат – җитмеш елга якын иҗат гомерен халкына багышлаган фидакарь әдипләребезнең берсе. Әдәбият-сәнгатьнең төрле өлкәләрендә үзен талантлы оештыручы, җитәкче һәм үзенчәлекле каләм иясе – драматург, прозаик һәм публицист итеп таныта. «Әдипләребез» исемле белешмәлектә урын алган мәгълүматларга караганда, булачак әдип хәзерге Башкортстанның Яңавыл төбәгендәге Бәдрәш авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Кызыл армия сафларында, Актаныш һәм Минзәлә якларында укытучылык эшендә тормыш мәктәбе үтеп, 1923 елны Казан театр техникумына укырга керә. Төрле елларда Татар дәүләт академия театрында режиссёр, Татарстан Мәгариф комиссариатында инспектор, Халык Комиссарлары Советы каршындагы Сәнгать эшләре Идарәсе мөдире урынбасары булып эшли. Драматург буларак та исеме шушы чорда танылa. «Пожар», «Данлы чор», «Мәдинә», «Тургай», «Гөлзадә» исемле драмалары тамашачы мәхәббәтен казана.

Бөек Ватан сугышында Р.Ишморат «Ватан намусы өчен» фронт газетасы хезмәткәре сыйфатында авыр юл үтә, Берлинда яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң әдип тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә. «Якты юл», «Якын дус», «Бистә кызы Гөлсинә», «Шайтан таягы», «Иске дуслар», «Серле моң», «Шаулыйлар дулкыннар» кебек драма һәм комедияләр драматургның иҗат мирасында күренекле урын тоталар.

Гомеренең соңгы елларында әдип туган-үскән яклары, замандашлары, әдәбият-сәнгать әһелләре турында «Сайрасын тургайлар» исемле документаль повесть, «Гомер сукмаклары», «Дусларым, остазларым» исемле хатирә һәм истәлек китаплары язып бастыра.

Татарстан радиосы архивында Р.Ишморатка кагылышлы берничә дистә язма саклана. Аларның зур өлеше, табигый ки – аның әсәрләре буенча куелган спектакльләр һәм шигырьләренә иҗат ителгән җырлар. Әлеге җырларның байтагы безнең көннәрдә дә эфирда яңгырап тора.

Бәхетебезгә, әдипнең үз тавышы да сакланып калган. Журнал укучылар игътибарына нәкъ әнә шундый язмаларның икесе тәкъдим ителә. Беренчесе 1989 елга карый. Татарстан китап нәшриятында Хәсән Туфан турында «Ак чәчәк атар иде» дигән истәлекләр китабы басылып чыккач, радиода мөхәррир булып эшләүче яшь шагыйрь Рафис Корбан китапка кагылышлы тапшыру оештыра һәм анда катнашырга Риза Ишморатны, Гомәр Бәшировны, Мәхмүт Хәсәновны чакыра. Тапшыру шул елның 5 ноябрендә эфирга чыга.

Икенче язма магнитофон тасмасына 1975 елның 10 сентябрендә язып алынган. Биредә әдип Таҗи Гыйззәт иҗатына карата фикерләре белән уртаклашкан.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## РӘИС УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү турында Указга кул куйды.

## ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ АЧЫЛДЫ

Татарстан Республикасының дәүләт эшлеклесе, ТР Фәннәр академиясенең беренче президенты, Татар энциклопедиясе институтының беренче директоры Мансур Хәсәнов истәлегенә Фәннәр академиясе бинасында мемориаль такта ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе, галимнәр, язучылар, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Мансур Хәсәновның улы Булат Хәсәнов мемориаль такта ачуда ярдәм күрсәткән Рөстәм Миңнехановка, Минтимер Шәймиевкә, Татарстан Язучылар берлегенә, Мәдәният министрлыгына, Фәннәр академиясенә рәхмәт әйтте.

## ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ

Казакъстанның Алма-Ата шәһәрендә дипломат, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Мурат Ауэзовның 80 яшенә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Әлеге чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстан халыклары Ассамблеясы Советы рәисе урынбасары Ирек Шәрипов катнаштылар.

## С.СӨЛӘЙМАНОВА ПРЕМИЯЛӘРЕН ТАПШЫРУ

Сәҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия беренче мәртәбә Казанда тапшырылды. Лауреатлар бүләкне Милли китапханә сәхнәсендә кабул итеп алды. Быел премиягә – шагыйрә һәм тәрҗемәче Алия Кәримова, балалар шагыйрәсе Йолдыз Шәрәпова, Әлмәттән шагыйрә Миңзифа Әхмәтшина, кызыксындыру бүләгенә Буада яшәүче шагыйрә Гөлнур Айзатуллова, Норлаттан прозаик Илдус Диндаров, Казаннан шагыйрә Ольга Овчинникова лаек булдылар. Бер төркем студентларга Сәҗидә Сөләйманова исемендәге стипендияләр бирелде. Лауреатларны һәм стипендиатларны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе Рөстәм Мөхәммәдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, С.Сөләймানованың улы Әнвәр Маликов һ.б. котлады.

## МӘДӘНИЯТ КӨННӘРЕ

Чечен Республикасында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре булып узды. Анда язучылар да катнашты. Әлеге чара кысаларында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучылар Рүзәл Мөхәммәтшин, Айгөл Әхмәтгалиева, берлекнең матбугат үзәге җитәкчесе Гүзәл Гыйззәтуллина Чечен Язучылар берлегендә булдылар, ике арада хезмәттәшлекне үстерү, уртак әдәби проектларны гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар. Чечен Милли китапханәсендә ике республика иҗат әһелләре катнашында түгәрәк өстәл утырышы булды.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ – МӨСЛИМ РАЙОНЫНДА

Мөслим муниципаль районында татар әдәбияты көннәре булып узды. Шушы уңайдан үткәрелгән чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстанның халык шагыйрьләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Татарстанның халык язучылары Марсель Галиев, Фоат Садриев, язучылар Ләбиб Лерон, Факил Әмәк, Рафис Корбан, Данил Салихов, Хәбир Ибраһим, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Шәмсия Җиһангирова, Фирүзә Җамалетдинова, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Гыйбадуллина, Миңзифа Әхмәтшина һ.б. катнашты. Алар шушы районнан чыккан каләм ияләре Зариф Мөэминов, Харрас Әюпов, Наис Гамбәр, Флүс Латыйфи каберләрен зиярәт кылды. Язучы, мәгърифәтче, фольклорчы З.Мөэминовның тууына – 130, прозаик Ф.Латыйфиның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәдә, Н.Гамбәр яшәгән йортка элмә такта кую тантанасында катнашты. Район үзәк китапханәсендә, Тукай, «Хезмәткә дан», «Бәхет» скверларында булдылар. Мөслимдәге гимназиядә, лицейда, Г.Тукай исемендәге мәктәптә, Кубәк, Тат. Бүләр, Тойгелде, Олы Чакмак, Әмәкәй авылларында укучылар белән

очраштылар. Мөслим районында язучылар белән үткәрелгән чараларда район башлыгы Альберт Хуҗин катнашты.

## СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕНӘ СӘФӘР

Язучылар, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреатлары Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, журналист, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе баш мөхәррире Рәмис Латыйпов Свердловск өлкәсенә сәфәр кылдылар. Алар өлкәнең Әҗегол, Арый, Шәкүр, Акбаш, Уфа Шигере, Үрмәкәй, Әрәкәй авылларында, Красноуфимск шәһәрендә – укучылар, Екатеринбургның Татар үзәгендә татар җәмәгатьчелеге белән очраштылар. Татарстанның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиле Хәйдәр Гыйльфанов аларга Рәхмәт хатлары тапшырды.

## ТӨБӘКАРА ФЕСТИВАЛЬ

Пермь өлкәсенең Лысьва шәһәрендә Хәсән Туфан белән Туфан Миңнуллинга багышланган «Ике Туфан йолдызлыгы» дип аталган V төбәкара фестиваль булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, язучы Хәбир Ибраһим, шагыйрь Идият Әширов катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## Р. ФӘЙЗУЛЛИНГА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ

Анкарада чыга торган «Төрки дөнья тарихы һәм мәдәнияте» журналының яңа санында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга багышланган зур сәхифә бирелгән. 10 биттән торган, 40лап фоторәсем белән бизәлгән бу язмада шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы тәфсилләп бәян ителгән, шигырьләре анализланган, әдипнең төрки әдәбияттагы урыны турында фикерләр әйтелгән.

## КИТАП БӘЙРӘМНӘРЕ

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Галиевнең берьюлы ике яңа китабын тәкъдим итү булды. Аларның берсе Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Чытырманлыкта», икенчесе «Милләт» нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Сүзләрдән – сәйләннәр» китаплары. Беренчесе – тәрҗемәләр китабы. Анда Максим Горькийның истәлекләре, Карл Фукснең татарлар, аларның көнкүреше, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре турындагы хезмәтләре, япон язучысы Рюнескә Акөтәгаваның новелласы, калмык язучысы Әренҗән Карадауанның Чыңгыз хан турындагы язмалары, испанлы Руи Гонсалес де Клавихоның сәяхәтнамәсе тупланган. Икенче җыентыкта – канатлы сүзләр, гыйбарә-афоризмнар. Китап бәйрәмен Татарстан китап нәшрияты директоры урынбасары Айдар Гыймадиев ачты, Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучылар Камил Кәримов, Сания Әхмәтҗанова, галимнәр Миләүшә Хәбетдинова, Гөлфия Гайнуллина, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Марсель Җаббаров, журналист Фәния Хуҗиәхмәтова, Азнакай якташлык җәмгыяте рәисе урынбасары Эльвира Вильдан, КФУның беренче курс студентлары – булачак журналистлар, автор үзе чыгыш ясады. Алмаз Хәмзин Марсель Галиев сүзләренә язган «Яле, Казан!» җырын башкарды. Китаплар тәкъдим итү чарасын Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова алып барды.

* * *

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә тагын ике китап басылып чыкты. Болар – язучы, галим Тәлгат Галиуллинның «Ана корт», Уфада яшәп иҗат итүче Дилә Мөхәррәм-Хәйретдинованың «Мәхәббәттән татлы җимеш» китаплары. Аларны «ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да тәкъдим иттеләр. Китапларның беренчесен тәкъдим итү тантанасында «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, галимнәр Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, Флёра Сәйфулина, Гөлфия Гайнуллина, шагыйрәләр Эльмира Шәрифуллина, Рәсимә Гарифуллина, КФУ студентлары чыгыш ясады. Бәйрәмне шагыйрә Фәүзия Солтан алып барды.

Икенче китапка багышланган бәйрәмдә «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, язучы Ринат Мөхәммәдиев, Уфадан әдәбият галиме Рәүф Идрисов, Бөтендөнья татар конгрессыннан шагыйрь Булат Ибраһимов, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркәтибе Ландыш Әбүдәрова, автор үзе чыгыш ясадылар. Чараны язучы Рафис Корбан алып барды.

## ӘДӘБИ КИЧӘ

Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылында шагыйрә, Сәҗидә Сөләйманова премиясе лауреаты Фәүзия Солтанның юбилеена багышланган иҗат кичәсе булды. Анда язучы, галим Тәлгат Галиуллин, шагыйрә Рәсимә Гарифуллина катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Язучы-тәрҗемәче Люция Гыйззәтуллинага – 70 яшь

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.ШАЙДУЛЛИНОЙ-МУРАТ «На вершине горы обитает волк», повесть С.ХАФИЗОВА «Скромный Бастам», рассказ Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Чужое брать – грех», рассказы М.КАГАРМАНОВОЙ; стихи Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ, Р.БАШАРА, З.АКБАРОВА, З.ЗАХАРОВОЙ.*
*«Новые имена»: стихи А.АХМАТГАЛИЕВА.*
*«Юбилеи»: автобиографическая повесть М.БАКИРОВА «Счастье с оттенком грусти».*
*«Литературная критика»: статья А.ХАБИБУЛЛИНОЙ.*
*«Наука»: статья Ф.ГАФФАРОВОЙ.*
*«Обзор книги»: статья А.СИБГАТУЛЛИНОЙ.*
*«Памятные письма»: письма М.ЮНУСА М.ГАЛЕЕВУ.*
*«2023 ел – год Учителя и наставника в России»: интервью А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с А.ШАМСУТДИНОВЫМ.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 120-летию Г.Кутуя и 120-летию Р.Ишмурата. Рубрику ведёт Н.Акмал.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*

*На наших обложках: Улица Большая Красная в сумерках. г.Казань. Фото И.АБРАМОВОЙ; доктор филологических наук, профессор Н.ЮСУПОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.SHAYDULLINA-MURAT«The wolf lives on the top of the mountain», story by S.HAFIZOV«Frugal Bastam», story by F.ZAMALETDINOVA«It's a sin to take someone’s belongings», story by M.KAGARMANOVA; poems by L.GIBADULLINA, R.BASHAR, Z.AKBAROV, Z.ZAKHAROVA.*
*«New names»: poems by A.AKHMATGALIEV.*
*«Jubilee»: autobiographical story by M.BAKIROV «Happiness tinged with sadness».*
*«Literary criticism»: article by A.KHABIBULLINA.*
*«Science»: article by F.GAFFAROVA.*
*«Review Book»: article by A.SIBGATULLINA.*
*«Memorial letters»: letters by M.YUNUS to M.GALEEV.*
*«2023 the year of Teacher and Pedagogue in Russia»: interview by A.KHABIBULLINA with A.SHAMSETDINOV.*
*«Priceless voices»: articles on the 120th anniversary of G.KUTUY and 120th anniversary of R.ISHMURAT. The column is led by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*

*On our covers: Bolshaya Krasnaya street, Kazan. Photo by I.ABRAMOVA; Doctor of philological sciences, professor Nurfiya Yusupova.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Зур Кызыл урамы. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* әдәбият галиме Нурфия ЙОСЫПОВА.